# КАЗАН УТЛАРЫ

1
ЯНВАРЬ
1979

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

1
ЯНВАРЬ
1979

## Бу санда

Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Интернационал. Шигырьләр . 3
М. ӘМИР. Үсә төшкәч. Автобиографик повесть . 9
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр . . . . . . . 63
М. ГАЛИЕВ. Ул чакта... Повесть . . . . . . . 69
Р. ЮНЫСОВ. Элемтәчеләр. Шигырьләр . . . . 116

ОЧЕРКЛАР

М. ГӘРӘЕВ. Академик . . . . . . . . . . . 120

Г. КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

М. ХӘСӘНОВ. Татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучы . . . . . . . . 131
Ш. ХАММАТОВ, Ф. МӨБӘРӘКШИН. Әдип һәм татар матбугаты . . . . . . . . . . . . 140
М. МӘһДИЕВ. Г. Камал «Йолдыз»да . . . . . 149
Н. ХАНЗАФАРОВ. Гаризалар ни сөйли! . . . . 155
Истәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . 160

Ф. КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

И. ЮЗЕЕВ. Озын гомерле шагыйрь . . . . . . 170
Г. МИНСКИЙ. Шагыйрьнең яшьлеге . . . . . . 172
Ф. КӘРИМ. Сөйләр сүзләр бик күп алар... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 178

КИТАП КҮЗӘТҮ

Х. МӘХМҮТОВ. Бурнаш белән яңадан очрашу. . 181
Г. МИҢНУЛ. Беренче карлыгач . . . . . . 183

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Юл дәвам итә . . . . . . . . . . . . . 187
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 26/IX-1978 ел. Басарга кул куелды 21/XII-1978 ел. ПФ 09025. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83349 экз. Заказ В-324. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

## Роберт Әхмәтҗанов

### Интернационал

Ак зынҗырын өзсә кышкы көннәр,
комач гөлләр чәчәк атсалар,
гөлләр, җилләр җырлый,
йолдызлар —
«Интернационал!»

Җылы хәбәр илтсә җилләр яздан,
язгы моңны көйли бакчалар.
Боз капканы ватып
килә язлар —
«Интернационал!»

Аягүрә басты бөтен гөлләр,
көйләренә колак сал:
төрле төсләр кушылып
бергә җырлый:
«Интернационал!»..

Яшәсен мәңге Шатлык илендә
аяз күкләрнең азат кояшы!
Кузгал, уян,
тапталып, көеп сугышлар җилендә
саргайган гөлләр дөньясы!..
Ин-тер-на-ци-о-нал!

### Йокла, инешем!

Йокла, минем елгам, агыйнешем,
ерак әле язга.
Ап-ак юрганыңа кызыл тәпи белән
кошлар шигырь язган!

Йокла әле, көмеш башыңны куй
тугай комнарына,
төштә күреп җәйне. Ерак әле
тургай моңнарына...

Йокла әле, газиз инешем минем —
көмеш канлы сабыем.

Йокла инде! Бу ак киңлекләрдән сиңа
җәйне каян табыйм?!

Йокла, инешем, тиздән туар бит ул
зур бәйрәм безнең дә:
гөлләр белән бергә минем йөзем
тирбәлер көзгеңдә...

Үги ана яфраклары сиңа
сузар сары утын...
Йокла инде — кыскарт минем сине
юксыну минутын!..

Йокла, инешем, язга чаклы гына...
Җилләр әкият сөйләр...
Минем дә бит җанда калгып тора
оеп җәйге көйләр!..

●

Ярларына тулып вакыт ага,
ага тулып
тыкрыклардан,
бөтен чатлардан,
вакыт ага бөтен ишекләрдән,
ярыклардан,
кесәдәге тишекләрдән.
Диңгез кире кайткан сыман,
чигенә ярдан,
мөлдерәп тулып ага урамнардан...

Ага вакыт, ага, йөрәкләргә кага,
ярларына каккан елга сыман...

Вакыт ага, ага һәр даим —
бармак арасыннан!..

## Җиз иләк

Ак яулыгын арттан бәйләп куйган —
чәен ясый татар апасы.
Күршеләре керә-чыга тора,
ябылып та тормый капкасы...

Дәрьяларга чыгып сөйләсәм дә,
сөйләсәм дә чыгып яланнарга,
бер сүзем дә, ди ул, ялган түгел,
килмәгәнмен җиргә ялганларга!

Якты, ачык йөзе — авыл кыры,
туры сүзне шунда отып алган.
Эчкерсезлек белән турылыкны,
әле ярый, авыл тотып калган...

Авылда ул яши — безнең дөнья!
Шунда гүя безнең рух сандыгы.
Шул почмакка кайтып сыенсам бер,
онытыла җирнең кысанлыгы!

Авылда ул яши безнең дөнья:
үлән арасында җир җиләге.
«Үт син шуннан» дигән мәгънә белән
кадагына элгән җиз иләге.

Үпкәләү юк сиңа, туган төбәк,
җиз иләктән мине иләсәң дә.
Бер сүзем дә менә ялган түгел —
дәрьяларга чыгып сөйләсәм дә!..

## Су бакчасы

Бу якларда шаулый су бакчасы.
Һәйкәл булып яңгырларга,
чишмәләргә, коеларга,
диңгезләргә, елгаларга, —
шаулый бакча —
фонтан булып үсә су агачы!
Су бакчасы — су бәйрәме,
шаулый су көйләре.

Сыек, йомшак су... Түтәлдә
суның җаны бөреләнә,
орлыклана су сабагы,
болытларга күтәрелә.
Кара туфракка шыбырдый
көмеш орлык — тамчылар!..

Су биредә
җан башына үлчәп бирелә —
түгел бу су азга!
Биредә кадере бар суның:
аны юкка агызмыйлар,
коймыйлар буш бугазга,
нотык сөйләп!

Биредә,
әсәрендә су күп диеп,
әрләмиләр язучыны.
Су — почетта!

Биредә
кояш белән сөйләшүче
тамчыларның тавышы тынмый.
Су бакчасы.
Бу якларда су үсә.
Чәчәк ата. Җырлый!..

## Балта бии...

... Алмагачлар бирешмәгән иде.
Сугыш елы кышын үткәреп,
тыныч көзгә килеп чыкты алар
иңнәренә алма күтәреп.

Үзәннәрне иңли алма исе,
алма исе аңкый — болында!
Баеп барган кояш төсе калган —
алма яна сабый кулында!..

Алмагачлар тынып йоклый иде,
сабыйлары йоклый баш төртеп
ана куенына...
Тын бакчага
Балта керде төнен, астыртын...

Балта керде! Кеше атлы адәм
шул балтаны селтәп чарпыды
алмагачның биленә! Ап-ак тәннән
туган җирнең сөте саркыды...
Туган җирнең зәңгәр сыман сөте
сиптерде дә акты үзәнгә.
Ә алмалар ыграк сыендылар,
корыч салкынынмы сизгәнгә?

Алма бакчасында Балта бии!
Балта бии — оча алмалар!
Балта шаша — китмәкче, ахры, җирдән
бар дөньясын зәһәр тамгалап...

## Кыр юлын сагыну

1

Канат җилпеп, тагын тургай
җыр игә кырларыма.
Яшь башаклардан тама чык
арыш тамырларына.

Чакыра тургай биеккә,
күкләрдән салып оран!
... Йөзеңдә буй-буй күләгә
арыш сабакларыннан...

2

Күк юлында оеп калган
ул болытлар мең садә!
Тургай кебек, күк катына,
җырым, сайрап менсәнә!

Сайрый-сайрый күтәрелче,
ак болытлар үтәли.
Тургайны да, моң булмаса,
канат кына күтәрми!

Сайрый-сайрый күтәрел дә,
тирбәлеп төш арышка.
Якты моң түк язгы җиргә,
кырны күммә сагышка!..

... Калгый тургай арышларга
җил кагылган тавышка.

## Төн һәм көн

Уйлыйм кайчак: бездән ни кала,
сөйләшсәк тә яфраклар белән,
таныса да безне һәр үлән.
Күңелем белән булсам да бала,
тормыш тәҗрибәсен бик беләм!

Юк, карамыйм һич тә шик белән
кояшка һәм җирнең һәр утына.
Хәтер дәфтәренә язылганнар
онытыла, онытыла!..

Уйлыйм кайчак: бездән ни кала?
Ташлар булып ташлар — уала,
җете төсләрне дә җил ала,
күзләр күргән бар гүзәллек югала...

Кояш кына карап кала дөньяга!

Биреләм дә шундый моңнарга,
карыйм күчмә болытларга, комнарга.
Китеп кабиләләр эзеннән,
аваз салам кыпчакларга, һуннарга!
Җавап эзлим сары ташлар йөзеннән...

Кайтавазлар булып кайта җил генә
Мәңгелек диңгезеннән!

Кичләрен мин керәм шундый уйларга...
Инде утым тоныклана: яңа көн уяна...

Таң каршына калкып чыга өстәлем,
ташлап китә төнге хисләрем.
Кайта җиргә үзенең чын төсләре!

Төн югала, ак мәйданда калгып ут яна.

Инде яңа өметләрем канатлана:
«Әйе, бар да кабатлана, кабатлана!»

Очып китә, зәңгәр коштай,
керфекләргә кунган йокы,
кабына җанда тыелгысыз кызыксыну уты!

Көн каршында җанлангандай була ташлар,
тәрәзәләрдә балкый кояшлар!

Эндәшкәндәй була хәтта чөйязмалар:
«Укыгыз, дип, монда ни язганнар!..»

Бөредәге хыяллар чынга аша.
Ак өметләр нурыннан күз камаша...

Башлана җирдә — өр-яңа тамаша!

●

Кителәә чикләрдән акрынлап,
күчелә иллардан,
кителә җырлардан...

Тавышың, яшьлек, тоныклана тәмам,
ераклаша һаман,
һаман!..

Үзгәрелә —
ваклап урлый көннәр,
ваклап урлый. Ваклап...
Ваклана җан, һич ваклану белмәс
бөтенлекне яклап...

Үзгәрелә —
җил китерми кебек
беренче кар исләрен,
язгы гөлләр,
май көннәре моңнарын...

Китә еллар чор түренә —
калдырып Иҗат Варисларын!

## Кырлай юлы

... Кырлай юлы буйлап
мин Апушны барам уйлап...

Авыл исемнәре очып кала:
Чиканас, Өчиле...
Ак болытлар алтынлана!
Шәфәкъ. Көз җиле.

Кырлай юлы —
язмышларны тоташтырган
гомер юлы, моңнар юлы...

Ай тузаны төсле сөрелгән кыр
тоташ соры.

**Мирсәй Әмир**

# ҮСӘ ТӨШКӘЧ

**АВТОБИОГРАФИК ПОВЕСТЬ**

**ИКЕНЧЕ КИСӘК**[1]

## Стәрлетамак

### I

**Әйбәт кешеләр. Көфер уй. Затлы әйбер. Колония. Мөслими. Самими атеизм. Тел чарлау.**

Һәм мин, Тукай әйтмешли, «алны-артны, уңны-сулны белмичә», укырга керештем. Мәктәпкә барам—беркемдә эшем юк, бар күңелем укуда. Торакка кайтам—беркемдә эшем юк, бөтен күңелем укуда.

Бәлки бүтәннәр дә миңа игътибар итмәгән булыр иде, бизгәгемне күреп алдылар. Хәпәзә әби айлар буе берни эшләтә алмаган әрсез чирне бер укол белән юк иттеләр дә куйдылар. Кире әйләнеп килмәсен дип, запаска тагы бер-икене кадап җибәрделәр. Мин килгәнче үк балаларны тансыга өйрәткән булганнар икән, малайлар малайлар белән, кызлар кызлар белән кочаклаша да биниләр. Үзем биемәү турында әйткән дә юк, башкалар биегәнне карап торырга да вакыт җәллим. Укыйм, сабагымны хәзерлим.

Дүртенче сыйныфка кертеп утырттылар бит. Бары да миннән бәләкәйрәк балалар. Җитмәсә, малайлар да, кызлар да бергә. Анысы гына да җитмәгән, шул кызлар арасында Фәүзия дә бар. Куаныргамы моңа, кайгырыргамы? Ул бит миннән биш яшькә кечкенә!.. Шулар белән бер сыйныфта утыруның ни куанычы булсын? Өстәвенә, сабагыңны дә белмәсең, страмы ни тора!.. Тырышам, көн димим, төн димим,

---

[1] Беренче кисәк «Без бәләкәй чакларда» исеме белән «Казан утлары»ның 1977 елгы 6—7 саннарда басылды.

Ниһаять, күрше караватта ятучы Фатих исемле малай түзмәде, тик торганнан әрләп ташлады үземне.

— Үләсең бит инде!—диде.—Кипкән таракан кебек калгансың бит инде! Нигә шул кадәр тырышасың? Уйнарга чык, тансыга өйрән. Чирләп егылсаң, кемгә кирәгең бар синең?..

Үзе дә карап торуга ябык, чирләшкә генә малай. Мине кайгырта. Яхшы күңелле кеше, димәк? Кипкән таракан дип мыскыл итүе ошамаса да, чын күңелдән теләктәшлек күрсәтеп әрләгәч, миңа рәхәт булып китте. Башлап шунда үземнең әйбәт кешеләр арасында икәнемне тойдым. Һәм әкренләп әйләнә-тирәмә күз сала башладым.

Мине таң калдырган хәл шул булды: укучы балалар көче белән мәктәп күләмендә кулъязма журнал чыга икән һәм югарырак сыйныф малайлары арасында (хәтта кызлардан да) үз күңелләреннән чыгарып, шигырь язучылар бар икән!..

Авылда чакта очраклы рәвештә кулыма килеп кергән журналлардан укып, шигырь турында миндә бик югары фикер туган иде. Шигырьне теләсә кем яза алмый, аны язу өчен тумыштан шагыйрь йөрәкле, илһамлы кеше булып туарга кирәк. Ул, пәйгамбәргә вәхи килгән шикелле, илһам булып, шагыйрьнең күңеленә килә. Шагыйрь күктән иңгән әзер шигырьне ашыга-ашыга кәгазьгә күчерә. Шулай түгел икән, илһамың булмаган килеш, тырышып, азапланып язасың икән, барыбер ул чын шигырь булмый. Соңгый, ягъни ясалма, фальшь акча кебек, ялган шигырь була. Андый шигырь язу гөнаһ. Намуссызлык, оятсызлык!

Шуңа күрә, кулга эләккән шигырьләрне бик яратып укысам да, үзем язып карау турында уема да килми иде. Ә монда минем кебек малайлар шигырь чыгарып ята. Ничек аларга илһам килә икән? Чын шигырьне ялганыннан ничек аерыргадыр, анысы турында уйламыйм. Шулай дип язалар икән, димәк, аера белүчеләр бар.

Ә менә көйсез нәрсәләр? Хикәя, мәкалә кебекләре? Нәсер дигәне?.. Чамалап карарга ярый. Бераз укый төшкәч инде.

Малайлар арасында төрле бәхәсләр чыгып китә. Яңа тормыш турында кызык-кызык фикерләр әйтәләр. Гыйшык-мәхәббәт мәсьәләләренә дә кагылалар. Колак салып кына йөрим. Күңелдән генә катнашып киткән чакларым да була. Кичләрен уйлап ятам...

Болай да кеше арасына керергә кыюлыгым җитмичә, оялыбрак кына йөргән чагымда, кемдер миңа кычкыра:

— Авылдашың килгән, сине сорый, чык!..

Чыксам... Гайфулла. Әсмага абый тиеш егет. Үзе генә булса бер хәл иде, авылдаш итеп, күрәсең, янына Фәүзия белән апасы да чыгып өлгергәннәр. Мине күргәч, авызларын читкә борып, көлә-көлә китеп бардылар. Тәки сизгәннәрме икәнни?

— Нигә кызарасың?—диде Гайфулла.—Син бит хәзер кала егете! Нихәл?

Сүрән генә исәнләштем.

— Нигә хат язмыйсың?

— Вакыт юк.

— Сөйгән ярыңа язарга вакыт табалар инде аны.

— Кит әле.

— Ярар, сөенчегә ни бирәсең?

Сизеп торам, мөгаен, Әсмадан хат-мазар алып килгән.

— Нинди сөенче инде?

— Нигә булмасын? Әллә оныткан дип беләсеңме?..

Тәки шулай булып чыкты. Хаты янына хушбуйга манчылган кулъяулык куйган. Аларны ялтырап торган тәти кәгазьгә төргән. Ык-мык итеп кенә алып калдым. Җавап язу-нитү кайда, бөтен кайгым: ничек итеп кешегә сиздерми генә үткәреп җибәрергә?..

Ничек үткәреп җибәргәнмендер, үләр чиккә җитеп, оялып йөрүем генә хәтеремдә калган.

Хәер, андый гына кайгыларны оныттырырлык хәлләр бар иде ул көннәрдә. Алла турында сүз көрәштерүләр еш була иде. Андый бәхәсләрне мин, әлбәттә, тыңлап та тормыйм, качам гына. Алла турында шикле сүз әйтү түгел, ул хакта уема китерүне дә көферлек саныйм. Ләкин кем дә булса кычкырып әйткән сүзне ишетмәү яки килергә теләгән яман уйны күңелгә кертмичә куып җибәрү бик кыен икән ул. Кич яткач, йокыңны куып, күңелгә килеп керә көфер уй. Ничек котылырга белмим. Баштанаяк юрган белән томаланам, күзләремне чатырдатып йомам. Күңелемнән ашыгып-ашыгып белгән догаларымны укырга керешәм. Төрле догаларны, әфтияк, коръән сүрәләрен шактый күп ятлаган идем. Шулар ярдәме белән көфер уйларны онытып, йоклап китәм. Иртән тору белән тагы дөньямны онытып дәресләремә ябышам...

Тырышуларым бушка китмәде, язгы сынауларда иң шәп укучылардан булып чыктым. Дөресен генә әйткәндә, мин мондагы дәресләрнең күбесен авылда чакта үткән булганмын икән, аларны үзләштерү мина авыр булмады. Мине дүртенчедән туры алтынчыга күчерделәр. Бу хәл минем күңелемне дә, малайлар каршында дәрәҗәмне дә күтәреп җибәрде. Кыюлана төштем.

Шулай да мондагы кешеләр белән үзләшеп җитүем түгел иде әле бу. Укулар бетеп, ял вакыты килгәч, күңелсезләнә башладым. Иялэшеп житкән якын дусларым юк. Авылны да сагынам. Ләкин кайтырга уйламыйм да. Киткәнемә күп булса да өч айдыр, кем анда көтеп тора дисең?.. Эчем пошкан чакларда Бәдретдин җизниләргә барып чыгам. Яхшы каршы алалар, ашатып-эчертеп кенә түгел, сыйлап җибәрәләр. Ләкин еш барырга оят, ашар өчен генә бару булып чыга.

Шәһәр белән танышып, аның төрле урамнарын, бакчаларын, Стәрле, Ашказар буйларын карап йөрим. Базар белән кызыксынып киттем. Авылда чакта ук инде калада көн дә базар дип ишеткәнем бар иде, дөрес икән. Нинди-нинди генә тәмле ашамлыклар юк анда, нинди-нинди генә кешеләр очрамый? Нәрсәләр генә сатмыйлар? Кесәндә сукыр бер тиенең булмаса, күз төшкән әйберләр бигрәк күп күренә икән ул. Кайдан әзрәк акча табарга соң?

Әхтәм абзый миңа үзе кими торган бер жилетын биреп җибәргән иде. Иске булса да, өр-яңа иде әле. Бигрәк тә аркасы — ялтырап торган кара атлас. Минем дә аны киеп әрәм итәсем килмәде. Бик затлы әйбергә исәпләп, кара көнгә дип, сандыгыма салып куйган идем. Талчукта төрле кием-салым тотып, сатып йөрүчеләрне күргәч, шул исемә төште. Тоттым да чыктым. Йөрим базарны әйләнеп, бер як читенә зур бәйләм кипкән балык эленгән алачык-лавка яныннан үткән саен кызыгам: эх, тизрәк сатасы иде дә бу жилетны, алып ашыйсы иде бер вобласын!..

Әмма ник бәрәү янына килеп карасын. Ичмасам, хакын сораучы да юк. Ташлап калдыру чигенә җиткән идем инде. Җиргә чыпта җәеп утырган бер бабай, бармагы белән генә ымлап, үз янына чакырды. Бардым. Чыптасы өстенә иске-москы бияләй, галош, зонтик, олтырак кебек товарлар таратып куйган. Эндәшми генә жилетымны тартып алды, эчен-тышын әйләндереп карады да кире сузды.

— Мә, үзеңә булсын.

— Алып кал инде, бабай. Бер килеп иясе чыгар әле.

— Күпме бирим соң?

— Үзең чамала инде шунда...

Әллә озак йөреп ачыгудан, әллә кесәгә акча керүдән башымдагы уйларым, ниятләрем үзгәреп китте. Кипкән балык онытылды. Берәүнең ап-ак калачны көнбагыш маена манып ашавын күреп, авызымнан сулар килгән иде. Ярты кадак күмәч алдым да шул якка ашыктым. Тик нәрсәгә салып алырга?..

Сатучысы әйбәт кеше икән, үзе үк калай кружкасын да биреп торды. Эх, мае! Хуш исе өчен генә дә акча түләрлек. Күпереп торган калач болыт-мунчала кебек эчә сыек майны. Өч-дүрт манарга җитте микән?.. Шулай да бу тәмле, туклыклы сыйдан тәмам канәгать булып, кружканы хуҗасына сузам.

— Мә, абзый кеше, рәхмәт.

Ә сатучы мине бөтенләй оныткан. Күзләрен тондырып, кемгәдер кычкыра: «Сюда, сюда!» Чакырган кешесе килмәгәч, үзе аңа таба атылды. Карыйм: олы гына кеше. Кулында өч-дүрт гәзит. Таушалып беткән иске-москы дәфтәрләр. Май сатучыдан башка тагын өч-дүрт кеше ябышкан үзенә. «Миңа да миңа!» дип, гәзитләрен дә, дәфтәрләрен дә йолкалар гына. Чак акча алып өлгерә. Кәгазь сата икән. Тәмәкегә.

Ташландык кәгазь? Ә мин, җүләр!.. Әллә нәрсә урынына күреп, көне буена жилет күтәреп йөргәнмен. Акчасы бер сынык күмәч белән икеөч кашык көнбагыш маеннан артмады. Хәер, әле дә соң түгел...

Безгә, караламага дип, карандаш белән генә язарга ярый торган кәгазь бирәләр иде. Теләгәнчә пычрат. Кирәклесе акка күчереп алынганнан соң, бернигә яраган җире калмый. Шулай да ташларга жәлли идем. Шактый җыелган булып чыкты. И ярап та куйды менә.

Базарга кереп җитәргә дә ирек бирмәделәр. Теге алачык-лавка янына килеп җиткәндә култык астына кыстырып килгән караламаларым акчага әйләнеп беткән иде инде. Менә сиңа чүп-чар! Кара көнгә дип саклаган жилетымнан үтемлерәк тә, кыйбатрак та булып чыкты.

Юкка гына кызыгып йөрмәгәнмен икән, кипкән вобла шундый тәмле, чәйнәп туя торган түгел. Башка малайларның да әчеләве җиткән, күрәсең: ач кандала кебек ябыштылар. «Кайдан алдың да, кайдан алдың?»

Минут эчендә бер кочак каралама җыелгандыр, бөтен торак балалары тәмам туендык кипкән балыкка. Малайлар гына түгел, кызлар да.

Ул чорда макулатура җыю кампанияләре юк иде, күрәсең, укучылар кулында каралама запасы күп иде әле. Ләкин кызганычка каршы (дөресрәге: бәхетебезгә каршыдыр), безнең арада бу кәсепкә артык җәелеп китәргә мөмкинлек булмады, колониягә күчтек.

Стәрлетамактан унике чакрым төньякта, Куганак елгасы буенда, мәктәп-интернатның утары, хәзергечә әйтсәк, ярдәмче хуҗалыгы бар иде. Балякин дигән алпавыттан калган шактый бай йорт-җиргә урнашкан бу хуҗалыкны ул вакытта без колония дип йөри идек. Анда безнең яшелчә бакчасы гына түгел, зур гына иген кыры да, әрәмәлек араларында матур-матур болыннар да бар иде.

Торган өебез әйбәт, алпавыт үзе яшәгән эче-тышы ап-ак ике этажлы зур өй. Ишектән чыгуга зур-зур юкә, каен, усак агачлары белән тулы йорт. Бакча дисәң дә ярарлык. Өй артында гына диярлек — Куганак. Чит-читләре әрәмәлек белән капланган бу инеш буйлап түбән китсәң, табигый урманга чыгасың. Урман арасында җиләкле аланнар...

Рәхәт яшәдек без анда. Яшелчә бакчасында да эшләдек, кыр эшләре дә башлыча үз өстебездә иде. Ләкин эш дигәнебез уен кебек рәхәт булды.

Уку башланганга кадәр коллектив эчендә тәмам үзләшеп, интернат балаларының эресе-вагы белән танышып, туганлашып беттем.

Алтынчы сыйныфта укый башлаганда үз яшьтәшләрем арасында идем инде. Күрәсең, шәрикләремнең дә күбесе минем кебек соңгарак калган укучылар булгандыр, арада миннән олыраклар да юк түгел иде. Хәзер инде мин мәктәбебезнең мөдире Габделхәмит Мөслими дигән кеше икәнлеген, аның революциягә кадәр үк танылган, «Шура» журна-

лында мәкаләләре басылган педагог булганлыгын, хәтта исеме Шәехзадә Бабичның «Китабеннас!»ына кертелгәнлеген дә белә идем.

**Габделхәмидел Мөслим, кафенең «Шура» берлән ура.**
**Шул вакыт оҗмах түренә мендерер сине хода!**

Көлеп язылган, әлбәттә. Ләкин атаклы шагыйрь аның исемен иң мәшһүр замандашлары белән бер җөмләгә керткән бит!

Мөдирлек белән бергә, Мөслими укытучылык эшен дә алып бара, безгә ана телennән, әдәбияттан керә иде. Ярата идек. Үзенә ишеттерми генә шаяртырга, көләргә дә җаен таба идек. Сөйләгән вакытта ул «р» авазын дөрес әйтә алмый, «утырыгыз» дигәне «утыгыгыз» булып чыга, «торыгыз» дигәне «тогыгыз» булып ишетелә. Дәрес биргән чагында кайвакыт, онытылып китеп, борынын казу гадәте дә бар иде, анысын да игътибарсыз үткәрмибез. Артистланырга яратучы шук малайлар аның дәресе алдыннан өстәл янында ул булып кыланып көлдерәләр иде.

Ләкин үз алдында, әле утыз тирәсендәге өйләнмәгән егет икәнен бик яхшы белсәк тә, без аны тиешенчә олылыйбыз һәм ул безгә бик могтәбәр кеше булып күренә дә иде.

Иң әһәмиятлесе, Хәмит обзый безне туган телебезне, әдәбиятны яратырга өйрәтте.

Егерме өченче елның көзе гомумән минем өчен рухи яңарыш чоры булды. Иң әһәмиятлесе — аллага каршы әйтелгән сүзләрдән курыкмый башладым. Хәтта андый сүзләр миңа хәзер кызык, яңа булып тоела, аларны ишеткән саен ишетәсе килә иде. Ниһаять, шундый бер көн килде — «алла юк!» дип, үзем әйтә башладым.

Әле кайчан гына минем өчен коточкыч булган, дәһшәт булган ул сүзне әйтергә курыкмыйм гына түгел, аны әйтә алуым белән горурлана идем. Әйтерсең экияттәге дию пәриен җиңеп чыккан батырмын. Бу җиңүдән үз алдыма үзем кинәнеп йөрү белән генә канәгатьләнмим, батырлыгымны башкаларга да күрсәтеп мактанасым килә. Сүз җае чыккан бер урында кирәксә-кирәкмәсә дә үземнең алласызлыгымны күрсәтергә, ходай исеменә карата хөрмәтсез сүз әйтеп калырга тырышам. Аллага ышану гади халык арасында гына түгел, хәтта күп кенә укытучылар һәм башка зыялылар арасында да киң урын алган чор шартларында бу, чынлап та, үзенә күрә батырлык сорый торган хәл булган. Без хәзер, яшьләр арасында булып үткән ул хәлләрне: аллаларны сүгү, дин әһелләрен мыскыл итү кебек күренешләрне хулиганлык дип, ягъни дингә каршы хулиганнарча көрәшү дип хөкем чыгардык. Уйлап-уйлап карыйм да, юккарак рәнҗетмәдекме икән замандашларыбызның яшьлеген? Такташ булып Такташ «иман шарты»н тәмәкегә ертып тартуы белән горурланган икән, «Сагынып сөйләр өчен ядкарь итеп, муллагызны кыйнап китәрмен!» — дип шигырь язган икән, безгә, ул вакытта әле яңа гына дин богауларыннан ычкынган малайларга, ни сан? Хулиганлык түгел, самими атеизм күренеше дияр идем мин моны. Тупасрак алымнар белән булса да, муллаларның, ишаннарның изге түгеллеген фаш итү, сукырларча дингә ышанып, алданып яшәүчеләрне көлкегә чыгару меңәрләгән яшь буынны рухи коллыктан коткаруга хезмәт итмәдемени?

Тора-бара барыбер аңладык: дин ул, теге вакытта без уйлаганча, ярлыларны изү өчен байлар тарафыннан юри уйлап чыгарылган гади карачкы гына түгел, аның катлаулы тарихы бар икән. Дәверенә карап, кешелек җәмгыятенең үсешен күрсәткән чаклары да булган. Хәзерге көндә дә аңардан аерылып бетә алмаучылар бар икән, кемнәр өчендер ул җан азыгы булуын дәвам итә икән, димәк, аның әле һаман да тиешенчә ачылып бетмәгән серләре бар. Шунысы безнең өчен ачык: ул һәрвакыт фәннең килешмәс дошманы, һәр сыйнфый җәмгыятьтәге социаль гаделсезлек күренешләрен яклап һәм саклап килүче кара көч.

Мин инде үземне малайлар арасында тигез хокуклы гына түгел, алла турында сүз чыкканда һаман да авыз ачарга куркып утыручы кайберәүләрдән өстен хис итә идем. Фикер алышуларда, дискуссияләрдә катнаштым. Ниләр турында гына бәхәсләшми идек без ул елларда! Нинди дә булса әһәмияте булган берәр мәсьәләне хәл кылып, конкрет бер фикергә килү өчен генә дә түгел, гади бер сүз көрәштерергә өйрәнү, тел чарлау өчен бәхәсләшкән чакларыбыз күп була иде. Шулай да артык мәгьнәсез мәсьәләләр тирәсендә буталырга яратмыйбыз, сәяси яктан принципсыз яки хата карашларга нигезләнгән каршылык уйлап табарга азапланучыларга юл куелмый иде. Мәсәлән, берәү «эт симерсә иясен талый» дигән мәкаль турында бәхәс ачарга тәкъдим итте. Ягъни, эт симерсә иясен талыймы, әллә иясе симерсә этен талыймы? Моның белән ни әйтергә телисең дип сорагач, болай аңлатып бирде: байлар бу мәкальне хуҗаларына каршы баш күтәргән эшчеләр турында әйтә, ә тормышта, янәсе, киресенчә, хуҗа симергән саен эшчене ныграк талый.

Хезмәт ияләрен эт урынына куеп карау сәяси хата, дип, бу теманы тәкъдим итүче каты тәнкыйтькә эләкте. Күбесенчә алла һәм муллалар турында сүз көрәштерәбез. Ләкин күп вакытта аллага чынлап ышанучылар мондый бәхәскә катнашырга курка, нәтиҗәдә дәһриләрнең үзләренә икегә бүленеп бәхәсләшергә туры килә иде. Ягъни берәү, аллага ышанмаса да, үзен динле кеше урынына куеп, динсезләр белән сүз көрәштерә.

Җанлы бәхәс кузгаткан мәсьәлә булып, тагын шул ачык хәтердә калган: яшәү өчен авыл яхшымы, шәһәрме? Монда инде шәһәр белән авылның үзең белгән күләмдә яхшы якларын да, начар якларын да санап чыгасың. Үзең белмәгәннәрен башкалардан ишетәсең. Бу турыда укыган шигырь яки хикәяләрне искә төшерәсең. Кайвакыт ул әдәбият турында бәхәсләшүгә әверелеп китә. Сәгыйт Рәмиевнең «Авыл» шигыре бик еш телгә алына иде.

Әй, авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш!..

Авылны мактап сөйләүче бу юлларны шундый тәмләп, горурланып әйтә, аңа инде шушыннан да көчле дәлил юк кебек. Ә шәһәрне мактап сүз көрәштерүче, шул ук шигырьне дәвам иттереп, аңа каршы төшә:

...Бер кеше юк бер урамда,
Нинди тын һәм нинди буш!..

— Нәрсәсенә кызыгырга моның? Кеше булмаган җирдә нинди ямь булсын?!

Мин үзем авыл малае булсам да (бәлки «булсам да» түгел, «булганга» дияргә кирәктер), шәһәрне мактаучылар ягында идем.

## 2

**Беренче язмаларым. Кәрзингә рәхмәт. «Җылан». Партшкола егетләре. Шпаргалка. Күмәк җыр. Хәмит дус. Күбәләк.**

Укучылар көче белән чыгарыла торган кульъязма журнал мине кызыксындыра гына түгел, мавыктыра башлады. Аның чыкканын түземсезлек белән көтеп алабыз. Анда басылган шигырь яки хикәяләр генә түгел, теләсә нинди темага язылган мәкаләләр дә, ташка басылып чыга торган чын журналлардагы кебек үк шәп тоела, аларны язган яшь каләм ияләренә сокланып туя алмый идем. Тәнкыйть күзе белән карау дигән нәрсәне белми идем әле. Кульъязма гына булса да, журнал

чаклы журналга урнаштырырлык булгач, минем өчен алар тәнкыйтьтән югары тора иде.

Шул журнал йогынтысы астында үземнең дә берәр әдәби әсәр язып карыйсым килә башлады. Тик нәрсә язарга?..

Еллар үтеп, Казанга килгәч, газета-журналларда хикәяләр бастырып, инде үзем дә редакциядә эшли башлагач, миңа күп кенә яшь авторларга хатлар язарга туры килде. Беренче шигырен я хикәясен җибәргән башлап язучыга яки ничек язучы булырга дип сораучыларга мондый җавап бирә идем:

— Ни дә булса язу өчен, сине кулыңа каләм алырга мәҗбүр иткән бер фикерең, укучыга әйтәсе килгән әһәмиятле сүзең булырга тиеш!

Ялгыш җавап биргәнмен дип әйтә алмыйм. Ләкин үземнең, әдәби әсәр язарга теләп, беренче мәртәбә кулыма каләм алганда башымда нинди дә булса ачыкланган бер фикерем бар идеме соң? Укучыга әйтәсе килгән әһәмиятле сүзем дә бар идеме?..

Яшерми генә әйткәндә — юк иде. Бик ачык хәтеремдә: язасым килә. Ни дә булса язып карыйсым килә. Ләкин нәрсә язарга? Ни турында? Һичбер фикер башыма килми. Нәрсә языйм дип, кешедән дә сорап булмый. Нәрсә язарга соң? Нәрсә генә язарга?..

Шул вакыт әниемнең кайчандыр миңа: «Син боларны яз, улым!» дигән сүзе хәтеремә килде. Әйе, эти сугыштан кайткан язны Җиргәнтау итәгендә тары чәчеп яткан көннәрдә Агыйдел буеның гүзәл табигатенә соклануым турында рухланып сөйләгәнемне ишеткәч, әнием, аркамнан сөеп, шулай дигән иде:

— Син боларны яз, улым!..

Ул вакытта аның бу киңәшенә нинди мәгънә бирергә белмәгән идем. Алты ел үткәч, кулдан күчерелеп чыгарылган гына булса да, әдәби журналга нәрсә дә булса язасым килә башлагач, аңладым. Зиһенем ачылып киткәндәй булды. Үзәк өзгеч матур картина булып, күз алдыма Агыйдел буе табигатенең гүзәл күренешләре килде. Күңелемдә җанланган шул күренешләрне шигырь итеп язарга тотындым. Үзем күреп сокланган куакларның, чәчәкләрнең гүзәллеген мактадым. Агыйдел суының ашыгып агуын тасвирладым, колакларымны иркәләп, җанымны рәхәтләндергән кош сайраулары, аллы-гөлле чәчәкләрдән бөркелгән хуш исләр...

Барын да тезеп чыктым. Ләкин сизәм, нәрсәдер җитми. Шигырь тәмамланмаган төсле. Мәгънәсен тапмыйм. Уйлана торгач, тарих дәресендә ишеткәннәремне өстәп җибәрдем: табигать күренешләренә карап, башкорт дусларым турында уйланам, дидем. Аларның бабаларының борынгы заманда җәйләүләрдә куй итеп ашап, кымыз эчеп, курай тартып йөрүләре исемә төшүе турында әйттем. Дуслык турында, үземчә, ирек турында ни дә булса әйтергә теләвем булды, күрәсең.

Ләкин язганымны укып карагач, күңелем канәгать булмады. Анда төрле куак исемнәре, чәчкә исемнәре бар, «матур», «гүзәл» кебек мактау сүзләре күп, «ак чәчәккә баткан шомырт куагы... булдым шул куакның күнагы» кебек кафияләр бар, мәгәр хыялымдагы матур күренешләр юк, алар кәгазьгә төшмәгән иде. Нишләргә белми икеләнеп, күңелсезләнеп утырган чагымда яныма малайлардан кемдер килеп чыкты, язганымны тартып алып диярлек укып карады да мактарга тотынды. Мин «менә дигән шагыйрь», имеш!..

Беренче әдәби язмам шундый, үземчә, шигъри калыпка салып, кафияләп язылган истәлек сыйфатында кулъязма журналда «басылып» чыкты. Дәртләнеп киттем. Бер хикәя дә язып ташладым. Анысы «Бер кисәк гранит ташының тәрҗемәи хәле» дип атала иде. Монысын язар өчен озак баш ватырга туры килмәде.

Табигать белеменнән безгә Лотфулла Галими дигән укытучы дәрес бирә иде. Стәрлетамак шәһәрендәге күренекле укымышлыларның бер-

се иде ул. Соңыннан белүемчә, «Каләм» ширкәтендә аның үзе язган китаплары да булган икән. Ул сөйләгәннәрне бик яратып тыңлый идек. Җир өстендәге тормышның ничек барлыкка килүе турында сөйләгән чакта әйткән бер фигуралы сүзе колагыма кереп калды.

— ... Әгәр дә ул гранит кисәге телгә килеп, — диде ул, — бу рәвешкә кергәнче үзенең нинди юллар үткәнен, башыннан ниләр кичергәнен сөйләсә...

Житә калды бу миңа. Шул ук көнне кич язарга да утырдым. Тау итәгендә үсеп утырган бер яшь кенә агач үз янында яткан ташка рәнҗетә торган сүзләр әйтә. Үзенең җилфердәп үсүе, дөньяны ерактан күрүе белән мактанып, ташны кимсетә. Берни белмисең, надан син, берни күрмәгәнсең, ди. Шуннан таш аңа сабыр гына тавыш белән үз башыннан кичкәннәрне сөйләп бирә. Таш теле аркылы, җирнең тарихы турында дәреслектән укып, Галими абзыйдан ишетеп белгәннәремне сөйләп чыгам. Яшь агач бу күпне күргән таш янында үзенең ни кадәр сабый икәнлеген аңлый, белер-белмәс көенә башкаларны кимсетергә ярамаганлыгына төшенә.

Бусы да журналда урнаштырылды. Мәкаләләр язам, аларына да урын табалар. Тик хәзер мине ул журнал гына канәгатьләндерә алмый иде инде. Ул бик сирәк чыга, ә минем көтеп торырга тәкатем җитми. Өзлексез язам. Язганнарымны кайда да булса чыгару турында да уйламыйм. Миңа язарга гына булсын. Язам. Ни исемә төшсә — шуны. Нәрсәләр язганмындыр, язгач, аларны кая куйганмындыр, бары да диярлек онытылган. Хәтеремдә калганы — «Тугыз Тукылдык, бер Мимылдык» дигән әкиятне шигырь калыбына салып, язып чыктым. Әкиятләрне күп белә идем. Аларны кем авызыннан ничек ишеткән булсам, нәкъ шулай итеп, төкми-чәчми кешегә дә сөйләп бирә ала идем. Һәм алар миңа бервакытта да онытылмас кебек иде. Онытыла икән. Хәзер ник шуларны вакытында язып куймаганмын дип үкенәм. Басылып чыккан әкият җыелмаларын бик күп укыдым. Берсендә дә бала чагымда ишеткән әкиятләрнең күбесен очратканым юк. Кулыма кергән никадәр халык байлыгын югалтканмын!

Тагы бер нәрсә хәтеремдә калган: «Коллар» дигән өч пәрдәлек пьеса яздым. Болай булды. Уфада чыга торган татарча газеталарның берсендә пьесаларга конкурс турында игълан чыкты. Аеруча революцион көрәш турындагы пьесалар кирәк дип әйтелгән иде. Күп уйлап тормадым. Күптән инде, әле эти сугышта чакта ук, әни Стәрлетамактан алып кайткан китаплар арасыннан «Бичара колның тормышы» дигән китапны бик яратып, мавыгып укыган идем. Бу китап «Хижина дяди Тома[1]» дигән мәшһүр романның татарча тәрҗемәсе икәнлеген белми идем әле. Минем өчен аны кем язган булуы да әһәмиятсез кебек иде. Яхшы күңелле, эшкә унган коллар, явыз-явыз хуҗалар, алар арасында барган авыр, фаҗигале вакыйгалар, колларның һәм бай хуҗаларның тормыш-көнкүрешләре, киемнәре, эшләпәләрен ничек киюләре, холык-табигатьләре белән бер-берсеннән аерылып торган, минем өчен күптән таныш булган кешеләр шулкадәр ачык хәтеремдә, әйтерсең мин аларны нинидер китаптан укымаганмын, ә барын да үзем күргәнмен. Шулар янына тагын тарих укытучысыннан һәм ул елларда еш була торган төрле лекцияләрдән ишетеп, нинидер дәреслекләрдән укып, крепостной крестьяннар, алпавытлар турында белгәннәрем килеп кушылды. Коллар белән крепостнойларны, колбиләүчеләр белән алпавытларны бергә бутап, аларга каршы көрәшүче большевик образларын да кертеп, ике кичтә өч пәрдәлек пьеса яздым да куйдым. Язып бетергәч, үзем укып та тормыйча, аны почта белән Уфага — конкурска җибәрдем.

[1] Бичер Стоу романы.

Бүләк-фәлән турында уйлаган юк инде, һич югында, пьесаны укып, житешмәгән яклары турында язып җибәрсәләр, миңа шунысы бик житкән иде. Анысы да насыйп булмады. Кулъязмам хәбәрсез югалды. Моңысына кайгырмаган идем. Еллар үтеп, әдәбиятның нәрсә икәнен тирәнрәк аңлый башлагач, шул пьесам исемә төшкән саен, үз алдыма үзем оялып йөрдем. Бөтенләй юкка чыккан булса, бик шәп. Әгәр табылса? Архивта-мазарда сакланып, берәрсе шуны китереп чыгарса, нишләрсең! Оятыңнан җир тишегенә керерсең!..

Ул еллардагы редакцияләрдә басарга яраксыз кулъязмаларны кәрҗингә ташлыйлар иде. Бәхеткә каршы, минем кулъязмам да шундый язмышка очрады булса кирәк...

Беренче язмаларым урнаштырылган мәктәп журналының исеме онытылган. Ә менә шул ук кышта чыккан икенче бер журналныкы хәтердә. Анысының тышына: «Ике атнага бер чага торган «Җылан» журналы», — дип язылган иде. Кемнәр чыгарганын сизенсәм дә, аны ничек әзерләгәннәрен, кайда эшләгәннәрен бөтенләй белмәдем. Минем өчен гаять кызыклы, искиткеч шәп яңалык булды бу. Аерым номерларын гына булса да, «Кармак», «Чүкеч», «Ялт-йолт» кебек көлке журналларны күреп сокланганым бар иде. Минем күзлектән караганда «Җылан» да, нәкъ шулар шикелле, менә дигән көлке журнал. Тик ташка басылган гына түгел.

Күбесенчә үзебезнең кызлар турында, шулай ук күп кенә малайларны да, хәтта кайбер укытучыларны да исемнәре белән телгә алып, көлке шигырьләр, кызыклы хәбәрләр язылган. Ә ул андагы карикатуралар! Стәрлетамакта бездән башка тагы бер үрнәк мәктәбе бар иде. «Икенче үрнәк» дип йөри идек. «Икенче үрнәк» малайлары белән «Беренче үрнәк» кызлары арасында танышу-дуслашу хәлләре булган, күрәсең. Шулардан көлеп төшерелгән рәсемнәр... Безнең үрнәк кызларын үрдәк кызлары, тегеләрнең малайларын үрдәк егетләре итеп ясаганнар. Язучылары кемнәр? Рәсем ясаучылары? — барысының да астында ялган имза.

Кулдан-кулга йөртеп, тетелеп беткәнче укыдык. Бераздан икенче номеры күренде. Анысын юньләп укырга өлгермәдек, юкка чыкты. Берәрсе урлагандыр дип уйлаган идем, алай булмады. Озак та үтми, безне җыелышка чакырдылар.

Мөдир һәм укытучылардан тыш, җыелышка комсомолның кантон комитеты секретаре Һади Кәримов та килгән иде. Ул елларда Стәрлетамак яшьләре арасында иң мәшһүр оратор, өстәвенә, исеме әледән-әле «Яшь юксыл» битләрендә чыга килгән бу кешене беренче күрүем иде. Җыелышны ачкач та аңа сүз бирделәр. «Килмәгән җире юк» дип, шундый кеше турында әйтә торганнардыр инде. Буе-сыны, өстендәге киемнәре — бары да менә дигән. Сөйләгән чагында күзләрендә очкын уйный. Карасу-ал йөзеннән акыл, белем нуры балкып тора кебек. Ачык, саф тавышы да, сүзләре дә минем өчен бик күңелле, ятышлы булып ишетелде. Башта ул безнең илдә хәзер бөтен балаларга уку-белем алу өчен киң юллар ачылуы турында әйтте. Аннары турыдан-туры безнең мәктәпкә күчеп, укучылар арасында һәр фәнгә кабилиятле, әдәби әсәрләр язарга да талантлы кешеләр күп икәнлеген күрсәтте. Язарга кирәк, үсәргә кирәк, диде. Янә тормыш төзегәндә бер-береңнең кимчелекләрен күреп, аларны иптәшләрчә тәнкыйть белән төзәтергә кирәклеген дә әйтте...

— Ә менә мондый тәнкыйть кирәкме? — диде ул капыл гына һәм ялт итеп, кайдандыр «Җылан» журналын китереп чыгарды. Үзе үк җавабын да биреп куйды.— Юк, кирәкми!

Исем китеп тыңлап утырам. Карале, күңелемнән генә, мин бит аны нинди шәп журнал дип, рәхәтләнеп укыдым. Ә ул! Нәрсәсе ярамый икән?..

Кәримов иң башлап аның яшерен төстә чыгарылуын яратмады. Хәтта ул аны подпольный журнал дип атады. Патша заманында, эшче-крестьян халкына теләкләрен әйтергә ирек бирелмәгән шартларда, революционерлар тарафыннан яшерен газета яки журнал чыгару табигый булган, кирәк булган. Ә безнең заманда?.. Кемнең дә булса ярамаган ягын күрәсең икән, теләсә нинди җыелышта чыгып әйт! Теләсәң нинди газетага язып бир! Якын иптәшеңме ул, мөгаллим абзыеңмы, зур урындагы җаваплы кешеме, совет законнарына сыймаган эшен күрәсең икән, тартынып торма. Хәтта бертуган апаң, я абыең булса да, хәтта әти-әниең булса да!.. Ә сез?..

Ул тагын журналны һавада селкеп алды.

— Бер-берегезне җылан булып чагасызмы? Иптәшләрчә тәнкыйть түгел, гайбәт капчыгы бит бу! — Ул үрдәк рәсемнәре төшерелгән битне ачты. — Иптәшләрегезне шушылай мыскыл итәсезме? Хурлык! Мәктәбегез өчен генә түгел, бөтен Стәрлетамак өчен хурлык!..

Аннары канткомол секретаре безнең мәктәп укучыларын шәһәр күләмендәге яшьләр тормышыннан аерылып яшәүдә гаепләде. Комсомол клубы күршебездә генә булса да, анда көн саен диярлек үткәрелә торган җыелышларда күренмәвебезне исебезгә төшерде...

Яратып, сокланып тыңладым. Бу кешегә мәхәббәтем үсеп калды. Шулай да журнал турында?.. Яшерен төстә чыгарырга ярамаганлыгын аңладым. Ике атна саен бер «чага» торган җылан дип аталуы да дөрес түгелдер. Ләкин аның исемен үзгәртергә дә була бит инде! Алайга китсә, әнә «Чаян» да чага ич! Шуларга карап кына ул кадәр яманлау нигә кирәк булды икән? Юк, журналга булган мәхәббәтем сүнмәде. Ул инде, әлбәттә, яңадан чыкмады. Ләкин күңелемдә бер якты сәхифә булып калды.

Бу җыелыштан соң без, чынлап та, киңрәк дөньяга чыктык.

Нәкъ шул елны булса кирәк, без яшәгән торак йортка күрше бинада беренче баскыч партия мәктәбе ачылган иде. Ә аларның күршесендә чиркәүдән үзгәртеп ясалган клуб бинасы. Комсомол клубы. Шунда кереп йөри башладык. Анда көн саен диярлек ни дә булса уздырыла. Җыелыш, лекция, дискуссияләр, һич булмаганда, уеннар. Һәр чараның үзәгендә—партшкола егетләре. Әйе, партия мәктәбендә укучылар бары да диярлек егетләр иде. Шул клубта без күн заводыннан, азыктөлек фабрикаларыннан килгән эшче егетләр һәм шәһәрнең төрле учреждениеләреннән җыелган хезмәткәр яшьләр белән дә очраштык. Ул вакытта клуб эшенең төп формасы булган җыелышларда актив катнаштым дип мактана алмыйм. Төрле мәсьәләләр буенча фикер алышуларда чыгып сөйләргә, хәтта кайвакыт теге яки бу мәсьәлә уңаенда залны яңгыратып сорау бирергә дә кыюлыгым җитми иде. Доклад яки лекцияләрдән соң сорауларны язып бирү тәртибе юк иде ул заманда. Сорауларны гына түгел, гомумән, нинди дә булса доклад яки лекцияне (фикер алышу тәртибендәге чыгышлар турында әйткән дә юк) алдан язып килеп уку дигән нәрсәне берәү дә белми, язуга карап сөйләү шпаргалка белән файдалану кебек оят эш санала иде.

Сүз уңаенда әйтеп китәсем килә, минем кордашлар арасыннан кайбер иптәшләр бу практиканы сагынып искә алырга, хәзерге ораторлар арасында киң тамыр җәйгән язуга карап сөйләү күренешен җае чыккан саен тәнкыйтьләп үтәргә яраталар. Язуга карап сөйләүне мин үзем, гомумән, гаепкә алмас идем. Дөрес, берәү үзенең әйтәсе килгән фикерен зур аудитория алдына чыгып, түкми-чәчми, төрлечә аңларга юл калдырмыйча, алай гына да түгел, үзе ышанганга башкаларны да ышандырырлык итеп, тыңлар өчен кызыклы да, җанлы да рәвештә әйтеп бирә белә икән, бик яхшы. Ләкин сөйләү куәсе, язучы каләме ши-

келле үк, табигать тарафыннан бөтен кешегә дә тигез бирелмәгән. Ә язганны чыгып уку бераүне дә ул кадәр куркытмый. Димәк, бу практика фикер алышуларда төрле кешеләрне күбрәк катнаштырырга киң юл ача, бусы—бер. Икенчедән, җыелыш яки киңәшмәләргә алдан әзерләнеп, әйтәсе килгән фикереңне тиешенчә туплап, аны төгәлрәк итеп әйтергә мөмкинлек бирә.

Дөрес, бу практиканың акыл ягыннан чикләнгәнрәк кайбер бюрократларга кеше язып биргән речьләр белән ялтырап йөрергә юл ачкан чаклары да була. Ләкин аңа карап кына кеше язып биргән текст белән трибунага чыгуны да гөнаһка санап булмый. Әйтик, хезмәте белән зур абруй казанган, ләкин ораторлык ягы йомшак булган берәү оешма яки коллектив исеменнән чыгып сөйләргә тиеш булган икән, аңа үзенең шәхси уйларын гына түгел, күпләгән хезмәттәшләренең дә фикерен әйтү бурычы йөкләнгән икән, әйтергә тиешле сүзләрен тәртипкә салып бирергә аңа бүтәннәр дә булышса, моның ни гаебе бар?..

Мәктәп күләмендә уздырыла торган әдәби кичәләр зур бәйрәм көннәрендә генә оештырыла, ләкин бар кадәресе гаять күңелле була иде. Гадәттә мондый кичәләрне Хәмит абый үзе, я булмаса, укытучылардан берәрсе кереш сүз яки доклад белән ачып җибәрә, аннан соң нигездә укучы балалардан торган концерт бүлеге башлана. Беренче булып, әлбәттә, хор. «Салкын чишмә», «Гөлчәчәк», «Карурман»...

Тау астында салкын чишмә
Чылтыр-чылтыр агадыр.
Гафил булып йоклап ятмыйк,
Заман узып барадыр...

Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым куш тирәк.
Ә-ә-ә-й!..
Дөньяда дус-иш кирәк...

Әйбәт җырлар. Йотылып, дөньямны онытып тыңлыйм. Үзем дә катнашсам, мин инде тагын да бәхетлерәк. Хорда катнашу — ялгыз җырларга тавышы җитмәгән кеше өчен аеруча зур бәхеттер ул. Күмәк эчендә үз тавышың да барлыгын, аның уртак җырны бозмау гына түгел, көчәйтергә ярдәм итүен тою рәхәт. Безнең заманда, бигрәк тә минем кордашлар арасында, үз гомерендә бер генә тапкыр булса да хорда катнашмаган кеше юктыр кебек. Уйлап карасаң, тормыш үзе күмәк җыр бит ул!

Мәктәп күләмендә уздырылган гомуми җыелыш яки әдәби кичәләр мин укыган чорга ничәү туры килгәндер, барын да хәтердә саклап булмый. Мәгәр бер җыелышның рәсми бүлегендә төп докладны бер укучы сөйләгәне истә. Җиденчедә, ягъни соңгы класста, укучы Хәмит исемле башкорт малае иде ул. Шундый җитди итеп, олыларча тирән мәгънәле итеп, бернинди оялу-тартыну белгесе күрсәтмичә, «мотлак», «һәрхалдә», «хосусан» кебек китап сүзләрен дә кыстырып сөйләвен дөньямны онытып тыңладым. Аның шундый зур кабилиятькә ия булуына сокланып, күңелемнән генә талантына баш иеп утырдым.

Укырга сәләтлелек ягыннан да, җәмәгать эшләрендә катнашуда да Хәмит Госманов алдынгы укучылардан иде. Кульязма журнал чыгару эше — башлыча аның кулында (әлеге «ике атнага бер чага» торган «Җылан» да аның эше булган икән). Хикәя, шигырь кебек нәрсәләр белән булышмый, мәгәр язарга оста иде. Шул чорга хас булган төрле мәүзугларга, аеруча әдәбият мәсьәләләренә карата язган мәкаләләрен ярата идем. Тора-бара ярыйсы гына дуслашып та киттек. Аның аркылы мин әдәби әсәрнең үзенә хас нечкәлекләрен ачыграк күрергә өйрәндем. Шунысы кызык: әдәбият-сәнгать әсәрләрен булсын, теге яки бу фәнгә

кагылышлы читен мәсьәләләрне булсын, җәмгыятьтә тоткан урыны белән, аң-белем дәрәҗәсе белән үзенә якынрак торган кеше аркылы тизрәк һәм күбрәк аңлыйсың. Хәтта җырны да шулай. Мәсәлән, теләсә нинди яңа көйне мин профессиональ җырчы авызыннан тиз генә ота алмыйм. Шул ук җырны гади кешедән, тавышы белән миңа якынрак торган берәр иптәшем авызыннан ишетсәм, аны шунда ук отып алам (шунда ук җырлый да башлыйм дигән сүз түгел, әлбәттә; яңа ишеткән көйне күңелдән кабатларлык хәлгә килүне дә мин отуга саныйм).

Кызык өчен генә булса да, мәктәп кичәләреннән хәтердә калган бер детальне искә алып үтәсем килә.

Иң кечкенә укучылардан ике кызчык концерт бүлегендә «бала белән күбәләк» булып сәхнәгә чыктылар. Күбәләк ролендәгесе, Нурия исемле иде бугай, беренчедә генә уку өстенә, шәрикләре арасында буйга да кечкенәрәк булганга, бөтенләй сабый булып күренә. Ак ефәктән тегелгән кыска кына күлмәктән, җитмәсә, марлядан канатлар да куеп җибәргән. Нечкә генә ялангач беләкләрен селкеп, сәхнә буйлап йөгереп йөргәндә аның йомшак чүәк кигән тәпиләре идәнгә бөтенләй тимиләрдер, ул, чынлап та, очып йөридер сыман күренә. Тфу-тфу! Адәм баласы түгелдер бу, чын күбәләктер, я күбәләк сурәтенә кергән фәрештә валчыгыдыр дип утырасың. Менә ул гади колакка чак ишетелерлек әкрен, ләкин һәр кемнең үзәгенә үтеп төшәрлек самими тавыш белән үз тормышы, ничек көн күреше турында җырлап, адәм баласына җавап бирә. Кырларда-болыннарда торуы, кояш нурларына иркәләнеп, очып йөрүләре, чәчәкләрдән бөркелгән хуш исләр белән тукланып яшәве турында әйткәч, кайгысын, зарын белдерә.

Тик гомерем бик кыска,
бары бе-е-ер көн генә!

Сабый бала күңеленнән агып чыккан саф моңнан да көчлерәк нинди генә сәнгать әсәре бар икән? Залда ниндидер серле, тантаналы тынлык урнаша. Өлкәнрәкләр кулында ак яулыклар күренә башлыйлар. Күбәләк сыйфатына кергән сабый, ялварып, соңгы сүзләрен әйтә:

Бул яхшы, рәнҗетмә
һәм тимә-ә син миңа!..

Билгеле, мондый җан эреткеч чыгышларны миңа аннан соң да күп күрергә туры килде. Ихтимал, рәнҗетүче булмаса, Нурия дә онытылган булыр иде. Шул сабыйны рәнҗетүче табылды бит.

Сәяси тәрбия эшләрен көчәйтү өчен дип булса кирәк, мәктәпкә бер яңа кеше килде. Зәйни абый дип йөри идек. Нинди фәннән укыткандыр, хәтердә калганы шул: төрле революцион темаларга, дөнья хәлләренә, ил күләмендә барган көндәлек агымдагы эшләргә бәглы мәсьәләләр турында докладлар сөйли иде. Беренчедән алып җиденчегә кадәр булган барлык укучыларны җыеп, ураза турында сөйләгәне онытылмый.

Интернат балаларыннан тыш, мәктәпкә үз өйләреннән йөреп укучылар да күп иде. Араларында ураза тотучылар да бар икән. Зәйни абый шуларны белеп алган. Кем язып биргәндер, уразаның зарары турында шактый ачулы итеп кереш сүз әйткәннән соң, докладчы гаепле укучыларны исемнәре белән атап тәпи бастыра башлады. Тәпи бастыра да сорый:

— Ураза тоттыңмы?

— Тоттым.

Икенчесен бастыра.

— Тоттыңмы?

— Тоттым.

Берзаман Нуриянең исеме чыкты.

Иң алгы рәттә утыручы беренче сыйныф балалары арасыннан әлеге күбәләк тәпи басты. Без, зуррак балалар, җиңелчә генә көлешеп алдык. Докладчы көлмәде. Күзләрен шар ачып, Нуриягә төбәлде.

— Син дә тоттыңмы?

— Төттем.

Әйе, үзенең күбәләк тавышы белән, чак ишетелерлек итеп, кешечә «тоттым» дип тә түгел, нәкъ күбәләкчә нечкәртеп, «төттем!» дип җавап кайтарды.

Куркышыннан юкны әйткәндерме, әллә чынлап та тиле балалык мавыгуы белән зурларга ошарга тырышып, ураза тотып азапланган булганмы, безгә, зуррак класс укучыларына, бик кызык тоелды бу. Шаулап көлеп җибәрдек. Зәйни абый дигәнебез көлмәде. Аның кырыс күз карашы астында без дә тынып калдык. Башын түбән игән хәлдә нишләргә белми басып торган кечкенә Нуриянең бөтен кыяфәте «рәнҗетмә һәм тимә син миңа!» дип ялвара кебек күренә иде.

— Кай җиреннән тоттың? — диде докладчы абый, ачу катыш мыскыллы тавыш белән.

Бала дәшмәде. Ул, тавыш чыгарырга куркып, тыелып кына елый иде.

— Оҗмахка керәсең килдемени? — диде дәһри абыебыз тавышын күтәрә барып. — Җитмеш хур егете кирәк булдымыни сиңа? Әзерләгәннәр анда сиңа җитмеш кишер!..

Әнә шундый педагогны да күрдек без үрнәк мәктәптә. Бәхеткә каршы, бу аның соңгы чыгышы булды, ахрысы, яңадан безгә ул кешенең нурлы йөзен күрергә дә, «хикмәтле» сүзләрен ишетергә дә туры килмәде.

## 3

**Аңлы рәвештә. Биктаһиров. Мәхәббәт уены. Фаҗига.**

Ул кышны безне олыларча җитди уйга төшергән зур кайгы — Ленин бабабызның үлеме булды. Юлбашчыны соңгы юлына озаткан минутларда бөтен Стәрлетамак халкы зур мәйданга — кайгылы митингка җыелган иде. Чатлама суыкта шәһәр җитәкчеләренең ялан баш килеш трибунада басып торулары, завод-фабрика гудокларының озак итеп, үзәк өзгеч тавыш белән елый-елый гүләүләре хәтердә.

Шул көннәрдә мин шәһәр күләмендәге ячейкага, үземне комсомол сафына алуларын сорап, гариза бирдем. Алдылар. Бу инде, унтугызынчы елдагы шикелле, үз исемеңә язылган печатьле документ алырга кызыгу гына түгел, нинди оешмага кергәнеңне ярыйсы белеп, аңлы рәвештә көрәш юлына аяк басу иде.

Кулга корал тотып, революция дошманнарына каршы сугыш кырларында көрәшү чоры үткән иде инде. Ләкин онытылмаган иде. Совет дәүләтен әле һаман да вакытлы хәл дип кенә караучы капиталистик илләр дә, элекке хакимлекләрен кире кайтарудан өметләрен өзмәгән эчке дошманнар да үзләренең барлыгы турында һаман искә төшереп торалар, революция җимешләрен төрле хәвефле көчләрдән сакларга һәр вакыт хәзер булу кирәк иде. Өстәвенә, гражданнар сугышы тудырган чуалчык көннәрдә, ачлык ел шартларында күбәеп киткән төрле бандитларның да беткәне юк...

Бер кичне шулай кайдандыр кайтып килә. Караңгы. Якын дустың очраса да танырлык түгел. Шунда берәү яхшы ук сизелерлек итеп корсагыма төртеп узды. Кем булды? Берәр таныш дисәң, тукталыр иде. Һич югында, нинди дә булса сүз кушар иде?.. Өстенә озын бишмәт, башына олы бүрек кигән кечерәк буйлы чатан кеше иканлеген генә шәйләп кала алдым. Явыз нияте булгандыр дисәң, болай гына төртмәс иде,

алай тиз күздән дә югалмас иде?.. Шайтан алсын ла. Просто ялгышкандыр, дидем дә куйдым. Куркырга да, ачуланырга да өлгермәдем. Шунда ук онытылган да иде. Икенче көнне исемә төшерделәр.

Милициядә хезмәт итүче бер егет килеп йөри иде безгә. Усман Биктаһиров. Буйга зур булмаса да, зифа гәүдәсенә таманлап тегелгән хәрби киеме үзенә сокланырлык дәрәҗәдә килешеп тора иде. Стәрлетамакта аны белмәгән кеше булмагандыр. Карап торуга кызлар кебек нәфис ак чырайлы иде үзе. Ләкин беркем каршында да курку яки каушап калуны белмәс кыю хәрәкәтләреннән дә, бернинди бәхәскә урын калдырмаслык итеп, үз-үзенә нык ышанып әйткән сүзләреннән дә аның ир йөрәкле кеше икәнлеге сизелеп торыр иде. Гади милиционер гына түгел иде ул. УРО[1] да куркыныч җинаятьләр белән көрәш буенча эшли һәм үз хезмәтенә чын күңеленнән гашыйк кеше иде. Ләкин без аны каланың шул чордагы иң күренекле яшьләреннән берсе булуы белән якын күрдек. Интернатка килсә — безнең арада үз кеше, партшколага керсә — андагы курсантлар янында шулай. Ә шәһәр клубында исә, үз кеше дию генә дә аз, андагы үзәк фигураларның берсе. Ул вакытта кантон үзәге булган шәһәрнең иң зур җитәкчеләре янында да үзен бик иркен тота, теләсә кайда, теләсә ни вакытта алар белән тигез хокуклы кеше булып сөйләшә, көлешә, кирәк булса ут чәчеп кычкырыша да ала, шул ук вакытта безнең кебекләр янында шаян, шук малай да була белә иде.

Безнең янга килүдән ни ямь таба иде икән соң бу егет? Ул вакытта башыма мондый сорау килми, ул килгәнгә бары шатлана гына идек. Малайлар да, кызлар да. Кызлар күзенә ул, әлбәттә, гашыйк булыр өчен генә яратылган чибәр егет булып күренгәндер. Ә безнең укучылар арасында буй җитеп килгән матур-матур кызлар бар иде. Усманның күңелен шулар тарткан булса, гаҗәпмени? Аларга якынлашу өчен иң унай юл — башта безнең белән аралашу икәнлеген дә зирәк егет яхшы аңлаган булса кирәк. Ул чордагы яшьләр арасында гомумән егет белән кыз кеше өчен тиз генә парлашып, аулак урын эзләү тотнаксызлык исәпләнә, үзенне алай тоту комсомол моралена сыймый, яраткан кызың яки егетең белән нинди дә булса күмәк эчендә очрашу хәерле санала иде. Гыйшык-мәхәббәткә җенси якынлык күзлегеннән генә карап, бу мәсьәләдә тәкатьсезлек күрсәтүче малайлар нинди дә булса берәр кухаркамы, өй җыештыручымы яки кер уучымы кебек олырак яшьтәге тол хатын белән яшерен элемтәгә кереп китәләр һәм, күбесенчә, мондый эшләргә карата артык уяу кызлар тарафыннан фаш ителеп, оятка калалар иде.

Усман саф намуслы, хатын-кызга мөнәсәбәт мәсьәләсендә, купшы итеп әйтсәк, джентльмен кеше иде. Бөтен кызларның диярлек үзенә гашыйк икәнлеген белеп, күреп торса да, мәхәббәт фронтындагы җиңешләре белән мактанырга яратучы кәперәйгән егетләргә охшаган чагын хәтерләмим.

Шулай да мактана торган гадәте, гомумән, юк иде дисәм, дөрес булыр иде микән? «Мактану» дигәнем шул: ул, УРО кешесе буларак, үз практикасында очраган хәлләр турында сөйләргә ярата иде. Шәһәрдә ниндидер притоннар барлыгы, шул тирәдә яшеренеп ятучы бандитларның явыз җинаятьләре, аларны фаш итү, алар белән көрәш вакытында куркыныч вакыйгаларга очрау, үткен хәнҗәрләр, төрле маркадагы мылтыклар, пистолетлар белән коралланган рәхимсез бандитларны кулга алган чакта күрсәткән батырлыклары, тапкырлыклары турында шул кадәр мавыгып, дәртләнеп сөйли, без аны дөньябызны онытып тыңлыйбыз. Ул минутларда безнең өчен аның эшеннән дә мактаулы, шунардан да әһәмиятле, шунардан да данлы хезмәт юк, һәм ул эшнең иң тапкыр геройларыннан берсе — Усман Биктаһиров...

[1] УРО — уголовно-розыскной отдел.

Төрле җинаятьләрнең очларын эзләү буенча аны кайвакыт чит өлкәләргә дә җибәрәләр иде. Иртәгә ерактагы бер шәһәргә китәсе кичендә ул безнең бүлмәгә кереп, шактый озак язынып утырды.

— Хатлар язам, — диде ул, безнең кызыксынуыбызны күреп.— Юлдан салып җибәрергә.

— Ничек юлдан?

Ул сәфәргә чыккан чакларында Стәрледә калган хезмәттәшләренә хат яза икән. Юлда вакыт булмау ихтималын күздә тотып, фәлән шәһәрдән, фәлән станциядән җибәрәсе хатларын өйдән үк язып алып чыга икән.

— Кызык. Ә ул станциягә барып җитә алмасаң?

— Хат салынмый кала. Бары шул гына.

Ихтимал, аның хезмәтендәге кеше өчен болай эшләүнең үзенә күрә бер мәгънәсе булгандыр. Һәрхәлдә, бу миңа бик сәер тоелды.

Тагы бер кызыгы.

Интернат кысасыннан шәһәр клубы дөньясына чыккач, без икенче үрнәк мәктәбе укучылары белән дуслашып киттек, бер-беребез белән аралаша башладык. Алар арасында бер төркем сәхнә сөючеләр бар иде. Хәмзә исемле егет, революцион тарих китапларына нигезләп, берсеннән-берсе фаҗигалерәк драмалар яза, үзе үк режиссер булып, аларны сәхнәгә куя, үзе үк җаны-тәне белән бирелеп, төп рольләрне башкара иде. Ихтимал, вакыты белән ул егеттән менә дигән драматург та чыккан булыр иде, яшьли дөнья куеп, әрәм булды.

Икенче үрнәк сәхнәсеннән хәзер инде шәһәр күләменә чыккан ул спектакльләрдә безнең мәктәп укучылары да, гомумән, клуб тирәсенә тупланган башка яшьләр дә катнаша иде. Биктаһиров та, әлбәттә, читтә калмады гына түгел, һәвәскәр артистларның үзәгендә булды. Зал һәр вакыт тулы була, спектакльләребез гөрләп бара, тамашачы күләсе урында рәхәтләнеп көлә, елыйсы урында елый, пәрдә ябылганнан соң шаулатып кул чабу белән генә канәгатьләнми, аяк белән дә идәнне дөбердәтеп, артистларга рәхмәтен белдерә иде.

Бер спектакль вакытында тамаша залында ниндидер тынычсызлану сизелде. Берәр билетсыз кеше фаш ителдеме, әллә берәр исерек кереп тавыш чыгардымы, әкрен генә башланган тынычсызлану бик тиз арада шау-шуга әйләнде. Ә сәхнәдә спектакль. Җаваплы рольдә — Биктаһиров. Аның янында башкалар. Бер мәл аптырап, таркалып калгандай булдык. Көтелмәгәндә килеп чыккан мондый кыенлык гадәттә пәрдәне ябу белән хәл кылына торган иде. Бу юлы ябарга өлгермәделәр, Биктаһиров ниндидер патша чиновнигын уйнап торган җиреннән кинәт кенә үзенең асылына кайтып, кырыс милиционерга әйләнде. Залга йөзе белән борылды да, аяк тибеп, гайрәтле тавыш белән кычкырып җибәрде.

— Тише!..

Шундый каты әмер булып яңгырады аның тавышы, чыгырыннан чыккан тамаша залы кинәт шым булып, тынып калды. Һәм, бер мизгел аптыраушта торганнан соң, кемдер, аңына килгәндәй, кул чабарга тотынды. Шунда ук аны бөтен зал күтәреп алды.

Билгеле, ботканы май бозмаган кебек, спектакльне дә кул чабулар бозмый. Берни булмагандай, уеныбыз дәвам итте. Усман яңадан бу фани дөньяны оныткан артист иде инде.

Бу инцидентны иң авыр кичергән кеше нечкә күңелле Хәмзә булган икән. Ул пәрдә ябылганда да тынычланып җитмәгән иде әле.

— Ничек шулай, сәхнәдән торып, халыкка аяк тибеп кычкырырга җөрьәт итә алдыгыз? — дип сорады ул Усманнан,— әгәр дә зал тынычланмаса, нишләр идегез?

— Тынычланмый карасын! Сәхнәдән сикереп төшеп, иманын укыта идем мин ул хулиганның!..

Теге кечне каранғы урамда минем корсагыма төртеп китүче кеше шул Усман булган икән, үзе әйтеп бирде.

— Бигрәк тыныч кеше икәнсең син,— диде ул миңа, килеп күрешү белән.

— Нигә?

— Минем корсакка шулай тиктомалдан төртеп китсәләр, дәшми каламмы соң мин!

— Ә сиңа кем әйтте аны?

— Үзем төртеп китим дә, шуны кешедән сорап торыйммы?

— Син?!

Минем шулай гаҗәпләнүемә кәефе килеп, Биктаһиров көлеп куйды. Бу аның шулай, бөтенләй бүтән кеше кыяфәтенә кереп, разведкага чыгуы, ниндидер шикле кешеләрне күзәтеп йөргән чагы булган икән.

— Кайраклы төбәгендә бер притон таптык,— диде ул.— Озаклямый облава булачак. Кызыксынсагыз, гайрәтегезне сынап карыйсыгыз килсә, сезне дә алып барырга була.

Бу сүзләрне ул, әлбәттә, безнең кызыксынуыбызны белеп әйтә. Беренче әйтүе дә түгел. Әйтә, ләкин алып барырга ашыкмый...

Бандитлар белән көрәш маҗараларын аеруча кызыксынып тыңлаучылар һәм кайчан да булса, Усманның безне дә шул кызыклы һәм хәтәр көрәшкә алып керүен өмет итүчеләр турында сөйләгәндә «без» дип язам икән, үземнән башка тагын бер иптәшемне күздә тотам.

Ибәт исемле бер малай белән дус идек. Янәшә караватта йоклыйбыз. Ул миннән яшькә олырак булса да, бер класста укыйбыз, теләкләребез дә, серләребез дә уртак иде. Хәтта уртак мәхәббәтебез дә була язып калды.

Ибәт сары чәчле бер кызга гашыйк иде. Ә ул кызның күңеле миндә, имеш. Мин моны үзем белми дә идем. Укуга караганда күбрәк уенкөлке ярата һәм малайлар янында үзен бик иркен тота торган ул кыз минем янда артык узынмый, сөйләшергә туры килгән чакларда миңа карата ихтирам күрсәтә, күзләр очрашса, оялчан елмаеп куя иде. Ләкин мин моңа бернинди дә мәгънә бирмим, матур-матур егетләр каршында абруе җитәрлек булган ул кызның күңелендә миңа карата ни дә булса бардыр дигән уй башыма да килми иде. Ибәт әйтеп бирде. Үзенең Сары чәчне ничек өзелеп яратуы турында сөйләп утырды-утырды да:

— Ә аның күңеле синдә!— дип куйды.

— Китсәнә, юкны сөйләп утырма.

— Белмәгән булып кыланма!

Дустымның мәхәббәтен уртаклашу ниятем булмаса да, миңа ничектер күңелле, кызык булып китте. Рәхәтләнеп көлеп җибәрдем.

— Ә син көлмә!

— Тыныч бул, минем аңа мәхәббәт белдерәсем юк.

— Ә ул үзе сиңа белдерсә?

— Җүләр булмаса шул. Ә ул... Әллә акыллы дип беләсеңме?

— Җүләр кызга исең китмәсен соң!

— Вәт нәрсә, — диде Ибәт, тагын да җитдиләнә төшеп. — Дус булсаң, арага кермә.

— Уйлаганым да юк. Синең исең китләч тә...

— Кара аны, яратам дип, үзе мәхәббәт белдерсә, сиңа аны кире кагу кыен булыр.

— Әйт, белдермәсен.

— Мин әйтсәм, үчегер генә.

— Мин әйтимме? Миңа гашыйк була күрмә, Сары сандугачым, димме?

— Шаяртма әле. Дус булсаң, син аңа юл куйма.

— Ничек итеп?

— Якты йөз күрсәтмә. Ул көлеп караса да, елмайма.

— Һы!.. Тиктомалдан мин аны дошман күрә башларга тиешме? Бернинди гөнаһсыз кызны?..

— Гөнаһсыз!..

— Җүләрләнмә, малай. Юкны уйлап чыгарып, башыңа кайгы алма!.

— Ярар, синеңчә булсын, — диде Ибәт, тынычлангандай булып. — Давай сынап карыйбыз!

— Пожалсты. Ничек итеп?

— Мин сине атарга ниятләнгән булыйм. Нишләр икән?

Торагыбызда бер винтовка бар иде. Төннәрен аны ишегалдында дворник тотып йөри, көндезләрен малайлар кулына керә, без аны өйрәнәбез. Анда да иң күп мавыгучы кеше — Ибәт иде. Шул мылтыкны кулына алды бу.

— Син бас әнә шунда ишек янына. Мин сиңа төзәп торган булыйм. Ә син, Әбүталип, бар, йөгер кызлар бүлмәсенә. Ибәт Мирсәйне ата, диген. Тиз бул!

Икенчедәме, өчендәме укып йөрүче кечкенә кара малай берсүзсез чыгып та китте.

Торам ишек янында басып. Ибәт миңа мылтык төзәгән. Кызык.

— Көлмә!— Ул инде тәмам ачуланган тавыш белән кычкыра. — Иманыңны укы!

Коридорда кызлар бүлмәсе ягыннан йөгерешеп килгән аяк тавышлары ишетелде. Ибәт тагын да ярсыбрак кычкыра башлады.

— Икебезнең беребез артык, дөньяда син булганда миңа көн юк! Укы иманыңны!..

Бу сүзләрне ул шундый ышандырырлык итеп әйтте, хәтта мин шикләнә калдым. Шаяртуымы соң бу моның? Әллә чынлап та... Ләкин сынатасым килмәде, нәкъ театрдагыча артистланып, кычкырып җибәрдем.

— Ат, башың ике булса, дурак!...

Йөгерешеп кызлар килеп керде. Иң алдан Сара. Атылып, алдыма килеп басты да, күкрәге белән Ибәткә каршы торган хәлдә, гәүдәсе белән мине каплап, кулларын ике якка җәеп җибәрде.

— Мине дә ат!.. Икебезне дә!..

Эш болайга киткәч, уеннан уймак чыкмагае дип, тиз генә ишек артына тайдым...

Дуслыгыбыз бозылу куркынычы астында калган иде. Тик Усман сөйләгәннәр белән уртак мавыгуыбыз гына безне якын тотып калды.

Усман үз хезмәте белән безне шулай мавыктыра алуына үзе дә бик канәгать, һаман безне үзе белән бергә бандитлар тоту операциясенә алып барырга вәгъдә итә иде. Хәтта бер караңгы кичне, разведкага дип, үзе белән бергә алып та китте. Тик шәһәр читендәге урамнарда төн буе диярлек йөрсәк тә, куркыну катыш кызыксыну белән хәвефле хәлләр көтсәк тә, бернинди мажара булмый калды. Усман, хәзергә шушында торып торыгыз, башта үзем белеп килим дип, безне берәр почмакта калдыра да, шомлы тыкрыкларга кереп югала, бераздан нәтиҗәсез кире борылып килә иде.

— Бу юлы барып чыкмады, ахрысы,— диде ул, ниһаять,— я сизгәннәрдер, подлецлар, я планнары үзгәргән. Әйдәгез!..

Безне хәтәр бандитлар белән очраштыру турындагы вәгъдәсе шуннан да ары китмәде. Ихтимал, тәҗрибәсез малайларны андый җитди эшкә алып баруның җаваплылыгыннан курыккандыр. Ә бәлки бу аның үзенә күрә көрәштәшлеккә кадрлар хәзерләү юлында безне сынап йөрүе булгандыр. Әмма ул чакта минем башыма мондый уйлар килмәгән иде. Хәтәр уенда катнашудан өметем өзелгәч, Усман турында: борчак сибәргә ярата торган гадәте бар, ахры, дип кенә уйладым. Безне, акыл

тешләре чыкмаган малайга санап, алдап кына йөрткәндер. Өстәвенә, тагы шунысы ачылды: Усманны безгә караганда да ныграк яратучы кеше әлеге Сарабыз булган икән. Димәк, егет чынлап та интернатка безнең өчен генә килеп йөрмәгән. Андый кешенең мәхәббәт дигәне дә озакка барыр микән?..

Ләкин Усманга карата мондый караш миндә гомергә калмады. Стәрлетамактан китеп күпмедер вакыт узгач, мин аның Сара белән бергә тора башлавы турында ишеттем. Үз вакытында һәркайсы күңелемдә матур эз калдырган яшьлек дусларымның шундый бәхеткә ирешүләренә куанып бетәргә өлгермәдем, Биктаһировның[1] фаҗигале үлеме турында хәбәр китерделәр. Егет үзе изге күргән көрәш юлында тормышын корбан иткән. Җинаятьчеләр белән бәрелештә һәлак булган яшь геройны зур хөрмәт белән җирләгәннәр. Җеназасына бөтен Стәрлетамак халкы җыелды дип сөйләделәр.

Бу хәбәр мине тетрәндереп җибәрде. Егерме ике яшендә корбан булган егетнең геройлыгы каршында баш ию белән бергә, кайчандыр аның турында аз гына булса да начар уйлавым өчен вөҗдан газабы кичердем. Юк, борчак сипмәгән икән ул. Арттырып сөйләү түгел, булган кадәресен дә әйтеп бетермәгәндер. Тагы да катлаулырак мажаралары турында, бәлки, профессиональ сер буларак, әйтергә дә ярамагандыр.

Халык бәхете, аның тынычлыгы өчен көрәш юлында тормышыңны корбан итү дәрәҗәсенә күтәрелү! Чын геройлыкның иң биек ноктасы шул түгелмени?!

## 4

**Козырексез фуражка. Спорт җене. Рәсемгә мәхәббәт. Кызыл йөзле рәссам. Кара күзле шагыйрь. Идеальный герой. Маруся. Шуклык.**

Яраткан кызының икенче кешегә каравы Ибәт өчен, әлбәттә, үзенә күрә фаҗига булгандыр. Ләкин бирешмәде егет. Бер-берсен табышкан ике саф йөрәк каршында үзенең ялгыз-ярты мәхәббәте көчсез икәнлеген аңладымы, ул чор яшьләре өчен самими дәрәҗәдә изге булган комсомол намусы өстенлек алдымы, көндәш дустына юл куйды.

Шулай да хәзер Усман сөйләгәннәрне сабыйларча авыз ачып тыңлау юк иде инде. Яңа дуслар табарга яратучан Ибәт ялга кайткан бер матрос белән танышып алды... Диңгезчеләр мәктәбендә укучы курсант икән. Егет шәп: кайтарылып төшкән яка читләрендә ак җияк тоткан зәңгәр күлмәктән. Башында озын койрыклы козырексыз фуражка. Җиргә тиеп торган киң чалбар балаклары астыннан кара шиблетының курнус борыны гына күренә. Телгә дә оста иде, күрәсең, сөйләгәнен тыңлап торсаң, бу дөньяда моряк тормышыннан да кызыклы, аннан да мәгънәле тормыш юк...

Ибәткә җитә калды. Диңгезчеләр мәктәбенә китү хыялына төште бу. Мине котырта. Диңгезче булу уема да кергәне юк иде. Шулай да иптәшемә каршы бара алмадым. Киттек мәгариф бүлегенә, диңгезчеләр мәктәбенә җибәрүләрен сорыйбыз. Разверстка юк икән, военкоматка барырга киңәш иттеләр. Аннан тагы ниндидер клубка. Учреждениедән учреждениягә чабып йөрүләребез шуның белән тәмамланды: кайдадыр безне хәрбигә тартым ирекле оешмага язып кайтардылар. Авиахим дип аталган чагы идеме, Добрахиммы, хәзерге ДОСААФның яңа оешып килгән чоры иде. Диңгез турында хыяллануыбыз шуның белән бетте.

[1] Уфа партархивыннан алынган белешмә буенча, Биктаһиров Усман Җиһанша улы 1905 нче елны туган, ВЛКСМ члены, 1925 елның маеннан ВКП(б) членлыгына кандидат, карточка номеры — 4884. Хезмәт эшчәнлеге: 1919—1920 еллар — РККА разведчигы, 1920—1921 — халык мәгарифе бүлегендә хисапчы, 1921—1924 — балалар йортында тәрбияче, укытучы. 1924 елның маеннан УРО агенты, администрация бүлеге, юстиция ячейкасы.

Батырлык, физик яктан ныклык, тазалык сорый торган хезмәтләр белән кызыксынып йөрүләрнең файдасы шул булды: спорт белән мавыгып киттем. Күршебездәге клуб каршында оештырылган физкультура түгәрәгенә йөри идек. Иртәнге алтыдан ук кузгалабыз да клубка йөгерәбез. Өйрәтүчебез Молоканов дигән абый иде. Безнең янда шактый озын буйлы, аяк-куллары гел сеңердән генә торган шикелле какча бәдәнле бу кеше, күп дигәндә, егерме бишләр тирәсендә булгандыр. Ләкин үзенең кырыс таләпчәнлеге белән ул безгә бик олы күренә иде. Аның җитәкчелегендә төрле тән күнекмәләре ясыйбыз, тора-бара пирамидалар оештырырга да өйрәндек, хәтта мәктәп кичәләрендә сәхнәгә чыгып һөнәребезне күрсәткән чакларыбыз булды.

Тик безнең өчен спортның иң кызык өлеше өйрәтүчебез юк вакытта була иде. Ул килеп җиткәнче җаныбыз теләгәнне кылана торабыз. Физкультура өчен кирәк булган төрле җайланмалар җитәрлек иде анда. Кул белән асылынып югары күтәрелү өчен көйләнгән баскыч, төрле биеклектә, төрле озынлыктагы кузлалар, турниклар, бауга тагылган тимер боҗралар, төрле авырлыктагы гантельләр, герләр... кайсын телисең!

Иң яратканым турник иде. Мин аны кайда күрсәм дә янышнан тыкыч кына уза алмый идем. Турникны хәтерләткән берәр аркылы агач яки киртә күзгә чалынса да, асылынып, бер-ике әйләнеш ясамыйча, һич югында, беләк мускулларын киереп, рәттән биш-ун тапкыр иякне турникка тидереп алмыйча үтә алмыйм. Биегрәк стенага сөяп куелган баскыч туры килсә дә шулай. Басмалары тотынырга җайлы ясалган булса, кул белән асылынып, иң югарыга кадәр менеп төшмичә узу юк.

Шулай да, ни кадәре яратсам да, турник остасы булу ягыннан күңелем теләгән дәрәҗәгә ирешкән чагым булмады. Нинди югарылыкта торган турникка да сикереп тотыну, теләсә кайсы ягыннан аның өстенә күтәрелеп чыгу минем өчен берни түгел. Беләк мускулларымның көче рәттән унбишәр тапкыр күтәрелеп төшәргә җитә. Терсәк буыныннан эленеп булсын, тез астыннан эләктереп булсын, турник тирәли өзлексез әйләнеп торуларын да булдырам. Ә менә скобка ясарга өйрәнә алмадым. «Кояш» мәсьәләсендә дә башкалар ясаганга сокланып торудан узмадым.

Теләк зур, дәрт җитәрлек булса да, спортка талантым чамалы булгандыр, күрәсең. Турниктан тыш кулы белән йөри белүчеләргә кызыга идем. Олыгайганчы тырыштым, анысына да рәтләп өйрәнә алмадым. Гантельләр белән шаяру, штанга күтәреп азаплану кебекләргә исем китми; әмма ике потлы гади герне җиңел уйнатучыларга бәләкәйдән үк кызыга килә идем. Насыйп булса, күрерсез, буем үсеп, көчем арткан саен гергә булган мәхәббәтем дә көчәя барачак әле.

Ләкин яшь чагында сиңа тынгы бирмәгән һәр мавыгу, теге яки бу һөнәрне керсез күңелдән ярату—бу әле синдә шул һөнәргә талант бар дигән сүз түгел икән.

Рәсем ясарга әвәслегем зур иде тагы. Бусы миндә бәләкәйдән үк килә. Шаян телле әнибезнең көлеп сөйләвенә караганда, миндә хәтта сабый чакта ук «сурәт төшерергә» омтылыш булган. Имештер, бер вакыт сәкегә терәлеп торган киң тәрәзә төбенә менеп утырганмын да, үзем чыгарган сары «буяуга», пумала урынына кулымны манып, тәрәзә пыяласына өянке сурәте төшергәнмен. Кулыма каләм тоттыргач та беренче эшем сурәт ясарга азаплану булган. Үзем белә башлаганда инде кеше рәсемен сызарга ярата идем. Әле дә күз алдымда: баш урынына түгәрәк боҗра, күз-каш урынына нокталар; буйга бер сызык, аркылыга бер—авыз белән борын. Гәүдә урынына югарыдан түбәнгә таба сузылган бер сызык, тырмага охшатып эшләнгән ике кул, аяк урынына—кәкре башлы ике таяк.

Үзем ясаудан да битрәк ташка басылган сурәтләрне карау рәхәт

иде. Укый белә башлагач, китапларны жанрлары ягыннан «көйле китап, көйсез китап» дип, эчтәлекләре ягыннан «кызык» яки «кызганыч» китап дип икегә бүлүем турында язып үткән идем. Бер уңайдан тагы шунысын әйтергә онытканмын икән: укый белә башлаганга кадәр үзем күргән китапларны мин «сурәтле китап», «сурәтсез китап» дип икегә бүлә идем. Һәм минем өчен иң әйбәте, әлбәттә, сурәтле китап иде. Үлеп гашыйк идем сурәтле китапка. Хәзер дә, Татгосиздатның балалар өчен чыгарган китапларында яки «Ялкын» битләрендә басылган матур-матур рәсемнәрне карыйм да, аеруча Хажиәхмәтов ясаган гүзәл иллюстрацияләрне күрәм дә:

— Их!—дип куям, сокланып.—Бу рәсемнәр мин кечкенә чакта булса! Җанымны бирердәй булыр идем мин аларга. Юк иде шул, юк иде. Хәзерге балаларга тәкъдим ителгән рәсемнәрнең йөздән бере дә эләкмәгәндер безгә. Сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да...

Үзем үскән саен рәсемгә булган мәхәббәтем кимемәде генә түгел, арта барды. Стәрлетамакка килгәч, минем кебек үк малайларның стена газетасына булсын, кульязма журналга булсын, менә дигән рәсемнәр төшереп куюларын күреп сокландым. Сурәт төшерүне моңарчы кызыклы уенга гына санап йөри идем. Уку сәгатьләрендә башка фәннәр белән беррәттән рәсем дәресе дә керүен күрү бу эшне уеннан чынга әйләндереп җибәргән кебек булды.

Ләкин рәсем дәресе мин көткәнчә үк күңелле булып чыкмады. Анда геометрик шәкелләр ясаталар: шакмак, шар, иһрам (пирамида) кебекләр. Бик зурга китте дигәне дә гипстан әвәләнгән яфрак яки берәр хайван сынын күчереп ясаудан узмады. Укытучыбыз үзе дә чын рәссам иде микән әле? Аның кешене сурәтләгән яки табигать күренешләрен гәүдәләндергән рәсемнәрен күрмәдек. Мәктәпкә миннән элегрәк килгән малайлар бик сагынып элекке укытучыларын искә алалар:

— Их, Яхшыбаев шәп иде, менә, ичмасам, художник дисәң дә художник! Теләсә кемне, йөзенә карап, тач үзе итеп төшерә ала. Майлы буяу белән! Их, ул төшергән табигать күренешләрен күрсәң! Нәкъ чын кебек!..

Аларны миңа үз күзләрем белән күрергә дә туры килде. Нииндидер күргәзмә идеме, әллә рәсемнәр сата торган махсус кибет идеме—зур рамга тартып киерелгән киндер-картина каршына килеп бастык. Су буенда үскән ямь-яшел яфраклы агачлар, чынлап та, нәкъ табигатьтәгечә. Бигрәк тә аларның суга асылынып төшкән күләгәләре!.. Дөрестән дә, нәкъ чын кебек.

«Тач үзе» итеп ясалган кеше портретлары нинди булгандыр, аларын күрергә туры килмәде.

— Үзе кайда соң ул, Яхшыбаев?

— Андый зур художник безнең Стәрледә нишләп ятсын? — диделәр. — Казанга китте.

Үземә бирелгән махсус дәфтәргә генә түгел, кайбер иптәшләрнең альбомнарына да истәлек урынына төшергән рәсемнәремне — чәчәк, кәгазь-каләм яки ачып куелган китап сурәтләрен күреп, мине стена газетасына җигә башладылар. Класс бүлмәсе өчен кирәк булган диаграмма, плакат кебек нәрсәләр дә ясыйм, төрле бәйрәм көннәренә карата лозунглар язып куям...

Шунысы кызык: рәссамлык миңа шактый җиңел бирелә торган һөнәр булып тоела башлады. Нииндидер журналда рәссамны шагыйрь белән бер дәрәҗәгә куеп язылган мәкалә укыгач, хәтта гаҗәпләндем. Ничек инде шагыйрь белән рәссамны бер дәрәҗәгә куярга мөмкин? Тукай! Сәгыйт Рәмиев! Бабич!.. Нинди рәссам белән чагыштырырга мөмкин аларны? Алар кебек атаклы рәссамнар турында ишетелгәне дә юк

бит әле. Кем бар? Яхшыбаевмы? Тырышсам, аның кебекне, пожалуй, мин дә булдыра алырмын.

Ул вакытта, чынлап та, татарлардан телгә алырлык рәссамнар булмаган икән шул. Бөек рус художниклары, дөнья классиклары турында берни белмим. Нарат урманында уйнап йөргән аю балалары, күл буенда моңаеп утыручы Аленушка яки балыкчы карт сурәте төшерелгән картиналарга сокланып, исем китеп карап торган чакларым күп булса да, аларны кем ясаган икән дигән сорау нигәдер башыма килми иде. Әйтерсең алар кеше кулы белән ясалган рәсем дә түгел, ә чын табигать үзе!..

Башкасында эшем юк, үземнекен беләм: кирәкле рәсемнәрне әзер килеш газета-журнал битләреннән күчереп алырга остарып киттем. Кульязма журналга, менә дигән итеп, Ленин портретын ясап бирдем. Барына да ошый тагы. Очыртып мактыйлар.

— Шулай да Барыйга җитми инде,— дип куйды берсе.

Барый турында беренче ишетүем түгел иде инде. Шушы мәктәптә укып йөргән малай булган икән ул. Рәсемгә бик оста булган.

— Аңа җиткән берәү дә юк әле безнең үрнәктә!—дип кенә җибәрәләр.

Узган ел Оренбургка БИНО дигән уку йортына киткән булган икән, шул кайтып төште. Өстәвенә, бер башкорт егете белән кайткан. Анысы шагыйрь.

Ул чорда безнең интернат Стәрлетамакның шаулап торган культура учакларыннан берсе иде. Барый белән кунак егет тә кайту белән безгә килеп җиттеләр.

Барый, миннән бер яшькә кечерәк булса да, тәрәккыяте ягыннан сизерлек алга киткән егет булып чыкты. Тышкы кыяфәте белән матур дип үк әйтерлек түгел: карасу-кызарып торган симез генә битле, кысыграк кара күзле. Авызы аз гына бер якка кыеграк. Коңгырт кара чәчләре һаман тузгып, хәрәкәтләнеп тора. Ак апаше якасы астыннан тагылган кызыл галстук шәүләсе белән тагын да кызара төшкән йөзендә һәр вакыт шат чырай. Үзе алай бик кызык сүзләр сөйли белмәсә дә, көлгәнне, көлдергәнне ярата. Иңбашларын аз гына бөкрәйтә төшеп, терсәкләрен беркадәр арткарак җибәргән хәлдә, «кая, нишлим?» дигән кебек, ике кулын күкрәк турысына күтәреп, бармакларын хәрәкәтләндереп тора. Ул миңа: «Кая, нинди рәсем ясап бирим?» дип әйтергә тели кебек. Әлбәттә, әйтми. Без аның чынлап та рәсемгә осталыгын «Кызыл маяк» газетасының ул кайткач аеруча матур булып чыга башлаган яңа номерларында урнаштырылган рәсемнәрендә һәм шәһәр клубының пионерлар бүлмәсенә куелган төрле плакатларында, картиналарында күрдек. Стәрлетамакка кайту белән ул пионер вожатый булып эшләргә керешә. Балалар аны бик ярата, Барый абый дип үлеп торалар иде.

Кунак егете минем өчен Барыйга караганда да тансыграк кеше булып чыкты. Шул вакытта ук аның турында сүз чыкканда, фамилиясе янына исемен дә кушып, Сәгыйт Агиш дип сөйләргә яраталар иде. Матбугатта чыгып өлгергән иде микән, шулай да безнең арада шагыйрь дигән исеме таралган иде инде.

Буйга кечкенә, карасу йөзе сизелер-сизелмәс дәрәҗәдә генә майлаган төсле балкып тора. Ул еллар модасы буенча подпольку алдырылган озын чәчләре чем-кара. Алар әледән-әле Сәгыйтнең күзләренә төшеп тора.

Күзләре димәктән... Күп еллар үтеп, инде Татарстанда яшәгән чагымда, Уфага барып кайткач, Казанда торучы бер Стәрле кызы миннән уртак танышлар турында сорашып, Сәгыйтне исенә төшерде.

— Күрмәдегезме?—ди,—нихәлдә икән?

— Күрдем, исән-сау. Элеккечә шаян, сораганнарга сәлам әйтте.
— Күзләре һаман шундыймы?
— Шундый инде—күрә карау. Ерактан күрми.
— Йу-у-к,—диде ханым, ничектер уңайсызланып.—Күзләре һаман шундый карамы? дип соравым...

Әйе, күзләре күргән кеше тиз генә оныта алмаслык кара иде. Тик алар, чынлап та, ерактан күрми. Сәгыйт яхшырак күрергә теләгән нәрсәсен күзенә якын ук китереп карарга мәҗбүр иде. Әмма аның бу кимчелеге дә ничектер үзенә килешле, кызык булып чыга, шаян егет, кешене көлдерү өчен, юри шулай кылана кебек тоела иде.

Барый, Стәрле малае буларак, үз өйләренә кайткан, Сәгыйт исә, Оренбург ягы башкорты, кунакка гына килгән икән. Ул һаман безнең янда булды. Төннәрен дә күбесенчә безнең торакта куна иде. Ниләр генә сөйләшмәгәнбездер! Эч катыргыч көлке анекдотлар, анекдоттан азган әкиятләр. Агиш исә, күбрәк үзе күргәннәр яки кешедән ишеткән хәлләр турында сөйләргә ярата, тормышта булган вакыйгаларны, үзе теләгәнчә урыннарын алыштырып, җитмәгән урыннарына үз хыялыннан өстәп, күңелле хикәя яки анекдот кыяфәтенә кертә иде. Аның белән бергә укыган һәм соңыннан берсе күренекле шагыйрь, икенчесе тәнкыйтьче-әдәбиятчы булып киткән Гайнан Хәйри, Г. Амантай исемнәре матбугат битләрендә күренмәс борын ук диярлек, Сәгыйт сүзләре аша безгә танышлар иде инде.

Дұслары турында сөйләгәндә ул гел шаяртып, көлдереп сөйли, шул ук вакытта аларга карата синең күңелеңдә мәхәббәт уята. Шаян иде, бик шаян. Кызыклы, тапкыр сүзләре белән бер күңелеңне җәлеп итеп алгач, аның гап-гади сүзләрен дә көлми тыңлый алмыйсың.

Көлдереп кенә калмый, сәхнәгә чыкса, ул сине, күңелеңне нечкәртеп, хисләр, сәнгать дөньясына алып кереп китә дә белә, татлы яшьләренне дә сыгып чыгара.

Шигырь уку остасы иде. Үз шигырьләрен укыганын хәтерләмим, мәгәр башка шагыйрьләрнең әсәрләрен шундый яратып, шундый бирелеп укый, аны тыңлап тәмам сихерләнәсең. Сәгыйт Рәмиев, Такташ, К. Нәҗмиләрнең иң матур шигырьләре минем күңелемә башлап Сәгыйт сөйләме аша керделәр. Хәтта Муса Җәлилнең бер шигырен аныңча укыйм дип, тилереп йөргән чагым да булды (ниләр кыланганымны хәзергә әйтеп тормыйм, алда бу турыда тәфсилләбрәк язарга ниятем бар).

Соңыннан башкорт әдәбиятында хикәяләр остасы булып танылган, «Нигез» романын, менә дигән хикәя һәм повестьлар һәм үзе турында күпләр күңелендә матур-матур истәлекләр калдырып, 1973 нче елда бу дөньядан киткән Сәгыйт Агиш аны беренче тапкыр күргән җәйдә әнә шундый егет иде.

Бу җәйдә тагы безнең интернатканиндидер приюттан берничә бала китереп керттеләр. Араларында руслар да бар иде. Аеруча Ипполитов дигән малай хәтердә. Карап торуга тыйнак кына, сыек сары чәчле, бөтенләй кашсыз диярлек ак чырайлы малай. Буйга зур түгел, төптән юан чыккан, аяк-куллары да кыска, ләкин аларның имән шикелле ныклыгы күзгә бәрелеп тора. Ул безне үзенең көчлелеге белән шаккатырды. Ике потлы герне сыңар кулы белән югары күтәрә, җитмәсә, аны инбашына кадәр кире китерә дә, җиргә төшермичә, тагы күтәрә, тагы... Рәттән бишәр, унар тапкыр шулай итә. Беләк мускуллары, корыч пружина шикелле, бер кысыла, бер турая. Аннары идәнгә куелган гернен өстенә утыра да, ике кулын артка куеп, аның божрасыннан тота һәм шул хәлдә, ягъни артына ике потлы гер таккан килеш, тезләрен турайтып, тәпи баса, шул ук хәлдә җайлап кире идәнгә чүгә, тагы тора, тагы чүгә. Бусын да унар тапкыр кабатлый.

Инде арыгандыр, дисәң, кая ул! Икешәр потлы ике герне янәшә куя, тотка бөҗраларына аяк башларын тыгып, өсләренә менеп баса да, китә атлап! Ягъни ике аягына да эленгән икешәр потлы герләрне күтәреп атлый. Адымнары эре-эре!

Физкультура, спорт белән бик дәртләнеп шөгыльләнүчеләр күп булса да, безнең интернатта Ипполитов күрсәткән номерларны эшли алган бүтән бер генә кеше дә юк, әмма кулы белән йөри белүче бер малаебыз бар. Һәммәбез аңа соклана, аның белән горурлана иде. Интернат патриотларыннан берәү нindидер приюттан килгән Ипполит каршында сер бирәсе килмичә шул малайны искә төшерде:

— Нәрсә ул гер күтәрү,—диде.—Кара көч кенә кирәк монда. Менә син кулың белән йөреп кара!..

Ипполитов берни әйтмәде. Куллары белән идәнгә таянды да, аякларын югары күтәреп, атлап та китте.

— Сиркач икән, чукынган!

— Бөтен күңелен шуңа биргән инде ул.

— Мөгаен, укуының рәте юктыр...

Рус балалары бүтән мәктәпкә йөри иде. Шулай да бик тиз белеп алдык, Ипполитов укуда да иң алдынгылардан икән. Интернат буенча булсын, шәһәр клубы тирәсендә булсын, җәмәгать эшләрен аның кебек яратып эшләүче, үзенә тапшырылган вазифаларны аның кебек намус белән үтәүче башка кешене хәтерләмим.

Мондый идеальный геройның чын тормышта гына булуы мөмкин. Әдәбиятта—аңа ышанмыйлар. Шунысы кызганыч, үз вакытында да, соңыннан да шул егетнең тормыш юлы белән кызыксына белмәгәнмен.

Гер белән булышучыларга электән кызыгып йөри идем, Ипполитны күргәннән соң, үзем дә мавыга башладым. Өстәвенә тагы, приюттан килгәннәр арасында бер рус кызы бар иде. Шуңа күзем төшкәндәй булды. Яңа мунчадан чыккан кешенеке шикелле йөзе һәр вакыт кып-кызыл булып янып торган, кечерәк буйлы, карап торуга тулы гына тәнле күренгән Маруся, барыннан да бигрәк, миңа рус кызы булуы белән ошады. Дөресен генә әйткәндә, кем белән булса да русча хат язышып карыйсым килеп йөри иде, тоттым да шул Марусяга яздым. Әлбәттә, русчага өйрәнәсем килә дип түгел, үзенә күрә мәхәббәт хаты.

Күрәсең, русча белү дәрәҗәм шундыйрак булгандыр, Маруся минем хатымны өйләнергә тәкъдим ясау дип аңлаган булып чыкты.— Бу турыда уйларга безгә иртә әле,—дип җавап язды ул миңа.—Бик күп укыйсыбыз бар, өйрәнәсебез!..—һәм шул уңайдан, тартынып-нитеп тормыйча, мине өйрәтергә дә керешкән: хатымда җөмлә-имла хаталары күп булуы турында әйткән һәм аларны төзәтеп тә күрсәткән. Хатының азагында исә,— шулай да сез матур гына яза беләсез,— дип, юатыпта куйган.

Шуннан башкасының миңа кирәге дә юк иде. Җавап алуыма куанып, дәртләнеп, тагы яздым. Бернинди өйләнү-мәхәббәт турында сүз бармый, минем бары дусларча хат язышасым гына килә дигән фикерне аңлатырга тырыштым. Узган хатымдагы ялгышларымны күрсәтүе, аларны ничек төзәтергә өйрәтүе өчен рәхмәт әйттем.

— Бу хатыгыз яхшырак чыккан,—дип җавап язды Маруся.—Хаталары да азрак...

Бер интернаттабыз, көн саен очрашып торабыз. Ләкин күзгә күз очрашканда сөйләшер сүз таба алмыйбыз. Ул минем турникта һөнәр күрсәтүемне карап торырга ярата. Мин үземнең нинди «шәп» егет икәнлегемне мускулларым, хәрәкәтләрем белән күрсәтергә тырышам. Турникта аяк йөзем белән генә эленеп, баштүбән асылынып торган чакларымда, ул «ой, ой! Егылырсың!» дип, куркынып, минем өчен борчылып торган була. Миңа кызык, аның саен «хәтәррәк» кыланам.

Ул күрмәгән чакларда гына гер белән шөгыльләнергә керештем. Ипполитов булдыра алганны, неужели мин булдыра алмам икән? Аның чаклы ук булмаса да... Ике потлы герне сыңар кул белән башыңнан югары күтәреп кенә күрсәтсәң дә...

Һәм, чынлап та, әллә нәрсәсе юк икән. Рәт чыгар төсле күренә. Тик бу кызыклы эшне озак дәвам иттерә алмадым. Бердән, җәйге каникуллар беткәнче миңа Җиргәнгә кайтып, туган-тумачаны күреп, азмыкүпме туган авылым һавасын сулап килергә кирәк иде. Икенчедән, Марусяның да минем өчен кызыгы калмады. Мин Ипполитов кебек кыланырга азапланып йөрим, ә ул Ипполитовны миңа караганда элегрәк тә, яхшырак та белә икән.

— Туктале, Әсма диден, Сара диден, инде менә Маруся. Фәүзиян кайда соң синен?

Бу сорауны миңа күптән биргәннәр иде инде. Повестемның беренче китабын укыганда ук журнал редакторы сорады: «Мулла кызына карата күңелеңдә шундый матур хисләр уянганын әйттең дә оныттың. Укучы моны көтә бит?»

Урынлы сорау. Укучылар арасында, яшьләр генә түгел, картлар (бигрәк тә карчыклар) арасында һәр әдәби әсәрдән иң элек мәхәббәт маҗаралары эзләүче кешеләр күп. Көтәләрдер. Ни әйтим?

Фәүзия шунда, миннән бер сыйныф артта укып йөри. Бер интернаттабыз. Ул әле һаман бала. Шулай да күңелемдә алган үз урынын беркемгә дә биргәне юк. Мин аның барлыгын тоеп торам. Ул бар җирдә үземне бүтәнчәрәк хис итәм. Ничектер, ихтыярымнан тыш, үземне әдәплерәк, тыйнаграк, акыллырак, матуррак тотарга тырышам.

Бала дисәң дә, күрәсең, малайларның игътибарын җәлеп итәрлек нәрсәседер булган. Габдулла исемле бер малайның Фәүзия артыннан сокланып карап калганы һәм ул узып киткәч: «Шушы кызның яхшы ат кебек атлап йөрүен ошатам», дип куйганы хәтеремдә. Аның турында кешедән шундый сүз ишеткәнгә күңелем үсеп киткәндәй булган иде.

Ләкин Фәүзия үзе бу турыларда берни белми. Ул бөтенләй гамьсез. Миңа карата да аның йөрәгендә уртак тойгы уянуын өмет тә итмим. Бу кыз балага нисбәтән күңелемдә яралган яшерен тойгының кайчан да булса шытып чыгасы, тамырланасы, күкрәп чәчәк атасы, мәхәббәт орлыгы булу ихтималы башыма да килми иде.

Шулай булгач, аның турында ни языйм? Хәзергә берни юк. Үссен әле, укысын. Үзем дә житлегә төшим. Инде унҗидедә булсам да, чын мәгънәсендә егет булып җитмәгән идем әле. Минем өчен беренче чиратта торган мәсьәлә: уку! Җәмәгать эшләре, спорт белән шөгыльләнү дә шул җөмләгә керә. Шулардан калган бөтен вакытымны һәм рухи дөньямны әдәбиятка мәхәббәт, язуга булган дәрт тутырган.

Шулай да кызларга карата бөтенләй гамьсез идем дисәм, дөрес үк булмас. Бу мәсьәләдә әле тычкан тотарга өйрәнмәгән бала мәче кебекмен: җепкә тагып сөйрәлгән кәгазь кисәгенә ташланам. Ягъни нәрсәсе беләндер игътибарны җәлеп итәрдәйрәк берәр кыз кисәге күргәндә, я берәр нәрсәсен (тарагынмы анда, кульъяулыгынмы, перчаткасынмы) тартып алып, тиз генә кайтарып бирми ялындырасың. Я булмаса, тәнәфес вакытларында аны карга егып кычкыртасың. Шуның белән күңел ачыла, дәрт басылгандай була.

Артык үткерләрдән булмасам да, бераз шуклык булган, күрәсең. Берәүне бөтен класс алдында җәберләп көлкегә калдыруым хәтердә. Алгы бер теше төшкән кыз бар иде. Ләкин тешсезлеге белән түгел, үтә яхшы укучы һәм артык акыллы кыз булуы белән малайларның ачуын китерә иде. Химия дәресендә мөгаллим абзыебыз шул кызга сорау бирде:

— Әйтегез әле, Миһри, ачыткычның үзенчәлекләре нинди?

Миһри, каушамыйча, кабаланмыйча гына, кислородның үзенчәлекләрен санарга керește:

— Иссез, төссез...

Шунда тыела алмадым, «тешсез» дип өстәп куйдым. Бөтен класс көлеп җибәрде. Хәтта мөгаллим абзый үзе дә елмаймый түзә алмады. «Иссез, төссез, тешсез» — акыллы кызның кушаматы булып китте.



## 5

**Яңгыр килә. Әхтәм абзыйның кайгысы. Әби васыяте. Яшь тирәкләр. Стәрледә соңгы кышым. Хат-сәлам.**

Мин тагын Җиргәндә. Агай-эне исән. Бары да кочак җәеп каршы алырга торалар. Ачлык елны Оренбург ягына киткән Әбүбәкер абзыйлар да кайткан икән, шуларга тукталдым. Һәр вакыт ачык чырай күрсәтүче йомшак күңелле Маһигөлсем җиңгине әнием кебек якын күрә идем, шул тартты.

Менә без өйдә аның белән икәү генә калганбыз. Тыныч. Ерактан гына, йөрәккә ятышлы яхшы хәбәр китергән кебек, күк күкрәгәне ишетелеп-ишетелеп куя.

— Яңгыр килә.

— Бирсен ходай,—ди Маһигөлсем җиңги тыныч кына.

Табигать авазы күңелдә серле тойгылар уята. Туган авылыма кайтканымны ачыграк хис итәм. Әйтерсең шулай мәгънәле, өметле итеп, шул ук вакытта әзрәк моңлы да, әзрәк шомлы да итеп күк күкрәү бер безнең авылга гына хас мәһабәт күренеш! Ул минем бала чакларымны, әти-әни белән, инде дөньяда юк энеләрем-сеңелләрем белән, күптән суеп ашалган Турат, атып үтерелсә дә ачлык ел корбаны булган Билнак белән бәйле көннәремне исемә төшерә. Гаҗәеп көч бу табигать дигәнең! Хәзер бит инде мин кара авыл малае түгел. Яңгырларның, яшеннәрнең нәрсә икәнлеген беләм. Шулай да...

Юк, ярамый. Калада укып йөргән кешегә, инде комсомолга кергән егеткә килешми мондый хисләргә бирелү!..

Берни булмагандай, авыл хәлләрен сорашам. Әбүбәкер абзый быел да мөгез чыгармый калмаган, Ратат күле буена яшелчә бакчасы чәчкән—карбыз, кавын... Җиргән татарлары арасында гомердә булмаган эш. Бу яңалык күңелемә бик хуш килде, Ратат күле! Бакча булгач, әлбәттә, аның куышы да булмый калмас. Молодец, шәктазый!

Күк күкрәгән тавыш якындарак ишетелә башлады. Шабырдап яңгыр яварга тотынды. Җиңги тәрәзәләрне яба. Ярым пышылдап,ниләрдер укына, дога аралаш үз сүзләре дә ишетелеп кала.

— ...лә-хәүлә... хәере белән бир...

— Әллә куркасың инде, Маһигөлсем җиңги?

Дәшми. Һаман укына. Морҗаларын карый. Күкрәү якынайганнан-якыная, ешая һәм көчәя бара. Авылны баскан тоташ болыттан караңгыланып калган өй әче яктырып-яктырып китә. Дәһшәтле күкрәү авазларыннан чылтырап, тәрәзә пыялалары селкенә.

— Я раббым, ходаем, үзең сакла.

— Курыкма, күк күкрәүдә алланың бернинди катнашы юк.

— Көлмә, зинһар, Мирсәяф туганым.

Миңа кызык, белем күрсәтүемне дәвам итәм.

— Яшен яшьнәү дә шулай. Электр көче генә бит ул. Яңгыры белән җиле дә хода эше түгел...

Нәкъ шул минутта бөтен өйне күтәреп бәрә язып, яшен атып җибәрде.

— Чыгып кит, имансыз!..

Шундый ярсып кычкырып җибәрде җиңгием, атылып өйалдына чыкканымны сизми дә калдым. Аның бу кадәр ачуланган чагын гомеремдә күргәнем юк иде. Кара нинди хәтәр көч бар икән шул ягымлы, һәр вакыт сабыр, көләч чырайлы кеше йөрәгендә! Үземә дә бик уңайсыз булып китте. Шундый кешене нинди хәлгә китердем бит, җүләр. Менә сиңа кунак!

Ачык калган өйалды ишегеннән карап торам. Коеп яңгыр ява. Ул да миңа ачуланган шикелле, көчәйгәннән-көчәя барып, ярсып, шашып ява. Чү!.. Бозы да бар лабаса? Әйе, «телеңне тыя белмәсәң, мә өстәвенә» дигәндәй, яңгырга борчак-борчак боз кушылып ява башлады. Шунда ук, кулына йәмкә тотып, Маһигөлсем җиңги чыкты. Дәшми-тынмый гына йәмкәсен ишегалдына— боз катыш коеп яуган яңгыр астына ыргытып, кире кереп китте.

Бозны туктата, имеш! Бу миңа көлке. Ләкин дәшмәдем. Ансыз да ярактан җиңгиемне шулай каты рәнҗетүемә күңелем борчылып тора. Өстәвенә, боз! Мин алып кайткан афәт булып күренә бит ул.

Аллага шөкер!—дип куйдым, үзем дә сизмәстән: афәткә әйләнә алмый калды шикелле. Йәмкә ташлагач, бер минут та үтмәгәндер, җирдә ак борчаклар сикерешүдән туктады. Ышандырып кара син хәзер җиңгине боз яуганда тимер ыргыту ырымының мәгънәсе юк дип!

Яхшы сабак булды. Яңадан бу турыда авыз ачмадым. Әхтәм абзый белән Хәпәзә әби янында да үземне бик тыйнак тоттым. Әхтәм абзый исә хәзер миңа караганда да тыйнаграк булып чыкты. Мине ул үз янында зуррак, акыллырак кешегә саный, нәрсәдәндер беркадәр уңайсызлана, тартына да кебек иде. Ни булган аңа? Кем дип белә соң ул мине? Әллә турыдан-туры үзенә кайтып төшмәгәнгә үпкәләп, шулай кыланамы?

— Карале, Мирсәяф,—диде ул, ниһаять, гаепле кеше тавышы белән,—ни бит... ә-ә.. белеп әйтәләрме, әллә юкны...

— Нәрсә бар, Әхтәм абзый?

— Син, укып кайткач, Әхтәм абзыйдан түләтәм әле, дип әйтәсең икән ди. Әйе, болай ансат кына котыла алмас, дип әйтәсең икән ди.

— Ни сөйлисең син, Әхтәм абзый? Нәрсәне түләтим ди мин синнән?

— Теге вакытта өеңне сатканга рәнҗисең, имеш, ди. Барыбер түләтәм дип әйтәсең икән ди.

Менә нәрсәдән уңайсызланып, борчылып йөри, имеш! Беркатлылыгын белеп, берәрсе юри шаярткан, күрәсең. Ихтыярсыз көлеп җибәрдем.

— Кит аннан, Әхтәм абзый, андый уйның, ичмасам, күңелемә кереп чыкканы да юк. Нигә миңа ул өй?

— Чынлап та, рәнҗеп йөрмисеңме?

— Што син! Рәхмәттән башка сүзем юк сиңа. Берәрсе шаярткандыр.

Әхтәм абзыйның йөзе яктырып китте.

— Алай димә. Укып бетер дә, кайт үземә. Менә дигән итеп, кәләш алып бирермен. Өен дә рәтләрбез, бүтәнен дә.

Хәпәзә әби берни ишетми, шулай да нининдидер җитди мәсьәлә турында сүз барганын сизенә иде, күрәсең, башта эндәшми генә утырды. Әхтәм абзыйның йөзе яктырып киткәнен күргәч, теле ачылды.

— Тәүфикълы гына йөре, улым. Олылар сүзен аяк астына салма. Үзеңнән көчсезләрне рәнҗетмә. Тәмәке тартма. Кяфер булма!..

Әбинең сабаклары тәэсир итте, ахрысы, Әхмәтша абзый янына хәтта башыма түбәтәй киеп бардым. Аның суфи күңеленә бу бик хуш килде. Безнең йорт урыны хәзер аларның бәрәңге бакчасы булып калган икән, шуны күрсәтте. Анда, башлары киселеп, яшәреп киткән бөдрә таллардан башка, бездән калган берни дә юк иде инде. Хәер, мәчет урнашкан җир белән безнең ишегалды урынын аерып торган читән буе-

на тезеп утыртылган яшь тирәкләр дә исән, алар бер ел эчендә бик нык сизелерлек дәрәҗәдә зурайганнар һәм, бу йортка берни булмагандай, шаулап, гөрләп үсеп баралар иде.

— Мәсәлимнең төсе итеп саклыйм, — диде Әхмәтша абзый. — Ул утыртып калдырган булырга тиеш.

Аларны мин утырткан идем. Анысын Әхмәтша абзыйга әйтеп тормадым. Әйдә, этинең төсе итеп сакласын. Бигрәк әйбәт...

Авылда озак юанмадым, тизрәк Ратат күле буена ашыктым. Яшелчә бакчасы, чынлап та, минем өчен бик әйбәт булып чыкты. Бердән, җүләр малай чакта гыйшык-мыйшык уйнап, хат язышып йөргән кызлар белән очрашу «кайгысыннан» котылдым. Икенчедән, абзыйлар өчен дә бушка җылы сөт эчеп ятучы әрәм тамак кына түгел, гаептән ингән бакча каравылчысы, өченчедән, минем өчен шуннан да шәп ял урынын кайдан эзләп табасың? Һавасы, күле-суы! Күңелләргә рәхәт биреп кошлар сайравыннан башка, бернинди шау-шу! Җил-яңгыр дисәң! Әкияттәге кебек гүзәл, серле куыш эчендә аларны тыңлап яту үзе бер рәхәт. Әх, карбыз-кавыны да өлгереп җиткән чак булса! Хәер, анысына артык исем китмәде. Хәтта аларның әле өлгермәгән булуы тынычрак та: усалрак караклар кызыгыр нәрсә юк. Минем өчен кыяры да бик җиткән иде.

Әбүбәкер абзыйның улы Рөстәм һәм Хәпәзә әбинең кече кызыннан ятим калган оныгы Камил белән бергә бакча караулап уздырган ул көннәр минем өчен чын мәгънәсендә күңел ачу, иң матур ял булды. Шулай да яшь чакта, нинди генә гүзәл шартларда булмасын, тынлык тиз туйдыра. Стәрлетамакта калган сабакташ иптәшләрем, алар белән бергә кайнашкан колония көннәре сагындырды, укулар башланыр вакыт җиткәнне дә көтмәстән, китеп бардым.

Яңа уку елы башланганда өлкән класс укучылары булып без калдык: Ибәтләр, Фәрдәнәләр, Нажияләр, Хөсниләр, Солтаннар, Рахманнар, Кәримнәр...

Төп көч укуга киткәндер. Кулъязма журнал һәм стена газетасы чыгаруларга, спектакльләргә һәм әдәби кичәләргә, спорт һәм уеннарга да аз вакыт бирелмәгәндер. Әмма ул кышта иң нык күңелемдә калганы — Хәмит Усманов белән хат язышу булды.

Ул Уфадагы фармацевтлар техникумына укырга кергән иде. Күрәсең, шәһәр күләмендәге әдәби оешмаларга, редакция тирәләренә барып йөри торган булгандыр, каләм әһелләре, матбугат тирәсендәге хәлләр турында язарга ярата торган иде. Шуның өстенә тагы ул минем хатларымны гади сәлам-хат сыйфатында гына түгел, үзенә күрә әдәби әсәр итеп тә карый, аларның һәркайсы турында диярлек үз фикерен язып җибәрә иде. Моны белеп, мин дә аңа җибәрә торган хатларымны мөмкин кадәр кызыклы итеп, традицион хатларга охшамаган итеп язарга тырышам. Хәмитнең үзенә генә түгел, хат аша танышып, аның белән бергә укучы иптәшләренә дә язам. Күрәсең, язасы килү теләгемне шул хатлар белән басып торганмындыр, күп яза идем. Ләкин бары бер хатым гына шактый ачык хәтеремдә. Зур бер табак кәгазьне дүрт битле газета итеп яздым. Иң башта — газетаның исеме: «Сәлам». Һәр газетада була торганча, елы, ае, көне, числосы, органы. Гадәттә газетаның ничә көнгә бер чыгуы күрсәтелә торган урында — «сагынганда бер чыга» дип куелган. Баш мәкалә урынында зур хәрефләрдән: «Хәмит дус!» дигән эндәш сүз. Аннары ике күз рәсеме. Шул күзләрдән агып чыккан ике елга бергә кушылып, зур күл тәшкил иткән. Күл өстендә аккошлар, көймәләр, хәтта пароходлар йөзеп йөри. Рәсем астына: «Бу минем сине сагынып түккән күз яшьләрем», дигән сүзләр язылган. Аннан соң инде, шул чордагы өлкә газеталарына охшатып, төрле бүлек-

лəр, рубрикалар астында торакта, мəктəп дөньясында, шəһəр күләмендә булган хәбәрләр, яңалыклар турында аерым-аерым мәкаләләр, фельетоннар. Әлбәттә, шигырь һәм карикатуралар да бар. Төрлесенә төрле имза куелган, ләкин барысының да авторы — үзем. Дүртенче битнең соңгы баганасы астында: мөхәррире — М. Әмиров. Аннан да аста — газетаның адресы һәм тиражы: 00000001 данә.

Гарәп хәрефләре белән язылган шул шаян хат-газета, көтелмәгән берәр могҗизага бинаән кайдадыр сакланган булып, бүген миңа аны күрергә туры килсә? Ихтимал, мин хәзер тасвирлаганга туры килеп бетмәгән урыннары да табылыр иде. Мәгәр шул чордагы тормышымны, мөхитымны хәтеремдә яңарту өчен искиткеч бер документ булыр иде ул.

Андый могҗиза булмас шул инде. Мин Башкортстаннан киткәч, Хәмит белән хат язышуыбыз сирәкләнә башлады. Ниһаять, бөтенләй өзелде. Ул, күрәсең, әдәбият-матбугат дөньясында мин фараз иткән дәрәҗәдә үк күренекле кеше булып китә алмады. Утызынчы елларда аның матбугат эшенә күчүе турында ишетсәм дә, бер-ике мәкаләсен искә алмаганда, язганнарын укырга туры килмәде. Ихтимал, үзендә булган эчке мөмкинлекләрен гамәлгә ашырырга өлгермәгәндер: соңыннан мин аның Ватан сугышында вафат булуы турында ишеттем.

## Авыргазы

### I

**Спорт өянәге. «Җир уллары». Тимер юл инженеры. Декламация. Агу гына микән? «Хәзер туктыйм...»**

Стәрлетамак мәктәбен тәмамлагач, 1925 нче елның җәендә мин Яңа Карамалы дигән авылга килдем. Бу вакытта инде Мәрьям апа шушы авыл кешесенә тормышка чыгып, шунда төпләнеп калган, авыл мәктәбендә укытучы булып эшли иде.

Башта мин үземне монда бик азга гына килгән вакытлы кунак сыйфатында хис иттем. Ниятем нинди дә булса берәр курс яки техникумга китеп, укуымны дәвам иттерү иде. Стәрлетамактан соң миңа Карамалы бик фәкыйрь күренде. Җиргән белән чагыштырганда да күп кайтыш иде. Кешеләре белән танышырга да ашыкмадым. Җизнинең пләмәннике — яшьтәшем Хөснулла бар иде. Мәрьям апа янына килеп йөрүче укытучы кыз Гайшә Дибердиева һәм аның миңа Стәрледән үк таныш булган сеңлесе Мәргуб — шулар житте. Өстәвенә, мин торган өйдән ерак түгел авыл читенә чыгарып салынган зур мәктәп янына допризывниклар өчен спорт мәйданы ясап куйганнар. Бауга асылган боҗралармы, турникмы, баскычмы, төрле озынлыктагы кузлалармы — бары да бар. Хәтта ни өчендер мәйдан уртасына төрле биеклектә такта коймалар да куелган...

Их, яшь чак! Кая барма, шунда, кочагын җәеп, бәхет көтеп тора сине! Мин килүгә махсус хәзерләп куелган бүләк бит болар барысы да!

Атна буе диярлек рәхәтләндем бер үзем. Допризывниклар килгәч, миңа көн бетәр дип, куркыбрак йөргән идем дә, юкка борчылганмын икән. Мәйдан тирәсендә алар көненә бер-ике сәгатьтән дә артык булмаганнардыр. Үзләре бер вакытта да мине күпсенмәделәр. Бары да диярлек төрле авыллардан җыелган яшьләр, авыр әйберләр күтәрүдә яки көрәшүдә ат көченә ия булсалар да, турникта әйләнү, боҗралар белән уйнау, төрле биеклектәге кузлалар аша сикерү кебек эшләрдә

тәҗрибәсезләр, аларны шаккатыру өчен күп кирәкми иде. Шулай да командирлары минем эше генә спортсмен түгел икән, турникта мин ни гомер азапланып та өйрәнә алмаган скобканы бик җиңел башкара. Кузлалар аша сикерүдә дә мин генә түгел. Шулар өстенә тагын ул әлеге минем өчен табышмак булган коймаларның да серен ачып бирде. Алар булачак кызылармеецларны төрле читен киртәләр каршында тукталып калмаска өйрәтү өчен куелган икән. Сере шул: йөгереп килгән уңайга, тукталып калмастан, аларны аркылы чыгарга да, ары йөгерергә кирәк... Бернинди катлаулы яки четерекле хәрәкәтләр соралмый. Иң кыены — кулың белән өске кырыеннан эләктереп алу. Аннары, читән аша сикергән эт кебек, тырышып-тырмашып, койманың өстенә үрмәлисең дә, аръягына сикерәсең.

Беренче койма аша һәркем диярлек чыга ала. Икенчесе авыррак. Монда инде, койманың өске кырыена асылыну өчен, шактый биек сикерергә кирәк. Кечерәк буйлы яки авыррак гәүдәле егетләр өчен җиңел түгел. Ә менә өченче койма! Куян җиңеллегең булса да, сикереп кенә өске кырыена буең җитәсе түгел. Хәтта командир аңлатып биргәч тә бу эшнең мөмкин икәнлегенә ышанасы килми. Имеш, җан-фарман йөгереп киләсе дә, иң элек аягың белән коймага басасы, шуннан инерция көче белән гәүдәңне югары ыргытып, койма башын эләктереп аласы?.. Ничек инде ул вертикаль торган коймага аягың белән басасы ди?

— Менә болай! — дип, командир үзе сикереп күрсәткәч, шигем калмады. Чынлап та була икән бит. Басу дигәне просто тибү икән.

Ләкин аныңча эшләргә тырышып караучылар берсе дә булдыра алмады. Кайсы күкрәге белән коймага бәрелеп егылып төшә, кайберләре аякларын авырттырып, читкә таба аксаклый.

Командир тагын бер тапкыр ыргып күрсәткәч, минем дә аяк-кулларым бик кычыткан иде дә, түздем. Кеше алдында оятка каласым килмәде. Кич кырын, аулаклап, ялгызым гына сынап карарга карештем. Барып чыга бит! Бәрелсәм бәрелдем, сугылсам сугылдым — иң биек дигәнен дә ике тапкыр аркылдым. Икенче көнне мин тагы шунда. Допризывниклар әле юк. Мәктәп болдырында гадәттәге тамашачыларым бар. Мәрьям апа да, ахирәте Гайшә дә шунда. Тагы кемнәрдер...

Иң элек куллар белән генә асылынып, биек, текә баскычның иң югарыгы басмасына кадәр менеп төштем. Аннары турникта бер-ике әйләндем. Болары минем өчен чүп тә түгел, буын язу гына. Иң әһәмиятлесе — хәзер койма аркылы сикереп күрсәтү. Унбиш-егерме адым чамасы читкәрәк китеп, иң биек дигәне каршына килеп бастым. Кулларны югары күтәреп, берничә тапкыр тирән сулыш алдым. Аннары бар көчемә тырышып, коймага таба атладым. Җан-фарман килгән уңайдан, темпны әз генә дә йомшартмыйча, уң аягымны мөмкин кадәр югарырак күтәреп, коймага терәдем...

Әллә ни булды шунда аягыма. Сындымы, берәр тамыры өзелдеме, үзем дә аңламастан, койма буена егылдым. Карыйм: аягым бизгәк тоткан кебек калтырап ята. Каны качкан. Селкетеп карарга да көчем җитми. Авыртуына адәм чыдый торган гына түгел... Мәктәп ягыннан чырык-чырык көлгән тавышлар ишетелә. Гадәттә, кеше алдында уңайсыз хәлдә калуыңны, башкаларга кушылып, үзеңнән-үзең көлгән булу белән яшерәсең. Ә бүген! Кайда ул! Оялырлык та, гарьләнерлек тә хәлем юк. Бөтен тәнем дер-дер калтырый. Күңелемдә коточыргыч ямьсез уйлар. Бөтенләй аяксыз калуым микәнни? Гомер буена аксап йөрергә туры килер микәнни?..

Болдыр ягында көлү авазлары басылды. Бераздан янымда гына Мәрьям апаның куркынган тавышы ишетелде.

— Абау! Бөтенләй төсе качкан моның! Ни булды? Нишләдең?..

— Аяксыз калдым...

Күтәреп, өйгә алып кайтып салдылар.

Ахрысы, берәр тамырым тартылган булып чыкты, атна буена урамга чыга алмадым. Җизнәм — партиянең волость комитеты секретаре Нури Әминов — көне-төне диярлек эштә, я командировкада. Мәрьям апа да, җәй булуга карамастан, мәктәптән, ликбез эшләреннән бушамый. Өйдә берүзем. Нишләргә белмим. Такташ шигырьләре белән җенләнеп ятам. Ул көннәрдә мин аның «Җир уллары» китабын иман шарты урынына янымда йөртә идем. Бетмәс серләр белән тулы Кабил фаҗигасен, «Онытылган ант», «Таң кызы», «Үтерелгән пәйгамбәр» шигырьләрен җенләнә-җенләнә кычкырып уку белән генә канәгатьләнмичә, алардан рухланып, рәсемнәр ясый башладым. Янар таулар, утлы еланнар, шомлы урманнар, дәһшәтле тау-ташлар, арыслан-юлбарыслар арасында йөрүче ялангач кешеләр төшерелгән акварельләр белән бөтен стена тулды.

Шулар белән җәйге ял вакытым узып та китте. Азаплана-азаплана аягыма баса башлаганда, Стәрлетамакка китәргә вакыт җиткән иде инде. Берәр уку йортына разверстка юлларга кирәк иде.

Илле чакрым араны җәяүләп узу әле җүнләп савыгып та җитмәгән аякка авырга туры килде. Стәрлетамакка килеп җиткәндә бөтенләй басып торырлык та хәлем калмаган иде. Таныш интернат торагында иске дуслар белән сөйләшеп бер кич кунгач, рәтләндем. Кантон мәгариф бүлегендә миңа Уфада ачылган тимер юлчылар мәктәбенә разверстка биреп чыгардылар.

Тимер юлның нәрсә икәнен үз күзләрем белән күреп белгәнем юк иде әле. Нindирәк булыр икән соң ул мин барырга тиешле мәктәп?

— Тимер юл инженеры булып чыгарсың,— дип тынычландырды кемдер.

— Тимер юл инженеры!

Инженер ул вакытта безнең өчен буй җитмәс дәрәҗәдә зур исем булып күренә, укымышлы кешеләрнең дә иң алдынгысы, иң мәдәние, иң бае санала иде. Түбәм күккә тиде инде. Ләкин куанычымны кешегә әйтергә ашыкмадым. Я барып чыкмас.

Бер килгәндә таныш-белеш, дус-ишләрне дә күреп кайтыйм дип, киттем клубка.

Килсәм, дежурныйдан башка беркем юк. Бары да Хезмәт сараенда, ди. Анда бүген зур кичә, имеш. Киттем шунда.

Стәрлетамак өчен шактый зур ике катлы таш йортның урамга караган ишек тирәсе тулы халык. Кысыла-кысыла эчкә уздым. Икенче катка күтәрелдем. Шыгрым тулы кеше арасыннан көч-хәл белән юл ярып, тамаша залы ишегенә якынлаштым. Ишек янында шау-шу, кычкырыш. Һәркемнең эчкә узасы килә. Берәүне дә кертмиләр. Ишек янында торучы егетнең ачуы чигенә җиткән, бар көченә кычкыра:

— Кая тыкшынасың, мөгезсез сыер! Ярамый диләр ич сиңа!

Тавышыннан да бигрәк, гайрәт чәчүеннән таныдым: Мөкаддәс икән. Үрнәкне минем белән бергә бетереп чыккан малай. Буйга кечкенә булса да, үзен җәберләтә торганнардан түгел, бик тере егет. Талант ягы чишмә кебек бәреп тора дип үк булмый, әмма белмәгән һөнәре юк. Мандолинада уйный. Чүгәләп-чүгәләп бии. Рәсем ясарга да ярата. Шигырь язып та ат чыгарып чамасы бар кебек. Тик ул чакта бездә ерактагы зур шагыйрьләрнең, Тукай, Такташларның, Бабич, Сәгыйть Рәмиев кебекләрнең талантына баш ия белү булса да, мәктәпнең үз эчендәге шигырь язучыларга әйтерлек хөрмәт юк, алардан бары көлү генә гадәткә кергән иде. Мөкаддәстән дә көлеп йөрдек. Бервакытны аның үзебездә укучы матур гына кызга гыйшык тотуы беленде. Кем кызына диген? Ул чорда (ягъни НЭПның чәчәк аткан заманында) шәһәрдә бер диган сәүдәгәр кызына. Менә сиңа ярлы эшче гаиләсендә туып үскән чирләшкә Мөкаддәс! Кемдер аның шул кызга багышлап язган

шигырен бөтен торакка фаш итте. Эчтәлеге тулы килеш хәтердә сакланмаган, ләкин мәгәр беренче юллары истә:

Әй, Стәрле кала, сәхра-дала!
Күгәреп күккә ашкан йөрәк-тау!



Аның бу юлларыннан без рәхәтләнеп көлдек. Янәсе сәхра-дала булгач, анда таулар буламыни? Яки күккә ашкан таулар үсеп утыргач, ул нинди дала булсын?

Хәзер килеп, ягъни ярты гасыр вакыт үткәч, уйга калдым. Шушыңа охшашлы җыр «Казан утлары»ның җитмеш алтынчы елгы өченче санында Стәрлетамакта нәшер ителгән китаплар турындагы мәкаләгә эпиграф буларак басылып чыкты. Мәкаләнең авторы Иосыф Гәрәй аны халык җыры дип куйган. Стәрлетамакта булып, минем андый җырны ишеткәнем юк иде. «Әллә Мөкаддәс үзенең шигырен халык җырыннан файдаланып язган иде микән?» — дигән уй килде башыма. «Әллә югыйсә исеме укучыга мәгълүм булмаган яшь авторның шигыре шулай халык җыры булып китте микән?» Стиле дә бик үк халык җырларындагыча түгел сыман. Белмәссең!

Кемнеке булса да булгандыр, әмма бүген бу җыр яшьлек юлдашларымның берсе булган Мөкаддәсне күз алдыма китерде. Әнә ул, янып, ярсып, тамаша залына бәреп керергә азапланучы тәртипсез төркем белән кычкырыша. Аны читтән күзәтеп тору миңа кызык. Кара, нинди усалланган! Бер дә тартынып тормый. Кайсын кычкырып ишектән кире бора, кайбер әрсезрәкләрен төртеп үк җибәрә. Миңа, әлбәттә, сүз әйтмәс, күрсә, чакырып үк алырга тиеш. Якынрак барырга кирәк, күзенә чалынырга.

Тырышып-тырмашып, якынрак бардым. Күз алдында диярлек торам. Күрми. Андагы мәхшәрдән башы әйләнгән булса кирәк. Хәер, күреп таный алмый торса да гаҗәп түгел, беләм, юкка гына күзлек киеп йөрми бит ул. Өстәвенә бүлмәсе дә караңгылы-яктылы... Аның чакырып алганын көтеп торсаң!.. Терсәкләрем белән юл ерып, янына ук килеп җиттем. Юри эндәшми генә ишеккә тыгылам. Танымый.

— Кая тыкшынасың?!.

— Мин авылдан килгән кеше!

Тәмам мие тонган икән. Тавышымнан да танымый.

— Авылдан килгән кеше күп булыр монда! — дип кычкыра. — Әйдә, бор кире тәртәңне!

Миңа тагын да кызыграк булып китте. Үземне танытырга ашыкмыйм, юри әрләшәм.

— Авылдан килгән яшьләргә сез шулай карыйсызмыни? Авылга йөз белән дип кычкыруыгыз шулмыни сезнең?!

Әз генә йомшара төшкәндәй булды. Шулай да бирешергә исәбе юк.

— Урын юк дигәнне аңлыйсыңмы син, мужик?!

Ә минем тавыш күтәрелә бара.

— Мужик?! Мена сез нинди икән! Бәлкем мин елга бер калага килгәнмендер? Иртәгә кире китәмдер? Бер генә кич булса да, концерт күреп китәсем киләдер? Мужик әпәен ашаганыгызны да онытмагыз!

— Өркетмә! Синең кебек кенә демагогларны күргән!..

Уенны артык дәвам иттерәсем килмәде, үпкәләгән булып кына, исеме белән дәштем.

— Ай-я-а-ай, Мөкаддәс! Сине бу тикле бюрократ дип белми идем.

Ниһаять, танып алды.

— Синмени әле бу? — диде. — Нәрсә баш катырып торасың! — тавышы һаман ачулы. — Кер тизрәк. Нигә соңга калдың? Син бит кичәдә катнашучы, бар йөгер сәхнәгә!..

Зирәклеген кара! Башкалар бәйләнмәсен өчен, ничек тиз хәйләсен тапты. Куанычыма каршы, аның бу хәйләсе шунда ук чынга да әйлә-

неп китте. Күзләрне чагылдырырлык итеп яктыртылган тамаша залында, чынлап та, бер генә буш урын да күренми иде. Сулга борылып, алгы рәтләргә таба атлавыма Дәминевне күреп алдым. Шунда ук тагын бер-ике таныш килеп кушылды.

— Әһә! — диләр. — Килеп чыгуың бик шәп. Давай, син дә берәр декламация сөйләп кит әле!

— Нигә сөйләмәскә, — мин әйтәм. — Бик рәхәтләнеп!

Такташ, Кави Нәҗми шигырьләре белән җенләнеп йөргән чагым иде, канатланып киттем. Яттан белгән шигырьләрне күңелдән барларга керештем.

Ниһаять, көткән минутлар килеп җитте. Чыктым сәхнәгә. Зур зал шыгрым тулы. Тик анда кемнәр утырганын күрү кыен: түшәм уртасында гөжләп янган газ лампасыннан сибелгән көчле яктылык көн уртасындагы җәйге кояш кебек күзләрне чагылдыра.

Хәзер туктыйм...

К. Нәҗминең «Тормыш төбендә» дигән шигырен шулай, «Ертык күңелләр, исерек хәерчеләр» турындагы юлларын калдырып, урта бер җиреннән башлап китәм:

Хәзер туктыйм...
Тагын бик аз гына
Серләр ачсам,
Бәлки тузәрсең,
Мин сөйләгән авыр серләр рәтен
Кайчан булса син дә тезәрсең...
Төрмә тәрәзәсен ватып качкач...

Дәртләнеп сөйләп чыктым. Шаулатып кул чаптылар. Ул кичне миннән дә бәхетле кеше булды микән? Кесәдә инженерлыкка юл ачкан документ! Бөтен Стәрлетамак тамашачысын шаулаткан декламатор! Кичәдән соң интернат торагындагы таныш, сагынылган малайлар, таныш кызлар белән көлешә-көлешә таң аттыру...

Иртәгесен миңа Карамалыга кайтып китәргә кирәк иде. Илле чакрым араны җәяү үтүнең нәрсә икәнен беләм. Берәр олаучы юлдаш тапмый ярамас. Базарга юнәлдем. Кәлчергә кайтырга җыенучы бер авыл кешесе очрады.

— Карамалыга сугылып үтәргә буламы?

— Нигә булмасын.

Документлар кесәдә, башка бернием юк. Күп сөйләшеп тормадык.

— Әйдә!..

Стәрлетамак — Уфа юлы өстендә Сахановка дигән бер авыл бар. Софиполь дип тә йөртәләр. Ул елларда бу авылны белмәгән юлчы сирәк булгандыр: самогон белән даны чыккан иде. Тыныч кына узып барган җирдән атыбыз бер капкага борылды.

— Ни булды, Габделхак абзый, кая борыласың?

— Ат бит! Үзе беләдер, күрәсең. Әз генә ял иттереп алырга кирәктер инде. Үзебезгә дә тамак ялгау начар булмас.

— Нинди тамак ялгау? Талбазы менә генә ич инде.

— Алай димә, энем. Талбазыдан соң сине Карамалыга кертеп чыгасы бар.

— Булса ни, борылып кына керәсе.

— Йончыган ат белән авылга кайтып керү күңелсез ул, чаптырып керерлек булсын! Тырр!..

«Рәхим итегез!» дигәндәй, капкасы алдан ук ачып куелган ишегалдына кереп тә тукталдык. Олаучым туармыйча гына атын солыга куштты да, өйгә уздык. Шыксыз зур бүлмә. Балта белән генә юнып ясалган диярлек ялангач өстәл. Шундый ук агачтан этмәләнгән озын эскәмия.

Аталарына охшаган балалар шикелле берничә рәтсез урындык. Башка бернинди җиһаз юк.

Габделхак абзый ипи капчыгын чишүгә, хуҗа хатын өстәлгә бер шешә болганчык су китереп утыртты. «Су» сиңа! Самогон, әлбәттә. Менә нәрсә икән олаучының «тамак ялгау» дигәне. Үзе бу турыда берни белмәгән кеше булып кылана.

— Бусы ни булды тагы? — дигән була. — Арыш мае микәнни? Ярар. Сыйлаганда су эч диләр. Аштан олы булып булмас инде...

Ул, шулай сөйләнә-сөйләнә, ике стаканны тутырып та куйды.

— Әйдә, берәрне тотыйк...

Тәмсез иде самогон. Шулай да беренче стаканны эчкәндә түзәрлек иде әле. Әмма икенчесен...

Кызык бу адәм баласы дигәнең! «Көлле хәмрен хәрамәйн» дип, әллә кайчаннан бирле шәригать кычкырып тора. Исерткечнең зарарлы булуы турында бөтен дөньяның акыллы кешеләре әйтеп килә. Якыннарың, хөрмәт иткән абзыйларың-апаларың сүз җае чыккан саен колагыңа шуны тукый. Ата-аналарың, әби-бабаларың васыять итеп калдыра: эчмә, эчмә, эчмә!.. Кесәңдәге һәр документның кисәтеп тора: ярамый сиңа, хакың юк! Чынлап та, зарарлы икәнен — аның кешене никадәр ямьсезләндерүен, адәмнәргә никадәр бәхетсезлекләр, афәтләр, бәлаләр китерүен үзең күреп торасың. Шуларның һәммәсе өстенә тагын аның тәмсезлеге!.. Дөрес, өйрәнә-өйрәнә аны кеше чагыштырмача җиңел йотарга гадәтләнә. Ләкин аның тәмен яратып эчүче (хәтта бал-шикәрләр, төрле ширбәтләр белән татлыландырылган төрләрен дә), аны капкач чыраен сытмаучы кеше бар микән?

Еллар үтеп, инде исемнәре матбугатта чыккан кешеләр белән аралаша башлагач, миңа үз күзләрем белән шундый берәүне күрергә туры килде: бер йотым да эчә алмый, хәмергә аның бөтен организмы каршы. Үтереп көчләгән кеше дә юк аны. Ләкин ул табигатьнең шундый изге самимилеген үзе өчен кимчелек күрә, бәхетсезлек саный. Һәм бөтен ихтыяр көчен җигеп, үзенең исерткеч эчә алмау «кимчелегенә» каршы көрәшә. Иптәшләре күтәргән вакытта рюмканы кулына ала, күзләрен чытырдатып йомган, борынын җыерган хәлдә авызына китерә. Ниһаять, янып торган утка кергән кеше тәвәккәллеге белән эчеп җибәрә һәм шунда ук, ике кулы белән авызын каплап, йөгереп чыгып китә. Туалетка барып җиткәнче түзсә түзә, түзә алмаса, йөгереп барышлый шунда идәнгә үк җибәрә. Шуны һәр тост саен кабатлый. Нәрсә өчен? Нинди максаттан чыгып, адәм баласы шул тыелган агуга тартыла? Агу гына микән ул?.. Бу каршылыкның серен шушы көнгә кадәр миңа бернинди закон да, бернинди фән иясе дә ышандырырлык итеп аңлатып бирә алганы юк әле.

Беренче стаканны эчкәч, олаучы агай ах-ух килде, ипи иснәде, аны бәләкәй генә итеп кабып та куйды. Һәм шунда ук стаканнарны яңадан тутыра башлады.

— Миңа салма, Габделхак абзый.

— Буш тормасын дип кенә салуым. Может эчеп тә куярсың әле...

— Юк, Габделхак абзый, күрәсем дә килми.

Чынлап та, бер стакан эчкәннән соң, икенчесен күрәсем дә килми иде. Бөтен вөҗүдем, кальбем котырып каршы тора. Ашказаным, үнәчем үзләренә йозак салганнар. Кирәкми, кирәкми, якын китермә! дип кычкыралар кебек. Тамагым, авызымдагы төкерек бизләрем карыша: кирәкми, якын китермә... Нинди кара көч җиңде шунда? Юк, олаучы агайның кыставы гына түгелдер дип беләм. Аңлы рәвештә үлемгә барган тәвәккәллек белән, бөтен вөҗүдемнең каршы килүен җиңеп, икенче стаканны да эчтем...

Бер минут та үтмәгәндер, хәмергә каршы котырып баш күтәргән барлык изге хисләрем миңа үпкәләгән кебек булды. Гүя байкот бирде-

лəр миңа: теләсәң нишлә инде, алайса, дип, кул селтәделәр дә, берни дәшмәс булдылар. Өченче стаканны бернинди каршылыксыз, нәкъ су эчкән кебек җиңел эчтем. Ура-а! Җиңдем, хәзер миңа самогон да, су да бер! Сал, Габделхак абзый!..

Шуннан соңгысын белмим.

Уянып киттем. Ниндидер тар, кечкенә бүлмәдә ятам. Бүлмә дә түгел, чолан. Яткан урыным карават дисәң, карават түгел, сәке дисәң, сәке, ниндидер тупас такталар белән йомры киртәләрдән әтмәләнгән эскәмия кебек нәрсә. Аяк очымда — су кисмәге. Баш астыма мендәр урынына ниндидер кием салынган. Каршы яктагы стена буена көрәк, себерке, балта кебек кораллар сөялгән... Кайда соң мин?

Торып утырдым, башым әйләнеп, күңелем уйнап китте. Кире яттым. Нәрсә бу? Кая китереп салганнар мине?.. Баш очымда кечкенә гәүдәле бер хатын пәйда булды.

— Нихәл, уяндыңмы?

— Миңнежамал апа?

— Әү?

— Син нишләп монда?

— Кайда булыйм соң, үз өебездә булмыйча?

Әһә! Җизни йортының ишек катындагы кечкенә чоланда ятам, имеш. Гомердә кеше ята торган урын түгел. Шуңа күрә ул миңа бөтенләй ят булып күренгән икән. Миңнежамал апа — җизнинең апасы. Кешегә изгелек эшләүдән башка берни белми торган тол җиңгә.

— Аллага шөкер әле, болай булгач,— ди ул миңа.— Үзебезнең өйгә кайтып яткач, бик шөкер. Югыйсә алла сакласын...

— Ничек кайттым соң монда, кайчан?

— Кичә кичкә таба, Кәлчер кешесе китереп китте.

Алай икән. Софиполь авылында ничек итеп өченче стаканны эчкәнем, самогонны су урынына эчә алам хәзер, дип мактанганым, куанганым исемә төште. Шуннан соңгысы...

Әкрен генә тордым. Баш әйләнүне, күңел уйнауны җиңеп, аяк өсте бастым. Сизәм, чалбарым төшеп бара. Күтәреп, тыгызлабрак бәйлим дисәм, каешым юк.

— Кайда соң минем каеш?

Нәкъ шул минутта тыш яктан җизни килеп керде.

— Нәрсә, герой? — ди. — Каеш юкмыни?

Ни әйтергә белмим. Күтәрелеп карарлык та көчем юк. Әйе, ул минутта минем әнә шул төшеп барган чалбарымны тотып торудан башкага житәрлек көчем юк иде.

— Ә-әнә теге читән буена барып кара әле, — диде җизни, — шунда калмаганмы икән?..

Каешым, чынлап та, шунда — ишегалды артындагы бәрәңге бакчасының читәне буенда калган булып чыкты. Кайчан барганмын мин анда? Ничек бара алганмын? Җизни үзе алып барды микәнни?..

Каешны бугач, чалбар кесәмә тыгылдым. Бөтен тәнем буенча ниндидер ямьсез сизенү, куркыну тойгысы йөгереп узды.

— Кәлчер кешесе кайда?

— Өендәдер. Исән-сау кайтып житкән булса.

— Хәзер Кәлчергә китәм. Документларым аның арбасында калган...

— Әйе, документ югалту уен түгел.

Җизни шулай диде дә өйгә кереп китте. Мин капкага юнәлдем. Урамга чыгып берничә адым үтүгә, артымнан Миңнежамал апа килеп житте.

— Кәлчергә барып йөремә, туганкаем, дукамитларың апаңда. Әйтмәскә кушкан иде дә инде...

Эчкә бераз җылы керде.

Мәрьям апа белән җизнинең ачулары бераз сүрелгәч, минем дә унайсызлануларым кими төшкәч, ничек кайтып керүемне сөйләп бирделәр.

Җан-фәрман чапкан арба өстендә, нишләгәнемне белми сикергәләп, урам буенча акырып килгәнмен.

— Үзеңчә, җырлавың булгандыр инде, — ди Мәрьям апа ачы мыскыл белән. — Адәм аңларлык түгел.

Арбадан төшкәч тә егылганмын. Үзем, шуны бик кызык эш күреп, тыела алмый көләм икән. Күрше-тирә җыела башлаганчы, тизрәк өйгә алып кергәннәр. Өйгә керү белән, кесәмнән документларымны тартып чыгарганмын да:

— Абзагыэ хәзер железнодорожный инженер! — дип кычкырганмын, һәм, — менә ул! — дип, документларымны идәнгә сибеп җибәргәнмен. Үзем көләм, үзем җыен тузга язмаганны сөйлим икән.

Иң кызыгы дип әйтимме, дөресрәге, апа белән җизнине чын-чынлап борчуга салганы шул булган: тегеләр миңа: «Җитте, күп сөйләнмә, тукта», — дисәләр, мин аларга: «Хәзер туктыйм», — дип җавап бирәм дә, шунда ук ниндидер серле-шомлы тавыш белән: «Тагын бик аз гына серләр ачсам, бәлки түзәрсез!» — дип, коточкыч нәрсәләр сөйләп китәм икән. Төрмә тәрәзәсен ватып качуым, тоткыннардан хат алып кайтуларым...

— Нинди төрмә, нинди тоткыннар ул? — ди Мәрьям апа, әле һаман да куркуын баса алмыйча.

Җизни белән апаның Кави Нәҗми шигырен укыганнары да, ишеткәннәре дә юк икән. Әйтеп бирдем. Стәрледә булган әдәби кичәнең тарихын сөйләдем. Теге шигырьне, кичәге кебек үк артистланмыйча гына, укып та күрсәттем.

— Шуның шаукымы!

— Уф, — дип куйды Мәрьям апа. — Җен! Чистый котымны алдың.

Барыбыз да бергә рәхәтләнеп көлештек. Шулай да җизни, тынычланырга ашыкма дигәндәй, әйтеп куйды:

— Шаукымы комсомол билетыңа кагылмасын. Ничек урам яңгыратып кайтып килүегезне күрүчеләр аз булмагандыр.

— Хәйрүш әйтә ди әнә, үзләре генә түгел, атлары да исерек иде аларның, дип әйтә ди.

— Кем соң ул Хәйрүш?

— Озаграк торсаң, белерсең әле.

## 2

**Яңа Карамалы. Эш башкаручы. «Чабаталы» почта агенты. Такташ таныштырган дус. Тәнкыйтькә почет. Мазһар катыгы.**

Озаграк торырга туры килмәс, бер-ике көннән Уфага китәрмен дип уйлаган идем.

— Ашыкма әле, — диде җизни. — Нинди инженер чыксын ул курслардан? Күп булса, кондуктор итәрләр.

Икеләнә калдым. Шәбрәк уку йортына юл тапканчы, вакыт узып та китте. Шулай итеп, миңа Карамалыда калырга, теләсәм-теләмәсәм дә, аны озаграк күрергә, яратсам-яратмасам да, аның кешеләре белән танышырга туры килде. Хәзер менә тагын үкенәм: өстән генә караганда шыксыз күренгән шул авылның социаль-тарихи яктан булган әһәмиятле үзенчәлекләренә, мәгънәви матурлыкларына тиешенчә игътибар итәргә культурам җитмәгән.

Илдар Юзеев чыгарганлыгын белсәм дә, күңелемә халыкныкы булып урнашкан бер җыр исемә төшә:

Сизмәгәнмен ииңнәремә нинди кош кунганлыгын,
Очып киткәч кенә белдем сандугач булганлыгын.

Мәгънәсе шунда: Карамалы һәм аның тирә-ягы — Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты белән бәйләнгән урыннар. Унике чакрымда гына әдипнең туган авылы Солтанморат. Карамалыдан күренеп үк тора диярлек — Кешәнле — Галимҗан башлангыч белемне шул авыл мәктәбендә алган. «Татар хатыны ниләр күрми» хикәясендәге атаклы Гөлбану образының прототибы Карамалыга күрше авылда гына яшәгән. «Яшь йөрәкләр» романында Зыя мәхдүм каралырга шушы Карамалыга килә. «Бу авыл зур вә киң яланнарның уртасында булган бер үргә утырган,— дип тасвирлый аны Галимҗан Ибраһимов.— Авылның нәкъ уртасында базар өчен дип хәзерләнгән бик зур мәйдан бар. Волостьның идарәханәсе дә шул мәйданга салынган. Идарәханә— иңе киң, буе озын, түбәсе карсак, тәрәзәләре зур вә караңгы күренгән бер бина булып, моның һәммә җире кызылга буялган. Шунлыктан тирә-якта моны «кызыл өй» дип йөртәләр... Бу өйнең ике ишеге бар: берсе төнгә, берсе кыйблага карый. Каралучылар шул кыйбла яктагысыннан кереп, төн ягыннан барып чыгалар»...

«Кызыл өй» дигәч, мин аны, укучы буларак, кирпеч йорт сыйфатында күз алдыма китергән идем. Ул бары түбә калае гына кызылга буялган гади агач бина булып чыкты. Озынлыкка, чыннан да, озын, киңлеккә дә Галимҗан тасвирлаганга туры килә. Ике ишеге дә нәкъ ул язганча.

Мин килгән вакытта бу йортта клуб иде инде. Язучы фантазиясе булгандырмы, әллә заман үзгәртүе беләнме, базар мәйданы авылның икенче урынына күчерелгән; революциядән соң идарәханәгә алмашка килгән «Миркитле волость башкарма комитеты» да хәзер бу «кызыл өй»дә түгел, ә урам аша таш нигез өстенә салынган зур агач йортка урнашкан иде.

Авылда калуым ачыклану белән шул йортка хезмәткә кердем. Иң якын начальнигым башкарма комитетының секретаре Мазһар Ибраһимов, өйләнмәгән егет булса да, һәр эштә тәртип, төгәллек, җыйнаклык сөюче һәм искиткеч чиста йөрүче кеше иде. Мин аның русча да, татарча да тиз һәм матур язуына, оста сөйләвенә сокланып бетә алмый идем.

Эш башкаручының вазифасы — төрле оешмалардан яки аерым кешеләрдән килгән кәгазьләрне махсус кереш дәфтәренә теркәү һәм аларны тиешле бүлек яки өстәлләргә тапшыру; шул ук вакытта совет исеменнән җибәрелә торган барлык документларны чыгыш дәфтәренә язып, номер һәм числоларын куеп, тиешле адрес буенча җибәрүдән гыйбарәт икәнлеген Мазһар абый миңа бер көн эчендә диярлек төшендереп тә бирде, аларның ничек башкарылырга тиешлеген үзе үк эшләп тә күрсәтте.

Минем өчен менә дигән мәктәп булды бу урын. Нинди-нинди генә язулар килми иде безгә? Күбесенчә кантон үзәгеннән, еш кына турыдан-туры Уфаның үзеннән дә төрле боерыклар, инструкцияләр килә; волостьтагы бөтен авыл советларыннан без җибәргән язуларга җаваплар, справкалар, аңлатмалар, сораулар, үтенечләр, аерым кешеләр язган гаризалар, шикаятьләр, хатлар... Ә кешеләр ул елларда бик күп төрле иде. Холык-фигыльләре яки һөнәрләре белән генә түгел, социаль яктан да. Авыл үзе генә дә әллә ничә төрле катлам тәшкил итә иде: ялчы, ярлы, урта хәлле, таза хәлле, хезмәткәр, кустарь, рухани, кулак, сәүдәгәр...

Совет властенең волость күләмендәге үзәге буларак, башкарма комитетка шуларның барысы белән дә алыш-биреш итәргә туры килә һәм алар барысы да эш башкаручы кулы аркылы үтә. Ул язуларда кузгатылган мәсьәләләрне, әлбәттә, мин хәл кылмыйм. Ләкин барысының да эчтәлеге белән танышырга мәҗбүр идем.

Мәҗбүр булсам да, бу эшне авырсынмый, яратып, мавыгып башкарам. Авыл, волость күләмендә булып торган эшләр, вакыйгалар белән, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, язмышлар белән танышу кызык иде миңа. Тик белгәннәремне зуррак, житдирәк хезмәткә файдаланырлык, киңрәк, тирәнрәк күләмдә фикер йөртерлек хәзерлегем булмаган: каләм хезмәтенә баглы хыялым — «Яшь юксыл» газетасында басылырлык хәбәр язудан ары китми иде. Ә хәбәр язуның үз логикасы бар. Кулымнан үткән язмалар, аерым шәхесләрдән ишеткән тарихлар, язмышлар арасында бәлки хикәя, повесть, хәтта роман язарлык материаллар булгандыр. Әмма комсомол газетасына хәбәр итеп язарлык фактлар табу җиңел түгел иде. Язып караган беренче хәбәрләрем ничектер эзсез югалды. Аңа карап кына, әлбәттә, күңелем төшмәде. Редакциягә үпкәләмәдем дә, ачуым да килмәде. Киресенчә, минем өчен «Яшь юксыл»ның дәрәҗәсе күтәрелә, кадере арта гына төште. Һәр санын көтеп алам. Аны башыннан ахырына кадәр укып чыгам. Исемнәре газетада басылган хәбәрчеләр миңа иң бәхетле кешеләр, зур акыл ияләре, талантлы каләм осталары булып күренә.



Ул елларда Уфада чыга торган газеталарда «Чабаталы» имзасы белән язылган хәбәрләр күп басыла иде. Карамалыда эшли башлагач, игътибар иттем: бар язганы шушы волость авыллары турында икән бит! Кем соң ул «Чабаталы?»

— Укытучы, — диде миңа Мазһар, — Гата Биккулов дигән кеше. Гомәр авылында укыта. Карамалыга килеп йөри, күрерсең...

Исеме газета битләрендә шул кадәр еш очрый торган булгач, мин аны бик мәһабәт кешедер, тышкы кыяфәте белән үк асыл шәхес булыр дип уйлаган идем. Көннәр үтте, атналар. Бәлки күбрәк тә үткәндер. Ниһаять, бер көнне аны миңа күрсәттеләр.

— Әнә ул...

Бәй, мин бу кешене күргән идем ич инде! Кызганып, күңелемнән генә, нинди бәхетсез кешеләр бар бу дөньяда, дип үткән идем. Сәбәбе: һәркемнең күзенә бәрелерлек дәрәҗәдә авызы кыек иде аның. Аксыл төкле кешеләргә хас булганча, йөзе дә нурсыз булу өстенә, кигән киеме дә иң гади авыл кешесенекеннән аерылмый. «Чабаталы» имзасы белән язганга, юри шулай киенеп йөри микән әллә? Аягына карыйм: юк, чабата ук түгел, төп салынган киез итек.

Ләкин бу кыяфәтенә карап, аңа карата хәбәрләре аркылы күңелемдә туган ихтирам тойгысы кимемәде. Хәзер инде ул миңа ягымлы, ничектер серле дә булып күренә, хәтта авызының кыеклыгы да гариплек булып түгел, аны башкалардан аеру өчен табигать тарафыннан бүләк ителгән үзенчәлеге булып тоела башлады. Хозыр Ильяс исемә төште. Авыр хәлгә калган адәмнәргә һәр вакыт ярдәм кулы сузучы, ни теләсә шуны эшләргә кулыннан килүче кодрәт ияse турында халык телендә шундый риваятьләр сөйләнә иде. Имештер, ул изге зат кешеләрне сынар өчен, кайчак юри шулай ярлы, гарип кеше кыяфәтенә кереп, халык арасында йөри. Шуңа күрә кем турында да, тышкы кыяфәтенә карап кына, начар уйларга, аны кимсетергә ярамый, Хозыр Ильяс булып чыгуы мөмкин.

Юк, «Чабаталы» булгач, бәхетсез түгел бу адәм!

Гата ага Биккулов минем янда инде шактый олы кеше иде. Үз кешеләрчә барып сүз кушарга кыюлыгым җитмәде. Якыннан танышып

китә алмадым. Шәхес буларак, аның турында башкалардан ишеткән сүзләр генә хәтеремдә калган: бик тапкыр, җор телле кеше, авызы кыек булса да, сүзе туры, диләр иде.

Газета-журнал битләрендә әледән-әле исемнәре чыгып торган хәбәрчеләр ул чорда минем өчен язучы белән бер дәрәҗәдә диярлек хөрмәткә лаек кешеләр иде. Аерма шунда: алар ничектер якындарак, тырышыбрак үрелсәм, минем дә буй җитәрлек югарылыкта торалар кебек тоела, үземнең дә шулар җөмләсендә буласым килә, редакция тарафыннан аларга мөрәҗәгать итеп әйтелгән сүзләрне турыдан-туры миңа да кагылалар кебек кабул итә идем. Газеталарга язылу кампаниясе башлангач, дәртләнеп, «Яшь юксыл»ны тарату эшенә керештем.

Минем бәхеткә каршы, нәкъ шул чорда волостыбыздагы почта агентының урыны бушап калды да, өстәмә рәвештә аны да миңа тәкъдим иттеләр. Шәп булды. Хезмәт хакым унсигез сумнан утыз сумга күтәрелде. Ул елларда ялгыз егет өчен ашарга-эчәргә дә, баштанаяк киенергә дә җитәрлек акча иде бу.

Ләкин минем өчен төп шатлыгы анда түгел, ә бәлки бу урынның газета тарату өчен уңайлы булуында иде. Үзләре белеп газетага язылырга теләүчеләр күп түгел. Нинди йомыш белән булса да почтага килүче һәр кешенең исенә үзем төшерәм. Араларында яхшы киңәшне кабул итүче аңлы кешеләр табыла. Ләкин күңел сизә: язылучылар барыбер аз, булганы белән генә канәгатьләнергә ярамый, берәр чарасын табарга кирәк.

Почта агенты булгач, волость күләмендәге хосусый сәүдәгәрләр налог акчаларын миңа китереп түли башладылар. Кулымда булган инструкция буенча санап, пенияләрен дә кушып исәпләп, алып калам. Бер көнне ничектер башыма килеп, шуларның берсенә газетага язылырга тәкъдим иттем. Хакы арзан булгач, исе дә китмәде.

— Әйдә, яз! — ди. — Каян килеп, кая китмәгән.

Икенчесе дә берсүзсез риза. Өченчесе дә. Күңелем үсеп китте. Чынлап та, ни тора соң ул сатучыга берничә тиен!

Бүтәннәреннән ризалыкларын сорап та тормыйм, абунә[1] хакын налог сумасына кушып исәплим дә, квитанция генә тоттырам.

— Минә монысы өчен сиңа газета җибәрерләр.

— Алаймы, ярар.

Шулай да, «нинди гәзит, нигә ул?» дип сораучы бер-ике кеше табылды. Әйтеп бирдем.

— Нигә ул миңа комсомол гәзите?

— Малаең укыр, я кызың.

— Малаем комсомол түгел, кызым да.

— Булмаса булырлар, — дим, көлгән булып.

— Булмый торсыннар әле...

Шулай да квитанция язылган акчасын кире сораучы берәү дә очрамады.

«Дөрес эшлимме соң мин болай?» дип, үз күңелемә үзем сорау биреп карадым.

— Зарар юк, — дип җавап бирде күңелем. — Сәүдәгәр, кулак халкы гомердә үзе теләп яздырасы юк бу газетаны. Ә өенә барып керсә, кайсы булса да күз салмый калмас. Бәлки малайлары, комсомол газетасын укыгач, контр аталарына каршы рухта тәрбияләнерләр. Бер дә булмаса, яраткан газетаңның тиражын күтәрү үзе файда. Курыкма, революция мәнфәгатен күздә тотасың!»

---

[1] Абунә — язылу бәясе.

Хезмәт иярәренә хәләл юл белән яздырганнарын да кушып исәпләсәң, ике йөз данәгә якын «Яшь юксыл» тараткanмындыр. Ул вакыт өчен аз түгел иде бу. Хәтта йөздән ким күләмдә тараткан хәбәрчеләрнең дә исемнәрен, мактап, газетага басып чыгаралар иде. Үзем турында редакциягә язып тормадым. Мактану булыр кебек тоелды.

Газета тарату эше матбугатка сусаган мәхәббәт хисләремне беркадәр кандырса да, язасы, язганнарымны кешеләргә укытасы килү теләгем, әлбәттә, сүнмәде дә, сүрелмәде дә.

Чарасы табылды тагы. Уфа газеталары басмаса басмас, стена газетасы да бетмәгән! Халык судында секретарь булып эшләүче Барый Сафин дигән егет белән таныштым. Такташ таныштырды дияргә мөмкин. Сафин миңа караганда яшькә олырак, беркадәр гражданнар сугышы фронтларын да күргән бик үткер егет иде. Мин әле бәлки аңа тиз генә сүз кушарга да кыймаган булыр идем. Такташ шигырьләре буенча ясаган рәсемнәремне күреп, үзе игътибар итте.

— Менә дигән рәссам буласы егет икәнсең син, — диде. — Рәсем мәктәбенә китәргә кирәк сиңа!

Мин укырга китә алмыйча, Карамалыда калып эшли башлагач, якыннанрак танышып киттек. Ул да әдәбият ярата икән. Минем Такташ белән мавыгып йөрүемне күргәч, язу-сызу эшенә дәртем барлыгын да белгәч, бөтенләй ачылды: алтынсу ак чырае балкып, зәңгәр күзләре яктырып, нурланып китте.

— Менә нәрсә, — диде, — безнең анда стена газетасы үлем түшәгендә ята. Давай бергәләп, шуны тергезеп җибәрик әле.

Бөдрәләнеп, тузгып торган чәчләре сары да булгач, ул миңа Такташ төсле күренә иде.

Чынлап та, кайчандыр Май бәйрәме көннәрендә үк чыгарып эленгән, хәзер инде бөтенләй чебен чуарлап бетергән стена газетасы булган икән. Аның бу хәлгә төшүенә Барый үзен үк гаепле сизеп, эче пошып йөргән, күрәсең, минем каршымда акланырга теләгәндәй: «ярдәм итүче булмагач... берүзем язу... ачу килде дә...» дип, үз алдына сөйләнә-сөйләнә, искергән газетаны алып куйды.

Яңа газета эленгәч, клубыбыз яктырып киткән кебек булды. Иң элек газета янында үзебез көлешәбез. Безне күреп, бүтәннәр килә. Газетага күз салган бер кеше, кадакланган кебек, урыныннан китә алмый. Ә кеше өзелми иде анда. Волость күләмендәге культура эшләренең үзәге булу өстенә, бу йорт Карамалыда булган бик күп учреждениеләр өчен утырышлар залы хезмәтен дә үти, шунлыктан бервакытта да диярлек буш булмый иде.

«Үлем түшәгендә яткан» газета терелде генә түгел, шаулый-гөрли башлады. Тәнкыйть утына эләккәннәрдән серкәсе су күтәрми торганрак берәр кеше шикаять белдереп килә икән, куанабыз гына: әһә! Төчкертәме? Шул кирәк сиңа, икенче саграк булырсың!

Тәнкыйть итәргә курыккан юк. Берәүнең дә дәрәҗәсенә карап тормыйбыз. Кырынрак эше, кешеләргә мөнәсәбәттә ярамаганрак гамәле булса, волисполком председателе дип тә тормыйбыз, хәтта волком секретаре дип тә. Бу вакытта минем җизни — Әминев — Кызыл Армиягә алынган, волком секретаре булып аның урынына Уразаев дигән коммунист килгән иде инде. Җитди кеше булса да, көлгән-шаярганны аңлый, тәнкыйтьне дә кабул итә белә иде. Тик дөрес язылган гына булсын.

Тагын да ныграк җиң сызганып, алдагы номерны хәзерләргә керештек. Сафинның Карамалыда гына түгел, бөтен волостьта диярлек, күрмәгән кешесе, ишетмәгән хәбәре юк икән. Миндә Стәрледән алып килгән тәҗрибә бар, йөзәм материал эчендә. Кайсын көйгә салып, кайсын

әкият, кайсын төш формасына кертеп, төзәм генә. Көлке рәсемнәр ясыйм. Барыйның да илһамы ачылып китте.

Волость үзәге булгач, тирә-ягыбызда һаман тормыш кайнап тора. Күршедә генә кооператив кибете. Авыллардан килгән олаулар өзелми. Кайвакыт волость йортының зур ишегалды шыгрым тулып китә. Араларында кызык хәлләр дә булгалый. Бервакыт шулай, эшләп утырам. Кинәт, тыны-көне бетеп, җыештыручы апа килеп керде.

— Мазһар кирәк иде! — ди.

— Юк бит әле ул. Ни булды?

— Аның катыгы була торган иде...

Чынлап та, Мазһар абзыйның иң яраткан ашы катык иде. «Катык— кеше организмына иң файдалы азык, аны ашаган кеше тиз картаймый» дип, башкаларны да өнди, үзе исә су урынына да, чәй урынына да катык кына эчә, һәр вакыт янында кисмәге белән катык тота, хәтта катыкка багышлап, кызыклы бәет тә язганы бар иде.

— Нигә ул кадәр ашыгыч кирәк булды?

— Берәү агу эчкән анда. Үлә!..

Атылып ишегалдына чыктым. Дистәләгән олаулар арасыннан кемнеңдер, түземсезләнеп, ах-ух килгәне, җан биргән тавыш белән үкергәне ишетелде. Шул якка ашыктым. Чуваш авылыннан килгән бер мужик икән. Сүзен дә әйтә алмый, үкерә, кычкыра. Тимер мичкә салынган арбасы янында бәргәләнә. Ул арада чиләк күтәреп чыккан теге апа килеп җитте.

— Мә, эч тизрәк тозлы әйрән! Тагын, тагын! Беткәнче эч! Беткәнче! Косканчы! Укшы, укшы!..

Арба тирәсенә җыелып өлгергән халык та көч биреп тора.

— Көчләп, көчләп! Менә шулай. Тагын! Тагын!..

Ниһаять, бәхетсезлеккә очраган кеше, бушанып, тынычлап калгандай булды.

— Ай-яй-яй... зәһәр икән...

— Ни булды соң сиңа?

— Фар-ма-лин эч... тем...

— Тилердеңме әллә?

— Исертми микән дип... бер генә уртлап караган ием... Ай-яй, зәһәр икән. Корт... ничек түзсен... дурак!..

— И ходаем, бу ирләрне!.. Аракы дигәндә... Үлгәннәрен белмиләр, илаһым!

Стена газетасы ничек көлми түзсен мондый хәлләрдән?..

### 3

**Хәерсез кәсеп. Вәкил юргасы. Сабырлыкның чиге. Хөкем. Кышкы салкын төн. Кар эрегәч. Сөенеч. Көенеч. Шау-шу. Казанга?**

Галимҗан Ибраһимовның «Карак мулла» хикәясендә угрылар шайкасының бикле сарайдан ат урлаулары, кистән белән сугып мие туздырылган каравылчы картның үле гәүдәсен өрлеккә асып китүләре сурәтләнә. Язучы бу канлы вәхши күренешне күреп кемнәрнең нинди тойгы кичерүләрен күрсәтә. Картлар: «Әй, заман, заман! Тагы нилэр күрәсебез бар икән! — диешәләр. Караклар үзләренең гомер буена кеше талап йөреп тә, шундый бер эш кыла алмауларын уйлап, эчтән кызыгу хис кылалар. Яшьләр, тыштан яманласалар да, болардагы йөрәк вә батырлыкка исләре китәләр».

Сәер тоела иде бу миңа. Караклар турындагы бер хәл, ә гомумән яшьләр турында? Юлбасар батырлыгына, башкисәр каһарманлыгына сокланучы нинди яшьләр икән ул? Миңа — Жиргән малаена аңлашылып бетми иде бу. Авыргазыга килгәч, аңладым. Бу як авылларында элек-электән караклык шактый киң урын алган булган икән. Ачлык-ялангачлыктан яки байлыкка кызыгудан гына түгел, күпләр өчен ул батырлык, тәвәккәллек, тапкырлык сорый торган күңелле кәсеп итеп каралган.

Кешегә үзендә булган куәтне, көч һәм сәләтне игелекле эшкә юнәлдерергә зәмин житмәгән заманнарда барлыкка килгән бу хәерсез кәсепнең калдыклары һаман да бетеп житмәгән иде әле. Карамалы кешеләре теге яки бу күршеләрнең төнге кәсептә йөргәндә башыннан кичергән мажаралары турында ачыктан-ачык сөйлиләр, авылдашларына зарарын салмаса, аның урлашып йөрүен артык зур гаепкә дә санамыйлар кебек иде.

Уллары караклыкка киткән бер ананың, намазлык өстендә теләк теләп: «Төнлә йөргән бәндәләргә төн савабын бир, алла!» дип, дога кылып утыруы кебек анекдотлар, күрәсең, юкка гына сөйләнмәгәндер.

Бәләкәйдән зур булдык,
Ат урладык — бур булдык.
Ат урлап та тотылмадык,
Кыз урламый хур булдык.—

кебек жырлар да юкка гына жырланмагандыр.

Волисполкомда тирә-якта тиңе булмаган шәп бер юртак бар иде. Тантаналы сәфәргә чыкканда яки Стәрлетамак, Уфа кебек үзәкләргә бик тиз барып житәргә кирәк булган чакларда гына жигелә, анда да волостьның иң зур түрәләренә генә эләгә торган ул Дөлдөлгә утырып йөрү дәрәжәсенә ирешә алмадым. Өмет тә итмәдем. Миңа аның тарихын белү дә житкән иде.

Вәкил юргасы дип йөртәләр иде аны. Вәкил тирә-якка даны чыккан карак булган. Карак кына түгел, бандит, башкисәр. Үз тирәсенә зур шайка жыеп, тирә-як авылларны куркытып торткан. Ниләр генә сөйләмиләр иде аның турында! Әнә ул, жил-давыл уйнатып, авыл аша узып бара. Ул узган вакытта урамда бер кеше күренми. Ярыкларга качкан тараканнар кебек, төрлесе-төрле урынга поскан кешеләр аны капка ярыкларыннан, читән тишекләреннән, пәрдә кырыйларыннан гына күзәтеп торучыларның берәрсен аз гына күреп калса, атын туктата, кызыксынган кешене өстерәп чыгара да каеш камчысы белән ярырга тотына.

— Вәкилне күрәсең киләме? Менә ул, күр! Барып әйт! Гуләйт итәргә китеп бара Вәкил!..

Күзе төшкән байлыкны ул урлап та тормый, мал иясенең үзеннән китерттерә. Күтәртеп кенә түгел, атын да жиктереп, йөккә төяттеп. Казнасы тулмый, тирәнәя генә бара. Байлыкны, яхшы атларны үзенеке итү белән генә туймый, шайкадашларына да китертә.

Котыруы шул дәрәжәгә барып житә ки, ул теге яки бу авылда булган иң яхшы өйләрне үз авылына, үз хужалыкларына күчертеп утырта башлый. Алла да юк аңа, мулла да, бернинди власть та. Сафин сөйләве аркылы хәтеремдә калган: Вәкил, төн уртасында ат жибәреп, бер мулланы үз өенә чакырта. Аны олылап каршы ала: «Әйдүк, хәзрәт, рәхим ит! Түрдән уз. Корьән укып, дога кылып, өемә фатиха биреп китәрсең!.. Мулла, әлбәттә, «бик хуп, бик әйбәт», дип, Вәкил ни әйтсә, шуңа ләббәйкә дип кенә тора. Корьән укый, дога кыла.

— Ходай биргән дәүләтеңнең игелеген күр.

— Тәгаменнән житеш, хәзрәт!

Табында сый җитәрлек. Бәлеш кирәкме, күркә-тавыкмы? Бал-май... Җаның ни тели.

— Рәхмәт, мелла кем, Вәкил, бик рәхмәт.

— Аша, хәзрәт, ашагач рәхмәт әйтерсең.

Хәзрәттә бу йорттан ничек тә исән-сау котылу кайгысы.

— Булды, мелла кем, Вәкил энем, — ди ул, — алланың рәхмәте яусын!.. — һәм тизрәк аш кайтарып, дога кылырга җыена.

— Ашыкма, хәзрәт, — ди Вәкил, түбәнчелек күрсәткән кыланып,— булмады әле. Хәзрәт чаклы хәзрәтне йокысыннан уятып алып килгәч, мондый гына сый-хөрмәт белән озату килешмәс.

— Бик җиткән, мелла кем, бик җиткән. Тагы нинди сый?!

— Минә монысыннан авыз ит! — ди залим һәм рәхимсез рәвештә хәзрәтне камчы белән ярырга тотына...

Аның берни белән дә акланмаган бу явызлыкларына волость органнары да тиз генә чик куя алмыйлар. Бандит үзенең эзләрен бик оста яшерә. Инде берничә дистәгә җиткән шайкадашлары булыша аңа. Тәмам тотылып бетте дигәч тә, ычкынып киткән чаклары бер генә булмый. Власть органнарында да Вәкилнең үз кешеләре бар, имеш, дигән хәбәрләр йөри.

Ләкин сабырлыкның чиге юк түгел. Банданың явызлыклары чамадан артып киткәч, аны тотарга халык үзе ярдәм итә. Ниһаять, баш бандитның кайдалыгын белеп, ул кергән өйне камыйлар. Вәкил капкында. Рәсми орган кешеләре аны кулга алып, хөкемгә бирмәкче. Ләкин халык инде ышанмый, тагы качырырлар дигән шик өстенлек ала. Явызлыкка каршы ярсыган кешеләр төркеме бик күп авылларның теңкәсенә тигән ата каракны үзе хөкем итә: Вәкилне кыйнап үтерәләр.

Бу хәбәр Уфага ишетелгәч, комиссариат кешесе, җирле органнарны шелтәләп, әйткән, имеш:

— Хәрап иткәнсез,— дигән,— күкрәге белән таш диварларны җимерә торган батыр командирны карап торып үтерткәнсез!..

Ләкин Вәкилнең соңгы еллардагы «батырлыклары» турында бәйнәбәйнә сөйләп биргәч, аның өстеннән язылган шикаятьләрнең әллә ничә папканы тутырганлыгын күрсәткәч кенә, каршы берни әйтә алмаган, көрсенеп кенә куйган, ди.

Көрсенүе юкка гына булмагандыр. Гражданнар сугышы чорында эчке һәм тышкы дошманнарга каршы корал тотып сугышкан чакларда Вәкил, чынлап та, Кызыл Армия сафында батыр командир булган, диләр. Ә менә тынычлык урнашкач, бигрәк тә яңа байлар: авылларда — кулаклар, шәһәрләрдә — нэпманнар пәйда була башлагач... Ихтимал, йөрәк белән генә мәйданга чыккан гаярь егетнең трагедиясе аның яңа икътисади сәясәтне аңлап җитмәвеннән килеп чыккандыр. Баштарак ул күбрәк байларга, руханиларга каныга торган булган, диләр. Ирярченнәре күбәйгән саен шайканың социаль талымсызлыгы арта, җан өшеткеч кыргый төс ала барган... Атаманнары үтерелгәч, шайкадагы каракларны кулга алганнар.

Мин Карамалыга килгәч, аларга суд булды. Уфадан килеп, Башкортстан Верховный судының күчмә сессиясе хөкем итте. Судья — Рафиков, прокурор һәм аның белән бергә килгән адвокат ул вакытта Башкортстан күләмендә исемнәре еш ишетелә торган кешеләр иде.

Суд безнең клуб бинасында барды. Берничә көнгә сузылган утырышлар көндез — эш сәгатьләрендә булганлыктан, мин аларның күбесенә керә алмадым. Үзем күреп хәтердә калган детальләр күп түгел. Ул вакытта минем өчен кызык һәм сәер тоелган бер эпизодны гына искә алып китәсем килә.

Суд өстәле артында утыручылар арасында Карамалы халык судьясы Ибраһимов та бар иде. Бу кеше үзенең тышкы кыяфәте белән үк минем игътибарны җәлеп итте. Аның алсу-ак булып, күзгә бәрелеп торган киң маңгае, ничектер, гаделлек, тугрылык, шуның белән бергә кырыс таләпчәнлек нуры балкып торган ягымлы йөзе миндә һәр вакыт үзенә хөрмәт хисе уята, аның яныннан беркайчан да илтифатсыз үтеп булмый иде. Әнә ул, суд өстәле янында утыручы берничә кеше арасында минем өчен үз кеше булып, күзгә бәрелеп тора. Уфадан килгәннәрдән берәү — судьямы, прокурормы — шаһит сыйфатында чакырылган һәм миңа шактый олы чырайлы күренгән бер хатыннан сорау ала. Ничектер бик әдәпле телдә, бик китапча итеп, җинаятьче турында нидер сорый. Теге хатын аны аңламый.

— Ә? Нәстә дисең? Белмим, белмим...

Сорау алучы инде икенче төрле сүзләр белән соравын кабатлый. Күкрәк турында нидер әйтә, ихтыяр турында... Теге хатын түгел, мин дә аңлап бетермим. Шул вакытта әлеге үзебезнең Ибраһимов ярдәмгә килде. Бик авылча һәм ачык итеп:

— Имчәгеңне тоттымы? — дип куйды.

Хатын шунда ук аңлап алды:

— Ә-ә-ә, тотты, тотты, тотмаган кая...

Ибраһимов, гомумән, авыл кешеләре белән эш иткәндә аларның үз телләрендә, үз жаргоннарында сөйләшергә оста иде. Кайчак китапка язарга ярамый торган сүзләр кулланудан да тартынып тормый һәм бу аның авызыннан табигый ишетелә, бернинди әдәпсезлек булып та тоелмый, шунлыктан авыл кешеләре аны бик үз күрәләр иде.

Судья Ибраһимов турында Карамалыдагы каләмдәш дустым Барый Сафин да бик яратып сөйли иде. Халык судының секретаре, аннары тикшерүче-следователь буларак, ул аның белән бергә эшли, көн саен аны хезмәтендә күрә, кешеләр белән ничек сөйләшүен ишетеп тора, аның кушканнарын үти иде. Үзенең начальнигыннан канәгать кенә түгел, аның кул астында эшләвенә куанып хезмәт итә иде Барый.

Болай да ачык йөзле, кырыс чагында да ягымлы чырайлы, киң күңелле, бай рухлы судьябызның Галимҗан Ибраһимовка якын кардәш тиеш Мотаһар икәнлеген белгәч, аңа карата хөрмәтем тагын да артып китте.

Еллар үтеп, Галимҗан Ибраһимовның үзен күргәч, Мотаһарның язучы абзыйсына бик нык охшаган икәнлеген дә белдем. Зур язучының тәрҗемәи хәле һәм аның турында чыккан истәлекләр белән таныш кешеләр Мотаһар исемен беләләр. Шуны да өстисем килә: ул Галимҗанның якын туганы сыйфатында гына түгел, үзенең хезмәте, кешеләргә эшләгән яхшылыклары белән дә җитди игътибарга лаеклы, үзенчәлекле шәхес иде.

Вәкил үзе үтерелеп, шайкасы кулга алынгач, тирә-як ярыйсы ук тынычланып калды. Караклар төрлесе-төрле срокларга хөкем ителгәч, халык тагын да иркенрәк сулыш алды. Ләкин бу электән килгән хәерсез кәсеп белән шөгыльләнүчеләр инде бөтенләй бетте дигән сүз түгел, юк-юк дигәндә дә, ниндидер каны кызган кайнар башларның тынычлыкны бозулары хакында һаман ишетелгәли иде әле. Берсенең җиле хәтта турыдан-туры безнең комсомол оешмасына да кагылып үтте.

Кантон съездына делегат булып барган идек. Өчәүләп. Яшь ягыннан да, дәрәҗә ягыннан да өлкәнрәгебез — ВЛКСМның волость комитеты секретаре Сәфәргали. Төн уртасында кайтып төштек. Кыш. Салкын. Барыбызны да йокы баскан. Үзара сөйләшмичә генә атны тугарып, волисполком аранына тапшырдык та, капчыкларыбызны күтәреп, өчебез өч урамга — өйләребезгә юнәлдек.

Иртәгесен Сәфәргали тирәсендә ыгы-зыгы. Ни булган? Кичә төнне, аркасына капчыгын аскан килеш, йокымсырап кына өенә кайтып барганда, арт яктан, җан-фәрман чабып, бер атлы килеп чыккан. Сәфәргали әйләнеп карарга да өлгермәгән, теге кайнар баш аны чана урәчәсе белән бәреп очырып, узып та киткән, күздән дә югалган. Юл читендәге көрткә чумып калган секретаребыз өстен кардан кага-кага тәпи баса, урәчәгә бәрелүдән шактый авыртып калган аягын төрлечә хәрәкәтләндереп, җиргә тибеп-тибеп карый. Шөкер, сынмаган икән. Шөкерен шөкер дә, нигә болай җиңеләеп калды әле ул? Йокы ачылып китүдән генәме? Ә капчыгы кайда соң? Карга чумды микән әллә? Юк, капчык юкка чыккан. Ә капчыкта? Капчыкта кала кучтәнәчләре генә түгел, зур төргәк комсомол билетлары! Бу инде уен түгел.

Беркем эзенә төшә алмады бу эшнең. Авылда дуамаллыгы белән даны чыккан берәү бар иде. Дуамаллыгы шунда: ат җигеп урамга чыкса, күзен алган кигәвендәй, кая барып бәрелгәнен дә белмәстән, җанфәрманга чабып йөрергә ярата иде. Шул түгел иде микән? дип шикләнеп йөрде Сәфәргали. Ләкин шикләнүгә таянып кына кая барасың!..

Март житте. Карлар эри башлады. Һәм нәкъ шундый матур язгы көннәрнең берендә, нәкъ шул дуамал кеше үзе, әлеге югалган капчыкны күтәреп, волкомга килеп керә.

— Менә, — ди, — читән буенда кар астыннан бер почмагы күренеп торгач, алып карасам, шушы капчык. Теге сез югалткан капчык түгел микән?

— Шул!

Чишеп карый Сәфәргали, комсомол билетлары исән.

— Ай, рәхмәт! Дошман кулына кермәгәннәр икән...

Юкка чыккан кала кучтәнәчләре, Стәрле бүләкләре турында сорап тору кая! Дуамал дип даны чыккан шикле егет, җәзага тартыласы урында, рәхмәт ишетеп чыгып китә.

Бу яз минем өчен истәлекле булды: куанычлы да, беркадәр көенечле дә...

Ячейка секретаре буларак, комсомол эше канәгатьләндерми иде мине. Тик тормадык анысы. Җыелышлар, лекцияләр, әдәби кичәләр, халык арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча күрелгән чаралар... Болары бар. Бик оешкан төстә булмаса да, физкультура-спорт белән шөгыльләндек: көч сынашырга, авыр әйберләр күтәрергә ярата идек. Гер уйнату эшендә үзем дә таза-таза авыл егетләре белән ярыша башладым. Стәрледә чакта теге Ипполитовтан күргән номерларның барысын да диярлек башкарырга өйрәндем...

Ләкин бу эшләрне комсомол булмаган яшьләр дә эшли ала. Комсомол булып, авылга нинди яңалык алып килде соң безнең ячейка? Чын мәгънәсендә яңа тормыш төзү турында уйлыйбызмы? — шундый сораулар тынгы бирми иде.

Уйлаша торгач, комсомолда торучы яшьләрнең үз көчләре белән ячейка өчен бер дисәтинә ашлык чәчәргә булдык. Ул вакытта колхоз мәсьәләсе беркайда да киң күләмдә кузгатылганы юк иде әле. Ләкин авылның киләчәге күмәкләшүгә барырга тиешлеге турында укып та, ишетеп тә белә идек. Ичмасам, шуңа бару юлында бер тәҗрибәбез булыр. Давайте, бер дисәтинә солы чәчәбез! Ни өчен солы? Сатарга уңай. Ни өчен сатарга? Ячейканың үз расходларына авыл советыннан ярдәм сорап йөрмәбез. Нинди расходлар? Газета-журналлар яздыру, уен кораллары алу, спорт инвентарьлары... азмыни?..

Комсомоллы хуҗалыклар арасында ике сабанга җитәрлек ат җыела. Кеше көченә аптырыйсы түгел... Басуларда кар ята иде әле. Җир бе-

ләр орлык турында авыл советы белән сөйләштек тә, бюро утырышында карар чыгарып, аны гомуми җыелыш белән раслап та куйдык. Һәм мин бу турыда бик рәхәтләнеп, «Яшь юксыл»га хәбәр язып җибәрдем.

Озак та үтмәде, редакциядән миңа хат килеп төште. Хәбәремне бик ятратканнар икән. Кем язган диген? Редактор үзе — Зәки Каебкулов!

— Бу хәбәрегез белән сез үзегезне хәбәрчеләр армиясенең батыр солдаты итеп таныттыгыз, — дигән. — Хәбәрегез шушы көннәрдә басылып чыгар, — дигән. — Ул инде җыелган, кызыксынсагыз, менә сезгә аның гранкасын җибәрәм, — дигән.

Кызыксынмаган кая ул! «Гранка» дигән сүзне башлап шунда укыдым, аның нәрсә икәнен дә башлап шунда күрдем: хәбәремне, үзен генә аерып алып, озынча итеп киселгән кәгазьгә чын газета хәрефләре белән бастырып җибәргәннәр. Нәкъ үзем язганча! Бер сүзен дә үзгәртмичә! Өстәвенә, тагын язып торуымны сораганнар.

Сөенүләремнең чиге булмагандыр. Куанычлы истәлек дигәнем шул. Ә көенечлесе?

Мине шундый мактаулы хәбәр язарга рухландырган карарыбызны тормышка ашыра алмадык. Тырышмадык түгел. Газетада язып чыгу өстенә, редакциядән шундый хат та алгач, үзем дә кулымнан килгән бөтен чараларны күрдем. Орлык табылды. Җир алынды. Эшләргә әзер комсомол егетләре дә бар иде. Мәсьәлә атка килеп терәлде. Атлы гаиләдән булган комсомолецларыбыз да берни кыла алмады: әтиләре хуҗа иде. Аерым хуҗалыктагы крестьянның турыдан-туры үз хуҗалыгына файдасы күренеп тормаган эшкә ат чаклы ат бирүен өмет итү буш хыял гына икәнлеген шунда аңладым. Яхшы нияткә таянып, карар чыгарганбыз, ә аның реаль нигезе бармы-юкмы, анысын исәпкә алмаганбыз булып чыкты.

Барып чыкмаган карар турында хәбәр язарга ашыкканлыгыма борчылып, вөҗдан газабы кичереп йөрдем. Нәтиҗәсе шул булды: яза торган хәбәрләремнең алдын-артын уйлабрак эш итә башладым. Тора-бара яшьләр турында бер нәсер кебек әсәрем дә басылып чыкты. Ачыграк хәтеремдә калганы — Карамалыдан бигрәк Стәрлетамакның үзендә шау-шу тудырган бер фельетоным булды.

Арба юлы төшкәч, Стәрлетамакка ешрак бара башлаган идем. Хәзер анда комсомолның кантон комитеты секретаре урынында кайчандыр мине сокландырган Кәримов түгел, яңа, тәҗрибәсезрәк кеше иде. Бер баруымда, үземә электән таныш булган яшьләр арасында шактый ямьсез хәлләр барлыгын күреп, уйга калдым. Исерткеч эчү белән мавыгулар, җенси тотнаксызлык күренешләре. Хәтта начар чир эләктерүне егетлеккә санап, шуның белән мактанып йөрүче кайберәүләрне дә күрергә туры килде...

Шул күренешләрне тасвирлап, комсомол комитетының яшьләр арасында тиешенчә эшләмәвен тәнкыйтьләп, фельетон язып җибәрдем. Тиз генә басып чыгармадылар. Редакциядән бернинди җавап та юк иде. Ахрысы, басарга кирәк тапмаганнардыр дип, оныта да башлаган идем инде. Онытмаганнар икән. Тагын бер килүемдә, гадәтемчә, Стәрленең шәһәр клубына бардым.

— Әһә! Әнә, герой үзе килә! — дип каршы алдылар мине. — Кайдан килгән акыл иясе! — Кайсылары көлә, кайсылары ачулы. Берни аңламый торам.

— Нәрсә булган? Нинди гаебем бар?

Яңа секретарь үзе дә шунда икән.

— Кара син аны! — ди, мине мыскыллап. — Белмәгән булып кылана. Ун кат укыгансыңдыр әле, рәхәтләнгәнсеңдер.

Сизенәм, әлеге фельетон турында сүз бара кебек. Ләкин аның газетада басылып чыкканын, чынлап та, күргәнем булмагач, ни диярга белмим.

— Чынлап, ни турында әйтәсез? Берни аңламыйм?

Ялт итеп, «Яшь юксыл»ның яңа, әле мин күреп өлгермәгән номерын китереп чыгардылар. Берсе борын төбемә үк китереп төртте.

— Ә бу нәрсә?

Карыйм: чынлап та, минем фельетон. Тулы килеш басып чыгарганнар, өч баганалык подвал.

— Күрмәгән идем әле.

— Пожалый. Күрсәң, безнең янга килергә базмас идең.

— Нигә? — дидем мин бик тыныч кына. — Әллә дөрес язмаганмы?

Тынып калдылар. Башлап секретарь телгә килде.

— Дөрес булса? — диде ул кырыс кына һәм беравык ни әйтергә белми сүзсез торганнан соң, тагы батыраеп китте. — Аны үзебезгә килеп әйтергә булмадымыни?.. Ә?.. Син әйтмәсәң, без аны үзебез дә белмибезмени?

— Ә газетага язарга ярамыймы?

Кемдер ярсып, «үз оешмаңның яманатын сатмасаң...» ди башлаган иде дә, секретарь үзен кулга алып өлгерде. Кемнең хаклы икәнен чамалап алды булса кирәк, артык тавыш күтәрүгә юл куймады.

— Ярар, тикшерербез.

Җиңүче сыйфатында горурлык саклап, тыныч кына үз юлыма киттем. Берничә адым үтүгә, артымнан килеп, кемдер дусларча җилкәмә кулын салды. Борылып карасам — Барый Дәминов.

— Молодец, Мирсәяф,— диде.— Шәп язгансың!

Миннән бер яшькә кечерәк булса да, Дәминов минем өчен авторитет иде: яхшы художник булуы белән өстен саный идем мин аны. Шат күңелле, киң карашлы кеше булуы өчен яратам, күңелемнән хөрмәт итә идем. Ләкин былтырдан бирле таныш булсам да, аның белән якынаеп, дуслашып китә алганым юк иде әле.

Шул егетнең дусларча кочаклап күрешүе, өстәвенә, мактау сүзе әйтеп куюы шатлыгымны тулыландырып җибәрде. Рәхәтләнеп сөйләшеп киттек. Ул вакытта Стәрленең үзәк урынын тәшкил иткән чиркәү бакчасына кереп утырдык. Икебезнең дә рәсем яратуыбыз безне тәмам дуслаштырды. Барый быел рәсем мәктәбенә китәргә ниятләп йөри икән. Казанга!

Казан! Татар мәдәниятенең үзәге! Барыннан да элек Такташ һәм аның тирәсенә тупланган башка бик күп шагыйрьләр, әдипләр белән атаклы артистлар, рәссамнар белән, җаның теләгән техникумнар, институтлар белән кайнап торган Казан! Минем өчен буй җитмәс югарылыкта торган хыял бит ул!

— Мөкаддәс белән бергә китәбез, — диде Барый.

— Мөкаддәс?

Соравымның мәгънәсен Барый тонымнан аңлап алды.

— Конешно, аңардан художник чыкмый, — диде ул. — Ну. Казанга барасы килә. Барсын. Бәлки шагыйрь булыр. Ә миңа иптәш.

— Миңа да бит рәсем мәктәбенә китәргә киңәш бирүчеләр бар.

— Правильно! — дип куйды Барый шат чырай белән. — Китәбез бергәләп!

Миңа шуны гына ишетү кирәк иде дә.

— Биш куллап риза! — дидем. — Шуннан башка беркая китү турында уйламыйм хәзер. Кайчан юлга чыгабыз?

— Августта. Көнен бергәләп ачыкларбыз.

## 4

### Агай-эне. Иске дуслар. Көлешү. Кызыл туй.

Шул көннән башлап, күңелем белән Казанда идем инде. Китәргә хәзерләнәм. Эштән бушандым. Өс-башымны юнәттем. Чит-ят җирләрдә кара көнгә булыр дип, үзем дә тиз генә таба алмаслык итеп яшереп, бишмәт чабуыма бер червонец тегеп куйдым.

Ерак юлга чыгу алдыннан туган авылым белән дә саубуллашасым килде. Кайттым Җиргәнгә. Җәй уртасы. Агыйдел буе табигатенең иң ямьле чагы. Агай-эне бары да исән. Бөтен шартын китереп, иген игеп, мал-туар үрчетеп, бала-чага үстереп яталар. Әбүбәкер абзый игенчелек хезмәте өстенә аз-маз сату-алу белән шөгыльләнә башлаган.

— Аллага шөкер, — ди, — вакытны бушка уздырмыйбыз. Иренмә генә икән! Дәрт иткән кешегә юл ачык.

Аның мондый юлга басуын хупламавымны сиздереп караган идем дә, мине малайга гына санады.

— Һи-и-и! — диде. — Совет белми рөхсәт итми ул. Нибуч, кулакка әйләнеп китәргә бирми. Дөрес эшли. Курыкма, харам кермәгән кәсепнең бернинди гөнаһсы юк. Алла каршында да, Совет каршында да...

Әбүбәкер абзыйны мин һәр вакыт хезмәт сөючән, һәр эштә иң гадел кеше итеп белә идем. Сүз көрәштерергә кирәк тә тапмадым, аның иманын үзгәртерлек дәлилләрем дә юк иде. Миңа ни кирәк соң? Бары да үз күреп каршы алдылар.

Тагын да күңеллерәге — үзем кебек кунакка кайткан иптәшләр бар иде, алар белән очраштым. Дөрес, мәктәптә бергә укыган малайларның күбесе авылда — үз хуҗалыкларында калганнар. Миңа исә, электән якынрак дус булу өстенә, язмышлары да үземнеке кебегрәк булганнар белән очрашу кызык иде. Шундыйларның берсе — Хөсәен. Теге вакытта, чукындырудан куркып, минем белән бергә рус школасыннан качкан иптәшем. Ул хәзер Куергазыда авыл хуҗалыгы техникумында укый икән. Үскән. Дөрес, буйга зур түгел, ләкин төп шикелле таза. Шулай да көч сынашып карадык — ике потлы герне минем кадәр үк җиңел күтәрә алмады.

Габделхәй кайткан тагы. Теге кыт-кыт көләргә яратучы малай. Хисап дәресендә хәлфә үзе чишә алмаган мәсьәләләргә дә теше үтә торган иде. Урынын тапкан: Уфа рабфагына барып эләккән.

Бала чакларны искә төшереп, сагынылган урыннарны — Агыйдел буйларын йөреп чыктым. Сөйләшә торгач, тагы шуны белдем: Фәүзиянең апасы да Габделхәй белән бергә рабфакта укый икән. Башта бу миңа бераз гаҗәбрәк тоелган иде. Ничек инде? Рабфакта? Мулла кызы?.. Үзем үк җавабын да таптым. Нәрсәсе гаҗәп? Фәүзия дә, апасы да күптән мулла кызы түгелләр бит инде. Яңа этиләре гражданнар сугышы елларында Азин отрядында сугышып йөргән кызылармеец. Хәзер гади игенче булса да, китап-газета күрмәгән, уңны-сулны белмәгән мужик түгел. Авыл тормышына кагылышлы җәмәгать эшләреннән дә читтә тормый.

— Әйдә киттек шуларга, — диде Габделхәй. — Фәүзияләре дә кайткан икән.

Анысын белә идем. Икеләнә калдым. Хөсәен дә эндәшми, миңа карый. Кушылыргамы Габделхәйнең чакыруына, әллә?.. Стәрледә чакта бер хәл, авылдаш янына баруның гаебе юк. Ә монда? Чакырмаган-нитмәгән җиргә?.. Барасым килә килүен, күңелемдә кадерле урын алган кызны өендә күрәсем килә. Шулай да сүзне йөрәгемә түгел, акылыма бирдем:

— Бар инде, Габделхәй, үзең генә, — дидем. — Ә безгә чакырылмаган кунак булып... Хәер, Хөсәен бәлки барыр?..

Габделхәй, гадәтенчә, кыткылдап көлеп куйды.

— Укучылар бит без, яшьләр, аның ни гаебе бар? Бик беләсегез килсә, чакырылмаган кунак та түгел, Кәрим абзый үзе әйтте, барыгыз да җыелып, килеп чыгыгыз, диде.

Кәрим абзый исемен телгә алу җитте. Әйе шул, миңа, әлбәттә, аның белән күрешергә, хәлен белеп чыгарга кирәк. Авылдан шуның арбасына утырып чыгып киткән идем бит.

— Әйдәгез!..

Күптәнге таныш урыс капканы ачып, ишегалдына керүгә, каршыбызга Кәрим абзый үзе килеп чыкты. Һәр вакыттагыча көләч, какча йөзенә килешеп торган сары мыегы аның көләчлеген тагын да арттырыр өчен махсус үстерелгән диярсең.

— Һә-әй, кунаклар килә! Рәхим итегез! Кызлар, күрәсезме?

Кызлар безне күргәндерме-юкмы, тик алар үзләре безгә күренми, кайдандыр мандолина моңы гына ишетелә иде. Кәрим абзый һәркайсыбыз белән аерым-аерым күрешеп чыкты. Минем белән күрешкәндә аның көләчлеге аеруча шаян төс алды.

— Мирсәяф? Синме бу? — диде.— Кайда «камалы» туның? — Онытмаган икән, көлә-көлә иптәшләргә дә сөйләп бирде. — Кара инде! Каткан туны белән бергә ындыр артына чыгарып түгәрлек кенә малай кебек иде, нинди купшы егеткә әйләнгән!

Купшы диярлек тә булгандыр шул. Башта менә дигән чәч, ике түбәле булганга, маңгай турысында өермәләнеп, тузгып тора. Өстә — ак апаше күлмәк. Ботларда — үзем эшләп тапкан акчага алынган кара чалбар, аякта — сары күн сандали. Кай җире ким кала егетеннән?

Без көлешкән арада мандолина моңы тынып калды. Ишегалдының түренәрәк салынган зур келәтнең ачык ишегендә берьюлы өч кыз күренде. Иң алда — Фәүзия, кыска җиңле ак күлмәктән, кулында мандолина. Икенчесе — ишетү буенча чамалыйм — авылда медсестра булып эшләүче кыз булырга тиеш. Арттарак — Фәүзиянең апасы.

Фәүзия апасына караганда да, миңа караганда да кыюрак иде, башлап ул сүз катты. Исәнләштек, көлештек. Ярый әле, шундый вакытларда көлешү йоласы бар. Бер-береңне аңлашуда күзгә-күз карап елмаешудан да мәгънәлерәк чара бар микән? Икәү генә түгел, өчәү-дүртәү бергә килгән дуслар арасында да уртак тойгылар гөрләп көлешүдә табыла...

Әхсән Баян белән бәхәскә керәсем килми, әйе, тавыш та табигать бүләге. Ләкин табигать ул бүләкне кешегә генә түгел, сандугачка да, каргага да биргән, ишәктән дә кызганмаган. Меңнәрчә төр бөҗәкләрне дә өлешсез калдырмаган. Хәтта агачлар, ташлар да мәхрүм түгел бу бүләктән. Ә көлү!..

Көлү — табигать тарафыннан фәкать кешегә, бары тик кешегә генә бирелгән бүләк!

Кәрим абзый безне күрештерде, җор теле белән күңел кылларыбызны чиртеп, шаян тойгыларыбызны кузгатты да үз юлына китте. Без, яшьләр, аңардан башланып калган көлешүебезне дәвам иттердек. Нәрсәдән генә көлешмәгәнбездер. Иң башлап, келәт эчендәге тәртипне, чисталыкны мактап көлдердек кызларны.

— Тәрәзәсе булмаганга гына шулай күренә ул, — дигән булдылар.

Тәрәзәсе булмаса да, зур ишеге тутырып ачып куелганлыктан, келәт эче ярыйсы ук якты һәм, чынлап та, келәт өчен җитәрлек җыйнак, чиста иде.

— Кияү ябар өчен махсус җыештырылган бүлмә бу, — диде Хөсәен. — Әнә, көзгесе дә бар.

— Бизәнеп беткәч, кияү килгәнче укый торырга китаплары да җитәрлек!..

Мондый «кызык» сүзләргә нинди кыз көлми түзсен. Ә кызлар көлгәндә малайлар ничек тыныч утырсын!

Ләкин бу көлешү генә көлешү булмаган икән әле. Көтмәгәндә-уйламаганда, өй ишегеннән шыр ялангач диярлек бер бәләкәй кыз атылып килеп чыкты. Бәләкәй дисәң дә, оялуның нәрсә икәнен бик яхшы белерлек яшьтә булгандыр, күрәсең. Безне күрепме, әллә тавышыбызны ишетеп, коты очып, шып тукталды да, шул ук секундта ялт кире борылып юкка да чыкты. Без аның бары елтыр күзле, тузган чәчле чәчрәп торган кара кыз икәнлеген генә шәйләп кала алдык.

Бу тамашадан көлешеп туктарга өлгермәдек, каршыбызда бер кечкенә малай пәйда булды. Каяндыр келәт артыннан мыштым гына атлап килә иде ул. Күренеп тора, ялгыш кына түгел, ят тавышлар ишетеп, нинди кешеләр икәнен белү өчен, аңлы рәвештә килгән. Шулай да якын ук елышырга кыймады, бераз читтәрәк тукталып калды. Сәламәтлеге алсу кызыл йөзенә генә түгел, бөтен торышына бәреп чыккан таза малай. Көлми дә, елмаймый да. Аның шулай, нигә көлә бу җүләрләр дигән сыман, гаҗәпләнеп безгә карап торуы үзе көлке тоелды.

— Бу нинди баһадир?

— Кем малае син? Исемең ничек?

Дәшми. Йөзендә каушау яки курку билгесе дә юк.

Монда да Фәүзия арадашлык итте. Малайны алдына алды, иркәләп башыннан сыйпады.

— Исемеңне әйт, туганым. Абыйларның беләсе килә.

Малайның йөзендә сизелер-сизелмәс кенә елмаю билгесе күренде. Шулай да җитдилеген саклаган хәлдә, яшенә күрә калынрак, басынкы гына тавыш белән исемен әйтте:

— Мидхәт.

«Әтиең кем? Әниең? Сиңа ничә яшь?» кебек сораулар ява башлагач, малай түзмәде, үзенчә, мондый шомарган сораулар туйдырды инде диюе булдымы, әллә, чынлап та, кирәкле берәр эше исенә төштеме, кинәт кенә салмактан җитезгә әйләнеп, китеп тә барды.

— Сурьюзный малай күренә! — дип куйды Хөсәен.

— Гордый!..

Фәүзия апасы аның, чынлап та, «гордый» икәнлеген күрсәткән бер кечкенә вакыйганы искә төшереп, сүрелә башлаган көлешүне яңартып җибәрде.

Күпчелек авыл кешеләренә хас булганча, ул елларда Кәрим абзыйларның да төп ризыклары күбесенчә ипи белән бәрәңгедән гыйбарәт икәнен бик яхшы белгән күрше хатын, әзрәк шаяртып, әзрәк мыскыл итәргә дә теләп булса кирәк, сорый икән Мидхәттән: «Нишләп син болай бик тиз үсәсең, ничек болай тазарасың? Нәрсә ашыйсыз сез?»

— Пилмә-ән ашыйм, — дигән Мидхәт җитди генә тавыш белән, — бәле-еш. Бавырса-ак...

— Ай, замана баласы!..

Көлештек тә оныттык без аны.

Еллар үткәч, шушы малайның танк командиры сыйфатында Бөек Ватан сугышы кырларында күрсәткән батырлыклары турында миңа очерк язарга туры килер дип, шул ук замана баласы Украинаны азат итү өчен барган сугышларда бер аягын калдырып кайтканнан соң, укып, тарих фәннәре докторы профессор Мидхәт Кәримович Мөхәррәмов булыр, китаплар язар, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында тел, әдәбият һәм тарих институты белән җитәкчелек итәр дип кем уйлаган!..

Икенче көнне безне туйга чакырдылар.

Габделхәйләрнең күрше кызы кияүгә чыга икән. Ярлы гаиләдән. Өйләре кечкенә. Кияү буласы егет тә байлардан түгел. Габделхәйнең әни-

ләре белән сөйләшеп, туйны аларның өендә үткәрергә булганнар. Өй хуҗасы буларак, Габделхәй мәҗлеснең түрендә утырырга хаклы кеше. Аның иптәшләре итеп, Хөсәен белән мине дә чакырдылар.

Туй дигәннәре, кода-кодагыйлардан да бигрәк, кияү белән кәләшнең иптәшләреннән-ахирәтләреннән җыелган гадәттәге аш мәҗлесе булып чыкты. Мәҗлеснең түрендә кияү белән кәләш утырасы. Бары да әзер. Тик мәҗлеснең ни өчендер башланып китә алмый торуы гына яшьләрнең беркадәр кәефен кыргандай булды.

— Нәрсә көтәбез соң?

Мулла килеп җитмәгән икән. Кияү буласы кеше, карап торуга зур гәүдәле, симез генә битле, ләкин «с» авазын әйткәндә теш арасына тел очын кыстырып, сабыйларча сакау әйткәнлектән, гөнаһсыз бала сыманрак тәэсир калдыра торган, Сәми исемле егет иде. Тик беренче карауга гына шулай. Чынлыкта исә, Яңавылда, ягъни ярлылар мәхәлләсендә, үскән шук малай. Кем каршында да үзен җәберләтә торганнардан түгел. Сайлаган кәләше дә үзенә пар килгән гаиләдән. Чая кыз. Туйларын яңача, яшьләрчә генә үткәрергә тәвәккәллекләре җитсә дә, никахсыз ук кушыласылары килмәгән, күрәсең. Мәҗлес никах уку белән башланырга тиеш икән. Мулла белән дә сөйләшенгән.

— Нигә һаман юк соң ул, бәлеш корты?

— Ялындыра, садака козгыны!

— Акчалырак җиргә чакырсалар, җилән чабуларын канат итеп, очып килер иде әле!

— Сабыр итегез, җәмәгать. Чүтеки мулла бит ул, үз җае белән килеп җитәр...

Һәм хәзрәт булган кеше өчен гафу итәрлек дәрәҗәдә генә кичегеп, Гыйният мулла килеп тә җитте. Сәлам бирде. Аны, олылаудан бигрәк иптәш күреп дигәндәй, үз кешеләрчә каршы алдылар. Түрдән урын бирделәр. Тәкъдим ителгән урынга тәкәллефсез генә кереп утырды.

— Туй мәҗлесен яшьләргә никах укудан башлап җибәрергә кирәктер дип уйлыйбыз инде, хәзрәт! — Моны Сәми ягыннан кода булып килгән бер яшь кеше әйтте. Күрәсең, табынчылык вазифасын аңа алдан ук билгеләп куелган булгандыр, ул үзен хуҗаларча иркен тота иде.

— Бик мәслихәт, — диде мулла тыныч кына. — Туегыз заманча булса да, шәригать кушканны онытмавыгыз бик әйбәт, бик хуп. Рәхмәт! Ыһым-ыһым... Кирәкле кәгазегез бармы?

— Анысы нәрсә тагы?

— Язылышу турында сәвиттән пичәтле кәгазь булырга тиеш.

— Менә анысын алдан белмәгәнбез икән, хәзрәт. Ну ничава. Никахы булса, язуы әллә кая китмәс. Иртәгә үк алып бирербез.

— Булмый, туганнар, законга каршы бара алмыйм.

Моңарчы тешен кысып түзгән кияү дә телгә килде.

— Бөгештермә инде, мулла, — диде ул коры гына. — Курыкма, буш итмәбез!

Эш болайга киткәч, мулла сөйләшеп тә тормады.

— Бигайбә! — диде дә, тыныч кына атлап, чыгып та китте.

Аның артыннан әйтеп, кычкырып калынган әрләү, каргау, сүгү, мыскыл итү сүзләренең исәбе-саны юк иде. Мулла кире борылмады. Бәлки хаклы да булгандыр. Бәлки, закон исеменә ышыкланып, изге йолаларга хөрмәтсез караучы яшьләрдән үзенчә үч алырга теләгәндер. Ни булса да, кияү белән кәләшнең хәлләре мөшкел иде. Бер мәлгә нишләргә белми таралып калдылар. Ыгы-зыгы купты. Туй мәҗлесенең башланмас борын ук рәте китте.

Кемдер шунда, бу уңайсыз хәлдән котылуның иң әйбәт юлын тапкан кебек, шатланып, дәртләнеп, кычкырып җибәрде:

— Җәмәгать! Кызыл туй ясыйбыз!

Өй эчен тутырган шау-шу кинәт басылып калды. Бер-ике секунд кына дәвам иткән тынлыктан соң, тагын да көчлерәк булып, яңадан күтәрелде.

— Ура-а! Кызыл туй!..

— Кызыл туй, кызыл туй!..

— Никахы үзенә булсын!..

Кияү белән кәләш, үзләре комсомол булмасалар да, мондый җай табылуга шатландылар гына. Бөтенебез берьюлы җанланып киттек. Тәртибен кем өйрәтте, кем житәкчелек итте, күп булса бер сәгать вакыт үткәндер, клуб хезмәтен үтәүче йорт халык белән тулды. Башланмаган мәҗлес өстәле яныннан кубарылган яшьләр яки кода-кодачалар гына түгел, кызыл туй күрәсе килгән бөтен кеше җыелган иде.

Гармун моңына кушылып кемнәрдер җырлаган арада туй җыелышының президиумы пәйда булды. Иң уртада кияү белән кәләш. Култык астына зур кенәгә кыстырып, авыл советы хезмәткәре дә килеп житкән иде. Кемдер тантаналы төстә кызыл туй җыелышын ачты. Яшьләрне бөтен халык алдында кенәгәгә яздылар. Гармун. Кул чабулар. Котлаулар...

Мин үземне очраклы рәвештә килеп чыккан бу күңелле тантананың уртасында хис итә идем. Эндәшми кала алмадым. Трибунага чыгып яшьләрне котладым. Карамалыда ячейка секретаре булып эшләп, телгә бераз шомарган идем инде. Сүзгә аптырамадым. Халык күз алдында, совет законы нигезендә, үз телебездә беркетелгән гаилә шайтан да аңламый торган гарәп телендәге никах белән ясалган гаиләгә караганда бәхетлерәк, ныграк, ирекләрәк булырга тиеш, дидем. Туйның шушылай халык алдында булуы яшьләрнең үзләреннән дә гаилә мәсьәләсендә җаваплылык соравын әйттем...

Тантаналы язылышудан соң, үзеннән-үзе диярлек, концерт оешып китте. Җырлаучылар да, биючеләр дә, төрлечә кыланып көлдерүчеләр дә табылды.

Концерт тәмамлануга, безне Габделхәйләр өендә башланмый калган аш-су мәҗлесе көтә иде.

Кызыл туй турында ишеткәнем дә, газеталардан укыганым да бар, ләкин үз күзләрем белән күрергә туры килгәне юк иде әле. Дөрес, Җиргән татарлары арасында беренче буларак, анда да шулай очраклы рәвештә, алдан оештырусыз-нисез килеп чыккан бу туйның йолалары килеп бетмәгәндер. Ямьсез яки законга сыймаган яклары да булгандыр. Шулай да яшьләр арасында яңалыкка омтылуның, мәхәббәт-гаилә мәсьәләләрендә дә алынган иректән файдаланырга тырышуның бер күренеше иде бу.

**Пароход. Дәрьяның көче.**
**Алда — Казан!**

Пароходны беренче күрүем дисәм, бик үк дөрес булмас иде. Язгы ташу вакытларында Стәрлетамакка бер-ике тапкыр пароход килә, аны каршы алу яки озатудан да бигрәк, күреп калырга бөтен шәһәр халкы диярлек пристаньга төшә иде. Елга бер генә килә торган бу тантанадан, әлбәттә, мин дә читтә калмадым. Бер этажлы гына булса да, ул вакытта миңа тау чаклы булып күренгән «Зюид» пароходының колакларны ярырлык итеп гүләве, көче-гайрәте эченә сыймагандай, уфылдап-пуфылдап, Идел өстен айкап, болгатып, яр күперенә килеп бәрелүе чын могҗиза булып тоелды. Аның эченнән бөркелеп чыккан шат чырайлы, бәйрәмчә киенгән кешеләр дә безнең шикелле гади адәм балалары гына түгел, гүя бөтенләй бүтән дөньядан килгән зур бәхет ияләре. «Пассажир», «дебаркадер», «палуба» кебек матур, серле сүзләр

дә таныш түгел әле. Пароходны, аның күккә ашкан мачтасын, гәүдәсенә карый кыскарак булган юан морҗасын, ул морҗадан чыккан куе төтенне күрү, дәһшәтле гүелдәвен ишетү — үзе зур бәхет!

«Мә, рәхәтлән!» дигән шикелле, ул тагын сузып кычкырта башлады. Гүелдәп туктагач та: «Җитмәсә, мә, тагы!» дигәндәй, кыска-кыска гына итеп, янә ике тапкыр кычкыртып куйды.

Авырлык белән генә кузгалган пароход ярдан аерылу белән йөрешен тизләтә барды, иләмсез зур борылыш ясады, төньякка таба әйләнде. Саубуллашу урынына тагы берничә кыска-кыска гудок биреп, эзенә төште — Уфа ягына юл тотты.

Яр буендагылар да, пароход өстендәгеләр дә бер-берсен күздән югалтканчы яулык болгаштылар.

Пароход белән килеп төшүчеләр арасында да, аңа утырып китүчеләрдән дә бер генә таныш кешем дә булмагандыр. Шулай да гомеремдә беренче күргән бу хәйран тамашага тыныч кына карап тора алмадым. Бәйрәм иде бу миңа. Тантана! Күңелем нииндидер шатлыклы да, ашкынулы да, борчулы да хисләр белән тулды. Моңарчы пароходның үзен күргәнем булмаса да, аның турында җырлар ишеткәнем бар иде.

Прахут килә, прахут килә, прахут күрми калабыз.
Яшь гомерләр узып бара, рәхәт күрми калабыз!..

Җырның беренче юлы икенчесенә йогыш килсен өчен уйлап чыгарылган буш сүзләр кебек кенә тоела иде миңа. Алай гына түгел икән. Пароход турында гына түгел, ата-бабаларыңның төшенә дә кермәгән яңалыклар килү турында сүз бара икән. «Яшь гомерем шуларны күрми узып китә бит!» дип өзгәләнә икән ниндидер тынгысыз йөрәк!

Кузгалып китү белән йөрешен тизләткәннән-тизләтә барган пароходның ерагайган саен тизлеге акрыная төшкәндәй булды. Ул хәзер бер дә ашыкмый, бары әкренләп кенә кечерәя бара сыман иде. Ниһаять, ул күздән югалды. Озатучылар да таралып бетте шикелле. Ә мин торам. Уйларым-хисләрем белән һаман инде күздән югалган пароходтан аерыла алмыйм. Тагын бер җыр хәтергә килә:

Пароход, кычкырасың! Эчемне пошырасың!
Туган-үскән якларымны исемә төшерәсең!

Бу җыр миңа киресенчә тәэсир итә. Ерак илләрдә дөнья гизеп йөрүче, туган илне читтән торып сагынучы серле кешеләр дөньясына алып китә.

Эх, шул күздән югалган пароход өстендә яңадан-яңа җирләр, яңадан-яңа калалар күреп барасы иде. Эх, олагасы иде әллә кайларга! Күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга!..

Өч кенә ел элек татлы хыял булган шул теләгем гамәлгә аша түгелме соң? Менә мин тагын пристаньда. Уфа пристане. Монда инде теге карсак «Зюид» яки «Ост»лар гына түгел, икешәр катлы зур пароходлар, Казанга кадәр баручы «Габдулла Тукаев»лар, «Шәһит Ходайбирдин»нар, ниндидер «Чермаз»лар...

Шул «Чермаз» дигәнен көтәбез. Билет кесәдә. Йөзләрчә пассажирлар белән бергә дебаркадер өстендә чайкалабыз...

Пассажир! Дебаркадер! Нинди матур, яңа мәгънәле сүзләр? Үзләре бер гыйлем!

Күңел кузгалган. Сәяхәт дәрте эчкә сыймый.

Таныш түгел юлга чыкканда иң кирәк әйбер нәрсә икән дисез? Акчамы? Түгел. Азык запасымы? Түгел. Документ? Түгел. Иң кирәге — ышанычлы иптәш!

Без, нәкъ яз көне үк сөйләшкәнчә, өчәү. Иптәшләрем: Барый Дәминов, Мөкаддәс Рәхмәтуллин. Бер-беребезгә ышанганбыз. Бездән дә ба-

тыр, бездән дә кыю кеше юк. «Чермаз» килеп туктап, ишеген ачуга, беренчеләрдән булып, кереп тә киттек.

— Дүртенче класс кайда?

— Кайда урын тапсаң, шунда!

Өзлексез шаулап, гөрләп һәм эссе бәреп торган машина бүлегенә якын гына ярым караңгы, тыгыз аралыкта тезелеп утырган мичкәләр янына килеп чыгуга, Мөкаддәс, шатланып, кычкырып җибәрде:

— Менә шәп урын!

— Булды! — дип куйды Барый да. — Тукталдык шушында.

Утыртып куелган мичкә төпләре, чынлап та, бик уңайлы иде. Теләсәң икән — менеп утыр. Кирәк булса, өстәл урынына файдалан. Җитмәсә, якында гына эче куыш итеп урап куелган юан аркан өеме. Артык әйберең булса, эченә сал да куй. Кайнар су агып торган кран да ерак түгел.

Озак та үтмәде, аралык бөтенләй тулды. Капчыклы пассажирлар мичкә яки аркан өсләрен генә түгел, стена буйларындагы как идәнне дә алып бетерделәр. Атлап йөрер әмәл калмады. Әй, шатланабыз. Янәсе, иң шәп урынны эләктереп калганбыз.

Иләшә төшкәч, белдек, дүртенче классның иң шәп урыны — пароходның койрык ягында, утырыр өчен махсус эскәмияләр куеп ясалган зур гына бүлмә булган икән. Юл йөреп тәҗрибә күргәнрәк кешеләр шунда урнашкан.

— Эх, алданрак белгән булсак!

Ләкин кайгырмадык. Без бит анда бары ашаган-эчкән чакларда гына булабыз да төнлә килеп йоклыйбыз. Өске этажга иләшеп алдык. Көн буена палубада йөрибез. Агыйдел буе күренешләрен карап барабыз. Үзебезне булачак художниклар хис итеп, һәр күренешкә рәсем күзе белән карарга, һәр нәрсәнең гади кеше күрми торган матурлыкларын, үзенчәлекләрен күрергә тырышабыз. Берәүдән дә тартынмыйча, кычкырып сөйләшәбез: тойгыларыбызны уртаклашабыз. Беренче-икенче класста баручы пассажирлар да моңа игътибар итте, ахрысы, безгә хөрмәт белән карыйлар. Хәтта тәртип саклап йөрүче матрослар да безне кумый, өске этаж пассажирлары итеп таный башладылар.

Шулай, аска төшсәк — аста, өскә күтәрелсәк — өстә үз кеше булып, шатлыгыбыздан кая басарга, ни кыланырга белмичә, бәйрәм итеп барабыз. Кирәге булса-булмаса да, бер генә пристаньга да төшми калмыйбыз.

Агыйдел буеның гүзәл күренешләреннән аеруча хәтердә калганы — аның «Сандугач бугазы» дип йөртелгән тар урыны булгандыр. Тал-тирәкләр, әллә ничә төрле куаклар белән капланган ике як яр да пароходка шул кадәр якын, хәтта бу безгә гайре табигый тоела. Идел, менә шулай тарайганнан-тарая барыр да, пароход үтә алмас дәрәҗәгә килеп кысылыр сыман тоела. Елга тарайган саен, аның агымы катылана бара. Безгә исә пароход үзе шулай ашыга, бу хәтәр арадан тизрәк узып котылыйм дип, йөрешен тизләтәдер кебек күренә.

*Агыйдел сулары кебек тар сулар булмас инде!..*

Бу җырны бәлки берәр шагыйрь йөрәкле пассажир шушы «Сандугач бугазы» аша узганда чыгаргандыр?..

Күңелдә тагын да тирәнрәк эз калдырган урын — Агыйделнең Камага кушылган урыны иде.

Бу юлдан безгә кадәр узган кешеләрдән ишеткәнебез бар иде инде. Дөрес икән. Ике елга, бер үзәнгә килеп кергәч тә, тиз генә кушылып, аралашып китә алмыйлар. Агыйдел суы, саф, якты тасма булып, бик озак вакыт карачкыл-болганчык Кама суы белән янәшә бара. Аннары гына алар, акрынлап, бер-берсенә аралаша башлыйлар. Күп тә үтми, көмеш Агыйдел каралҗым Кама суына йотылып югала...

Ике елга бергә килеп кушылган урынның ниндидер серле мәгънәсе, үзенә хас сихри бер романтикасы бар. «Тамак» сүзе белән тәмамланган географик атамалар, авыл яки шәһәр исемнәре азмыни? Юкка гына түгелдер.

Елгалар кушылышы — һәр кечкенәнең зурга омтылу символы. «Чыпчык тезеннән генә» булган Стәрле елгасы үзеннән шактый зур Ашказарга килеп кушылды. Аның хисабына зурая төшкән Ашказар дәвам итә. Озакламый ул да үзеннән зуррак елгага — Агыйделгә килеп тоташты. Һәм шунда өзелде. Агыйдел калды. Ниһаять, менә Агыйдел дә, юл уңаенда үзенә килеп сыенган бик күп инешләрне эченә ала-ала, озын, бормалы-бормалы һәм искиткеч гүзәл юллар үтеп, Камага килеп житте. Кушылды. Хәзер инде безнең алда Кама гына калды. Алабуга малае атаклы Шишкинны сокланып туймаслык пейзажлар язуга рухландыручы, мәһабәт урманнары, серле-сихерле ярлары, легендар тарихы, өметле киләчәге булган калалары белән үзенә генә хас матурлыкка ия Кама елгасы! Халыклар күңелендә чиксез бай һәм катлаулы тарихы белән сакланган Чулман бабай! Вакыт житәр, без аның зур Иделгә йотылганын күрербез!

Буеннан-буена олы Россиянең бик күп халыкларын үз куенына жыйган бөек Идел! Вак-вак елгалар бер-берсенә кушыла-кушыла, әнә кая барып житте! Ләкин бу мәһабәт, мәгънәле процессның бөтен гүзәллеге — аның мәңгелек күренеш булуында, өзлексез дәвам итүендә! Минем өчен ул бүген дә яңа, иртәгә дә! Елгалар кушылды, зурайды. Ләкин берсе дә бетмәде. Һәр кушылдык, бөтен гүзәл үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, үз тирәсендә булган табигатьне, тереклек дөньясын юмартлык белән сугарып килә. Кушылдыклар исән булсын! Чиксез зур уңышлардан башы әйләнер чиккә житкән фәнни-техник революция лавалары аларның чыганакларын томаламасын, юлларын бумасын! Төрле майлардан, газлардан бушап калган куышлыкларны тутыру өчен аларны кире жир астына куып бетермәсен.

Дәрьяларның көче кушылдыкларның исән булуында!..

Кама тамагында безне хәйран калдырган яңалык... алма базары күрдек. Ишеткәнебез бар иде барын. «Анда алманың бидрәсе утыз тиен», диләр иде. Без, алма үстерми торган як малайлары, шундый затлы, шундый ләззәтле жимешнең арзан жирен күрербез дип куанышсак та, «бидрәсе утыз тиен» дигән сүзне экияткә саный идек. Алма бәрәңгедән дә арзан буламы соң, жүләр?!.

Тәки чын булып чыкты бит! Пристань базары тулы алма. Капчыклап та чиләкләп. Дөрес, чиләгенә бер сум сораучылар да бар. Илле тиенгә бирәм дип торучылар да байтак. Сортына-сыйфатына карап шулай төрле хак сораулары булгандыр инде. Ә без ул вакытта алманың начары яки тәмсезе буладыр дип уйламыйбыз да. Бөтенләй черегәне генә булмасын. Эреме-вакмы? Нинди сорт? Алмамы — алма. Хәтта корт тишкәнен дә ташлыйсы түгел. Алманың тәмсезе буламыни?

Тәмлесе-тәмсезе булганын аермасак та, кыйбатлысы, арзаны барлыгын белдек. Утыз тиен сораган сатучыны егерме биш тиенгә ризалаштырып, эреле-вaклы, кызыллы-яшелле, кортлы-кортсыз бер чиләк алма алып кердек. Күңелебез булганчы ашадык. Хәтта инде без алманың бары да бер иш түгел икәнлеген дә аера башладык. Әйе, бар иде ачылары, бар иде төчеләре-баллылары. Мәгәр тәмсезләре... безнең өчен юк иде...

Үзебезгә калса, нәкъ байларча, алма ашый-ашый, «Чермаз» пароходының өске палубасында Идел киңлекләренә килеп чыктык. Пароходыбыз кечерәя төшкәндәй булды. Дөнья зурайды, иркенәйде. Мәһабәтләнде. Соңгы пристаньны уздык бит! Алда — Казан! Хыялыбыз күгендә ничә еллар буе якты йолдыз булып балкыган кала!..

## Равил Фәйзуллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Теләк

Көннәр, төннәр үз көенә
алышынса — сөен генә!
Китергән мәшәкатьләрен
авырсынмый ал иңеңә!

... Борчудан, йокысызлыктан
көнгә әйләнгән төннәр яман!
Җанда кайгы-болыт булып
төнгә әйләнгән көннәр яман!

Тыныч йөзеңне төн япсын.
Керфегеңнән таң уятсын!

### Бишбармак

Йодрык — төен. Ул язылса —
аерылыр бармаклары...
Өчпочмаклар булып калыр —
Өзсәң йолдыз канатларын.
Бишкә бүлсәң бер халыкны —
аннан — исем калыр бары...

### Хәтер

*Ветеран җыры*

Олыгайган саен йокылар сак.
Үткәннәргә Хәтер еш кайта.
Кайчак таңнарның да алсулыгы
сугыш яраларын кузгата.
Утны-суны кичкән ирләрнең дә
күңелендә күпме моң ята!

Әй, син, Хәтер, гомер язларыннан
яшьлекләрне безнең чакырып ал!
Җырлыйк, дуслар!
Безнең гомерләрдә,
безнең бу көйләрдә
кайтмый калганнарның хакы бар!

Талгын гына аккан сулар кебек,
тыныч кына еллар агалар...
Тормыш үзәгендә — яңалар.
Чирәмнәрдә уйный балалар.
Сорый Хәтер: яшьли киткәннәрнең
дәвамчысы булалырмы алар?

Әй, син, Хәтер, гомер язларыннан
яшьлекләрне безнең чакырып ал!
Җырлыйк, дуслар!
Безнең гомерләрдә,
безнең бу көйләрдә
кайтмый калганнарның хакы бар!

## Казан

Кем белгән ул түккән кан-яшьне!
Кем белән ул туган ел-яшьне!
... Әләмдәй чайкала агачлар —
ямь-яшел...

## Безме соң бу? яки Хушлашкач янә бер очрашу

Хыялланып, балкып-янып сөйләр сүз юк.
Элеккечә очып түгел,
шуышып кына чыга сүзләр.
Утырулар шул ук,
урындыклар шул ук...
сөйләшүләр бөтенләй бүтән!

Һава хәлләреннән зарланулар,
эчә торган чәйнең мәтрүшкәсен мактау,
әдәп өчен «хәлең ничек?» диеп сорашулар,
уртак танышларны искә төшерү,
һәм тагын чәй,
һава хәлләре...

... Кисәк-кисәк икебезнең дә искә төшә
шашкан чаклар (сизәм): яхшысы да, яманы да...

Тик аларны искә төшерүне
белгертәсе килми бер-беребезгә.

Күзләр генә ара-тирә, онытылып,
очкынланып ала
элеккечә!..

## Ирешү

Атым — акбүз. Иңдә — җилән. Башта — бүрек.
Киттем тауга үзәннәрдән качып.

... Мендем. Торам. Ялгыз. Атым — үлде.
Тауда — җилләр. Ялан башмын. Күкрәк — ачык...

## Иске блокнотлардагы исемнәр

Хыял тулы юллар арасында
теркәлмәгән нинди исемнәр!

Кайберләрен хәзер күргәч —
күңел укшый.
Кайберләре — бөтенләй тәэсирсез.

Ә менә бар шундыйлары! —
исемнәрен эре итеп, алтын белән
язып чыгасы килә
дөньядагы бөтен-бөтен диварларга!

●

Туфрагында сөрелгән зиратларның,
көлләрендә яндырылган китапларның,
«аһ»ларында чыга алмаган сүз-уйларның —
һәммәсендә Б е з бар.
Җиңүчеме, җиңелүчеме —
барыбер...

## Чегәннәр

Юл читендә чатырлары.
Башкалада — театрлары!
... Сәнгате чыкмаса юкка —
үлем юк халыкка!

## Искәртү

Каршы төшсә дус дуска!..
— «Тел — озын, гомер — кыска!»

## Шәм яки бер мәҗлестән калган хатирә

Шаулы кунаклардан төн буена
мәдхияләр яуды бу шәмгә!
Бокал күтәргәндә шат шәүләләр
гел уйнаклап торды түшәмдә.

Аннан кайсы кайда йоклап китте,
тәмле изрәп үзенең гамендә...
Таңны каршылады үз нурында
онытылган ялгыз шәм генә...

●

Әле болай дөнья, әле алай...
Гел үзгәреп тора бәя дә.
Фронтовиклар кими барган саен
сугыш батырлары күбәя...

●

Былбыл сайрый. Кеше җырлый.
Һәр икәве — канатлы!
Шагыйрь җанның бар өстәмә
канатлы тулпар аты!

...Җыры артык көчле булса,
имгәтерләр канатын.

## Хәтерләтү

Тау күчкәндәй
килде күкрәп кургаш болыт.
Дәһшәт булып,
яуды күкрәп, яуды орып!

... Хәзер тынып, китеп бара.
Тетелгән мамыктай — сыек, тонык.

... Күккә сүзсез баккан карт җырчы.
Искә алдымы яшьлек тавышын?
Яңагында көмеш тамчылар...

●

Корт чебене белән бергәләп
гөлгә кунып йөрде күбәләк...

Бер уйласаң, бары шул гына!..

...Ак эшләргә хаклы тик гали җан,
керсез вөҗдан, чиста кул гына!

## Кайтаваз

«Бу дөньяда син бар өчен
Табигатькә — рәхмәт! Рәхмәт!»
«Очраштырган көннәр өчен
Язмышларга — рәхмәт! Рәхмәт!»

Кайсыбыз әйтте бу сүзләрне?
Истә түгел. Хәтерләрдә калган бары —
Рәхәт! Рәхәт!

... Гомер кичкәч килде аваз:
«Ул көннәргә — нәфрәт! Нәфрәт!»
Еллар аша менә нинди
кайтавазлы булган Р ә х ә т!..

Ә шулай да, ул көннәргә
барыбер — рәхмәт! Рәхмәт!

●

Мин Ирекне тойдым, татыдым тәмен.
Татыган саен... сусадым гына!

Баер дип күңелем, коендым Сөюдә —
бушандым гына...

## Бер җавапка дүрт сорау

Очкан килеш калырмы кош күк йөзендә?
Гел торырмы буй җиткән кыз ата нигезендә?
Менә алырмы һәр теләгән шәп ияргә?
Бер гомер җитәрме сине сөяргә?

## Тагын бер кат искә төшерү

Якынлаштым, тартылдым.
Хыялландым, омтылдым.
Уйда гына очрашсам да,
ләззәтләндем, оныттылдым.

Уй бүлештем, серем чиштем,
эшемдә киңәшләштем.
Сәфәремдә юлдаш иттем,
төшләремдә эндәштем.

Тарып рәхәт газапларга,
Мәҗнүннәрчә яраттым.
Чак кына төссезләнсә дә,
хыялымда яңарттым.

Ул нишләде? Белә алмыйм...
Язмыш безне кушалмады.
. . . . . . . . . . .
...Барыбер бәхил багалмама!

## Яшьлек дәфтәрендә саф сүзләр

Аерылсак,
сагынган чакларда карар өчен
билге иткән булганбыз бер йолдыз.
Ул — күзгедәй —
бер-беребезнең карашларын
нуры аша җиткерергә тиеш.

Укыдым да, яшьлек дәфтәреннән
бу сүзләрне,
чыктым атылып
багар өчен күк гөмбәзенә.
Кайсы йолдыз соң ул? Кайсы?

Адашты күзләрем...

## Имеш, мин дә яр сөйдем!..

Мин дәшкәч, сүз катмады.
Үзе... килеп күреште.

Дәртләндем дә ярсыдым!
Имеш, мин дә яр сөйдем!..

Минем белән сер бүлеште.
Бүтән белән үбеште...

Кызыштым да ярсыдым!
Имеш, мин дә яр сөйдем!..

«Гыйшык тоталар икән!» — дип,
таныш-белеш сөйләнде!

Үчектем дә ярсыдым!
Имеш, мин дә яр сөйдем!..

...Бер көн мин дә көйләндем.
Бүтән кызга өйләндем.

Үкседем дә ярсыдым!
Имеш, мин дә яр сөйдем!..

**Марсель Галиев**

# УЛ ЧАКТА...

ПОВЕСТЬ

## 1



Кәрешкәләр төбендә нидер селкенеп куйды. Ул чалгы янавыннан туктады да, үләннәрне аралап иелә төште. Кәлтәләр сугыша икән. Үзенә бер ысылдау чыгарып, чияләнеп бәргәләнгән кәлтәләр, өсләренә кеше күләгәсе сузылуга, кинәт бер-берсеннән аерылдылар да, куе үлән арасына кереп йомылдылар. Берсенең өзелгән койрыгы гына, чыкмый калган җанын кая куярга белмәгәндәй, уңлы-суллы селтәнә башлады. Ул аны киндер бияләе белән тотып, якындагы кырмыска түмгәгенә таба китте. Кырмыска оясында мәхшәр купты. Көч сынашкан сыман, берсен-берсе алыштыра-алыштыра, әле анда, әле монда сөйри торгач, ниһаять, кәлтә койрыгын якындагы тишеккә китерделәр дә, турайтып, эчкә тартып төшерә башладылар.

Бераздан кырмыскалар хәрәкәте басыла төште. Карасаң, тирә-юньнән һәр төрле бөҗәк өстерәп кайтучы кырмыска халкы бихисап икән бит. Югарыдан алар язмышына тын гына көлемсерәп карап торучы кешене искәрмиләр дә...

— Сәйяр!

Урман эченнән дәшкән тавышка ул борылып карады. Чалгысын иңенә салган абыйсы авыр күн итекләре белән чаштыр-чоштыр чыклы үләнне ерып килә иде.

— Кая югалдың син?

— Менә, кырмыска оясы карыйм.

— Нәрсәсен карыйсың аның?

— Кешеләр үлгәч кырмыскага әйләнәләр ди...

— Кем әйтә аны?

— Үзем әйтәм.

— Һы, —абыйсы мыскыллап көлемсерәп кәгазь эшләпәсен маңгаена төшеребрәк куйды. — Көн кыздырганчы селтәнеп калыйк, үлән йомшак чакта.

Туганнан-туган абыйсын нигәдер яратып бетерми Сәйяр. Авылда бүтән якыннары булмаганга күрә генә, солдат хезмәтеннән туры аңа кайтып төште ул. Дөресрәге, әбисен күрергә дип кайткан иде. Өч ай элек

жирләгәннәр икән. Шунда хәбәр дә итмәгән абыйсы. Димәк, Сәйярның дөньяда барлыгына да битараф ул. Сәйяр чалгы сабын кысып тотты. Яратмый ул абыйсын. Әнә бит, нинди нык басып, үз-үзенә генә ышангандай, җиргә мәңгегә килгән сыман атлап бара. Һәр нәрсәгә җавабы әзер булыр. Тук чыраена мыскыллы көлемсерәү җәелдереп, кистереп кенә әйтер.

Ихатасында сарай өстендә сарай, келәт өстендә келәт — таң кояшы да күренерлек түгел. Капка төбендә тагын яңа бура өлгереп килә. Бусы нәрсәгә, дигәч, сатарга, энем, машинага акча җитми, ди. Кич җитсә, бура кебек ике сыер, капка элгечен мөгез белән генә чөеп, ишегалдына кайтып керә. Каты яшисең, ә, дигәч, ялкау гомер-гомергә ярлы булган, эшләргә кирәк, энем, ди. «Мин чабата киеп йөргән чакта, тегермәнче Сафа малае ыспай гына киенеп гармун тартып йөри идеме! Аңарда гына велосипед, аулак өйдә кызлар аңа гына карый. Китапларда гына ул ярлы егетен яраталар. Ә хәзер нәрсә... Атайдан калган малы озакка барды дисеңме. Кемнән йөз грамм тамар дип иснәп йөри хәзер! Дөнья шулай ул, бер алдын күрсәтә, бер артын. Мин ул малай янынңан тузан туздырып машина белән узарга тиеш. Шундыйларга үч итеп яшим мин!»

Тукталып кешеләрне тыңлый, гаҗәпләнә, соклана белмәгән абыйсы яныннан тиздән китәсен уйлап, Сәйяр ашыгыбрак атлый башлады. Аны ике көннән Казанда, сәнгать училищесында имтиханнар көтә. Иртәгә үк моннан китәргә кирәк дип уйлады Сәйяр. Поселокка. Татлы һәм газаплы сагыну Сәйярның күңелен биләп алды. Юк, сагыну гына түгел, ә күп нәрсә алдында көчсез булган үткәне өчен оялу, үкенү хисе соңарган бер көч булып кабынып китте. Шул бәреп чыккан гайрәтеннән котылырга теләгәндәй, ул абыйсына:

— Әйдә, минем арттан! — дип кычкырды да, калган кишәрлек кыреннан алагаем селтәнеп, каерып-каерып чабарга кереште. Алан түрендәге карт каен төбенә җиткәч, туктап маңгай тирен сөртте дә артына борылды. Абыйсы, биш-алты адым артка калып, җай гына селтәнә иде. Покосы гаҗәп тигез булып салынып бара, аяк эзләре дә Сәйярныкы кебек бер анда, бер монда түгел, ә юеш үлән камылы өстендә куе яшел чигү кебек тезелеп кенә килә.

Күләгәләр җыела төшкәч, ялга туктадылар. Кыяк кебек чалгы никадәр генә янасаң да, сурыккан печәнне авыр алдыра башлаган иде.

— Чишмә янына төшеп капкалап алырбыз, — диде абыйсы.

Чытырманлы куакларны аралап, биек ярдан аска төшә башладылар. Урман ешкынлыгында посып кына аккан Эстәрле елгасының башы иде бу. Тасмадай елтырап, куак араларыннан чишмә йөзе чагылып китә. Ярның текә урынына җитүгә абыйсы туктап калды, Сәйярга нәрсәдер аңлаткандай кулы белән ымлады. Сәйяр абыйсының җилкәсе аша яр астына карады.

— Пошилар...

Беренче карашка пошилар хәтсез булып күренде.

— Нигә дип шул кадәр җыелганнар алар?

— Бер... ике... өчәү генә бит, — диде абыйсы.

Янәшә баскан пошиларның тырпайган агач тамыры шикелле мөгезләре, бер-берсенә бәрелеп, чыкылдап куйды. Алар, агымсуга аркылы кереп яткан пошига ачулы мөгрәп, алгы аяклары белән туктаусыз тибәләр, ятканы кызганыч итеп ыңгырашып куя.

Сәйяр урыныннан кузгалган иде, абыйсы теш арасыннан мыгырданып аның беләгеннән тотты.

Ике поши һаман аяусыз тибәләр. Менә ятканы, ыңгырашып, урыныннан күтәрелә төште. Су чапылдатып тагын ауды, типкәләгәнгә чыдый алмыйча, яңадан кузгалды һәм алгы аяклары белән мүкәләп ярга таба китте. Кызгылт комлы сөзәк ярга чыгып җитүгә гөрселдәп ауды.

Теге ике поши аны бераз иснәштереп тордылар да, каршы як ярдан күтәрелеп, куаклар арасына кереп югалдылар. Сәйяр абыйсы белән йөгереп килгәндә, поши җан биргән иде инде. Абыйсы мүкләк пошиның башын җайлабрак борып куйды. Аның тереклек китеп өлгермәгән зур күзләрендә кояш нуры чагыла, борын тишегеннән карасу-кызыл кан саркый иде. Сәйярнең карлыккан тавышы дерелдәп чыкты:

— Нигә дип үтерделәр микән аны?

— Җүләр син, — диде абыйсы. — Карт поши бу. Соңгы тапкыр су эчәргә дип төшкән дә суга егылган. Җәнлекнең акылы юк димә син, үлеп-нитеп калса, суны пычратыр дип, типкәләп чыгардылар бит аны...



## 2

Поселокка житәргә ике чакрымнар ара калды дигәндә, кола ялан уртасында автобустан төшкән Сәйярга шофер гаҗәпсенебрәк карап алды. Автобус асфальт читендәге вак ташларны чәчрәтеп кузгалып китүгә, Сәйяр уңга, тау ягына таба борылды. Көмешсу төсен югалткан әремнәр аяк тиеп китүгә тузаннарын кагып алдылар. Кичәге урман һавасына күнеккән борынга төче, коры һава бәрелде. Сәйяр зеңләп торган телефон чыбыклары астыннан үтте дә, сөзәк тауга күтәрелә башлады. Уйдык-уйдык утырган әнис үләненең йомшак исе күңеленә кагылды.

Кинәт калкынып алда Чатыр тау күренде.

Сәйяр гүя галәмәт зур җәнлек сыртыннан бара. Гасырлар буена йокымсырап яткан тау уяныр да торып кагыныр шикелле.

Ул офык читендә күренгән бу тауга еракта҆н карап торырга ярата иде. Башы киселгән пирамида шикелле тау зәңгәрләнеп әллә каян үзенә чакырып тора. Чатыр тау... Аның тирәсенә елышкан сөзәк калкулыклар бил бөгеп тын калганнар.

... Беренче тапкыр ул Чатыр тау түбәсенә мәктәпне тәмамлаганнан соң менгән иде. Якыннан текә тау бөтенләй башкача икән бит. Түбәсендә әз генә исеп куйган җилдән дә кылганнар тибрәнә. Күзгә күренмәс җилләр көрмәкләшкән урында кылганнар кайный, күләгәле дулкыннар хасил итә.

Күкрәгенә тулган билгесез шатлык хисеннән үсмер чак һәм сабыйлык тойгылары бергә кушылдымы — Сәйяр ерак кинлекләргә карап кычкырып җибәрде:

— Ә-һә-һә-һәййй!

Тавышы япан киңлекләрдә бер мәлгә йотылып торды да, тау тезмәләре арасыннан өзелә-өзелә киредән яңгырады. Соңгы аваз колак төбендә бик озак чыңлап торды. Кинәт аңа моңсу, бик тә моңсу булып китте.

Зәңгәрләнеп күренгән урман артында зур җирләр, илләр бардыр. Аларга барып җиткәнче нинди адым ясалырга тиеш соң әле?.. Менә шул чынбарлыкка караган сораулар аны күңелсезләндереп, чарасыз калдырды. Әйтерсең лә Сәйяр мәктәптә ел саен бер ишекне ачып кереп, әзер баскычлардан күтәрелә-күтәрелә килде дә, соңгы ишекне ачып чыккач, олы дөнья каршында югалып калган иде. Укытучыларның әзер тәгъбирләренә, вагазь укуларына күнегеп, йокымсырап беткән уй-фикерләре белән тормыш каршысына баскач, күңелендә сәер бер курку катыш көчсезлек уянды.

Аста, бик түбәндә, төз урамнары белән җәйрәп яткан поселок аның беренче адымын кабул итәчәк. Көн ритмына буйсынган андагы хәрәкәт, эш, читтән карап кына тоеп булмый торган эчке агымнар — олы бер сер, билгесезлек булып аны куркыта түгелме? Һәм шул билгесез-

лекне ачарга, шул тормышка хокук алып кушылырга теләү аны алгысыта да иде.

Сәйяр, аяк астында яткан ташны алды да, кулын сузып, тауның сөзәкләнгән төбәгендә күпереп торган куаклыкка төбәде. Шуңа җиткерә алсам, бөтен хыялларым тормышка ашачак дип уйлады ул. Таш куаклыкның артына ук барып төште. Сәйяр, канәгатьләнеп, киртләч-киртләч кәҗә сукмагыннан аска төшеп китте.

Яфракларына тузан сарган яшь өянкеләрнең салкынча күләгәсеннән ул поселокның үзәгенә таба атлады. Чатта чәчәк түтәлләре, плакатлар белән чуарланган мәйданчык түренә урнашкан бинага җиткәч, ул тукталып калды. Бер кырые кителеп төшкән пыяла вывескага «Төзү-монтаж идарәсе» дип язылган. Сәйяр эчкә үтәргә кыймыйча басып тора бирде. Мондый идарәләргә аның бер тапкыр да кергәне юк бит әле. Күз кырые белән генә баскычта челем тартып торган кешене күзәтә башлады. Күзлекле. Юан гына гәүдәле. Түгәрәкләнеп киерелгән корсагын чалбар каешы чак җыеп тора. Начальник-фәләндер дип уйлады Сәйяр. Бераздан әлеге кеше челем көлен какты да эчкә кереп китте. Ишектән янә берәү чыкты. Көрән джемпердан. Галстук бугән. Мәйданчыкка туктаган машиналар ягын караштырып, инде кереп китә дигәндә, Сәйяр, тәвәккәллеген җыеп, аңа дәшеп өлгерде:

— Сезне бер генә минутка мөмкинме?

— Бик мөмкин.

— Сезнең идарәгә художник кирәк дип ишеткән идем.

— Дөрес ишеткәнсез.

— Мин....

— Училище бетергәнме?

— Юк, урта мәктәп.

— Алай... Танышыйк булмаса. Мин хезмәт һәм хезмәт хаклары бүлеге инженеры булам, Әхмәт Зиятдинович. Фамилиям Шәрәфиев.

— Сәйяр.

— Әйдәле кереп сөйләшик.

Кабинет ишекләренең барысы да диярлек ачык иде. Берсеннән арифмометр чытырдавы ишетелә, икенчесендә кызып-кызып сөйләшәләр. Бу бүлмәләрдә бик башлы кешеләр утыра кебек тоелды Сәйярга.

Кабинетына кергәч, Әхмәт Зиятдинович:

— Мондый эш сорап синдәй яшь кешенең килгәне юк иде әле, кызык, — диде. — Лозунглар яза беләсеңдер инде. Пыялага ничек?

Сәйяр төбәп бирелгән бу сораудан кызарып куйды. «Дөньяда әдәм баласы булдыра алмастай эш юк»,— дия иде әбисе, димәк, беләм дию гөнаһ түгелдер.

Шәрәфиев биргән рәсемне ватман кәгазенә зурайтып, Сәйяр икенче көнне үк ясап китергәч, Шәрәфиев гаҗәпләнеп куйган булды.

— Булды дамыни? Кая әле?

Рәсемне өстәлгә җәеп салды, аскы иренен тешләре белән әвәләп алды. Инженерның соры күзләре вакыт-вакыт кысылып бетә, уртасы ярыклы калын иреннәре дә, күзләр иркенә буйсынып, сизелер-сизелмәс кенә эчке бер хәйләкәрлек белән елмая иде.

— Яраган бу, хәрефләрең эрерәк сыман, пропорцияне сиземләп бетермисең, зарар юк, анысы тәҗрибәдән тора. Әйдә әле, постройком председателенә күрсәтеп чыгыйк.

Коридорның түр ягындагы кабинетка керделәр. Киң өстәл артында утыручы киң җилкәле кеше башын аска иеп, керүчеләргә күзлеге өстеннән төбәлде.

— Менә, Җомай Әхмәтбаевич, яшь рәссам үзе.

Постройком председателе вәкарь белән генә урыныннан күтәрелде.

— Бозылмаган яшь егет. Унны гына бетергән, — дип өстәде Шәрәфиев һәм Сәйярның эшен өстәлгә җәеп салды.

Постройком председателе рәсемгә карап озак кына дәшми торганнан соң кинәт:

— Молодец, — дип куйды.

Күкрәк читлегеннән гөмбердәп чыккан бу ышанычлы тавыш рәсемнең, чынлап та, әйбәт чыкканлыгына шик калдырмады.

— Тору кайда инде синең?

— Авылдан мин. Әби янында үстем. Мәктәпне монда бетердем. — Сәйяр постройком председателенә күз кырыен гына төшереп алды. «Борыны бигрәк тупас, тау битеннән убылып төшәргә торган таш кебек. Ташының да нинди әле, җил уйган шадралысы», дип уйлады Сәйяр.

Бераздан ишекне сак кына ачып, бик пөхтә киенгән ир кеше керде.

— Җомай Әхмәтбаевич, минем теге, ясле турындагы заявлениены карамадыгызмы?

— А как же! Сездәй инженерларның кадерен беләбез инде аңысы. Бер атнадан булыр.

— Рәхмәт. Шул иде йомышым, гафу итегез.

Ул чыгып киткәч, Җомай Әхмәтбаевич мыскыллы елмаеп әйтте:

— Килгәненә ике генә ай, күзгә күренеп картайды. Җитди булган булып, җыерчыклар чыгарып утыра.

— Эш рәтен белеп бетерми әле, ул, — диде Шәрәфиев.

— Менә-менә, я эш сине буйсындыра, я син — эшне.

— Артык ышаныч та кайбер киртәләрне җимерүгә китерми микән?..

— Дөрес җирдән җимерсәң, сукмак салына ул! Пәйгамбәрләр заманы түгел, эш, хәрәкәт заманы. — Җомай Әхмәтбаевич ишекле-түрле йөренә башлады, кисәк кенә чалбарын күтәреп куйды. «Урында эшләүчеләргә хас сыйфат. Аның калын тавыш белән һәр сүзне җиренә җиткереп төгәллә әйтүе үзенә буйсындыра кебек. Мәһабәт буе, көчле тавышы белән монда кергән һәммә кешене «йөгәнләп» аладыр бу. Кара нинди: һәр авазы почмакланып чыга да, кыры белән йөрәккә бәрә», дип уйлады Сәйяр.

Ул көнне Сәйяр эшкә керү турында гомерендә беренче тапкыр гариза бирде.

## 3

Беренче эш көнендә үзенә бирелгән остаханәне чистартып маташканда, ишекне киереп ачып, авыз эченнән җиңел генә көй көйләп, бер көн идарә баскычында чилем тартып торган такыр башлы кеше килеп керде.

— Аһа, безнең ыругка яңа кеше өстәлгән икән! — дип, буынлы-буынлы кыска бармаклардан торган кулын Сәйярга сузды. — Таныш булыйк, Әсфән Сафич булам. Идарәнең баш диспетчеры. Фамилиямне әйтеп тормыйм Бибишев икәнен, машина-фәлән кирәк булса, белеп килерсең.

Ул тәбәнәк кешеләргә хас гадәт белән сузылыбрак куйды. Буйга Сәйярдан кайтыш булса да, башын артка ташлабрак, үз дәрәҗәсе биеклегеннән үлчәп кенә, өстән аска карап сөйләшергә гадәтләнгән, ахры.

— Бүлмәңне рәткә сал, энем. Җыйнак бүлмәдә, ярлы күренсә дә, эшләве күңелле була. Тәртип ягы әйбәттер инде синең? Капкаламыйсыңдыр? Нәрсәне дип, шул инде... Бик хуп, бик әйбәт. Яшьтән үк бозылмасаң, картайгач бозылырга соң була ул.

Сәйярны гаҗәпләндергәне — аның шул кадәр пөхтә кырылган, кояшта янып көрәнләнә төшкән түгәрәк матур башы булды. Скульпторлар баш өлешен ясаганда, күзләрен бәйләп, бармаклары белән генә сиземләп эшлиләр ди. Чынлап та шулайдыр. Бу башны экспо-

нат итеп куймалы. Йөзе дә хәтердә калырлык. Түгәрәк ясыйсың да, шуңа ике колак беркетәсең. Күзлек кидерәсең. Вак детальләр кирәкми. Сызылып киткән авыз. Борын читләреннән төшеп, авызын каймалап торучы сызыклар һәм шарж әзер. Гомумән, ул өч түгәрәктән тора. Баш, гәүдә, кыска аяклар.

Бибишевның күзлек пыялалары салкын гына ялтырап китте. Сәйяр-үз уйларыннан үзе кыенсынып куйды.

Бибишев бүлмәдәге һәр нәрсәне күзәтеп чыкты.

— Бу пумалалар теге художниктан калганмы? Менә бит, алып киткән булса, калмаган булыр иде, әйеме? Син үзең, энем, татар мәктәбен бетердеңме? Шулаймы, татарча укысаң, русча белмәскә ару була ул.

Сөйләшүе шулаймы, әллә шаяртуы шундыйракмы — Сәйяр аның йөзенә карап һич кенә дә төшенә алмады.

— Әрмиягә китәргә ничә ел калды, энем? Бер ел дисеңме? Әтиең җибәрәме соң? Ә-ә-ә... әтиең булмагач, алалар инде. Ярый, энем, әйбәт кенә эшлә. Сүзгә ярлылык шул кадәр бай инде миндә, гаепләмә. Телефоннар өзгәләнә торгандыр, миндә алар эт балалары кебек, өстәл тутырып яталар.

Ул чыгып киткәч, Сәйярның кулы үзеннән-үзе карандашка үрелде. Ватман кәгазенә зур итеп ул Бибишевка шарж ясады.

Төштән соң вак-төяк заказлар алып кергән Шәрәфиев рәсемне күргә:

— Безнең Бибишев ич бу! Кулыңнан килә икән. Болай булса, сатирик газетаны менә дигән итеп чыгарачакбыз. Рәсемеңне аппарат хезмәткәрләренә күрсәтим әле, — дип алып чыгып китте.

Эш сәгате бетәр алдыннан Сәйяр идарәгә сугылды. Диспетчерның ишеге ачык иде, ул Сәйярны искәреп алды.

— Энекәш, кереп чык әле!

Бибишев гадәттән тыш ачулы итеп күзлек аша сөзеп кенә карады да:

— Комсомолмы әле син? Тәк... Нәрсә бу?! — Сукыр тырнаклы бармак диаграмма кырыена эленгән шаржга төртелде. — Җыелышта персональ эшеңне тикшертәм бит. «Главвостокнефтегазстрой»га караган бишенче трест идарәсенең баш диспетчерыннан мәктәп бусагасын атлар-атламас кына чыккан малай көлсен инде, ә! Нәрсә бу!

Сәйяр эсселе-суыклы булып китте. Гөнаһсыз шаяртуны болай кабул итәрләр дип кем уйлаган. Бибишевның комарланган тавышы баш өстендә чыбыркы кебек бәргәләнә торды.

— Мин моны болай гына калдырмам!

Сәйярның стенага сеңә баруын күреп, Бибишев капылт сүзеннән туктап калды һәм шаркылдап көлеп җибәрде:

— Әй, энем, энем, мин ачуланганга да ышаныр кеше булыр икән. Шаяртам гына ич! — Ул күзлеген салды, кулъяулыгын чыгарып яшьләнгән күз төпләрен сөртеп алды. — Тормыш вакытлы гына уен ул, шаяртып та калмасаң... Әйбәт ясагансың, нәкъ үзем. Шәп егет син, утыр әйдә. Рәсемеңне өйгә алып кайтып эләр идем, хатынның кәефе китәр дим. Ул мине һаман егет чагындагыча дип фараз итә бит. Ярату шулай үзгәрешне сиздерми диләр.

Телефон шалтырады. Өстәлдә яткан өч-дүрт телефонның берсен һич ялгышусыз алып, Бибишев кызып-кызып сөйләшә башлады. Эш турындагы җитди ґенә әңгәмәне ул: «Син аны табар идең инде, таба гына алмагансың», — дип тәмамлады. Трубкадан көлү тавышы ишетелде. Аның шундый гадәтенә күнегеп беткәннәр, күрәсең.

Бибишев саргаеп беткән баш бармагын трубка башына бер басып, бер алып тәмәке төтәтә башлады. Тәмәкенең тәмен ул гүя иң башта бармагы белән татып карый иде.

— Менә шулай,туган, җитди дә була алмадым, рәхәтләнеп көлеп тә кала алмадым, гомер үтте дә китте. Бүгенне сызып ташласаң, пенсиягә чыгарга бер ел да утыз ике көн кала. Пенсиягә чыксаң, эшләмәскә ару була, шулай бит.

Ошыймы бу кеше Сәйяргә, ошамыймы — бер караштан өздереп кенә әйтә алмас иде ул. Сүздән туктадымы, күзләре моңсуланып китә. Әйтерсең сөйләнеп торуы белән ул эчендәге сагышын яшерә, дөресрәге, онытылып тора иде.

— Диспетчер кызык кеше сезнең,— диде Сәйяр, Шәрәфиев кабинетына кергәч.

— Зыянсыз кеше ул, — диде Шәрәфиев. — Хәзерге заманда зыян салмау — үзе бер яхшылык.

Шәрәфиев Сәйяр алдына кара исәп белән генә сызып ташланган кәгазьләр куйды:

— Контора кырыена бик зур панно эшләргә кирәк, тимер-бетоннан. Эскизын ясап китер әле. Бу синең беренче зур эшең булачак. Син шуны бел: монда безнең кебек оешмалар бик күп, идарә алдын матурлау, бизәү ягыннан бер-берсе белән ярышалар. Шәп эшлә, кемнеке дигәндә, безнеке диярлек булсын.



## 4

Һәр авылның аксакалы булган кебек, һәр поселокның да һәммә кешегә билгеле шәхесләре бар. Андый кешеләр турында сүз чыкса, эчке бер мәгънә белән , соклануга ишарә ясагандай: «Ә ул... бик акыллы, яисә көчле кеше», диләр. Әнә шундыйларның берсе, поселокның ин шәп художнигы дип танылган Уразаевны күрергә дип, Сәйяр нефтьчеләр сараена килде.

— Бар, таныша тор, бераздан үзем дә сугылырмын, — диде ана Шәрәфиев.

Сәйяр, ак колонналар күләгәсендәге авыр ишекләрне ачып, эчкә узды. Ярым караңгы фойеда вахтердан башка һичкем күренми. Эчке бүлмәләрдән килгән өзек-өзек музыка авазлары, төрле тавышлар биек түшәмнәр, заллар арасында адашып, болганчык шау булып ишетелә. Сәйяр икенче катка менеп, кирәкле ишекне эзләп тапты. Тоткасына кулын гына сузган иде, ишек ачылып китте, уртача гына буйлы берәү «Шифалы су»дан бушаган шешәләр тутырылган әрҗә күтәреп чыга башлады.

— Исәнмесез, миңа Уразаев кирәк иде.

— Мин булам Уразаев, — ул уңайсызлангандай бер Сәйяргә, бер үзе күтәргән әрҗәгә карады. — мин хәзер киләм, буфетка төшеп менәм дә, керә тор, — дип, бүлмәсенә ишарәләде.

Ишекне ачык калдырып, Сәйяр эчкә керде. Зур тәрәзәләрдән бүлмәгә иркен яктылык төшкән. Стена буенда — эреле-ваклы рамнарга тартылган плакатлар, идәндә — чиста киндер. Түрдә — күне кыршыла башлаган кресло. Кая карама — төрле буяу банкалары. Бу тәртипсезлектә үзенә күрә шигърият бар сыман. Стеналарга эленгән картиналар, төрле афишалар, сынар кнопка белән генә каптырып куелган кәгазь битләрендә, тәгәл эшләнеп тә бетмәгән, күнелнең давыллап куйган бер мизгелендә кыю сызыклар белән ниндидер күренешне, хәрәкәтне тотып алган рәсемнәр бүлмәне тулыландыра, вак-төяк җыйнаксызлыктан игътибарны аера, сине шулардан өстен халәткә менгерә кебек. Агач савытта пумалалар. Стеналарга кадәр сеңгән эретмә-буяу исе борын эчләрен рәхәт кытыклап тора. Бу ис — төсләрнең хәтере дип уйлады Сәйяр. Әнә, зур рам эчендә табигать күренеше. Уң як почмагына, камышлар төбенә, сары буяу белән «Уразаев» дип язылган. Сәй-

яр картинаны үтә бер кызыксыну белән карады. Моңарчы аңа бөек рәссамнар ясаган күпме картиналарның репродукциясен күрергә туры килмәгәндер. Алар бөтенләй башка бит. Хәтта ул художникларның гадәти кеше булуларына һәм кайчандыр җирдә яшәгәнлекләренә дә ышанасы килми. Ә моны гап-гади кеше ясаган.

Бераздан Уразаев керде. «Шифалы су» бөкесен өстәл читенә бәреп ачты һәм чыжылдатып стаканга агызды. Аннары комсыз бер ләззәт белән тын да алмыйча эчеп җибәрде. Шундый картиналар ясаган кешенең, бугаз төерләрен хәрәкәтләндереп, су эчеп торуын кабул итә алмыйча Сәйяр читкә борылды. Уразаев «әх» дип тәмләп сулыш алды да, Сәйяр күңелендә картиналарга карата туган соклануны кул селтәве белән кагып төшерде:

— Боларга игътибар итмә, эч пошканда ясаган нәрсәләр генә,— тәмәке кабызып арлы-бирле йөренә башлады. — Сәярмы? — диде кинәт туктап, — миңа Шәрәфиев әйткән иде.

Танышып китү, сүз башлау үзеннән-үзе килде.

Уразаев Сәйярны тәрәзә янына чакырды.

— Кара әле, тышта нинди якты. Гомумән алганда, табигатьтә сызыклар юк, яктылык һәм күләгә генә. Төсләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтен чагыштыр. Монда таба килүче кызга игътибар белән рәк кара әле. Алсу бәйләм күлмәге әнә нинди балкып күренә. Хәзер бинага кергәч карыйк.

Баскычка чыктылар. Тышкы ишекнең ачылып ябылуы ишетелде. Әлеге кыз вахтер белән исәнләште дә, билет кассасына юнәлде. Үтешли борылып карады, Уразаев аңа елмаеп баш кагып алды.

— Күрәсеңме алсу төс бина эчендә бөтенләй сүнеп, югалып калды, — диде художник тавышын әкренәйтә төшеп. — Чөнки монда фон башка. Гомумән, сиңа мин бик билгеле нәрсәләр турында сөйлим.

Яңадан художник бүлмәсенә керделәр.

— Төсләрнең чын асылы бер-берсе белән янәшәлектә ачыла, тоннар — ярымтоннарда. Ягъни төснең күләгәсен таба белергә кирәк. Ренессанс чорында Италия художниклары кул астында алты меңгә якын төс булган, шуңа да карамастан алар төс әзлектән зарланганнар.

Аның пафос белән сөйләве дә, тышкы кыяфәте дә Сәйярга ошый башлады. Күренеп тора: бөтенләй башка дөнья кешесе.

— Абстракт әсәрләр белән танышлыгың бардыр? — дип, Уразаев өстәлдә яткан калын китапка кагылып алды. — Хәзерге технократия чорында сәнгатьнең үз тавышын таба алмыйча каушап калган чагы. Форма төрлелеге — бихисап.

— Мин күп нәрсәне белмим әле, — диде Сәйяр, кызара төшеп.

Уразаев тамашачысыннан канәгать булмаган актер кебек сүрелә төште.

— Сиңа әлифтән башларга кирәк. Зур уең бар икән, хәзердән үк тотын. Булдыра алганча һәркөнне рәсем ясарга тырыш. Абстракционистлар турында шуңа сүз кузгатуым: техника, төсләрне куллану ягыннан алардан да нәрсәгәдер өйрәнергә була. Кеше дигәнең бу дөньяны тулысынча аңлап, кабул итеп бетерә аламы?! Менә шул аңлашылмаучылыкны әйтергә тырышу бәлки үзе бер фикердер?..

Уразаев тәрәзәне киереп ачып куйды. Бүлмә эченә машиналар шавы бәреп керде. Кинәт ишек ачылып китте. Үтәли искән җилдән өстәлдә яткан кәгазьләр тузгып күтәрелделәр. Шәрәфиев кәрә-керешли кәгазьләрне тотып тиз генә ишекне ябып куйды.

— Нәрсә, әфәнделәр, эш сәгате бетеп киләме? — Уразаев белән кул биреп күреште дә креслога барып утырды.

— Ни әйтмәкче буласың? — диде Уразаев.

— Мин бүген премия алдым.

— Шуннан?

— Кичке ашка «палуба»га менәргә мөмкин. Тик бер шартым бар, ачуланышмыйча, тыныч утырырлык булсаң гына.

— Алай кызык булырмы соң?

Шәрәфиев башын селкеп көлеп куйды.

— Хәзер, мин бер эшне генә тәгәллим дә, — дип, Уразаев чыгып китте.

— Ничегрәк соң үзе? — дип, Шәрәфиев Сәйярга таба борылды. — Сәнгать институтын бетергән кеше ул. Яшь чагында күрсәң иде син аны! Мин аңардан бер-бер даһи чыгар диган идем, әллә нишләп кенә монда кайтып төште. Син кергәч, су эчтеме соң әле? Һы, хатыны ташлап киткәннән соң бөтен азыгы су аның. Их, яши белми шул, яши белми...

«Палуба» дип нефтьчеләр сараеннан урам аша урнашкан ресторанны атыйлар икән. Шунда керделәр. Монда һәр нәрсәдән пөхтәлек, купшылык сизелеп тора. Һәммә нәрсәне кире ягы белән чагылдырып торган тантаналы көзгеләр, затлы агачтан бизәкләп эшләнгән стеналар сине үзеннән-үзе мәшәкатьле дөньядан аера. Калын паласлы баскычтан күтәрелүгә залда тезелеп киткән өстәлләр күренде. Шәрәфиев ак калфак кигән официантка белән ерактан ук купшы исәнләште дә аңа таба юнәлде, кулын үбеп алгандай итте. Кызык сүз дә әйтте бугай, кыз башын артка чөеп яңгыратып көлеп җибәрде. Бераздан Шәрәфиев кул изәде, һәм өчесе дә әлеге кыз артыннан эчкәрге бүлмәгә керделәр. Стеналарына каен агачлары тезеп эшләнгән бу җыйнак бүлмә зур залдан табигыйлеге белән аерылып тора икән.

Официант кыз чытлыкланып Шәрәфиевнең каршына утырды, кыска итәген йомры тезләренә табарак тартып куйды.

— Я, ни боерасыз, җантельмәннәр?

— Кара икра, кета дияр идем — безнең меридианга хас нәрсәләр түгел. Менюда күрсәтелмәгәннәре кирәк.

Шәрәфиев ул кыз белән китеп, хәтсез торганнан соң гына чыгып утырды. Өстәлдәшләренә горур бер караш сирпеп алды. Уразаев әкрен генә:

— Яшәр өчен тугансың син, дус, — диде.

— Яхшы әйберне һәммә кешегә тигез бүлсәң, кадере китә. Дөресрәге, җитми. Шуңа күрә ул сирәкләр өлеше. Менә шул сирәкләрнең берсе булу кызык бит.

— Андый талантлар хәзер күбәя бара.

Өстәлгә салат, кета балыгы, шашлык, яшел суган һәм озын шешәле шәраб «Старый замок», кечкенә графин белән ак аракы килде.

— Аһа, каян чыккан бу! — дип, художник чәнечкесе белән балыкка үрелде. Шәрәфиев серле елмаеп, «ак» салынган графинны үз алдына тартты.

— Бу сиңа фәлсәфә сату түгел, кәефле булу өчен яхшы ашарга кирәк.

Сәйяр шәрабтан баш тартты. Аны артык кыстамадылар.

Инженерның һәр чак шат, кәефле булуы Сәйярга ошый. Художникның гына сытык чыраен, тыңкышланып сөйләшүен өнәп бетерми, бая үзе нинди ачылып киткән иде.

Шәрәфиев калын иренenә йогып калган каймакны салфетка белән сөртеп куйды.

— Бу дөньяда яшәп калырга кирәк. Теге дөньяга исәп тотып, изге булып яшәү заманы түгел. Материализм шулай өйрәтә.

Уразаев әйтеп куйды:

— Кем ничек аңлый бит.

Шәрәфиев түкле, эре бармаклары белән рюмканы сак кына элэктерде дә, башын каз кебек артка чөеп, бер генә йотып җибәрде. Аның симез бите уртасында, адашып калудан курыккандай бер-берсенә

елышкан түм-түгәрәк күзләре үтә бер житезлек белән тәгәрәп йөри башлады.

— Карап-карап торам да, тагын бер карап куям мин сиңа. Күпме вакытыңны зрәгә сарыф итәсең. Ул рәсемнәреңне кабул итәчәкләрме, юкмы — бу бит суга сәнәк белән язылган. Булмаган данга алданып бүгенен корбан итүче ыштансыз даһилар модада түгел, аңлыйсыңмы! Заман башка. Акчасыз акыллыга караганда акчалы җүләр акыллырак күренә.

— Үзеңне шулай ук түбән төшерәсеңмени?

— Салып куй әле син, кызлар кебек утырма.

— Сине күп тыңлаган, миңа ярый инде, янәшәдә яшь егет барын онытма.

— Һи, болармы! Болар, туган, дөньяның барышын синнән-миннән яхшырак аңлыйлар. Минем бер күрше бар, яшь кенә егет, Сәйяр чамасында булыр, су сиптерә торган машинада эшли. Былтыр җәй коры килде бит, онытмаган булсагыз. Поселок артында безнең һәммәбезнең бакчасы бар. Менә шунда җәй буена су сиптереп акча җыйды да егетең, алланың казасыннан файдаланып, иплэп кенә машина сатып алды. Шулай ул!

Уразаевның маңгае җыерылудан куе, салынкы кашлары бергә кушылды. Шул кашлар күләгәсенә яшеренергә тели иде сыман ул.

— Ярый әле, ходай җәнлекләргә тел бирмәгән, юкса, гел ашау турында гына сөйләрләр иде.

— Көләсем килә минем синнән, — Шәрәфиев балык кисәген авызына оста гына ыргытты да тәмләп чәйни башлады.

— Ә син җыла,— дип, Уразаев көлеп җибәрде.— Йә, бетердек, син, егет, безне гафу ит инде, — дип, Сәйярның җилкәсенә кулын салды.

Боларның тыныч кына, һич әреплэшмичә бер-берсен чагып утырулары Сәйярга сәер тоелды. Аңа әле берсенең, әле икенчесенең сүзе дөрес тоела, хакыйкать кайсында, тәгаен гына аныклыйсы килми. Алда — башланмаган тормыш бит әле, барысы да тәҗрибә аша, үзеннән-үзе ачылыр. Чөнки ул күп нәрсәгә нәкъ үзенчә яшәп, үзенчә төшенергә тиеш бит...

Рестораннан чыкканда поселок өстендә караңгылык хәйран куерган иде. Төнге һава тагын да сафланып киткән. Чәрдәкләнеп күренгән фонарьлар яктысында күбәләкләр биешә.

— Мин бу якка,— дип, Уразаев кулларын як-якка киереп күнегү ясап алды. — Хуш иттек, рәхмәт сиңа, магнат, — дип, башта Шәрәфиевка, аннан Сәйярга кул бирде дә китеп барды. Шәрәфиев Сәйярга көтеп торырга кушып, киредән ресторанга кереп китте. Бераздан ак салфетка кәгазенә төрелгән шәраб тотып чыкты.

— Өйгә дип алдым әле, мондый нәрсә гел булып тормый.

Сәйяр аның белән бер төбәктә яши иде. Стадионны узып, алар ябалдашлары кыркылмаган, биек топольләр белән шомланып утырган ярым караңгы урамга керделәр. Оеп калган яфраклар аша зәгыйфь ут яктысы тротуарга челтәрләнеп төшкән.

Шәрәфиев художникның кызык кеше булуы, үзләренең дуслыгы турында сөйләп бара. Каршыга килүчеләр очраганда тавышын әкренәйтә төшә иде.

Алда, барак ишеге каршында, тротуарга сузылган яктылык турында ике шәүлә күренде. Берсе, озын буйлысы, бөкрәя төшеп баскан, икенчесе төп кебек таза егет, ике кулын кесәсенә тыгып басып тора, өндәү билгесе кебек. Юл уртасында шикле басып торган бу ике егет яныннан Шәрәфиевнең бер дә әйләнеп үтәргә исәп тотмавын күреп, Сәйяр да аңардан калышмады. Мондый тәвәккәллекне көтмәгән идеме, кыска буйлысы соңгы чиктә тайпылып юл бирде. Ләкин арттан янаулы тавыш яңгырады.

— Абзый, затлы шешәне монда калдыр!

Илтифатсыз гына ары китәселәр иде, кинаяле тавыш янә кабатланды.

— Кемгә әйтәләр!

Шәрәфиев кырт туктап егетләргә таба борылды. Озын буйлысы тәмәкесен чыжылдатып суырды да:

— Санчо, алып кил әле монда, — дип, иптәшенең җилкәсеннән этеп җибәргәндәй итте. Сәйярның тез буыны тотрыклыгын җуеп, вак калтырауга күчте. Кыска буйлы егет һич тартынусыз килеп үрелим дигәндә, Шәрәфиев шешәне Сәйяргә сонып өлгерде. Моны көтмәгән егет, салкын кыяфәтен саклап, куен кесәсенә тыгылды. Шул чак Шәрәфиев яны беләнрәк борылып, әллә нинди кыргый тавыш белән чинап, егеткә таба сикерде. Күз ачып йомган арада аяк һәм куллары белән чыкылдатып берничә мәртәбә тондырып та өлгерде. Егет, сырты белән төшкән мәче кебек, шәрран ярып газон читенә ауган чакта, кесәсеннән, балык сыман ялтырап, нидер газон читенә очты. Ярдәмгә килеп житкән озын буйлы егет, Шәрәфиевнең артына төшеп, инде сугыйм дигәндә, Сәйяр аңа таба омтылып кычкырып җибәрде. Шәрәфиев читкә тайпылды, һич көтелмәгәнчә, уң кулын кылыч кебек селтәп, әлеге егетнең муен тамырына бирде. Исәнгерәгән егет чайкалып торды да, гыжылдаулы ыңгырашып, сәрби куаклары өстенә бөгәрләнеп төште.

— Каратэ диләр аны, юкка гына биш ел буе шөгыльләнмәгән, — диде Шәрәфиев костюмын каккалап.

Егет кесәсеннән ялтырап төшкән балык кебек нәрсә хәнҗәр булып чыкты. Төсле ташлардан тезеп эшләнгән матур саплы хәнҗәрне Шәрәфиев учында әйләндерә-әйләндерә карады.

— Сугышуның да яме бетте хәзер. Элек көчлеләр генә сугыша торган иде. Йодрык белән, куәт белән, берниндиди мәкерсез, изүләрен чишеп — ирләрчә! Ә хәзер нәрсә... Коралга тотыну — көчсезлек билгесе инде ул. Димәк, егетлек бетеп бара. Егылганга тию безнең канда булмаган. Киресенчә, егылганны изеп китү аларга бер ни тормый хәзер...

Олы урамга чыккач, ул каршыга килүче милиция машинасын туктатты. Рульдә утырган лейтенант белән дусларча исәнләшеп:

— Такташ урамында, өченче барак каршында, ике молокососны аудардым, шуышып ята торганнардыр, барып алыгыз, — диде.

— Синнән булыр, — лейтенант тигез тешләрен күрсәтеп елмайды. — Бу егет өйрәнчегеңме? — дип Сәйяргә ымлады.

— Алмаш кирәк бит, — диде Шәрәфиев. — Менә берсенең истәлеге, — дип, хәнҗәрне лейтенантка тоттырды.

Техника заманында кешедәге физик көч-куәт мөһим түгел дип йөри иде Сәйяр. Баксаң, үз иминлегеңне сакларга туры килгәли икән бит. Сәйяр каршында Шәрәфиев ун башка үсеп китте. Соклана алырдай кешегә буйсынырга була дип уйлады ул.

5

Беренче авансны алырга оялып йөргән Сәйярны кассага Шәрәфиев үзе иартеп китте.

Кәгазь акчалар Сәйяргә күп тоелды. Ләкин ул моңа шатланырга да, шатланмаска да белмәде. Күңелгән эздән барган дөньяда акча килеп кергәч, аны нишләтергә дигән сорау туа икән бит. Бәхеткә каршы, иртәгә шимбә. Авылга, әбисе янына кайтырга була.

Әбисенә ул кара бәрхеттән күлмәклек алды. Ярата ул әбисен. Әтиәнисез калгач, үзен карап үстергәне өчен генә түгел, ә яшәү дәртен җуймаган, хәрәкәтчән, һәр вакыт ни дә булса уйлап чыгарырга яратучан әбисенә ул эчке бер мәхәббәт саклый иде.

Бәрхетне алдына җәеп салгач, Җиһан әби беркавым сүзсез калды. Сөякчел кулы белән сыпырып карады, битенә тигереп, бәрхетнең йомшаклыгыннан, хуш исеннән ләззәтле оеп алды. Хәтта күзләре дымланып киткәндәй булды.

— Әй, улым,— дип, килеп Сәйярнең аркасыннан сөйде.— Кирәкмәс иде, мәшәкатьләнеп... Миңа соң, карт кешегә... Моны бит байлар гына кия иде...

— Син дә, әби, бай хатыны булгансың ич.

— Күптән бит инде ул...

Җиһан әби шым гына барып юка мендәрле урындыкка утырды да, кушучын йөзенә китереп дога кылды.

— Сәламәт бул, улым. Кинәнеп яшәргә язсын үзеңә. Амин. — Бәрхетне алып, кадерләп кенә чиста яулыкка төйнәде һәм шыңгырдатып почмактагы олы сандыкны ачты. Өйгә нафталин исе, Сәйярнең хәтеренә бала чактан ук сеңеп калган әллә нинди тәмле исләр таралды.

— Кичәгенәк, әйберләремне җилләтергә алыйм дип сандыгымны ачып җибәрсәм... шаклар да катып торам.

— Ни булган, әби?

— Кәфенлегемә дигән ак ситсымны көя тураклаган, имансыз. Барыбер китә белмәс бу карчык диләр инде әллә.

— Кая әле, әби, синга китү турында уйлау.

— Бәрәч, сиксәнгә җит тә... Оят кирәк. Җыйган ризыгыма шөкер.

— Җитмеш тугыз гына бит әле, әби, синга.

— Артыгы белән, улым. Һи-и, бу гомер дигәнең, бер карасаң: ай күрде, кояш алды дигәндәй, икенче карасаң: бара-бара күзең күгәрә.

Сәйяр портфеленнән катыргыга беркетелгән рәсем чыгарды. Әбисенең каба белән җеп җегерләп утыруын блокнот битенә сызгалап алган иде. Шул килеш онытылган булган. Кәгазьләр актарганда килеп чыкты да, берочтан кузгалып, акварель белән әйбәтләп буяп ясады һәм менә бүген әбисенә күрсәтергә дип алып кайткан иде.

— Менә бу кем, әби, яле, танырсың микән?

Җиһан әби, сандык ачу кебек ләззәтле бер халәттән аерыласы килмичә генә кузгалып, рәсемне ике куллап алды, битен җыера төшеп бераз карап торды да:

— Бәрәкалла, бу мин түгелме соң?! — дип, кулы пешкәндәй, рәсемне өстәлгә ташлады. Түзмәде, янадан кулына алды. — Кара син, аны, гел үзем шул. Кай ара эләктереп алдың аны, шайтан малай?

Сәйяр сүзсез генә елмаеп тора бирде.

— Гөнаһасын кая куярсың, суретка кереп.

Җиһан әби гомерендә үенә бер сурәт элдермәде. Ләкин бүген нәкъ үзенә охшатып ясалган рәсемне күреп әллә нишләде. Эчтән балкып китте. Каратут йөзенә кызыллык саркып чыккандай булды.

— Мин тагын олы урындагы түрәләрнең генә сурәтләрен төшерәләр дип йөри идем. Баксаң, безнең ише кеше дә үзенә охшап чыга икән ләбаса. Әйткән булсаң аны, матур яулыгымны бәйләгән булыр идем, теге, кара җирлеккә кызыл төшкәнен.

Җиһан әби рәсемне сандыгына, саргаеп беткән ниндидер кәгазьләр арасына пөхтәләп алып куйды. Баягы төенчекне янадан сүтеп, бәрхет тукыманы кулына алды.

— Бигрәк йомшак, затлы нәрсә инде. Күлмәк итәргә дә жәл.

— Алай димә әле син, әби.

— Соң инде миңа, улым. Вакытында насыйп булмады. Әле абыең да посылка салган ие, менә, ефәк шәл җибәргән. Гомәрне әйтәм.

— Кайтам димәгәнме соң?

— Кайтыр сиңа, көт. Озын акча эзләп кит тә. Анда да җиңел генә бирмиләрдер. Әллә кемгә охшап комагайрак булды шул.

Әби, хискә бирелеп китүдән курыккандай, сандыгын җәһәт кенә ябып куйды. Аның изге хатирәләрен, яшьлеген, үткәнен саклаган борынгы сандык шыңгырдап ябылгач, Җиһан әби мендәрләрне кабартып өсте-өстенә өйде, үзе дә шунда йомшак сырма өстенә менеп утырды. Бая күңеленә салынган сүзне кинәттән генә башлап җибәрде.

— Бай дигән булып, исеме генә инде аның. Нәрсәбез генә булды икән. Хәзерге белән янәшә куйсаң... Стена сәгатен, бабаңның актык толыбын алып чыктылар. Түбән оч Кәримне беләсең бит. Ата ялкау. Бабаңның толыбын шуның җилкәсенә салдылар. Киеп туздырды толыпны Кәримең — барыбер ярлылыктан чыгалмады. Соңгы дәвердә генә әзрәк тернәкләнеп китте. Һәй, ул чакларны искә төшерсәң... Авылда беркемдә сәгать калмады. Вакытны Шәмсениса абыстайның әтәче кычкыруыннан гына белә идек. — Җиһан әби, күңелсез хатирәләреннән арынырга теләгәндәй, йөзен куллары белән сыпырып куйды. Күләгәләнеп торган җыерчыклары бер мәлгә язылып алды. — Кәримнең атна кич карчыгы үлеп китте бит әле, авыр туфрагы җиңел булгыры. Җирләп кайтуга ук, өйдәш кирәк дип, кортка эзли башлаган. Көн итүләр кыен шул карт кешегә. Ялгызлык — бер аллага хуш. Күрше карчыгын миңа җибәрткән. Әйттем үзенә! — Җиһан әби иякочларын сыпырып кеткелдәп көлеп җибәрде. Ашыгып кына сандык өстеннән төшеп, кече якка, чыжлый башлаган самавары янына китте. Чәй әзерләп, өстәл янына утыргач та, өзелгән сүзен дәвам иттермәде. Сәйяр аның бу гадәтен яхшы белә иде. Вакыйганың иң кызык җирендә тукталып калыр да, берәр шөгыль тапкан булып вакытны сузар. Янәсе кеше аны тыңлыймы, аңа кызыкмы — яшертен генә сынавы иде. Сәйяр эчке елмаюын яшереп:

— Шуннан, әби? — диде.

Сорау бирүгә, Җиһан әби, канәгатьләнеп, Сәйярны тонык карашы белән сыйпап алды.

— Соң, әйтеп җибәрдем үзенә. Бүтән килүче булмады. Күрше авылдан бер карчык алып кайткан ди.

Нәрсә дигәнен әби тәки әйтмәде. Сәйяр аны соңыннан, капка төбендә гәп саткан авыл агайларыннан белде. Әләк Җиһан әби теленә, Кәрим бабайның яучыларына: «Бүрек әләрлек чөе бармы соң?»... дигән.

Китәр алдыннан Җиһан әби Сәйярның сумкасына бүген иртүк учак янында мәш килеп пешеренеп йөргән нигъмәтләрен тутырды. Көн болытлы иде. Өстәвенә салкынча җил дә исеп тора. Җиһан әби калынрак яулыгын бәйләде, аның өстенә кубанка бүрек киеп куйды. Сәйяр белә: әбисе, капка төбеннән генә озатып калмыйча, тауга ук менәчәк. Каршы килсәң, рәнҗеп калуы бар. Картлыгына ишарә ясауны, кызгануны һич тә күтәрми. Бер дә тиктормас, эшчән әбисе әнә шулай туктаусыз хәрәкәттә булып кына гомерен озайта шикелле.

Сөзәк тауга бер җайга салмак кына күтәрелделәр. Җиһан әби авызын яулык почмагы белән каплап ютәлләгәндәй итте.

— Арыдыңмы, әби? Чирәмгә утырып ял итик.

Җиһан әби кулын гына селтәде. Күзләрен кыса төшеп, аста ак түбәләре белән тезелеп утырган авылга карады.

— Аруны белә идеммени, әле кайчан гына... әә-әнә, авыл читендәге теге өйгә сөт аертырга йөри идем, көянтә-чиләк асып. Бер ягына бер бидрә сөт, икенче ягына таш тутырган бидрә асар идем. Кешеләр көлә иде үземнән. Ике якка да тигез ассаң, җиңел була бит ул.

Сәйяр әбисе белән янәшә үк басты.

— Үсәм-үсәм, әби, һаман сине куып җитеп булмый,— дигән булды. Сабыйларча эчкерсезлек белән басып торган әби, чынлап та, Сәйярдан калкурак иде.

— Безнең нәселне алаңгыр Нәгыймнекеләр дип йөртәләр иде. Сайлап алган кебек, нәселдә ник бер кәрлә булсын. Кияүгә чыккан елны,

амбарга арыш керткәндә, үлчәнгәнем хәтеремдә — сиксән кило килдем. Көләләр иде үземнән. Йөрәге житеп нинди егет сиңа сүз катар икән дип көләләр иде. Һәр кемгә тиңе дигәндәй, табылды тагын үзе. Харисым мәрхүм жилкәмнән генә иде. Халыкта тел әшәке бит, чөлди Харис дип исем тагып куйдылар үзенә. Буйга курачрак булса да... — Жиһан әби сүзеннән бүленеп тирән кесәсен актара башлады. — Акчамны онытканмын бит, каһәр суккан.

— Нигә ул, әби?

— Юлга вак акчалар кирәктер бит сиңа.

— Рәхмәт, әби, үземнеке бар. Сәйяр әбисенең иңенә кулын салды. — Их, әби, әби, кызык синең белән.

Жиһан әби оныгына мөлдерәп карады да, ялварулы тавыш белән:

— Әсфәнгә чаклы озата барыйммы соң? — диде.

— Асфальтка кадәр ерак бит, әби.— Сәйярнең әллә нигә күңеле тулды. Капыл саубуллашып китәргә базмыйча тора бирде, бераздан, сумкасын кулына алгач кына, Жиһан әби иң соңга калдырган гозерен чишәргә булды.

— Борыл әле, улым, менә бу якка, — диде ул Сәйярнең жиңеннән тотып. — Әнә тегендә, тегермән артында чаукалык бармы, шул төбәктә Торна сазын беләсең бит. Чишмәсен дә хәтерлисеңдер?

— Тәмсез сулы чишмәнеме?

— Алай димә син. Суы тәнгә сихәтлек бирә торган су аның. Изге су. Атнасына бер барып шешәгә тутырып алып кайтам мин аны. Йотымлап кына эчәм аннары. Хикмәт аның суында гына да түгел, балчыгында! Сызлаган буыннарны яза торган балчык ул. Менә мин күптән инде кеше күзенә карап урын өстендә ятасы идем, тфү, тфү, шул балчык аякларымны кеше итте. Хәер, сезгә әйттең ни, әйтмәдең ни. Жиһан әби өметсезләнеп кул селкеде. — Көләргә генә беләсез.

— Шуннан, шуннан, әби?

— Шуннан димә, тыңлап кына тор! Берәр иҗтиһатлы кеше тап, алып кил, тикшерсеннәр. Шифага ярый торган балчык булмагае. Файдалы әйберне нигә әрәм яткырырга.

— Газетага синең исемнән языйммы соң, әби?

— Исемен-жисемен белмим, ахыры күренерлек булса яз.

Сәер кеше аның әбисе. Кыргый жәнлекләр кебек һәр үләннең исемен, тәмен, шифасын белә. Кырдан учмалап җыеп кайта да, вак себеркеләр итеп чормага элеп куя. Бөтен күрше-тирә, сырхаулап киткәне аңа килә.

Әбисе яныннан Сәйяр рухи күтәренкелек белән китә. Кызык һәм сәер кеше ул. Каратут йөзле, куе һәм эре чәчле, таза бәдәнле. Карашының үткенлеген жуймаган мондый карчыкларда борынгы шәрык дастаннарыннан килгән бер чалым бар. Жиргә тартылгандай, чүгә, кечерәя барган ак йөзле, юка чәчле карчык-корчыклардан алар ни беләндер аерылып торалар. Алар йөзеннән шәрыкның ком чүлләрен, тауларын, көйдергеч кояш эзен гасырлар пәрдәсе аша шәйләгәндәй буласың. Мондый карчыклар мәһабәт, төз сынлы агач шикелле сынмыйча-бөгелмичә үрә баскан килеш картаялар һәм бер көнне... кинәт кенә авалар.

Сәйяр әбисенә гажәпләнеп карый. Ничек инде үлем турында шулай тыныч күңел белән сөйләмәк кирәк. Ә үзенең күзләрендә, бөтен торышында бу тормышны яратуы, яшисе килү теләге. Төптәнрәк уйласаң, Жиһан әби соңгы юлга чын күңелдән әзерләнми дә бугай... болай, кешедән күреп кенә, авылда үзенең өлкән кеше булуыннан һәм чират, һичшиксез, миндә дип уйлавыннан гына бугай. Кордашлары, чордашлары китә барган дәвердә, карашы, шөгыле-фигыле бүтән яңа буын белән уртак уй-фикерләре, хатирәләре калмаган борынгы әби бүгенгедән үзен читләшкән итеп күрә, барысы да аңардан башка эшләнә,

аңардан башка ага, ә ул тыныч култыкта бары тик күзәтүче генә. Шуңа да үзен бу дөньяда артык дип саный бугай. Бәлки үлем турында сөйләнгән булып, кешеләрне астыртын гына күзәтә, сыныйдыр, янсә сабый кебек җылы сүз, юату көтәдер.

Офыкка төшеп баручы кояшны тотып тора алмаган кебек, Җиһан әбинең дә гомерен озайтып булмас, ләкин соңын, нәкъ менә соңгы ноктасын Сәйяр күз алдына китерә алмый, дөресрәге, ул турыдагы уйлардан да курка иде.

Сәйярнең башына мондыйрак фикер дә килеп куя: әгәр гомер озынлыгы бүген галимнәр әйткән якынча саннардан артыграк булса, кеше җитмеш-сиксән яшендә картайдым дип уйлаудан оялыр иде бит.

Шундый бер тәҗрибә эшләп карыйсы иде: яңа туган балаларны берәр утрауга күчереп куясың, эшләү һәм яшәү шартлары булдырасың һәм аларга сабый чактан ук кешенең гомере уртача ике йөз ел диган карашны сеңдерә киләсең, ышаныч тудырасың. Беләсе иде, алар ничә яшькә җитәрләр иде икән? Хәер, гадәти шартларда да гасыр ярым яшәгән кешеләр тарихта билгеле бит. Димәк, алар нииндидер барьерны үтә алган көчле рухлылар...

## 6

Шәрәфиев кечкенә генә яңалыгын да Сәйяргә килеп сөйләүдән тәм таба иде. Юктан да шатлана белә, хәтта Сәйяр аның шулай табигый итеп шатлана белүенә эчтән генә кызыгып та куя иде. Сәйяр аны бөтен нәрсәне булдыра алырдай кеше дип йөри иде, ләкин ярты елдан артык бергә эшләү дәверендә нәкъ менә бүген ул бөтенләй башка яктан ачылды да куйды.

Ишекне шар ачып, җиле белән килеп кергән Шәрәфиевнең йөзе бүген аерата бер шатлык белән балкый. Үзалдына канәгать елмаеп, кулын-кулга ышкый-ышкый, ишекле-түрле йөренеп алды.

— Син получка көнен онытмадыңмы, мәхшәр анда. Бер чират кассага, икенчесе газета янында. Шәп чыккан. «Чаян»ың бер кырыйда торсын. Бик күренергә тырышма инде, халык кайный анда.

Шәрәфиев эчке кесәсеннән аракы шешәсе һәм газетага төрелгән сыр кисәге чыгарды.

— Алдынгы бригаданы тәнкыйть итеп чыгуның хикмәтен аңладыңмы инде син? Аңламасаң да, рәсемнәрен ошатып ясагансың. Синең түгел, «абзыйларга» да аңлату җиңел булмады. Стена газетасы бит ул гаиләдәге читкә чыгармыйча ачыктан-ачык сөйләшү кебек. Алдынгы бригаданың житешсезлекләрен күрсәтү — бүтәннәргә икеләтә сабак дигән сүз. Менә бит аның хикмәте кайда! Шулай бит, иптәш Рембрандт! Рембрандт французмы әле ул? Ошый ул миңа.

— Әйбәт художник.

— Исеме дим. Каяндыр ишеткән идем шунда. Малайга куштым мин аны. Рембрандт Әхмәтевич. Шәпме?

Бөтенләй ятышсыз дияргә кыймады Сәйяр. Җилкәсен җыера төшеп, ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Ярый, — дип куйды.

— Кыюрак бул әле син, кайчагында бигрәк мәмерәеп төшәсең. Шеф безнең шундыйларны ярата. Көчле кеше ул. Зур үсәчәк. Тиздән трестка алачаклар үзен. Гомумән, шәп коллектив безнең. Җомай Әхмәтбаевичны гына ал, титан бит. Ә беләсеңме... Заманында исполком председателе булган кеше. Ул кунып калган авылда сыерларны көтүгә аскы урамнан куа торган булганнар. Хәтамтаев йоклый, тавыш чыга янәсе. Ун ел утырып чыкмаса, белмим хәзер кем булыр иде.

Шәрәфиев, әле тегесе, әле монысы белән кызыксынган булып, Сәйяр тирәсендә йөренде, аннан соң төчерәк елмаеп:

— Бер яңалык бар бит әле, — диде. — Синең рацпредложение трестта өченче урынны алган, кырык сум премия килде.

Сәйяр аптырап калды.

— Мин сиңа әйтмәдеммени? Бетон болгаткычның камилләштерелгән варианты. Күрмәдем дип, син эшләдең — бетте. Безгә бит кешеләр саны да кирәк.

— Үзегез уйлап чыгарганмы соң ул?

—Алай ук дип әйтеп булмый инде аны. Төзелешкә багышланган журналлар чыгып тора. Башка төзелеш оешмаларына да баргалап торабыз. Гел уйлап чыгарганны көтсәң, кем планны тутыра ди.

— Уйлап чыгаруга да план бармыни?

— Сабый син. Ул экономия, акчага бәйләнгән ич.

— Ә бу сызымны трестта сизсәләр?

Шәрәфиев көлеп куйды.

— Аларның планы юк дисеңмени. Кәгазь эшен белмисең әле син. Күз алдыңа китер: саннар, мәгълүматлар кечкенә оешмадан югарысына китә. Инстанция буенча үсә, зурая бара. Кеше — саннар каршында кеп-кечкенә булып кала һәм үзе дә саннарга буйсына башлый.— Шәрәфиев кесәсеннән акча алып саный башлады.— Мә, яртысы сиңа.

Сәйярнең кузгалмавын күреп, акчаны өстәлгә куйды. Голтыратып стаканга аракы агызды.

— Эчмисең инде син, мин үзем дә периодлап кына.

Сәйяр эшли торды, Шәрәфиев исә, тәмләп эчә-эчә, бернинди җавап, хуплау сүзе көтмичә сөйләнә бирде.

— Син шуны бел, Сәйяр дус, кеше дигәнең һәр көнне ятар алдыннан, мин бүген үземә файдалы нәрсә эшләдем әле, дип уйланырга тиеш. Хәрәкәт, хәрәкәт кирәк! Бөтен эшчәнлекнең төбендә акча ята. Нинди генә матур төшенчәләргә төренмә — асылда шул. Акчаны бетер генә, дөнья тугарылган арба шикелле калачак. Туләмәсәләр, художнигың да, галимең дә булмаячак. Бер-икесе калыр, безнең Уразаев шикелле җүләрләр...

Сәйяр плакатын язып бетергәндә, Шәрәфиев инде башын беләгенә салып йоклап ук киткән иде.

Ничек шулай шым гына килеп кергәндер, Хәтамтаевның калын тавышыннан Сәйяр сискәнеп куйды.

— Шәрәфиев мондамыни?! — дип, ул каударланып барып өстәлдә торган буш шешәне күтәреп карады да, җирәнгән сыман кире утыртып куйды. — Тагын бер атнага ычкына икән. Син нәрсә болай, тор әле, тор!

Шәрәфиев башын күтәрде, чуалган чәчләрен аралап аңа карады.

— Нәрсә, нәрсә? Мин үзем беләм...

— Бөтен бригада килгән анда миңа петиция белән, стена газетасы хакында. Үзең башлагансың, үзең җавабын да бирергә иде.

Шәрәфиев, буяу банкаларын идәнгә коя-коя, урыныннан күтәрелде.

— Барыгыз да югыйсә минем алда, — дип өстәлгә йодрыгы белән китереп сукты. — И-иих, булмады, булмады... Чүп бит сез, чүп! Бөҗәкләр! — Аннары ул Хәтамтаевның җилкәсенә кулын салды: — Гафу итегез, мин сезгә түгел, ә... ә... бөтенегезгә. Кемдер этеп җибәргән дә... әйләнәсез, әйләнәсез...

— Әйдә күп сөйләнмә, машина белән өеңә озаттырам. Тынычлан, ял ит. — Хәтамтаев Сәйяргә ишарәләде. Шәрәфиев култыкларга ирек бирмәде, кулларын тартып алды да, кемгәдер янагандай сөйләвендә булды:

— Малай чакта тегермән куласасына ябышкан малай мин... Бер ялгызым туктатам, имеш... Булмады, булмады... Берегезне чиртеп төшер — берни үзгәрми... ә куласа барыбер әйләнә... Бөҗәкләр.

Шәрәфиевне озатып кергәч, Сәйяр үзендә кулын пычраткандай бер чиркану, күңелсезлек тойды. Идәндә яткан буш буяу банкасын ачу белән тибеп очырды. Стенага бәрелгән калай банканың күкле-яшелле тавышы тынуга, ишек шакыдылар. Сәйяр эчке бер сизенү белән, менә хәзерге халәтен яктыртып җибәрердәй яңалык буласына тәмам ышанган шикелле түземсезләнеп:

— Керегез, — диде.

Ишек ачылуга, үзе дә сизмәстән артка чигенеп куйды. Ул булыр дип үк көтмәгән иде. Очрашу-күрешү каядыр хыял җитмәс җирдә, гадәти булмаган урында булырга тиеш сыман иде. Ә ул менә бүген гади генә итеп килде дә керде. Апрель кояшы белән елмаеп, Сәйяр хәтерендә калганча, ал бәйләм кулмәктән дә түгел, ә ак костюмнан, ак чалбардан, җилкәсенә аскан озын баулы ак сумкасына бер кулы белән таянган килеш, иңнәренә төшкән кара чәчләрен уйнатып килде дә керде. Исәнләшкәч, үзе дә аптырап калды.

— Күптән килгәнем юк иде, монда хәзер сез эшлисезмени? Гафу итегез, исемегез кем әле. Сә...

— Сәйяр.

— Шулай бит әле. Минем — Мәдинә. — Һәм ул ирләрчә кискенлек белән күрешергә дип кулын сузды. — Менә бит, теге чакта очрашырбыз дигән идем.

— Теге чакта...

Буранлы көн. Кырлар уртасыннан ярылган юлның як-ягы дөя үркәче сыман кабарып тора. Кар өермәсе ялкынланып күтәрелә дә, шул ике үркәч арасына кереп сылана. Кар ятмасы күз алдында үсә, тыгызлана бара.

Авылга өч чакрымнар чамасы булыр. Сәйяр анда, төзелешкә плакатлар илтә. Кечкенә автобус асфальтны төшүгә, кар ятмасын юргалый-юргалый барды да, бөтенләй туктап калды. Шофер, рульгә ята төшеп, бөтен гәүдәсе белән суырылып, машинаны әле алга, әле артка тирбәтә башлады. Бераздан рульне ташлады да, тирән сулап, тирләгән маңгаен бүрек колакчыны белән сөртә-сөртә, Сәйярга борылды.

— Барып булмас, ахры.

Утыргыч астыннан кыска саплы көрәген тартып чыгарды. Ишекне ачып җибәрүгә, эчтәге җылыны суырып алып, аның урынына карлы җил ыжгырып бәреп керде.

Алмашлап кар көри башладылар.

Буран гөжләвен кисеп, якында гына ачы сигнал тавышы ишетелде. «Ашыгыч ярдәм» машинасы икән. Маңгаенда янып торган Кызыл хач билгесе. Машинадан яшел бияләй белән йөзен җилдән каплый төшеп бер кыз чыкты. Пальто итәге ачылып киткәндә эчтән ак халаты күренде.

— Үткәреп җибәрәсезме, безне анда авыру көтә?

— Бесполезно, — диде шофер аңа сөзеп кенә карап. — Күрәсең бит ике яр арасында утырабыз.

— Нишләргә соң? — кызның тавышы еламсырап чыкты.

Сәйяр бу эчпошыргыч буран эченнән килеп чыккан кызга онытылып карап тора бирде.

— Тәпи-тәпи атларга туры килер, туташ. Ат белән килерерләр, ә машинагызны, кар күмеп киткәнче, асфальтка чыгарып куегыз, — диде шофер.

Тупасрак әйтте бугай ул. Кыз борылып үз шоферына нидер әйтте дә, юлсыз юлдан йөгерә-атлый, авыл ягына таба кузгалды. Моны битараф кына күзәтеп торган Сәйяр үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде:

— Туктагыз әле!

Кыз, ишетепме, ишетмичәме, җилдән каерыла төшеп борылып карады.

Икәү янәшә буран эченә кереп йотылдылар. Сәйяр аның сумкасын үзенә алды. Аннан соң житәкләштеләр, жилгә каршы кулга-кул тотышып бару жиңелрәк иде.

Кашлар, керфекләр юешләнеп бозланды. Яка эчләренә җепшек кар тулды. Буранлы кырның очы-кырые юк сыман. Тирә-юньне томалаган буран аръягында тормыш барлыгына ышанасы да килми. Артта калган тирән-тирән эзләрне җәһәтрәк күмәргә теләгәндәй, кар күче үҗәтләнебрәк сылана.

Гомер буе шулай үзеңә таныш та, таныш түгел дә кеше белән бергә киләсеңдер кебек. Гомер буе шулай тоташ аклык эченнән нидер күренүен өмет итеп барырсың да барырсың кебек.

Менә буран аша пәрәвез кебек жиңел карамчыклар шәйләнде. Бара торгач, ул карамчыклар биек өянкеләр, ак түбәле өйләр булып каршыга бастылар. Сырынтылар аша үтеп иң кырый ихатага керделәр. Киез итекләренә ярмаланып сарган карны кагып та тормыйча, эчкә уздылар. Таныш түгел кешеләрнең шулай кинәт кенә тупырдашып килеп керүе, жил гүләвенә оеган ызба эченә җан өреп, хуҗаларны бер мәлгә аптырашта калдырды.

Врач кыз, кулъяулыгы белән битен сөртә-сөртә, нинди йомыш белән, кемгә килүен әйткәч, хуҗа хатын аңга килеп җәһәт кенә киенә башлады.

— Бездән өч-дүрт өй аша гына ул, кызым, улым. Хәзер илтешермен. Бәрәч, үскәнем, битеңне өшеткәнсең бит! Тукта, хәзер каз мае алып керәм.

— Рәхмәт, апа, вакыты ул түгел, тизрәк барыйк.

Сәйяр шунда гына врач кызның агарып чыккан бит очларына игътибар итте. Нидер әйтергә теләде — әйтә алмады. Барыбер кызның сүзе сүз иде. Шулай да, чыгып барышлый, хуҗа хатын чоланнан нидер эләктереп чыкты.

Авыру яткан өйгә килеп җиткәндә капка шар ачылган, ишегалдында жигүле ат тора иде. Өй эчендә хәрәкәт күпты. Врач кыз тиз генә пальтосын салып куйды, кечкенә сумкасын ачып приборлар алды. Аңа комган белән су китерделәр. Ул, тиз-тиз җыенып, авыру яткан бүлмәгә кереп китте.

Кызның канәгать төс белән чыгуы, яулык почмагы белән кызарган күзләрен сөртеп торган хатынның: «Ничек соң, кызым, терелерлекме?» — дип, иренең хәле турында сорашуы, врач кызның: «Бер дә борчылмагыз, апа, бар да әйбәт булыр», — дип, әлеге апаның иңнәреннән кочаклагандай итеп, аны юатуы, апаның: «Юлны күтәрер микән?» — дип борчылуына каршы, врач кызның, һич шик калдырмыйча, авыруны кузгатырга кушуы... Һәм пальто кигезешкәндә ак халаты астыннан чагылып киткән алсу бәйләм күлмәк, каз мае сөртелгән, кызара төшкән бит очын яшерә-яшерә Сәйяр белән саубуллашуы, барысы да онытылмас төш кебек хәтердә калган.

Ул чакта Сәйяр таныш түгел авыл башында бер ялгызы басып калды. Күз алдында — алсу төс. Кайда күргән иде соң ул аны? Кайчан? Ә! Нефтьчеләр сараенда күргән иде бит ул аны. Шул үзе ич. Йөзен хәтерендә калдырмаган, ә алсу төсне... Буран эчендә нинди якып күренер иде ул. Ә тавышы... Ягымлылыгы белән әсир итә торган тавыш:

— Исемеңне сорарга да вакыт булмады, гафу итегез.

— Сәйяр.

— Минем — Мәдинә, без очрашырбыз әле, шулай бит? — Һәм елмаю, үзенең чибәрлеге турында онытып, хәвефле борчылудан арынган, эчке бер ышаныч-сөенү аша елмаю.

Буран бөтен нәрсәне акка манып туктаусыз дулый, сызгыра, кайный. Һәм шул буран эченнән япа-ялгыз калып бару — кабатланмас мизгел икән. Бөтен авазлардан аралап алып, күңеленә сеңеп калган

ягымлы тавышны, учындагы кошның нәни йөрәк тибешен тойгандай, күңелеңнән тыңлап бара алу — кечкенә генә бәхет икән.

Ул көн карларын апрель кояшы эреткән инде. Аклыгы — Мәдинәнең бүгенге киемендә.

«Менә бит, теге вакытта очрашырбыз дигән идем».

Үзенә якын ук килгән кызның сулыш кайнарлыгын тойган хәлдә, Сәйяр кызарып китте. Теге, буранлы көндә, оялу турында бөтенләй онытткан иде бугай ул. Хатын-кызларга туры карарга базмаган егет бу чая карашлы кыз каршында каушап калудан курка иде. Җитмәсә, кылт итеп, сул як яңагындагы яра исенә төште. Бу яра, бала чак шуклыгының мәңгелеккә салынган бер мөһере, Сәйяргә һич тынгы бирми иде. Көзгегә карау белән иң алга шул җөйләнгән яра эзе бәреп чыга, көзгегә якынрак килгән саен җөй тагын да зурая бара сыман. Андый чакта Сәйяр үзен, кызлар күзе төшүдән мәхрүм бер мәхлукка санап, көзгегә аркасын куя иде. Менә әле дә, яңагындагы җөйнең кайнарлана баруын тоеп, кызга уң ягы беләнрәк борылырга тырышты.

— Теге чакта, әле дә ярый, иптәшкә сез булдыгыз. Рәхмәт тә әйтә алмый калдым бугай.

— Әйбәт кенә кайтып җиттегезме соң?

— Өлгердек. Операция уңышлы чыкты. Хәзер исән-сау, эшләп йөри. Күптән түгел генә килгән иде. Врачка да, миңа да бүләкләр алып килгән. Безнең эштә андый хәлләр булгалый. Бүләген алмасаң, үпкәләүең бар, алсаң, әллә ничек кыен...

«Тавышы бик тә ягымлы аның», дип уйлады Сәйяр. Әгәр йөзе ямьсезрәк булса да, мондый ягымлы тавыш аны барыбер чибәр итеп күрсәтер иде». Мәдинәне очратмам микән дип, кайсы көннәрне, эштән кайтышлый, үзәк урамнарны бер әйләнеп чыга торган иде. Ярый әле, аны эзләп эш урынына бармаган: аңарда Сәйяр тиңләшә алмаслык ниндидер затлылык бар сыман...

Мәдинә сумкасыннан кәгазьләр чыгарды.

— Минем монда килүемнең сәбәбе шул: житәкчегездән ризалык алдым, безгә Май бәйрәменә алып чыгарга транспарант кирәк иде, ясарсыз бит? Менә текстлары. Договорны хәзер үк төзибезме?

— Нинди договор?

— Акча түләү турында.

— Болай гына ясармын.

Мәдинә көлеп җибәрде.

— Бушка эшләүче художникны беренче тапкыр күрәм. Ярый, анысын эшләп бетергәч карарбыз.

Мәдинә төрле плакатларны карап йөргән арада, Сәйяр йөгерек сызыклар белән аның рәсемен «кәгазь хәтеренә» алырга тырышты. Бик авыр рәсемләнә икән ул — нәфис сызыклардан торган йөз рәвеше. Һәммәсе үз урынында. Фантазиягә ирек бирденме, төгәлсезлек күзгә бәрелеп калка да чыга. Шунын өчен дә Сәйяр никадәрле хәтерен айкап та, аның рәсемен ясый алмаган икән. Табигать биргән бу нәфислек кабатлауга мохтаж түгел, бары тик сокланыр өчен генә яратылган, ахрысы.

Мәдинә кинәт кенә борылып өстәл янына килде. Сәйяр, каушап, кәгазен яшерә башлады.

— Күрсәтегез инде, — диде Мәдинә елмаеп. Егет дәшми-тынмый кәгазьне өстәл тартмасына салып куйды. Мәдинә китәргә җыенып сумкасын кулына алгач кына, Сәйяр:

— Китәсез дәмени? — диде.

— Китмәсәм ни әйтерсез?

Мәдинәне шушы акшарлары купшаклаган стеналар фонында, ярым тәртипсез бүлмәдә азга гына тоткарлыйсы килү теләге Сәйярны кыюландырып җибәрде.

— Вакытыгыз булса, иркенләп рәсемегезне ясап карамакчы идем.
— Аһа, булачак бөек художник натурщицага кыюсыз гына тәкъдим ясый. Ничегрәк басыйм? — Мәдинә уң аягын төрле буяулар тамудан төсен югалткан урындыкка куйды. Сумкасын шул урындык башына элеп, тезенә таянды.
— Миңа таба карагыз.
— Күзгә туры карый алырсызмы? — Мәдинә кинәт кенә «син»гә күчте. — Мин сине үзебезнең өйгә чакырырмын әле, стенага берәр рәсем ясарга иде, үземнән булмый.
Сәйярның каушавы, тартынуы онытылды: бөтен дикъкате кәгазьгә күчте. Каршында торган чибәрнең чая карашы да, вакыт-вакыт елмаюы да Сәйярга тәэсир итми, хәтта сүзләре дә ишетелми башлады. Кәгазьдә төсмерләнә башлаган сурәт белән җанлы-тере кеше арасындагы аермалыктан охшашлыкка якыная-якыная, Мәдинәнең битендәге һәр көләгәсен, керфекләр бөгелешен, кашларын, чәч дулкыннарын салкын бәяләүче сыйфатында күздән кичерә-кичерә, вакыт-вакыт канәгатьсезләнүдән тешләрен кысып, кискен сызык белән ялгышын төзәтә-төзәтә җансызга җан өрү кебек рәссамнар өчен иң сәгадәтле, ләззәтле «авыру» күпме дәвам иткәндер — ниһаять, соңгы хәрәкәт. Соңгы сызыкны төгәлләүгә, рәсем үзенең кызыклыгын, тәэсирен югалта. Һәм шул чакта аны онытасы, аннан аерыласы килә һәм күпмедер вакыттан соң кабаттан кулга аласы, яңа караш белән бәя бирәсе килә.
Барысы да гадәти хәленә кайта, Сәйяр элеккечә оялчан егеткә әйләнеп кала. Мәдинә рәсемне үзе белән алырга итә. Ләкин уңышлы чыгуына әле генә тәмам ышанган Сәйярның рәсемнән аерыласы килми.
— Төсле буяу белән ясагач бирермен, — ди ул.
— Тиздән минем туган көнем, шуңа өлгертерсеңме?
Сәйяр аны шатландырырлык нәрсә эшли алуына канәгать. Мәдинәнең күз карашында ул күңелне иркәләрлек яшерен бер тойгы искәреп алгандай булды.
Күңеле сине ят итмәгән хатын-кыз карашында, төнге күл төбендә саркып кына киткән йолдыз нуры кебек, тоелыр-тоелмас кына моңсулык булучан. Сирпелеп кенә киткән ул моңсулык сине тукталырга, үзенә төбәлергә мәҗбүр итә...

## 7

Сәйяр стенага буяу тамызудан сакланып кына рәсемнең кырый сызыкларын йөртеп чыкты. Читкәрәк китеп, үз эшеннән канәгать булып, бер мәл карап торды. Йокы бүлмәсенең стеналары киңәеп, һавасы сафланып киткәндәй булды. Рәсемдә, ни дисәң дә, диңгез бит. Әз генә фантазияне кушсаң, яшькелт-зәңгәр дулкыннарга карап салкынча диңгез сулышын тоярга мөмкин.
Мәдинә тәрәзә төбендә утырган җиреннән сикереп төште дә Сәйярның кулын кысты.
— Рәхмәт. Минем йокы бүлмәмдә хәзер диңгез шавы булачак, — дип җиңел генә бөтерелеп алды. Ул, походка җыенгандай, калын табанлы ботинка, джинсы чалбар, ал свитер кигән. Чәчләрен кызгылт беретка астына яшереп куйган.
— Киттекме? Әйдә, урман һавасы белән сыйлыйм үзеңне.
Түбәнгә, беренче катка төшеп ишекне ачуга, бөтен муллыгы белән дөньяга тулган май кояшына күзләре иләнә алмый торды. Талгын гына шыбырдап утырган топольләрдән яфрак исе килә, һәммә җирдә яшеллеге белән тернәкләнеп, язгы тамашага иләшә барган табигать җәйге сабырлыкка күчү алдында тора иде.
— Автобус белән барабызмы, җәяүме?

— Ә бу машина нәрсә өчен? — дип, Мәдинә ишек төбендә торган «Москвич»ка ымлады. — Әйдә утыр. Курыкма, кешенекен урламыйбыз.

Ишекләр шапылдап ябылды. Мотор бик тиз кабынды.

— Утыргыч каешын киеп утыр. Тизлек йөз илле булачак.

— Безнең юлларда йөз иллегә җиткерсәң, җирдән аерылуың да ихтимал, — диде Сәйяр.

Поселокны чыккач, уңга борылдылар. Мәдинә машинаны егетләрчә оста йөртә икән. Моңа кадәр Сәйяр белгән, тыйнак булып кыланган, үз-үзен чикләгән кызларга һич тә охшамаган ул. Үзен иркен, гади тота белә.

Юл кырыендагы соңгы өйләр чүгеп артта калуга, машина тизлеген арттырды, үз җиленнән үзе жуылдап бара башлады. Як-якта, бер-берсен узарга теләгәндәй, телефон баганалары артка таба томылып кала. Ә еракта урман, киресенчә, алга таба шуыша. Капма-каршы агучы дәрья уртасыннан йөзеп барасың шикелле.

Мәдинә, үрелеп, алгы тәрәзә өстенә беркетелгән көзгене борыбрак куйды.

— Тилгән атканың бармы синең?

— Юк, — диде Сәйяр.

— Минем дә юк.

«Нигә тилгән? Кыр үрдәге, яисә кыр казы түгел, нигә тилгән?» дип уйлады Сәйяр, әмма төпченеп торасы килмәде.

Икесенең дә карашлары көзгедә очрашты. Сәйяр ашыгып читкә борылды. «Сәер бу көзге дигәнең. Бер үк моментта ул да миңа карый, мин дә аңа. Бер-беребезне күрәбез. Ул да үзен күрми, мин дә үземне күрмим... Ә күзләр бер үк ноктада, бер үк көзгедә... Сәер бу», дип уйлады Сәйяр.

— Синең кызаруың ошый миңа, — диде Мәдинә. — Кызара белгән кешегә ышанырга була.

Алда сөзәк кенә үр калыкты. Машина тигез җиргә караганда да кызулыйрак төште. Асфальт буйлап каршыга тәгәрәп килгән кояш күзләрне чагылдыра. Тәрәзәнең козырекларын төшереп куйдылар.

— Тилгән ату уе миңа бала чактан кереп калган. Авылда әби бар иде безнең. Шуңа кунакка кайтканыбыз хәтердә. Тауга әби белән бәбкәләр сакларга чыктык. Каз бәбкәләре шундый матур иде, уенчык шикелле генә. Үлән өзгәндә чүмәлеп-чүмәлеп китәләр, менә-менә егыла дип торасың инде. Алардан туеп, бүтән уенга бирелеп киткәнмен, күрәсең, әби дә яшел чирәм өстендә мереп йокыга киткән. Бервакыт казлар каңгылдашкан, әби кычкырган тавышка йөгереп килсәм... ни күрим, коточкыч зур кош тырнаклары белән ике бәбкәне эләктергән дә, күтәрелеп китеп бара. Ул чакта мин тилгән дигән кош барын белми дә идем. Үзем бәбкәләрне жәлләп елыйм, үзем әбине юаткан булам. Мин ул кошны сиңа атып китерәм дигән булам.

Мәдинә җәһәт кенә тормозга басты. Машина кинәт пәйда булган чокырны әйләнеп үтте дә, яңадан кызулый башлады.

— Минем әти аучы иде, — диде Мәдинә, өзелгән сүзен дәвам иттереп. — Хәзер ул һөнәрен ташлады. Шәһәр читендә бакча үстерә. Крестьяны каны яңадан кузгалды.

Ике якның да тәрәзәсен ачкач, машина ерып барган һаваның жуылдавы көчәйде. Асфальт өсте урыны-урыны белән ялтырап ала, су жыелган кебек. Һәм ул ялтырап киткән урыннарда шактый ерактагы машиналарның да шәүләләре чагыла. «Мираж», дип уйлады Сәйяр. Мәдинә белән икәү генә шушылай янәшә бару да ерактан күренгән мираж гына булып калыр төсле. Әнә рульне нинди ышанычлы тотып бара ул. Сәйяр аның үзеннән күпмедер яшькә олырак икәнен сизенә, йөзенә карап түгел, болай күңеле белән сизә. Ләкин яшь аермасы Сәйярның аңа карата булган хисләре үзәгендә бик кечкенә булып кала.

Бу юлның очы булмасын иде. Шулай янәшә утырып күз күрмәгән җирләргә кадәр барасы да барасы иде. Ләкин һәммә рәхәтнең чиге бар шул. Шулай булмаса, баганалар кебек артка йөгергән минутларның кадерен белер идеңмени.

— Шушы юлдан керәбезме? — диде Мәдинә, уң кул ягына баш изәп. Сәйяр баш какты. Руль кош канаты сыман җиңел шыгырдап борыла башлады. Уртасында тузан сарган үләнле ат юлына чыккач, машина тизлеген акрынайта төште.

— Ә син сөйләш, кавалер, даманы күңелсезләндермә, — дип, Мәдинә аны үртәп алган булды.

— Кешеләрне тыңлый торган чор әле минем, — диде Сәйяр.

«Москвич» яр читенә үк килеп туктады. Кырыйда стена булып күтәрелгән урман өнсез тынлыкта сагаеп калган кебек. Машинадан төшеп, ишекләрен шапылдатып япкач, урман тынлыгы сискәнеп куйгандай булды.

— Яратам табигатьне! — дип, Мәдинә, җәйрәп яткан киңлекләрне кочарга теләгәндәй, кулларын җәеп яр кырыена килеп басты. Аста — тар гына инеш. Урман ешкынлыгыннан ачыклыкка килеп чыгуга, җиңеләеп, уйнаклый-уйнаклый, төбендәге вак ташларны кояшка күрсәтеп, борыла-сырыла еракка агып китә. Анда, офыкта, оеп калган кабарынкы дулкыннар сыман тау тезмәләре. Уртада иң биеге, тугыз баллы дулкын булып торганы — Чатыр тау гөмбәзе.

Мәдинә Сәйярга тотынды.

— Биектән мин тыныч кына карый алмыйм. Сикерәсем килә.

— Килгәч сикер, — диде Сәйяр, уйлап та тормыйча. Үз уйларына бирелгәндә бүлдерсәләр, кырыс кына дәшеп куя торган гадәте бар аның.

Мәдинә ялт итеп Сәйярга борылды. Күзләре моңсу, урман кебек сак иде. Ләкин ул моңсулык аның холкына хас шаянлык белән алмашынды. Мәдинә яңгыратып көлеп җибәрде.

— Кара әле, синдә тәвәккәл егет йокымсырап ята икән бит! — Һәм ул, актерларча кулларын алга сузып: — Ә кем аны уятыр?! — диде.

Каен урманы үзенең чисталыгы, тыныч яшеллеге, кошларның күңелле чыркылдашуы белән яшьләрне эчкәрәк әйдәде. Анда-санда чәчәкләр күренә. Әле керләнмәгән, сафлыгын җуймаган чәчәкләр. Мәдинә иңенә аскан киң каешлы сумкасын Сәйярга тоттырды. Үз алдына ниндидер җыр көйли-көйли чәчәкләр җыя башлады.

...Мәхәббәттән үлә чәчәкләр,
Мәхәббәттән үлә чәкләр...

Биек, төз сынлы агачлар астында алар кечерәеп калдылар, берберсенә якынрак елыштылар. Монда сүзләр серлерәк, мәгънәлерәк тоела. Урман кычкырып сөйләшүне өнәми. Саксыз, кискен тавыш агачлардан-агачларга чөелеп читкә ыргытыла.

Гадәттә, урман сукмакларының ниндидер сере, күз буучанлыгы була. Барасы ягыңны, кыйблаңны онытпырып, янәшәсендәге чәчәкләре, яки бөрлегәне, чияләре, миләшләре белән кызыктырып, үзенә ияртә дә алып китә.

Бу юлы сукмак аларны чишмәгә алып төште. Чишмә бөтенләй үк кыргый түгел, кеше кулы тигәне сизелеп тора. Ярына басып эчәр өчен ташлар җәелгән. Суы нечкә генә тимер торбадан бер көйгә агып тора. Шунда ук каен тузыннан эшләнгән, уңайлы сап куелган чүмеч эленгән.

Тәмләп су эчтеләр, юындылар, көлешә-көлешә су сибештеләр. Шул вакыт Мәдинә кычкырып җибәрде:

— Күбәләк, кызыл күбәләк!

Күбәләк боларны үртәгәндәй бер болай, бер тегеләй китеп очына, уйнаклый, урман һавасының җиләс агымына ияреп кинәнә, учактан

өзелгән ялкын чаткысы сыман кызгылт канатлары белән җилферди-җилферди, бер өскә, бер аска төшә иде. Сәйярнең быел беренче тапкыр күбәләк күрүе иде. Сарыны күрсәң — сагышка була, дия иде әбисе. Ә бу кызыл!

Күбәләк куып аргач, каен төбенә утырдылар. Мәдинә сумкасыннан «Кара ком» кәнфите чыгарды. Яртысын Сәйярга тешләтте, яртысын үзе капты.

— Серләребез уртак булсын.

Кызның күзләренә каен яктылары төшкән. Якыннан, бик якыннан Сәйяр аның күзләрендә үз күзләренең чагылышын күрде.

— Мәдинә...

Иреннәр иренгә тиде. Мәдинәнең башыннан береткасы шуып китте, чәчләре таралып, битләрне җылы яңгыр кебек сыйпап агып төште. Мәдинә егетнең ут янып торган яңакларына салкынча кулларын куйды.

Аннары йомшак кулы белән аның битен сыйпап:

— Сабыем. Берни дә белмисең бит әле син... Бу яра сиңа килешеп тора, — дип өстәде.

Сәйяр аның ишетте дә, ишетмәде дә. Ниһаять, күк, агачлар, җир үз урынына кайтты. Хатын-кыз иркәләвеннән Сәйярнең күңеле нечкәрде. Аның менә хәзер, һич кичекмәстән, Мәдинәне әбисе янына алып кайтасы килде, икесен таныштырасы килде.

— Әйдә, безнең авылга барабызмы? Мин сине үземнең әбием белән таныштырырмын.

— Ерак түгелме соң?

— Турыга, урман аша әллә ни түгел.

Урманнан җитәкләшеп чыктылар да, ялгызын калдырганга үпкәләгәндәй бер якка янтаебрак торган машина янына узыша-узыша йөгерделәр...

... Капка төбенә машина килеп туктаганны Җиһан әби сизми дә калды. Кече капка шыгырдап ачылгач кына, тавыкларга җим сибеп йөргән җиреннән борылып карады. Сәйяр белән кереп килгән ят кызны күреп, бер мәлгә аптырап калды. Җим савытын кая куярга белмәгәндәй тулганып йөрде-йөрде дә, ахры, җиргә утыртты. Кулларын күлмәк итәгенә сөртә-сөртә, каршы килде.

— Ни хәлләр, әби! — Атна саен диярлек кайтып йөрсә дә, әбисен кул биреп күрешергә өйрәтеп бетергән иде Сәйяр.

Әби ике кулын сузып Мәдинәгә борылды.

— Үзебезнең мөселман кызымы соң?

— Таныш бул, әби, Мәдинә булыр ул, — диде Сәйяр.

— Исәнме, әбекәй, — дип, Мәдинә Җиһан әбинең кулларын йомшак учына алды. Кочаклагандай итте. Әби Мәдинәнең буй-сынын картларча өлгерлек белән күздән кичерде.

Мәдинәнең ягымлылыгы, әбинең сүзчәнлеге ике араны бик тиз якынайтты. Кыз әбинең сәламәтлеге турында сорашкаласа, әби ул арада кызның нәсел-нәсәбе турында белешеп алды.

Аяк киемнәрен ишек төбендә калдырып өйгә керделәр. Җиһан әби өчен Сәйяр икенче планга күчте, аның игътибары Мәдинәдә генә иде.

— Кытай дигән илдә хатын-кызлар да чалбар кия икән дип, элек исләре китеп сөйлиләр иде. Бездә дә аптырап тормыйлар хәзер.

— Уңайлы бит ул, әби, — диде Мәдинә.

— Болай гына әйтүем, кызым. Яшьләргә ни дә килешә.

Мәдинә Җиһан әбине бер күрүдә ошатты. Аңа яхшылык эшлисе, күңелен күрәсе килде. Ләкин нәрсәгә тотынырга да белмәде. Әнә тәрәзә төбендә гөлләр, кайсылары чәчәк тә атып өлгергән. Сусамаганнармы? Юк, туфраклары дымлы, су сибелгән икән шул. Идәнне юар иде, күренеп тора: бүген иртән генә сап-сары итеп юылган.

Жиһан әби самаварын кузгаткан арада үз алдына сөйләнгән кебек кенә әйтә куйды:

— Чишмә суы бик тәмле була торган иде дә, сукмагы онытылып бара, торбадан килгән суны эчәбез.

Мәдинә очынып әби янына килде:

— Алып кайтыйкмы, әби, чишмәдән? Сәйяр белән без аны хәзер!

Әбинең ай-ваена карамыйча, көянтәсез генә чиләкләр алып, су буена төшеп киттеләр. Кайсы тәрәзәдә пәрдә кымшанып куйганын, кемнең койма ярыгыннан кызыксынучан күзләр төбәлгәнен бары Сәйяр гына искәрде. Чишмә инешенең аргы ягында, күпер аша. Кайчандыр, яшь киленнәрнең җиңел аяк эзләрен иңендә тойган сукмак үлән арасында йомылып, ятим калган. Чишмәсе дә, кемгәдер үпкәләгәндәй, уланые белән аска иңгән. Суы да, җирнең әллә кайсы тирән катламнарындагы тибеше белән бәреп тормый, ә моңсу гына челтерәп утыра.

Алар кайтуга Жиһан әби күлмәген алыштырган, тасланган эзе дә бетмәгән яңа яулык бәйләгән, аягына читек киеп җибәргән иде.

Бераздан чәй кайнады. Нарат бүрәнәле өй эчендә яңа пешкән чәй исе аерата бер хуш ис белән таралып, табынга утыру теләген көчәйтеп җибәрде. Жиһан әби иртән пешергән төче коймагын да җылытып китереп куйгач, өстәлдә урын тарайды. Яңа әйберләр өстәлә барган саен, бал-май, затлы кәнфит арасындагы шикәр савыты читкәрәк күчә барды, ахырда бөтенләй табыннан алып куелды.

Өстәл тирәли түгәрәкләнеп утырдылар. Сап-сары булып пешкән төче коймак авызда эреп бетмәле тәмле иде. Мәдинә Жиһан әбидән мондый коймакны ничек пешерергә икәнен сорашкалады.

Радиодан көндезге ял концерты тапшыралар иде. Менә «Карурман» җыры башланды. Бернинди гармун, оркестр күләгәсенә сыймаган моңлы тавыш бер ялгызы, бүлмәгә генә сыеша алмыйча, ачык тәрәзәдән тышка омтылды.

Жиһан әбинең кул ишарәсен искәрепме, әллә болаймы, табын кинәт тынып калды. Сәйяр тәрәзәгә борылды. Кеше, артык тәэсирле моңны күңеленә сыйдыра алмыйча, таяныч эзләгәндәй тирәлеккә карый. Әнә авылның үзәк урамы. Биеклеге, буяулары төрле коймалар. Туйлар кергәндә киерелеп, хуҗасын кайтмас юлга озатканда сызланып ачыла торган капкалар. Бер үк нигездә дәвам иткән нәселләр хәтерен саклаган өйләр чүгеп тыңлый сыман бу җырны.

Бу җыр яңгыраган вакытта авыл киселгән агач төбенә утырган ялгыз карт шикелле, күзләрен йома, хәтеренә китеп адаша...

Бу җыр күңеленә, җанына күчкән борынгылар авазын уятып бирә, сүнгән учакны тергезгән кебек.

Мондый тавыш мең елга бер генә туадыр. Болай ук та моңлы, болай ук та тирән итеп бу җырны аңа кадәр бер кем дә җырлый алмагандыр, аннан соң да булмас... Гасырлар буе килгән моңны нәкъ менә син яшәгән чорда бөтен барлыгы белән ачып салган тавышның шаһите булу — язмыш тарафыннан бирелгән сирәк очраклылыктыр...

Җыр беткәч тә әле, яңгыравын хәтердән җуярга теләмәгәндәй, чәйгә үрелмичә бер тын утырдылар. Ниһаять, күз төпләрен яулык почмагы белән сөртеп Жиһан әби телгә килде:

— Йа рабби, бу кадәрле дә моңны бирер икән кешегә. Көткән әҗәленне кире борырсың.

Яңартылып ясаган чәйләр эчелеп бетте. Кайнар сулышын бөркеп, шәбәеп утырган самавар да суына, сүрәнләнә төште.

Жиһан әби онытып торган булган икән, әлеге, Сәйярның хаты буенча, Торна сазындагы чишмә суын, балчыгын тикшерергә килүләре турында сөйләп алды. Казаннан ук килгәннәр ди. Башлап Жиһан әбигә кергәннәр. Әби аларны Торна сазына алып барган. Соңыннан чәй дә эчертеп чыгарган икән. Араларыннан берсе, әллә шаяртып, әллә чынлап:

— Бу балчык файдага яраса, медаль бирдерәбез үзеңә, әби, — диган.

— Сугыш елларында медален дә тактык инде, миңа бер ни дә кирәкмәс, шул тиклем җирдән кубып килгәнсез икән, ахыры хәерле булсын, — дигән Җиһан әби. Әгәр барып чыкмаса, кузгатучысы син дип, бәлагә тарыктырмасыннар тагын дип, пошаманга да калган үзе.

Сүз иярә сүз чыгып, ике «медик» (берсе укыган, берсе укымаган) дарулар, шифалы үләннәр турында гәпләшә башладылар. Мәдинә блокнотын кулына алды. Сәйяр монда үзен артык тоеп, алып китәсе әйберләрен җыйный башлады. Чоланнан иске әрҗә тартып чыгарды. Анда — буяу тюбиклары, пумалалар салынган иде. Тик берсен, ат кылыннан үзе ясаган, грунт салу өчен менә дигән зур пумаласын гына таба алмады. Эзләп-эзләп тә очына чыкмагач, әбисен тәмле сүздән аерырга туры килде. Җиһан әби анда сугылды, монда сугылды, тапмагач, аптырап, өйалды бусагасына утырды.

— Сәйяр улым, — диде гаепле бала сыман бөрешә төшеп. — Әллә соң онытып калдырдым микән? Өченче көн, гөнаһ шомлыгына каршы, зиратка менгән идем, бабаңның кабер рәшәткәсен буярга дип. Хатынкыз җенесеннән дип тормыйлар хәзер, теләгәне керә анда. — Бусын Җиһан әби Сәйяр алдында акланган сыман әйтте.

— Узган ел гына буяган идем бит аны, әби.

— Буявы бер сәбәп кенә инде... Зират ягына аяк басмаганыма ун ел булгандыр — күрәсем килде.

Җиһан әби моңсуланып, бер мәлгә тынып калды. Аннары гадәттәге житезлеге белән урыныннан кузгалды.

— Бер кергәч, каберләрне дә карап йөргәндәй иткән идем. Шунда исемнән чыккандыр инде. Хәзер барып кайтырмын, улым.

— Ярар инде, әби, калган икән калган, юкка борчылма.

— Юк, юк, оныткан әйберне барып алырга кирәк.

Ник кузгатканына үкенде Сәйяр. Кечкенә нәрсә белән хафага калдыруын абайлап әбисен тынычландырырга ашыкты.

— Кунак белән утырып тор, әби, йөгереп үзем барып кайтам, — дип, аның иңнәреннән йомшак кына тотып, өйгә кертеп җибәрде.

Зираттан Сәйяр күңелсез уйлар белән кайтты. «Минем әби дә шулай ук картайдымени? Ничек алай саташырга, ялгышырга мөмкин. Әйтергәме үзенә, юкмы?»

Иң кадерле кешесе бит ул Сәйярнең. Ата-ана назыннан мәхрүм икәнен онытьтыра белгән бердәнбер якын кешесе бит ул аның. Туган як — бу кырлар, бу урманнар, бу тыйнак таулар Җиһан әби булмаса кинәт үзгәрер, моңсуланып калыр шикелле. Әбисенең тууын, сабый чагын күз алдына да китерә алмый ул. Гомеренең башы булмагандыр да кебек. Шушы таулар, урманнар, кырлар белән аерылгысыз бергәлектә мәңгелектән киләдер шикелле...

Иң кадерле кеше... Моңа кадәр ул берәү генә иде. Хәзер — икәү, янәшә. Сәйяр күңелендәге хисләр, бер гөлнең ике тармагы кебек, берберсен күләгәләмичә икегә таркала.

Кайчандыр хәтерендә калган бер күренеш Сәйярны нигәдер сискәндереп җибәрде. «Язгы бакчада агачларга карап баскан малай. Ул беренче яфракларны көтә. Бөреләр менә-менә ачылып китәргә тиеш. Әнә беренчесе, икенчесе! Аскы ботакта язга кадәр исән килгән сары яфрак тирбәлә. Һәм тулышкан бөре. Алар икесе дә бер тармакта. Кинәт бөре ачылып китә, һәм шул чакта сары яфрак җиргә өзелеп төшә. Сәйяр сары яфракның өстенә басып, саф, яшел яфракны тотарга үрелә...»

Сәйяр кайтып кергәндә Мәдинә ак тастымал белән тәлинкә-чынаяклар сөртеп утыра, Җиһан әби өстәл башында иде. Берәр кызык вакыйга сөйләшкәннәрме — икесе дә елмаюлы. Уртак сергә икәү генә ия булган кыяфәт белән Сәйярга борылдылар.

— Таптыңмы, улым?

Өй эчендәге мөлаем бер яктылыктан Сәйярда бая туган самими, моңсу уйлар берьюлы таралып китте.

— Таптым, — диде ул елмаеп җибәрүдән чак тыелып. — Син, әби, кем рәшәткәсен буядың соң?

Җиһан әби аптырап Сәйярга карады.

— Бабаңныкын булмыйча, үземнекен түгел бит инде.

— Бөтенләй башка рәшәткәне буягансың шул менә.

Җиһан әби ялгыш ишетмәдемме дигәндәй кашларын җыерып Сәйярга карады.

— Китчәле. Шаяртасың дисәм, андый гадәтеңне хәтерләмим, чынлап әйтәсең дисәм, ышанырлык түгел... Олы нарат кырыен бутарга инде мин...

— Соң, әби, теге югары оч Мәҗит бабай кабере бит ул нарат кырыендагы рәшәткә.

— Бабаңның кабере кырыенда да нарат бар ич инде.

— Ул нарат күптән череп ауды бит, әби. Авыл картыныкы диләр иде аны.

— Илаһым! — Җиһан әби эченнән генә нидер укыгандай оеп торды.

— Шайтан котырыгыдыр бу, бер дә бүтән булмас. Капкасыннан да бисмилланы әйтеп кергән идем югыйсә. Габделмәҗит кабере дисең инде.

Мәдинә әби кырыена килеп утырды, аны юатырга теләгәндәй сөеп куйды. Әби аптырап утырды да, кеткелдәп көлеп җибәрде.

— И-ии, балалар, менә бит нәрсә эшләп кайткан әбиегез, ә! Габделмәҗит мәрхүм яратмаслык егет түгел иде, яшь чагында бик мут егет иде. Сезгә гыйбрәт итеп сөйлим инде моны. Ул шахтага эшкә китәр алдыннан сүз куештык. Мин — көтәргә, ул — кайтырга дип. Ул кайтты, яшьлектә ике уйлап торасыңмени аны, мин генә көтә алмадым. — Җиһан әби Сәйярга карап баш кагып куйды. — Бабаңа ярәшеп чыккан идем инде. Гомер буе миңа рәнҗүле булды, Габделмәҗит мәрхүм. Үлгәндә дә бәхилләмәм дигән иде. — Җиһан әби бераз тын гына утырды. Күзләре дымланып, моңсуланып калды.— Тиктәскә түгел бу, рухы чакырып китергәндер, рухы зиһенемне чуалткандыр, ходаем. Соңлап булса да бер яхшылыгы тисен дигәндер.

Кичкырын, Сәйярлар китәргә дип кузгалгач, Җиһан әби капка төбенә озатырга чыкты. Йөзендә пошаманлык, хәрәкәтендә таркаулык сизелә иде аның. Машина кузгалып киткәндә кул болгагандай итеп нәүмизләнеп басып калды.

## 8

Туган көнгә бүләк эзләп тормады ул. Элек ясаган рәсемнәр буенча, Ван-Гог стилендәрәк итеп Мәдинәнең портретын эшләде. Майлы буяуның тиз генә кибәсе юк, шуңа күрә картон тартма табып, нечкә металл рамга беркетелгән рәсемне шул тартма эченә салды.

Мәдинә яшәгән биш катлы йорт янәшәдәгеләреннән бер ни белән дә аерылмый кебек. Ләкин Сәйяр өчен ул иң үзәктә тора. Йорт каршындагы тирәкләр, агачтан гади генә ясалган беседка — барысы да аңа таныш. Читтән-читтән генә карап бу тирәдән ничә тапкыр урамагандыр.

Энгер иңеп килгәндә Сәйяр утыргычта утырган пөхтә киемле карчыкларның сынаулы-көйдергеч карашлары аша үтеп, ике баскыч арасын бер генә атлап бишенче катка күтәрелде. Звонок төймәсен бармагы белән батыруга, эчтән тонык кына чылтырау ишетелде.

Мәдинәнең артык купшы кыяфәтен күргәч, Сәйяр артка чигенеп куйды. Ишелеп төшкән чәчләре арасыннан күренеп торган зур божра ал-

калар, бил турысыннан тыгызланып, аяк йөзенә таба иркенәеп бөтерелмә дулкыннар булып төшкән озын итәкле күлмәк һәм бәйрәм тантанасын чагылдырган бәхетле күзләр... Сәйяр бу зәвыклы нәфислек каршында үзен бөтенләй уңып, таушалып калгандай тойды. Мәдинә исә югалып калырга ирек бирмичә, кулыннан тотып диярлек аны эчкә алып керде.

— Кунаклар үз кешеләр, син тартынып торма, — дип, Сәйярны култыклап түрге бүлмәгә әйдәде. Табын шактый кызып килә икән. Хуҗаның «ишәкләре» дә Сәйярнең танышлары икән. Гаҗәпләнүле йөзләр Мәдинә белән Сәйярга текәлде.

— Менә, дуслар, иң кадерле кунак, сөттән ак, судан пакь.

— Рембрандт, — дип куйды Шәрәфиев аптыраулы тавыш белән.

— Кунаклар, таныш булыгыз, Сәйяр — художник.

Мәдинәнең художник дип арттырып җибәрүеннән Сәйяр тагын да кызарыбрак китте. «Алай ук кирәкми иде инде». Мәдинә житезлек белән өстәл тирәли йөреп таныштырырга кереште:

— Менә безнең арада район газетасының мәшһүр сотрудникы Ясир Сабитов.

Өстәлнең аргы башында утырган монгол кыяфәтле кеше актерларча баш игән булды:

— Аның кырыендагысы — дипломсыз инженер...

Шәрәфиев ашыгып Мәдинәне бүлдерде:

— Возражаю, бер елдан техникум.

— Заочник. Ә менә бусы, — Мәдинә Уразаевның җилкәсенә кулларын куйды. — Художник Уразаев. Дөнья талантсыз бәхетлеләргә һәм талантлы бәхетсезләргә бүленә ди ул. Кайсы категориягә кергәнен үзе әйтер. Я, Сәйяр, утыр, танышларың белән кабат таныштырган булсам гафу ит. Штрафной, егетләр!

Шәрәфиев Сәйяр алдында торган фужерга күбекләндереп шампан агызды. Сәйяр оялып кына фужерга тотынды, әйтерсең бөтенесе дә аңа карый иде, баксаң, барысының да күзе табын үзәгендә — Мәдинәдә икән. Ә ул барын да үзенә гашыйк итә алуына шиге булмагандай, горурлыгын яшермичә үзен иркен тота. Аның һәр хәрәкәтендә ничектер итагатьле, килешле бәйсезлек. Менә ул эчендә терекөмеш кебек һава куыклары уйнап торган шәраблы фужерын өстәлгә куйды да, сул кулын югары күтәрде. Табын бердәм тынып калды.

— Нәрсәдә калган идек әле? Менә шул, дуслар. Мин туйдым бу провинциядән. Эш срогым тулуга китәм. Мондый сүлпән ритмда бөтенләй ялкауланырга мөмкин. Ничек яшисез монда сез? Ни дип? Нинди мәгънә?

— Мәгънә дисең... — Уразаевның аска карап, караңгы чырай белән генә сүз башлавы барысын да сагайтып җибәрде. — Район газетасының кичәге санында сыер савучы турында очерк басылган. Авторы сезнең каршыда, Сабитов. Анда — яшәү мәгънәсе үз хезмәтеңне яратуда диелгән.

Мәдинә башын артка ташлап яңгыратып көлеп җибәрде:

— Иптәш Сабитов, сез — даһи. Гений! Басыгыз әле урындыкка, басыгыз әле! — Мәдинә буш урындык алды да, аңа кәгазь җәеп бүлмә уртасынарак чыгарып куйды.

— Я, — дип боерды ул икеләнүгә урын калдырмыйча.

Сабитов ирен читләренә поскан мокытлык чалымын тагын да искәртеп елмаеп җибәрде. Нәрсә булачагын һич төшенергә теләмәстән, бары тик Мәдинәнең аңа әмер бирүеннән һәм шуны үтәүдән канәгать хәлдә урындыкка менеп басты. Мәдинә көйгә салып сөйли башлады:

— Иптәшләр, ничә мең еллар буена философлар кешенең яшәү мәгънәсен, ягъни кеше ни өчен яши дигән сорауга җавап таба алмый интекканнәр. Ә безнең Ясир Сабитов, егерменче гасыр вәкиле, сыер

савучы турындагы очеркта җавапны әйтә дә бирә. Кул чабыйк, иптәшләр! Һәйкәл шәпме, Әхмәт Зәйниевич?

Сыек кына кул чабулар астында Шәрәфиевнең сүзләре күмелеп калды. Мәдинә канәгать елмаю белән Сабитовка текәлде.

— Я, бүген нинди шигырьләр алып килдең?

— Төшәргә мөмкинме?

Мәдинә ишарә ясауга Сабитов урындыгыннан төште, өстәл янына килеп, кечкенә рюмкадагы шәрабны эчеп җибәрде. Битараф кыяфәт белән үз-үзенә төбәлгәндәй, бер мәл тын гына торды да, кесәсеннән көрән тышлы блокнот чыгарды. Калтыравын сиздермәскә тырышыпмы, блокнотны бер кулыннан бер кулына күчерә-күчерә актарырга тотынды.

— Багышлаулар циклыннан, — диде. Кыюсыз тавышы әкрен-әкрен дәртләнә, калтыраулы баритонга әйләнә барды.

Мин утрау булсам иде
күзләрең диңгезендә.
. . . . . . . . .

Сәйяр почмактагы зур көзгедән Мәдинәне күзәтә. Ул аңа ара житмәслек мираж булып тоела. Бу якларга ялгыш кына килеп чыккан, сайравы да, очышы да бүтәнчә булган ят кош кебек күңелләрне җәлеп итәр дә, күз тидергәнче дип очып китәр шикелле...

Сәйяр бу мәҗлестә үзен бөтенләй кирәксез, артык итеп санаганга күрә, киеренке халәттә утыра. Ул мондагы сөйләшүгә ияләшеп, ияреп китә алмый. Әле менә үзе турында уйланып, шигырьнең эчтәлегенә дә төшенә алмый калды. Мәдинәнең тавышы айнытып җибәрде аны.

— Ничек, дуслар?

Йөзенә кызыллык йөгергән, икеләтә кыюланып киткән Шәрәфиев кистереп куйды:

— Шигырьне гомумән не приз-на-ю.

Кулларын өметсез салындырып торган Сабитовка карап Мәдинә:

— Шигырьләреңдә кычкырып уйлама син. Чишендермә. Серле калсын, сере! — диде.

— Бик серле булса аны кем аңлый ди. Әнә Джоконданың...

Мәдинә стенага эленгән рәсем янына килде:

— Ул — икенче мәсьәлә. Хәзерге информация мөмкинлекләре белән юк кына кешене даһи итәргә була, һәм киресенчә... Имеш, Джоконданың сере бар. Шуңа ышанган кешеләрне күпме вакыт инде ул гипнозлап килә. Беләсегез килсә: Джоконданың сере — аның бер нинди дә сере булмавында.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Ярдәм эзләгәндәй, бу фикергә каршы әйтерлек бердәнбер син генә дигән өмет белән Уразаевка текәлделәр. Ә ул мыскыллы елмаеп, башын селкеп торды да, бер ни әйтмәве белән үзе дә сер калдырып, алдында торган рюмканы күтәрде һәм озаклап, үзенә бер тәм белән шәрабны теш арасыннан суыра башлады. Мәдинә ят, сүлпән тавыш белән мәҗлеснең агышын ялгарга тырышты:

— Сабитовның бәетен тыңлыйбызмы?

— Я елатыр, — диде Шәрәфиев.

Моңынчы гел һөҗүмгә дучар булган Сабитов кинәт кабарынып китте, күзләрендә тәвәкәл усаллык кабынды.

— Сез әле бәетләрдән көләсезмени?! Шарлатаннар. Утырган агачыгызга балта белән чабасыз. Үткәнеңне белми торып...

Шәрәфиев урындыгыннан сикереп торды:

— Ташла әле. Үткән, үткән. Нәрсәгә үткән белән мактану. Үткәнең турында белешмә судта гына кирәк. Язмышың хәл ителгәндә: я бетәсең, я каласың дигәндә...

Мәдинә кыза барган бәхәсне суытырга теләгәндәй, йомшак, ягымлы тавышы белән сүзгә кушылды:

— Тарихыбызны һичшиксез хөрмәт итәбез. Тик үткәнгә карап мөкиббән китеп утырырга димәгән бит. Дөньяны бүгенгеләр хәл итә!

Уразаевның урыныннан кубуы бөтенесен сагайтып җибәрде. Сәйяр сиземләвенчә, бу кешегә ихтирам белән карыйлар, һәр сүзе белән сиздермичә генә, эчке бер инану аша килешергә мәҗбүр булалар сыман иде. Уразаев ак нейлон күлмәгенең өске сәдәфен ычкындырып куйды.

— Син тарихыбызны бик яхшы беләсең ди. Без битарафлар ди. Шуннан! Журналист буларак син бүген нәрсә кырасың? Су өстендәге күбекне генә җыясың түгелме?! Анысын без дә күрәбез. Ә син тирәнгәрәк чумып кара, төптә ни ятканын күрсәт безгә!

— Туктагыз, туктагыз! — Мәдинә кулларын чәбәкләп ирләр арасына керде. — Бөтенләй ачуланышып китмәгәек. Мин тост тәкъдим итәм, дуслар.

— Гафу, — дип, Уразаев Мәдинәнең аркасыннан сөеп куйды. — Игътибарны арабыздагы бердәнбер хатын-кыздан читкә җибәргәнбез, гафу ителмәслек хәл бу.

Табынның эзлекле ритмы югалды. Кемдер магнитофонны көйләп җибәрде. Дәртле көй бөтен авазларны күмеп, бүлмәне һәм күңелләрне биләп алды. Әйтеләсе тост онытылды бугай. Өстәл-урындыкларны читкә алып мәйданны киңәйттеләр. Мәдинә нәзакәтле реверанс ясап Сәйярны танцыга чакырды. Шәрәфиев өстәлдәге шәмгә ут элеп электр лампаларын сүндерде. Бүлмә серле караңгылыкка чумды. Шәм ялкыны бии-бии үрсәләнеп яна, стеналарга җиңел күләгәләр сирпи. Күңелне тынычландыра торган ярым яктылык бу, хисләрне чит күзләрдән яшерә торган ярым караңгылык бу. Мәдинәнең чәчләре Сәйярның йөзенә рәхәт дулкын булып кагылып китә. Ниһаять, ул аның тән кайнарлыгын, сулышын якыннан тоя. Аның белән танцы итү шул кадәр җиңел икән, бер-береңне аңлап, көй бөгелешләрен алдан тоеп, тәгәл хәрәкәтләр белән бию сәнгатен Сәйяр беренче тапкыр татый иде. Ул нидер әйтергә тели, әмма тыелып кала. Сүзләре бу халәткә яраша алмас, артык купшы, я артык тупас булыр шикелле. Музыка, күләгә, яктылык, яктылык, күләгә һәм аларның урын алмашуы — бары, бары хәрәкәттә. Егет күңелендәге хисләрнең иң чиста халәте, нәкъ менә бүгенге халәте бүтән бер кайчан да кабатланмаячагын кисәткәндәй бер үк аваз кабатлана, кабатлана, кабатлана. Һәм бөтерелеп әлеге саф, чиста авазга түбән ноталы башкалары кушыла. Дөнья үсеше кебек, еллар үсеше кебек, уйлар үсеше кебек көй үсә, үсә, куера, тармаклана бара. Әлеге саф, галәми аваз бүтән кабатланмый инде. Ул аваз, дулкынын җуйган акчарлак сыман, сулкылдап-сулкылдап хәтергә генә төшәчәк...

— Сиңа бик күңелсез түгелме?

Мәдинәнең сүзләренә Сәйяр бер мәлгә төшенми тора, аннары каушап:

— Юк, юк, миңа бик ошый, — ди.

— Синнән башка бер кемне дә чакырмаган идем, сүз берләшкәндәй шаулап килеп керделәр. Алар минем якын танышларым. Бергә-бергә кунакка йөрешәбез.

Бер якта художник белән Сабитов сөйләшеп тора. Сүзләре колакка чалынып китә. Бигрәк тә Сабитовның тавышы. «Юк, син тыңла әле, тыңла. Кешене җүләргә санама син, туган. Мин әле доказать итәрмен!»..

Тиздән бу көйнең бөтенесен һәм бу мизгелнең кабатланмаячагын белү Сәйярны кыюландырып җибәрә.

— Ә мин сиңа бүләк алып килгән идем.

— Чынлапмы? — диде Мәдинә шатлыгын яшермичә. — Нигә күрсәтмәдең аны?

— Бер кемгә дә әйтмичә үзең генә карасаң, күрсәтәм.
— Әйдә.
Алар житәкләшеп алгы бүлмәгә чыгып барганда, арттан Уразаевның тавышы ишетелде.
— Кара син яшьләрне!
Алгы бүлмәдә утны яндырдылар. Сәйяр каушый-каушый гына тартманы ачты. Әйтерсең ул күрми торган арада рәсемгә кемдер кагылган да, бөтенләй бозып ташлаган. Мәдинә хатын-кызларга гына хас соклану белән рәсемне бер еракка, бер якынга куеп карады да, көтмәгәндә Сәйярның битеннән үбеп алды. Бу шул кадәр тиз булды. Сәйяр моңа ышанырга да, ышанмаска да белми торды.
— Егет син, Сәйяр! — дип, Мәдинә рәсемнән аерыласы килмичә генә кире тартмасына салды.— Соңыннан ныклап карарбыз. Әйдә, кунакларны күңелсезләндермик.
Кунак бүлмәсенә керүгә үк, Мәдинә Уразаевны танцыга чакырды.
— Ә мин? — диде балкон ишеге төбенә баскан Шәрәфиев, үпкәләгән сыман итеп.
— Яшь буенча бара. Син миннән бер яшькә олырак, — диде Уразаев жилкә аша гына.
— Ә-әә, син егерме тугызда гына бит әле, чынлап та...
Бераз исерә төшкән Сабитов Сәйярны әйдәкләп балконга алып чыгып китте.
— Тартыйк әле бер,— дип, кесәсеннән изелеп беткән «Беломор» пачкасы чыгарды.
— Тартмыйм, рәхмәт, — диде Сәйяр.
— Мут әдәмнәр болар, өйләнгән булсалар да, күз кыздырып йөриләр, ә! — дип, папиросын йомшартып авызына капты. — Их, яшьлек. Сезнең заман шул, сезнең заман. Сабитов Сәйярның жилкәсенә шапылдатып сукты. — Эчмәсәң дә кызарып киттең, килешә үзеңә, брат, килешә...
Әйтәсе сүзләрен тәмәке төтене белән чыгарып жибәрүдән курыккандай, кабызмыйча гына папиросын авыз читендә тота бирде. Сәйярның иңенә кулын салып нелә төште:
— Сиңа гына әйтәм, туган, яратам мин аны. Мәдинә — гажәп кеше. Әгәр ул булмаса, монда яшәү нинди күңелсез булыр иде. Шигырьләрне дә мин аңа гына атап язам бит. Ошадымы сиңа, дөресен генә әйт әле, шигырьләрне әйтәм.
Сәйяр, бер яктан Мәдинә өчен горурланып, икенче яктан аның Мәдинәгә карата булган хисләреннән көнләшеп, хәтта ачуы килеп торса да, кызганды. Сабитовның өмет тулы күзләренә карап ялганларга мәжбүр булды. Кешене рәнжетмәс өчен гөнаһсыз ялган кайчак гафу ителәдер.
Сабитов жинел сулап сүзгә юмартлана төште.
— Сиңа ничә яшь?
— Унсигез.
— Менә бит. Безнең арада ун ел гомер икән. Син әле белмисең, сонарып килгән мәхәббәтнең газабын белмисең. Соңгы өмет. Сизәсең, алда бүтән булмаячак. Ул да жимерелә икән — беттең. Син канаты сынган жәяүле кош.
Сәйярда баягы кызгану тойгысы берьюлы юкка чыкты. Әгәр нидә булса бүлешергә туры килсә, ул аңа һичшиксез риза булыр, килешер иде. Ә мәхәббәт бүленми икән. Мәхәббәт юл бирү, чигенүне күтәрә алмый икән. «Каян соң әле бу — үз-үземә шул кадәр ышаныч. Аның миңа булган мөнәсәбәтен анык белмәгән хәлдә, гоманлау, сизенү аша гына үземдә тулы хокук тою. Каян соң әле бу?» — дип уйлады Сәйяр.
Балконга Уразаев чыкты.

— Синдә очсызлы тәмәке була торган иде, тарткан сыман итик эле, — диде.

Сабитов ашыгып кесәсеннән папирос алды. Сәйяр эчке сизенү белән пәрдәне ачты, ләкин эчкә үтә алмыйча бусага төбендә туктап калды. Кермәскә иде аңа, күрмәскә иде. Талгын гына аккан музыка авазлары аша икесенең дә сүзләрен аермачык ишетә ул.

— Мин сине бер кемгә дә бирмим.

Мәдинә көлеп җибәрде.

— Ә хатының сине кемгә бирер?

— Әйтмә шуны! Болай күпме йөрергә була. Мәдинә, өйләнәм мин сиңа, билләһи, өйләнәм. — Шәрәфиев аны кысып кочаклап алды һәм үбәргә үрелде. Сәйяр, түзәтелмәслек хатаны йолып алырга теләгәндәй, кычкырып җибәрүдән чак тыелып калды. Мәдинә аның кочагыннан дулкын кебек шуып чыкты да, читкә китте. Аягы идән буйлап магнитофонга таба сузылган шнурга эләкте, ахры, көй капылт өзелеп туктап калды. Музыка туктауга, Сәйяр таянычын югалткандай ярсып, өстәл янына килде һәм бер талпынуда мөлдерәмә тулы рюмканы эчеп тә куйды. Күзләренә яшь бәреп чыкты. Рюмканы куяр урын эзләп өстәлдә капшанды-капшанды да, кулыннан төшереп җибәрде. Рюмка идәнгә төшеп чылтырап ватылды. Менә хәзер аңа игътибар итәчәкләр, нинди-дер сүзләр китәчәк, аның беркемне күрәсе дә,ишетәсе дә килми иде. Сәйяр үз-үзен белештермичә ишеккә ташланды.

— Сәйяр!

Мәдинәнең тавышы шапылдап ябылган ишек артында өзелеп калды. Аскы катның баскычында Сәйярны Шәрәфиев куып җитте һәм җилкәсеннән умырып тотты.

— Тукта дим!

Еш-еш сулу алып, бер-берсенә төбәлеп калдылар.

— Кара син аны, ярсыган колын аттан яманрак ди. Әллә чынлап гашыйк булган инде. Ха-ха-ха. Ул хатын киң күңелле, барыбызга да җитәр. Нигә ашыгырга!

«Хатын» дигән сүз Сәйяр күңелендәге иң нечкә җиргә хәнҗәр очыдай тиеп китте. Баягы рюмканың чылтырап ватылуы колагында чыңлап куйды. Күңел түрендәге иң изге әйбернең төшеп ватылуы иде бугай бу.

Аның тирләгән йөзен, мыскыллы карашын, кырыс, тупас сүзләрен күз алдыннан юк итәргә теләп, ул Шәрәфиевкә ташланды. Тимер кебек кысылган каты куллар астында Сәйярның ныгып җитмәгән мускуллары шыкырдап куйды. Гарьләнүеннән ачынып, Сәйяр елап җибәрде..:

... Күпме вакытлар буе иң кадерле уй-хыялларын биреп, үтә нечкәләп, бары тик үзенә генә билгеле төсләр белән ясаган матурлыкны кемдер тупас рәвештә бозып китсен әле. Аны яңадан тергезеп буламы соң? Бер үк төсне кабат тудырып була дисәләр, сүнгән йолдызны да яңадан кабына дисеннәр. Кеше чарасыз кабатланырга мәҗбүр була. Ләкин нәкъ элеккечә дип үз-үзеңне ни кадәр генә ышандырма, күңел түрендә әүвәлгесен сагыну, аны юксыну калачак.

Әүвәлгесе... Мәдинәнең чын күңелдән, матур итеп көлә белүе, үзенә ятышып, чибәрлеген тантана итеп торган кыюлыгы, һәм шул кыюлык эчендә сине алгысыта торган яшерен бер көч — барысы томанлы пәрдә артында калды түгелме? Бер ни дә булмады кебек югыйсә, шул томанлы пәрдәне атлап кына чыгасы да... тагын шул елмаю, ягымлы тавыш тормышның бөтен ваклыкларын еракка чигерер дә куяр иде. Ләкин кечкенә генә нәрсә, кеше кулы, акылы җитә алмый торган нәрсә... тойгы сине бәйдә тота, җибәрми икән.

Читтән караганда, салкын акыл белән бик тиз хәл ителердәй мәхәббәт фаҗигаләре, ялгышуларның күбесе, әнә шул рәнҗүле, яисә горурлык тойгысы аркасында гына булуын Сәйяр әлегәчә белми иде.

Икенче көнне эшкә Сәйяр шундый уйлар белән гаҗизләнеп, яшәүгә өметен өзгән халәттә килде. Бер кемне дә күрәсе килми иде аның. Нигә мин болай соң әле, берни булмады бит, берни дә булмады дип, үз-үзен күпме генә ышандырырга тырышса да, барыбер төшенке уйлардан арына алмады. Кичәге төсләр бүген уңган шикелле. Бөтен нәрсә мәгънәсен югалткан шикелле.

Эш бүлмәсендә ни кылырга белми арлы-бирле йөренгәндә идарәдән курьер килде, Сәйярны постройком председателе чакырган. Юлда аңа диспетчер очрады. Сөйләнеп тормаса гына ярар иде дип уйлап куйды Сәйяр. Бибишевның күрешү әмәленә һич ияләшеп бетә алмый ул. Болай гына исәнләшер дисәң, юк, сиздерми генә кулын сузган булыр. Җиң эченнән чыгар-чыкмас торган симез кулы җәнлек сыман посып кына якынаер. Бик искәрми торсаң, Бибишев ике уйлап тормый, эчкә китереп төртә. Соңлап булса да күрешергә мәҗбүр итә. Бүген дә шулай булды.

— Син нәрсә, бөтенләй төсең качкан, әллә авырыйсыңмы?

— Әйе,— диде Сәйяр сүз озатмыйча. Ни өчен кәефе юклыгын әйтеп бирсә, Бибишев шаркылдап көләр иде. Сәйяр халәтен аңлау өчен аңа дистәләгән еллар аша, үткәненә чигенергә дә чигенергә бит.

— Синең белән бер сөйләшәсе бар әле, энем. Күзеңне ачыбрак йөр син, үз башың белән уйла. Хәлләр буласы бар әле алда...

... Постройком председателе Сәйярга күтәрелеп карамыйча гына баш кагып исәнләште һәм нидер язуын дәвам иттерде. Сәйяр өстәл тирәли тезелгән урындыкларның иң читтәгесенә утырып, инде күп тапкырлар күргән булса да, кабинет эчен кабат күздән кичереп чыкты. Бераздан Хәтамтаев кәгазен читкә этәрде дә, күзлеген салып Сәйярга төбәлде.

— Килдеңме?

Җавап таләп ителмәгән бу сорауга Сәйярның «юк, килмәдем» диясе килде.

— Үзең беләсең, безнең идарәдә яшьләр юк диярлек. Менә быел көз ГПТУдан яшьләр килгәч, спорт эшенә махсус кеше алачакбыз. Ә хәзергә... Киләсе атнада трест күләмендә җиңел атлетика ярышы булачак. Ун спортсмен сораганнар. Бишесе хатын-кыз затыннан. Былтыргы кубокны үзебездә калдырасы иде бит.

Хәтамтаев сынаган шикелле Сәйярга төбәлеп бераз тын утырды.

— Житәкче булып син барырсың. Команданы бүген үк җыя башларга кирәк. ГПТУга бар, мәктәпләрне йөреп чык. Көчлеләрен үзебезгә тартырга кирәк.

Сәйяр ялт итеп Хәтамтаевка борылды. Сәйярның болай туры караганын ул беренче тапкыр күрә иде, шуңамы бу гаҗәпләнүле-кыю карашны үзенчә юрады.

— Без аларга түләрбез, борчылма, кеше хәзер бушка төчкерми дә. Документларда безнең эшче булып күренерләр, анысын гына әмәлләрбез.

Сәйяр мондый көтелмәгән тәкъдимнән аптырап калды. Бүген ул һәммә нәрсәгә сак карый, шикләнә иде. Хәтамтаевның сүзләрен ул үз бизмәненә сала барды һәм кискен бер нәтиҗәгә әзерләнде. Хәтамтаев тыныч кына үз тегермәненә су коя торды:

— Әллә син башка оешмаларда шулай эшләнми дисеңме? Ярыш ул хәйләсез булмый.

Сәйярның тавышы карлыгып чыкты:

— Булдыра аламы-юкмы, үзебезнең эшчеләрне алырга кирәк.

— Син нәрсә! — диде Хәтамтаев тавышын көчәйтеп, — оятка калыргамы! Моңа кадәр шәп урыннарны алып кил дә, ә быел... Ни уйларлар безнең турыда?

— Ялганлап җиңүдән кемгә файда?

— Сабыйлыгыңа барасың. Олылар әйткәнне тыңла син.

— Мин үземчә дә эшләргә тиештер бит.

Хәтамтаев күндәм егеттән мондый каршылык көтмәгән иде, гаҗәпләнүен яшермичә авызын ачып калды. Аннары кабалана-кабалана тартмасыннан чиста кәгазь алды да, шома өстәл өстеннән Сәйярга таба шудырып җибәрде:

— Яз, эшлисең килми икән, гариза яз!

Сәйяр кыюсызлыгын онытып үҗәтләнә төште.

— Минем эштән китүне сез хәл итмисез бит.

— Безнең сүзгә ышанмый калмаслар.

Сәйярнең күзләре кайнарлана төште. Мондый ук борылышны көтмәгән иде ул. «Куласа... Куласага ябышкан малай мин... Туктатам, имеш...» Кайчан ишеткән иде соң ул бу сүзләрне? Кемнән ишеткән иде? Мине дә шул тормыш дигән куласа үзе теләгән якка бөтереп алып китәрмени? Каршы килергә көч җитмәсмени? Куласа... ә нигә ялгыз, бер үзең, тирә-юньдә таяна алырдай кешеләр бар ич. Ә кемнәр?

Сәйяр куен кесәсеннән авторучка алып нидер яза башлады. Уйларының очына чыгу өчен вакытны сузасы килә иде аның. Хәтамтаев почмакта торган радиоалгычны борып карады, тавышы чыкмагач, өстенә йодрыгы белән сугып куйды. Карлыккан музыка авазы гына бүлмәнең эч пошыргыч халәтен тернәкләндерә алмады. Хәтамтаев ашыгып килеп Сәйяр кул астындагы кәгазьне тартып алды да, бөгәрләп чүп савытына ыргытты. Янәшәгә утырып Сәйярнең иңенә кулын салды.

— Мине яхшылап тыңла әле син. Безгә спорт-масса эшенә каралган акчаларны вакытында тотып бетерергә кирәк. Бу — бер. Шушы олы ярышта үзебезне күрсәтсәк, кирәк нәрсәләрне югары оешмалардан кыю рәвештә сорый алабыз. Бу — ике. Файдасы үзеңә дә тияр, мин сиңа әкренләп аңлатырмын...

— Мин андый юлга баса алмыйм.

Хәтамтаев кисәк кузгалды, урындыгын шыгырдатып читкә тибәрде.

— Әллә нишләп килгәнсең әле син. Бар, икеләнеп торма.

— Мин уйладым инде.

— Бар, бар, вакыт кадерле безнең. — Хәтамтаев Сәйярны ишектән этеп диярлек чыгарып җибәрде.

Вак кына яңгыр сибәли. Асфальт өсте нәни генә тамчылардан сипкелләнеп килә. Биткә сирпелгән тамчыларның сизелер-сизелмәс кенә салкынлыгы да Сәйярны өшетеп җибәрде. Юк, яңгыр тамчылары түгел, ә шушы минутта барып сыеныр кешесе булмау, ялгызлык өшетә иде аны.

Поселокта ике ел уку дәверендә, төрле авыллардан җыелган классташлары арасында ул нигәдер үз кеше булып китә алмады. Йомылып читтәрәк йөрде. Уку бетте һәм төрлесе-төрле якка таралыштылар. Уйлап баксаң, сагынырлык бер генә якын дусты да булмаган икән. Сәйяр ни өчендер үзеннән өлкәнрәкләргә тартыла, аларга ышанып карый иде. «Һәммәсенә ышанып кына яшәүнең чиге бардыр. Мин дә яшим бит. Мин дә уйлыйм бит. Мин дигән мәгънә алга бәреп чыга башлаган икән, димәк, икеләнүсез беркатлылыкка чик куярга кирәктер. Мин уйланам, мин яшим, шулай булгач, үз хөкемемне, үз нәтиҗәмне үткәрә алырга хакым бардыр бит!

Төсләр, буяулар Сәйяр өчен күп нәрсәдән кадерле. Буяулар изге сурәтләр ясар өчен яратылган. Аларга чиста кул, ак күңел белән генә якын килергә мөмкин. Әгәр алай түгел икән, ул буяулар, төсләр сиңа хыянәт итәчәк...

Сәйяр киредән идарә ягына борылды. Әсфән Сафич белән киңәшәсе килә иде аның.

Бибишев белән сөйләшкәннән соң ул ныклы бер карарга килде.

## 9

Вагон тәгәрмәчләре бер алгысынып, бер талгынаеп тыкылдый-тыкылдый рельс җөйләрен санап бара. Урман куенына поскан кечкенә станция утлары караңгы вагон эчен ялмап ала да, суырылып артта кала.

Сәйярнең уйлары да бер яктыра, бер караңгылана: ул өске сәндәрәгә кырын ятып үз уйларына бирелгән дә, вагон тирбәлешенә оеп бара, кисәк кенә үзалдына елмаеп куя, тагын сагышлана.

Сәйяр тиздән яшел солдат киеме киячәк. Солдат киеме турында уйлагач, Сәйярнең бала чагында хәтеренә кереп калган икенче бер яшел кием исенә төште...

... Бик бәләкәй чагында абыйсы Сәйярны җитәкләп районга алып киткән иде. Кызу кояш астында тирләп-пешеп килгәннән соң, урамдагы сатучыдан алып Сәйярга абыйсы тәмле су эчерде, ә үзе сыра эчәргә дип ишек тупсалары ашалып беткән, эчтән әчкелтем ис килеп торган бинага керде. Сәйярны почмактагы мичкәләрнең берсенә утыртып куйды да, үзе чиратка барып басты.

Сәйяр бу шау-шу, тәмәке төтене эченнән ничек чыгып китәргә белми хәтсез утырды ,абыйсы чиратның алдына җиткәндә тәмам түземен җуйган иде инде ул.

Шул вакыт ишектән аксаклый-аксаклый, бер кулына кәкре башлы таяк тоткан абзый килеп керде. Өстенә кояшта уңа төшкән яшел гимнастерка, галифе чалбар кигән, башында — ямьшәйгән хәрби фуражка. Килеп керде дә ул, чиратсыз-нисез үтеп, сатучыга акча сузды. Сәйярнең абыйсы шунда гына искәреп алды һәм чыраен сытып аның кулын этәреп куйды. Яшел киемле абзый аның саен үҗәтләнебрәк ешына башлады. Сәйярнең абыйсы түзмәде, әйләнеп торып аны кисәк кенә этеп җибәрде. (Аның гарип икәнен күрмәде бугай ул.) Әлеге абзый чайкалып китте, тигезлеген саклый алмыйча, мичкәләр арасына, юеш идәнгә барып төште. Агарынып, калтырый-калтырый торды, каударланып Сәйярнең абыйсына таба китте һәм таягын күтәреп аның чыраена уңны-сулны бәреп тә алды. Бөтен чират ни булганын төшенмәстән ушсыз калган иде бу минутта. Сәйярнең абыйсы кан бәреп чыккач битен каплап бөгелеп төште. Сәйяр кычкырып мичкәдән сикереп төште дә әлеге абзыйның гимнастерка итәгенә ябышты. Бераздан әлеге абзый ярсып, нидер сөйләнә-сөйләнә, ишектән чыгып китте.

Сәйяр абыйсы белән бу ярым караңгы бинадан чыкканда, яшел киемле абзый таягына таянган килеш гаҗәп житез атлап, аксаклый-аксаклый ераклашып бара иде.

Сәйярнең калтыравы һаман басылмаган: ике хис көрәшә иде аның күңелендә, битеннән юл-юл кан бәреп чыккан абыйсын кызганды ул, яшел киемле абзыйга ачуы килде. Ә бер уйлаганда абыйсына ачуы килде, яшел киемлене җәлләде ул.

Поезд тәгәрмәчләре дәртле тыкылдый. Тышта тоташ караңгылык иңгән очсыз-кырыйсыз тайга сөңгеләрен өскә чөеп килгән яу кебек шомлы, уйларыңны чәчеп җыя алмаслык тирән, ага да ага бу тантаналы чиксезлек, ага да ага.

Туган ягыннан Сәйяр отыры ераклаша бара. Ераклаша барган саен, инде хәзер үткәндә калган вакыйгалар, үз вакытындагы борчулар җиңел генә хәл ителәсе булган кебек.

Хәтамтаевка буйсынып, ялганга барырга теләмәде ул. Бәхетенә каршы, начальник шул көннәрдә генә командировкадан кайтып төшкән

иде. Сәйяр үзен ташчылар бригадасына күчерүләрен сорап гариза язды да, бар кыюлыгын җыеп начальникның ишеген какты. Беренче тапкыр керүе иде. Күн тышлы ишекне ачу белән, кабинетка керү өметен каршыдагы икенче ишек бүлде. Ике ишек арасындагы караңгылыкта чәчелеп киткән кыюлыгын җыярга да өлгерә алмый калды. Кабинет эче хәтәр зур икән. Өстәл бик түрдә икән. Затлы келәмнән өстәлгә кадәр араны үтү Сәйяр өчен тагын бер сынау булды.

Начальник Сәйяр белән коры гына сөйләште. Ул, рубкасында утырган капитан кебек, «палубада, трюмда» булган хәлләрне үзенә турыдан-туры буйсынган кешеләр аша белеп тора иде. Димәк, Сәйяр турында җиткереп өлгергәннәр. Начальник сүзенерактан уратып килде дә: «Эше канәгатьләнерлек булмаган художникны без гади эшче итеп бригадага күчерә алабыз», — дип куйды. Аклану көтте бугай ул. Ләкин аның кисәтү өчен әйтелгән сүзенә каршы Сәйяр бригадага күчерүләрен сорап язган гаризасын җәеп салгач, ул гаҗәпләнә калды. Вәкарьле карашын төбәп алай сорашты, болай сорашты, Сәйяргә исә үзен аклау бәрабәренә бүтәннәр бакчасына таш ату хас түгел иде.

Начальник нидәндер шикләндеме, гаризага тиз генә кул куюны үз дәрәҗәсенә хилафлык китерү дип санадымы, бер ни әйтмичә үзендә калдырды.

Бер-ике көннән соң Сәйярга остаханәсе белән саубуллашырга туры килде. Әйберләрен җыйнаштырганда, буяу банкасы астыннан ике унлык чыкты. Бөтенләй оныткан булган. Шәрәфиевнең распредложение өчен дип калдырган акчалары иде алар. Сәйяр кыштырдап торган акчаларның почмакларына куе буяу сылады да, Шәрәфиевнең кабинет ишегенә ябыштырып китте.

Стена газетасына кайчандыр карикатурасын ясаган Мәрданшин бригадасына эләкте ул. Сәйяр кебек үк яңа гына эшкә кергән егет белән икесен измә ташырга куйдылар. Кран ватылган икән. Чиста киенеп кенә контора тирәсендә уралган Сәйярның төзелешкә эшкә килүен төрлечә юрадылар. Бигрәк тә хатын-кызлар. Кайсылары үтешли «чагып» та алгаладылар.

— Нигә галстугыңны тагып килмәдең, үскәнем?

— Аксөягеңә тузан кунмасын!

Измәне носилка белән өченче катка ташу торган саен авырлаша барды. Сәйярга ничек тә сер бирмәскә кирәк иде. Күзәтәләр бит, астыртын гына сыныйлар .Сәбәп кенә булсын, дәррәү көләчәкләр үзеннән.

Мускуллар соң чиккә җитеп тартыла, йодрыклар носилка сабына берегеп кысылган. Һәр юллаган саен Сәйяр: «Тагын бер генә этаж калды», аны менеп җиткәч, «ун адым гына... Биш... Ике...» — дип үзен юмалап көчен саклый, измәне илтеп аударгач, тагын бер адым атлыйсы булса кулдан төшеп китәсе иде дип уйлый һәм җиңел сулап куя иде.

Эш соңында бригадир килеп Сәйярның җилкәсенә кулын салды.

— Син, брат, миңа ачуланма инде, күрәм, бик авыр булгандыр. Синең бәхеткә кран ватылды бит, каһәр. Иртәгә башка эшкә куярмын үзеңне, — диде.

Арып ватылган тәнен язып Сәйяр урыныннан торды, күңелендә ниндидер канәгатьлек иде. Бригадирның тоныч, күксел тавышына көч бирергә теләгәндәй ул тамагын кырып куйды.

Шул бригада аны хәрби хезмәткә озатты.

...Вагон тәгәрмәчләре һаман бер көйгә тыкылдый. Тайга өстеннән сыек зәңгәр яктылык сирпелде — таң билгесе.

Сәйяр ерагайган саен туган ягы кичерәя, кичерәя, йөрәгенә керeп йомыла барды.

Зурая, зурая барган сагышы уртасында бары тик бер кеше торып калды. Аңа — үкенүле мәхәббәтенә ул әйләнеп кайтыр әле...

## 10

Менә бүген, ике елдан соң, ул тагын Чатыр тау түбәсендә. Бу биеклектән күз күреме житмәс япан киңлекләр ачыла. Туган як киңлекләре. Әнә елтырап яткан елга буйларында яшеллек арасына поскан авыллар, челләдән качып, күләгә эзләп төшкән көтү шикелле тыныч бер моңсулыкта яталар. Бары да элеккечә, Сәйяр киткәндәгечә сыман. Әмма нечкәләп карасаң, тирә-юньдә һәммә үзгәреш күзгә чалына икән. Әнә офыктагы урманның бер төше сынган таракка охшап сирәкләнеп калган. Ә элек урман әкрен генә агып барган яшькелт-зәңгәр тәтен сыман тоташ, тигез иде. Йомшаклыгы белән күңелне иркәләп тора иде.

Анда-санда кырлар инәнә таянып баскан нефть вышкаларыннан тимер салкынлыгы бәреп тора.

Әнә көн кызуына ак түбәләрен жәйгән поселок тагын да киңәя, зурая төшкән. Моннан караганда поселокның агачларга күмелгән урамнары тараеп, яшел елгалар булып тармаклана.

Сәйяр таудан түбәнгә таба төшеп китте. Артык текәләп караудан-мы Сәйярның күзенә яшь килде. Сискәнеп як-ягына каранды. Кемдер сиздермичә генә күзәтә кебек. Көн хозурында оеп яткан яшеллек аша ул әбисенең карашын тойгандай булды. Һәм аны шунда гына жанын сулкылдатып татлы юксыну биләп алды. Кеше үлгәндә йолдыз атыла диләр. Искәрмибез генәдер. Ә бәлки урманның да сөюле караш житмәүдән берәр агачы, аңа гына атап яратылган агачы корыйдыр. Тагын, тагын нидер сүнәдер, өзеләдер...

Бер караганда абыйсына юкка үпкәли Сәйяр. «Тиздән бөтенләйгә кайтаралар, бүтән хат язмагыз», — дип хат салган иде, абыйсы шуңа күрә дә Сәйярга хәбәр бирмәгәндер. Жиһан әби дә: «Сәйяр улымны мәшәкатьләмәгез, ерак юлдан азапланып кайтып йөрмәсен, мин аны бәхиллим», дигән.

Жиһан әби апрель аеның кояшлы бер көнендә сырхауламыйча, сәламәт йөргән жиреннән үлеп киткән. Иртүк мунча яктырган. Килене белән һәйбәтләп юынып кайткан. Сандыгыннан үлемтегенә дигән әйберләрен алып, улы белән килененә, кайсын хәергә, кайсын гүр сәдакәсенә икәнен күрсәтеп биргән. Чиста жәймә жәеп караватка менеп яткан. Бераз ял итим әле, балалар, дип пошаманга калган улы белән киленен тынычландырып түр өйдән чыгарып жибәргән һәм... йоклаган жиреннән үлеп киткән. Сәйярга ул төшендә үлгәндер шикелле тоела. Була бит шулай: саташулы төшеңдә өстеңә ажгырып поезд килә, янсә бик биек кыя түбәсеннән ычкынып китәсең. Төпсезлеккә очкан вакытта куркудан кычкырып уянасың. Ә шул чакта уяна алмый калсаң?.. Жиһан әби нәкъ менә төшендә үлгәндер шикелле тоела Сәйярга. Соңгы мизгелдә уяна алмый калгандыр, янсә үзе теләмәгәндер...

Жиһан әби бакча башына көнбагышлар утырта торган иде. Сәйяр күз алдында әбисе һаман да үз алдына сөйләнә-сөйләнә сары чәчәкле көнбагышларны тибрәтеп йөри кебек.

Быел анда көнбагыш утыртмаганнар, ызанда исә иске бишмәт, колакчынлы бүрек кигезгән карачкы гына Жиһан әби куйгандагыча тора. Әгәр әбисенең бердәнбер истәлеге булып шушы шәлперәйгән, бер якка янтайган карачкы гына калган булса, нинди күңелсез, үкенечле булган булыр иде. Юк, Жиһан әби үзеннән соңгыларга олы истәлек калдырган. Ул тапкан шифалы балчыклы Торна сазының мәңгелек тынычлыгын кузгатканнар. Анда өч катлы санаторий бинасы салынып ята. Жиһан әби йөргән сукмаклар өстенә асфальт жәелгән. Жиһан әбине күрергә дип газетадан корреспондент та килгән булган, ләкин соңга калган. Шулай да ул, төзелеш конторасы аша, Жиһан әбинең каберенә мәрмәр таш куйдыртып та киткән. Каберлектәге бердәнбер мәрмәр таш — авыл анасына хөрмәт билгесе. Аны карты белән янәшә жирлә-

ганнәр. Бу юлы ялгышмаган инде ул. Салкын рәшәткәгә тотынып торган чакта Сәйярны сискәндереп шундый уй килгән иде: «Бу юлы ялгышмагансың, әби».

Ана назын биргән, туган якка бәйле бердәнбер якын кешесеннән калу кайгысын Сәйяр ничек кенә булса да үткәреп җибәрергә тырыша иде. Җиһан әби, үлеме белән дә, Сәйярны юата алды бугай.

Мәдинәләрдәге мәҗлестә «Кеше ни өчен яши?» дигән бәхәс бик абстракт булып, Сәйярга кагылышсыз, ерак тоелган иде. Баксаң, бу сорауның барлыгын да белмичә, һәммә кеше үзенең яшәве белән шуңа җавап бирергә омтыла түгелме? Тик гомереңнән артып калу һәркемгә дә язмагандыр шул. «Гомереңнән артып калу» — әнә шул сорауга җавапның бер тармагы түгел микән? Үзеңнән соң да яшәү, кешеләр хәтерендә генә түгел, матди җирлектә дәвам итү — хикмәт шуңа ирешүдә түгел микән?..

Сәйяр поселокның тар урамына килеп керде. Бакча эченә чумып утырган финский йортларны үтеп уңга борылды. Чуерташлары калкып чыккан иске тротуар аны мәктәп юлына алып китте. Инде укулар беткәндер. Укытучылар ялдадыр. Бинасын булса да күреп чыгармын дип уйлады Сәйяр.

Мәктәп янына килеп житкәч, ул аптырап калды. Коймалар сүтелгән. Кая карама анда бетон плитәләр. Зур балконлы төп бина урынына, кызыл кирпечтән төзелгән өч катлы бина калыккан. Кран йөреп тора, машиналар кычкырта — төзелеш кайный. Сәйяр иске мәктәп бинасы белән саубуллашкан шикелле басып тора бирде. Димәк, ул ачып кергән ишекләр, ул йөргән коридорлар бетәргә хөкем ителгән. Бөтенесе дә яңа булачак. Кеше хәтере — биналарга, елгаларга, урманнарга бәйле. Читләрдә йөреп кайткач, хатирәләргә бәйле урыннарның үзгәргәнен, юк ителгәнен күреп күңелдә рәнҗү туа. Хатирәләр җир астына киткән су кебек, күңел чоңгылына кереп йотыла.

«Яңа капканы да элеккесе урынына ясаганнар. Капкадан кергәндә, уң тарафтан күзгә рәхәт күләгә төшеп тора иде, күк йөзе болай якты булып күзне чагылдырмый иде. Нигә болай соң? Ә! Монда мәктәп түбәсеннән дә биек тополь агачы бар иде бит. Кискәннәр... Мәһабәт баскычлы бина төзеләчәген белсә, моннан йөз еллар элек бу агачка җан өргән кеше аны тегеләйрәк утырткан булыр иде».

— Ишетмисеңмени, егет, бәлки панеловозны уздырып җибәрерсең, ә!

Арттан килгән тавыш Сәйярны сискәндереп җибәрде, ул читкә тайпылды һәм борылып карагач күзләрен түзә алмады. Каршында түгәрәк корсагын киереп Бибишев басып тора иде. Нәкъ элеккечә, тамчы да үзгәрмәгән. Хәтта галстугы, кара бостон костюмы да шул ук, тик бераз кыршыла төшкән, артык еш үтүкләүдән урыны-урыны белән ялтырап тора.

— Исәнмесез, Әсфән Сафич, куркыта яздыгыз.

— Куркытырсың солдатны. Баядан бирле карап торам аны, безнең художник түгелме соң бу, минәйтәм. Ошатсаң ошамаган да, ошатмасаң ошаган да кебек. Кайчан кайтып төштең?

— Шушы арада гына.

Бибишев сатып аласы малын тикшергән сыман, Сәйярның мускулларын кыскалап алды.

— Кара син аны, зәһәр егет булып кайткансың гел. Кырыкмыш тайларны тәртә арасына кертә бу әрмия дигәнең.

Тормозларын шыгырдатып кырыйга «Бобик» — ГАЗ-69 машинасы килеп туктады.

— Бу объектта эш бетте минем, идарәгә кайтабыз, теләсәң, әйдә,— диде Бибишев.

Машина идарәгә кайтып туктады.

Сәйяр диспетчерның кабинетында әллә ни үзгәреш күрмәде. Стенада элеккечә диаграммалар, таблицалар. Бөтен нәрсәгә сеңеп искергән тәмәке исе дә хәтта таныш иде.

— Бездә хәтсез генә үзгәрешләр булып алды бит әле, — диде Бибишев. — Хәер, ишеткәнсеңдер инде. Юк? А-һаа, алга китеп син бөтенләй артта калгансың. Иске начальникны трестка алдылар. Урынына, план бүлегендә пөхтә генә киенеп йөргән егетне беләсең ич, шуны куйдылар. Юаш кына сыман иде, переворот ясады да куйды. Мә, карап чык, — дип, Бибишев өстәл тартмасыннан гәзит чыгарды.

Анда Шәрәфиев белән Хәтамтаевның төрле махинацияләрен ачып салган зур гына мәкалә урнаштырылган икән. Шәрәфиевне эшеннән алганнар. Хәтсез генә сумма штраф түләп, сынау шарты белән калдырылган. Хәтамтаевка шелтә бирелгән. Мәкалә астына калын хәрефләр белән «Өлкә газетасының үз корреспонденты Я. Сабитов» дип язылган иде.

Сәйяр укып чыгып газетаны өстәлгә куйды.

— Элек бездә эшләгән Сабитов язган, — диде Бибишев, — Шәрәфиевне бер елга дәвалау йортына җибәрделәр. Җәл, әйбәт егет иде ул, каһәр. Хәтамтаевка иярәп кенә харап булды. Аларга ияресең дип, мин синнән дә курыккан идем.

Бераз сөйләшеп утырганнан соң Сәйяр диспетчер кабинетыннан чыкты. Тышкы ишек катындагы шомарып беткән култыксага таянды. Ул чактагы хәлләр Сәйяр уйлаганнан күпкә җитдирәк булган икән шул. Сәйяр китеп бармаган булса, нишләр иде икән? Юк, алар «уенына» тартылмас иде ул. Бер максатсызлар гына бирешә, ә Сәйярның омтылышы сәнгать иде бит. Бик авыр чакта да, үзен бәхетле тойган чакта да, юаныч, теләктәшлек эзләп үзе ясаган рәсемнәрне хәтеренә төшерә, кайдадыр, тормыш ваклыкларыннан читтә, мәшәкатьле чынбарлыктан өстә, үзенә генә билгеле булган сәнгать дөньясына таяна иде ул. Үткәне белән киләчәк өмете арасында чистарып, яңа бер гамь, кичерешләр белән тормышка кайта иде.

Хәрби хезмәттә чакта, музей эшләргә килгән Греков студиясе рәссамнарына булышырга дип, кулы белгәнрәк берничә солдатны алганнар иде. Сәйяр да шулар арасына эләкте. Бу бәхетле очраклылык аның өчен һәр яклап та кабатланмас мәктәп булды. Анда алган күнекмәләрдән соң, сәнгать училищесына керә алуына шиге юк иде аның.

Күп нәрсәне аңлады ул. Тормыш — олы көрәш икән. Вак көрәшләр көндәлек каршылыклар икән. Берсеннән чигенгән кеше икенчесеннән чигенүне җиңелрәк кабул итә, үзен аклар өчен сәбәп таба башлый, һәм шулай күнегә бара. Олы көрәштән читтә кала...

Сәйяр үзе эшләгән остаханәгә китте. Гүя ул шул бүлмәгә сыйган оялчан үсмер чагы белән мәңгегә саубуллашырга дип бара иде.

Ишек катында ул беразга тукталып торды. Эчтән чүкеч . тавышы ишетелә иде. Ишектән бер дә бүтән түгел, маңгай чәчләрен сыпырып сөйләшә торган ул чактагы Сәйяр чыгар кебек тоелды. Әгәр шундый могҗиза булса, Сәйяр аның җилкәсеннән кагып: «Их син, егет», — дияр иде.

Чүкечне егетләрчә оста уйнатучы кыз кеше булып чыкты. Үзе ябык кына, үзе чалбар кигән кыска чәчле бу кыз Сәйяр белән битараф кына исәнләште. Кыска буйлы кызлар гадәттә чая була дип уйлады Сәйяр.

— Сез эшлисезмени монда?

— Мин эшлим монда.

Кайчандыр үзе эшләгән бүлмәгә хуҗа булган бу кыздан Сәйяр көнләшеп тә куйды.

Стена буена искерә төшкән плакатлар өелгән. Сәйяр ясаган панно-дан яңартырга дип алганнар, күрәсең. «Шәп чыккан, бу синең беренче

унышын», — дип Шәрәфиев Сәйярның кулын кыскан иде. Кичә генә кебек, ә уйласаң, еллар үткән.

— Боларны сез ясаган идегезме?

— Каян беләсең? — «Малай башлы бу кызга сез дип торырга әле», — дип уйлады Сәйяр.

— Ишетеп тә, күреп тә беләм.

— Күреп?

Кыз өстәл тартмасыннан ватман кәгазе чыгарды.

— Менә бит, автопортретыгызны ясап калдыргансыз.

Сәйяр рәсемне карап тормады. Нигәдер аның кәефе күтәрелеп китте. Әгәр бер көннән китәсе, күрәсе кешеләре булмаса, бу кыз янында онытылып утырыр иде ул.

— Син нефтьчеләр йортында эшләүче Уразаевны беләсеңме?

— Ишетеп кенә беләм, — диде кыз.

Сәйяр китәргә җыенды.

— Сез анда барасызмы, әйдәгез утыртып барам, мин дә шул якка, — диде кыз.

— Исемең кем соң синең?

— Нигә?.. Гөлсирин.

«Бу исем аңа ябышмый» дип уйлады Сәйяр.

Аның утыртып барам дигәне «кәҗә» дип йөртелгән бәләкәй мотоцикл булып чыкты. Лаклары кубып беткән, арткы утыргычы ябагасын койган, эчтән пружинасы төртеп тора.

Гөлсирин ачкыч тишегенә шырпы тыкты да, бер тибүдә моторны кабызды.

— Әйдә, нык тарта ул, курыкма.

Сәйяр күнми булдыра алмады. Утырды. Утыргычы ярый инде, тик менә тотынгычы юк икән бит.

— Төшеп калмыйм дисәң, мине ныгытып кочакла,— дип, кыз газны арттырды да, мотоциклны урыныннан хәтәр генә кузгатты. Мотор тавышын җиңеп Сәйяр аның колагына кычкырды:

— Малай булып туасы калган сиңа.

— Үзем дә беләм, соң шул, — диде кыз. — Авылдан мин. Безнең гаиләдә ир заты юк, умартаны да үзем карыйм.

Гөлсирин мотоциклны нефтьчеләр сараеның колонналы ишек төбенә җилдереп кенә китереп туктатты. Сәйярның кулын егетләрчә кысты да:

— Килгәлә, — диде. — Ходай тәгаләнең планы буталган, квартал азагында туганмын мин.

Мотоциклын сикертеп диярлек урыныннан кузгатты.

Сәйяр колонналар арасыннан эчкә керде. Уразаевны күрәсе килә иде аның. Яңа эшләрен карап, үзенеке белән чагыштырасы килә иде. Эчке ишек катында пешәләнә-пешәләнә чәй чөмереп торган вахтер хатын, Сәйярның соравына каршы тупас кына итеп:

— Юк ул, командировкада, — диде. Бүтән сорау бирүең файдасыз дигәндәй сүзеп кенә карады да, яны белән борылды.

«Нишлисең бит, министрларның гадиләшә барган, вахтерларның тәкәбберләнә барган заманы. Чигенүдән башка чара юк».

Сәйяр олы урамга чыкты. Дүрт рәтле топольләре белән шаулап торган урамны танырлык түгел. Топольләрнең ян-яктагы ике рәтен төбе-тамыры белән кубарып чыкканнар. Юлны киңәйтәләр. Машиналар агымын сыйдыра алмый, күрәсең. Сәйяр тәүге тапкыр вакыт агышын әйберләрнең үзгәрә, туза, искерә баруында күрде. Вакытны шулай ап-ачык итеп, реаль әйберләр аша тою аның күңелендә ямансу бушлык тудырды. Ярый әле, онытылырга була: урам читләренә паннолар, өй фасадларына плакатлар куелган. Тәҗрибәле кеше сыман гаебен-кыегын табып йөрергә була.

Сквер янына житәрәк Сәйяр һич көтмәгәндә Хәтамтаевны очратты. Искәрми дә үтеп киткән булыр иде, тик... Хәтамтаевның кыяфәтенә үтеп баручы һәр кемнең игътибары тукталырлык. Ул июнь челләсе дип тормаган, өстенә иске кара плащ, култыгына тузып беткән иске папка кыстырган — карачкы сыман килә. Төз, мәһабәт гәүдәсе сыгыла төшкән, иңнәре салынып тора. Аның төбәлеп караганын күргәч, Сәйяр исәнләшми кала алмады.

— Бәй, син безнең художник түгелме соң?

Аның алгы тешләре урынында бушлык күргәч Сәйяр кызганулы бер хистән тетрәнеп китте. Хәтамтаев папкасын сул якка күчереп, уң кулын күрешергә дип сузды. Элек, тәвәккәл бер өстенлек белән, кулыңны магнит кебек суырып ала торган йонлач нык кул хәзер инде ятсынган песи шикелле сак кына сузылды.

— Молодец, энем, исән-имин кайткансың.

«Чарланган тавышы ныклылыгын җуймаган икән әле».

— Әйдә бераз утырып хәл алыйк, — дип, Хәтамтаев якындагы эскәмиягә ишарәләде. Утырырга дип бөгелгәндә билен тотып эчтән генә ыңгырашып куйды.

— Әрмиядән шәбәеп кайталар хәзер, молодец. Ә мин чүгеп барам, энем. Пенсия юллап йөрү менә, эшләр рәт калмады. Стажың җитми диләр. Теге яңа начальник бик вакчыл бәндә булып чыкты. Киттем мин аннан. Шәрәфиев кенә... Ишеткәнсеңдер. Үзе дә инде, бигрәк узынып киткән шул.

Сәйярда бая туган кызгану хисе берьюлы юкка чыкты. Бу куян рәвешенә кергән кешенең күңелендә һаман да бүре икән бит. Эчке халәтен күзләре яшерә алмый, әнә нинди үткен хәйләкәрлек белән яна.

— Сездән дә уздырганмы? — диде Сәйяр ачу белән.

— Мин, энем, чиста эшләдем. Черки дә борынын тыгарлык түгел. Кеше кесәсенә кермәдем.

— Ә хөкүмәтнекенә?

— Үзең ничек соң, эшкә урнашмадыңмы әле?

— Кешенекенә кермәдем дисез инде!

— Алай вакланмадым мин, энем.

— Ә хөкүмәтнекенә?

— Алла, билем авыртып китте, — Хәтамтаев ыңгырашып куйды. Сынып калган тавышын ялгап Сәйярга борылды. — Нәрсә дип болай төрпәләнәсең әле, әйбәт кенә сөйләшеп утырганда. Башың яшь әле синең... Эш ул черекле нәрсә, туган. Меңне үтәргә дигәннәр икән, закон бозыла дип торма, булдыра алырдайларга йөзлекне ыргыт, артыгы белән кире кайтачак. Артыгын үз кесәңә салырсың. Сарыклар да исән, бүреләр дә тук.

— Уртак малга эт табыла дисез инде.

— Ярпачланма, энем. Синнән казауракларны күргән. Дөнья малы беткесез ул. Таптылар бәйләнү әмәле: бер пот балык тотсаң да, браконьер дип бәйләнгән булалар. Вакыты белән бер завод отходыннан миллион балык корбан була.

— Бер пот, имеш, сезнең ишеләрне кушсаң, меңнәргә җыела. Бәрәмтекләп кисәргә кирәк сезне.

— Бар, энем, делоларны күтәр. Эскәк белән эзләп тә берни таба алмассың. Кәгазь алдан йөри торган заман, кәгазь! Мөһере дә булса... Печать ул бер генә яклы.

— Дөреслек бер ярып чыга ул.

— Хәтер ялгышырга мөмкин, тел ни сөйләмәс — кәгазьгә ышаналар. Тузанын гына кагасың да.

— Хәйләкәр сез, ә!

— Хәйләкәр булмасаң, дөреслекне эзләргә кала инде.

Ярый әле, Хәтамтаев кул селкеде дә, бил сызлавын да онытып,

жәһәт кенә урыныннан кузгалды. Ачудан тәмам кызыша барган Сәйяр аның якасыннан алыр дәрәҗәгә җиткән иде.

Мондый кешеләр дулкын шомарткан таш кебек гомер буена чарланып үз фәлсәфәләрен булдыралар икән. Ялган белән үзе өчен генә яшәп, синнән көлеп үләчәкләр бит алар.

Сәйяр кичәгенәк урманда күргән пошиларны исенә төшерде. «Үлеп калса, суны пычратыр дип типкәләп чыгардылар бит аны»... Җәнлекләр гадәте кешеләрнекеннән аерыла...

Зәһәр кояш йортлар артына күмелүгә көн сүлпәнәйде, эссе бөркеп торган тротуарлар сизелерлек суына башлады. Урам төркем-төркем булып эштән кайтучы кичке халык белән тулды. Кояш нурлары иң өске каттагы тәрәзәләрдә генә күмерләнеп яна иде.

Җирнең бу төбәгендә Сәйярның тагын бер кеше белән күрешәсе килде. Ул аның иң кадерлесеме? Әллә инде, кайчандыр аңа багышланган сәгадәтле минутларның шаһите буларак икеләнүле уйларына җавап табу өчен, болай, кызыксынып кына күрергә теләвеме?

Сәйярны эчке бер калтырау, астыртын шом били барды.

Увольнениегә чыккач, шәһәрара телефон станциясеннән ул аңа шалтырата иде. «Әйе, Мәдинә тыңлый», — дигән сүзне ишетүгә, трубканы куя иде дә, үзендә ихтыяр көче булуыннан, сөйләшеп китмәслек көч табуыннан канәгатьләнеп һәм Мәдинәнең әле дә шул поселокта яшәвеннән тынычланып китеп бара иде. Ә бүген ул якында гына ич...

Сәйяр чаттагы телефон будкасына кереп номерны җыйды. «Беренче гудок. Кухняда чәй әзерләп йөридер, шалтыратуны ишетеп залга чыгар. Икенче гудок. Залны үтеп йокы бүлмәсенең ишеген ачар. Өченче гудок. Ике тиенлек шалтырап автомат эченә йотылды».

— Әйе, Мәдинә тыңлый.

Бу юлы да сөйләшеп китә алмады Сәйяр. Көтелмәгән бер яңалык ишетер дә еллар буе сүрелми килгән өмете челпәрәмә килер шикелле тоелды. Билгесезлек газабын азга гына сузасы килә иде аның. Трубкаканы куйды да, агачлар күләгәсе астыннан Мәдинә торган йортка китеп барды.

Әнә тактасы шомарып беткән утыргычлар. Тик анда электәгечә гәпләшеп утыручы карчыклар гына күренми. Аларның сынаулы-күзәтүчән карашларын яратмый иде Сәйяр. Бүген исә, ул карчыклар булмагач, бу утыргычлар тол калган шикелле.

Баскыч янында чия төсендәге «Москвич» тора. Аның тәрәзәсе турына нәзек резинкага курчак-шүрәле эленгән.

Сәйяр өске катка күтәрелде. Күн белән тышланган ишек яңагындагы кнопкага баскач кына: «Аның янында бүтән берәү булса...» — дигән уй Сәйярның башыннан йөгереп узды. Ишек ятсынган кебек кыюсыз гына ачылды. Сыңар кулы белән халат изүен тоткан Мәдинә гаҗәпләнүдән зур булып ачылган күзләрен Сәйярга төбәде. Бу караштан Сәйяр үзенең буйга үсеп киткәнлеген, үзгәргәнлеген тойды. Теге вакыттагы үсмер оялчанлыгын эредән кубып сөйләшерлек өстенлек алыштырды...

— Сәйяр...

— Юк, мин түгел бу, төш дип уйла.

Мәдинәнең һич тә үзгәрмәгән чибәрлеге каршында ул бер мәлгә онытылып калды. Аны кочып аласы, билгесезлектә үткән сагынулы һәм үпкәләүле еллар аша үтеп, үсмер чактагы хыялына ирешәсе, онытыласы килде. Ләкин аны канәгать бер салкынлык, эчке бер тартыну биләп алды.

Гади генә күрештеләр. Сәйяр тузанлы ботинкаларын салып, Мәдинә тәкъдим иткән чүәкләрне киде дә залга узды.

— Мин сине күчеп киткәнсеңдер инде дип уйлаган идем.

— Белгән булсаң, кермәс идеңме?

Сәйяр дәшмәде. Телевизор өстендә торган сувенирны алып караган булды.

— Син ничек соң әле болай кыю гына килеп кердең? — диде Мәдинә.

— Нигә? — дип сорады Сәйяр аптырап.

— Ике ел буе син бит минем турыда бер ни белмәдең, дөресрәге, кызыксынмадың да. Ул дәвер эчендә ни булмас, кияүгә чыгу, бала-чага...

Сәйяр агарып китте. Чынлап та шулай булу мөмкинлегенә ышанырга теләгәндәй, Мәдинәнең сынаулы карашын да тоймыйча басып тора бирде. Мәдинәнең көлеп куюы гына аны аптыраулы торыштан айнытып җибәрде.

— Гафу ит, мин башкача булуын күз алдына да китермәдем, — дип, Сәйяр Мәдинәнең иңнәренә кулын куйды. Мәдинә карышмыйча якын ук килде.

— Сине көттем мин...

Айлар, еллар шушы гади генә өч сүзгә сыйган иде. Ләкин аңа Сәйярның ышанасы килмәде. Мәдинә аның күзләрендәге салкынлыкны күрмәскә тырышып үзенә шөгыль тапты, чәй әзерләргә дип кухня ягына кереп китте.

Сәйяр пианино капкачын ачты. Озын бармакларын клавишлар буйлап йөгертеп узды. «Моцартны көтеп арган пианино», — дип үз алдына сөйләнеп куйды.

Кухня ягыннан савыт-саба шылтыравы ишетелә, саркып кына килгән тәмле азык исе борынны рәхәт кытыклый. Һәрчак күңел өстендә: менә хәзер кем дә булса чакырып алыр, менә хәзер нинди дә булса команда булыр дигән солдат хезмәтенә хас киеренкелектән соң, хатын-кыз кулы сизелеп торган өй җылысы һәм шунда тынычлап ял итә алу ирекe Сәйярны әллә нишләтеп җибәрде. Читтә үткән ике ел дәверендә ни кадәр арыганлыгына ул яңа гына төшенде. Казарма бер төрлелегеннән читтә менә шушындый тормыш барлыгы Сәйярга бер төш кебек кенә тоела иде. Дөресрәге, ул үзенең үткәненә ышанмый да башлаган иде. Кайту насыйп булса, тормышның кадерен белер, бөтенләй башкача яшн башлар сыман иде. Ә кайтып төшүгә, рухи арыткан кырыс казарма тормышы булмаган да кебек еракка чигенде дә куйды. Ләкин барыбер ул күңелен утырып җитмәгән шатлык белән хәлдә мондагы тормышка күнегеп китә алмый иде әле. Янәшәндә кадерле кешең булу ни бәхет югыйсә. Мәшәкатьле дөньядан аерган шушы бүлмәдә Сәйярның соңгы кадерлесе калды түгелме соң? Нигә ул аңа һаман да бер генә дә җылы сүз әйтә алмый, аны иркәләми, һәм үзе дә иркәләнә алмый соң әле?..

Сәйяр Мәдинәгә булышырга дип кухняга юнәлде. Бераздан өстәлгә төрле ашамлыклар салынган тәлинкәләр куелды. Иң соңыннан шампан һәм фужерлар урта бер җирдән урын биләде.

Өстәл янына кара-каршы утырдылар. Салкын тир бәреп чыккан авыр шешәне алып Сәйяр тимер чыбыгын сүтә башлады. Шул чакта хрусталь фужерларга күзе төшеп кашын җыерып куйды. Теге чакта, туган көндә, кулыннан төшеп ватылган фужерның ишләре иде бу. Бүлмәдә өченче кеше барлыгын бөтен күзәнәге белән сизгәндәй аны чиркану белән алды.

Мәдинә бөкегә төбәлеп, ике кулы белән колакларын каплап, башын җилкәсенә яшерә төште. Бөке шартлап атылды. Ромашка чәчәкләре сыман салынып торган люстраның бер таҗын челтерәтеп ватып төшерде. Сәйяр белән Мәдинә бер-берсенә аптыраулы карашып тордылар да, сүз берләшкәндәй икесе берьюлы көлешә башладылар. Шушы кечкенә генә көтелмәгәнлек Сәйяр күңелендәге газаплы киеренкелекне өзеп,

жинелэйтеп жибэрде. Яшелчә салаты өстенә төшкән пыяла кисәген ул чеметеп кенә алды да, Мәдинәгә сузды:

— Бу безнең очрашу көненең ядкаре булсын, яшереп куй.

Пышылдап торган алтынсу шәрабны ләззәт белән тәнгә сеңдереп шактый сүзсез утырдылар.

Мәдинә магнитофонны көйләде, элеккечә купшы жестлар ясамыйча гына Сәйярны танцыга чакырды.

— Синдә шәм була торган иде, яндырып җибәрик.

— Юк инде алар, — диде Мәдинә. — Шәмнәр янып бетте, дуслар да таралды.

— Ничек яшисең син бер ялгызың, — дигән булды Сәйяр. Мәдинә аңа үпкәләүле караш ташлады.

— Дуслар белән дә ялгыз булырга мөмкин бит...

— Үзгәргәнсең син.

— Картаям, ахры. Ә син көлмә.

— Болай моңсу итеп сине һич тә күз алдына китерә алмый идем. Тамашачы җитми сиңа, дуслар.

— Мин кечкенәдән үк күнеккәнмен, безнең гаиләдә шау-шулы мәҗлесләр, кызыклы сөйләшүләр уза торган иде... Ә син беләсеңме, Уразаевның әсәрләрен Мәскәүгә күргәзмәгә алдылар бит. Аның уңышында бәлки минем дә кечкенә генә өлешем бардыр. Ирләрне төшенкелеккә бирелүдән хатын-кыз коткармый микән?

— Сабитовны да син «шагыйрь» иттеңме?

— Ул шигырьләрен бер кайда да бастырып чыгармады, шуңа көче җитте. Молодец. Әхмәт кенә кызганыч... Ул дәвалану йортында.

— Беләм.

— Дуслар дисең... Монда башкачарак карыйлар икән шул. Шикләнәләр, җилбәзәк, имеш, тагын әллә ниләр. Минә шуларны ишеткәч, әллә ничек үз-үземә бикләндем дә калдым. Дөньяны мин генә үзгәртә алмыйм икән шул. Туган шәһәремә кайткач дусларым танымас та инде. Хәер, алар да үзгәргәндер...

— Без барыбыз да әкренләп үзгәрә барабыз.

— Сине дә танырлык түгел.

— Ничек?

— Буйга үсеп киткәнсең. Усалланган сың.

— Юаш чагымны бер дә сагынмыйм.

— Синең шундый буласыңны белгән идем мин.

— «Синдә тәвәккәл егет йокымсырап ята, аны кем уятыр?!»

Мәдинә кайчандыр үзе әйткән сүзләрне искә төшерүдән көлеп җибәрде.

— Кара, син хәтерле дә икән.

Мәдинәгә рәхәт иде бу минутта. Ул йомшак кына итеп Сәйярның битеннән сыйпап алды.

— Бу яра сиңа килешеп тора.

— Бу турыда син бер әйткән идең инде.

— Чынлапмы?

— Урманда... ә, мин дә бер шигырь яздым бит әле, теләсәң укып күрсәтәм.

Сәйярның «мин дә» дигән сүзгә нигә басым ясавын аңлап, Мәдинә елмаеп куйды. Сәйяр магнитофонны борып сүндерде. Пианино янына килеп клавишларга басып-басып алды.

Яхшылыкмы, яманлыкмы
синең кабатлануың —
минем шәхси дөньям өчен
синең үлә баруың...

Мәдинәнең чынлап торып тыңларга ниятләнүен күреп, ул:
— Шул гына, — диде.
— Кызык, — диде Мәдинә. — Әллә син рәсем ясавыңны ташладыңмы?
— Киресенчә. Рәсем ясый белмәгән кеше шигырь яза белә димени.
Мәдинә пианино янына утырды. Нәфис бармаклары ак һәм кара клавишларны сыйпап-сыйпап ала, көйне бар итеп йөзеп кенә йөри. Ә тавышы, нәкъ менә якыннан, интим халәттә тыңлау өчен генә яратылган диярсең. Көйнең бөтен эзлеклелеген белеп, вакыт-вакыт тавышын әкренәйтеп түбән төшереп җибәрә дә, салмак бөгелешләр белән киредән җыеп ала. Мәдинә, үз моңы агышына иркәләнеп яткан шикелле, әле уңга, әле сулга янтая төшеп җырлый. Читтән тыңлагандай, күзләрен йомып, үз-үзенә бераз соклана да кебек. Көй бетүгә, сабый шикелле мөлдерәп Сәйярга карый.
Тышта караңгы. Сирәк йолдызлы июнь төне. Оеган караңгылыкны тергезеп күк капусы ачылгандай, урыны-урыны белән сәер яктылык сирпелеп үтә. Көндезге эсселектән арган өйләрдән җиргә салкынча күләгәләр шуып төшкән. Түбәдәге антенналарга тырналып сүрән ай күтәрелеп килә.
Сәйяр тәрәзә яныннан кузгалып, йокы бүлмәсенең ишегенә килүгә, Мәдинә ашыгып аның кулыннан тотты:
— Гафу ит, башта үзем карап чыгыйм әле, тәртиптә микән, — эчкә кереп китте һәм тиз генә әйләнеп тә чыкты.
Сәйярнең нигә дип ул бүлмәгә керәсе килде соң әле? Ә, стенага кайчандыр рәсем ясаган иде бит ул. Исән микән? Әгәр сакланмаган булса, ни хаҗәтемә «сагындым» кебек җылы сүзләр.
— Кунар урының да юктыр әле синең. Теләсәң монда кал, бүлмә икәү бит...
— Телефоннан шалтыратырга мөмкинме? — Сәйяр көтмәгәндә шундый тапкыр уй килүенә сөенеп куйды. Бердән — кемгәдер шалтыраткан буласың, икенчедән — әлеге рәсемне карарга җай чыга.
Пөхтә җыелган йокы бүлмәсенә керә-керешкә үк, Сәйяр каршы як стенадагы рәсемне күреп алды.
Саклаган...
Күңеленнән рәхәт дулкын йөгереп узды.
Рәсем кырыена алсу төс сызылып киткән, димәк, стенаны яңадан буяганнар, элекке төсе нинди икәнен Сәйяр хәтерләми. Телефоннан ул башына килгән очраклы номерларны җыйган булды, ә үзе рәсемнән күзен алмады. Искереп, уңа башлаган гуашьны сыпырып карады. Кипарислы диңгез яры, яр кашагасында торган кыз ераклаша барган пароходка яулык болгый. Ни кадәр беркатлы, зәвыксыз ясалган сурәт, ә барыбер, үсмер чакның шаһиты буларак кадерле... Ул чакта модада булган мондый рәсемнәрне сәгать циферблатына ясыйлар иде. Сәйяр ул рәсемгә нинди дә булса мәгънә салуны уйлап та карамагандыр. Яулык болгаучы кыз, үтеп баручы пароход. Кызның анда бер танышы да юктыр. Яр буена ул ялгызлыктан бушау өчен генә килгәндер...
— Дуслар җавап бирми, — диде Сәйяр залга чыккач. Калган шәрабны эчеп куйды.

Сәйяр олы бүлмәдә бер ялгызы. Ай нуры идәннән мыштым гына аның ятагына таба шуыша. Төнге тынлыкка хуҗа булган сәгать тавышы тантаналы текелди. Гел бер көйгә. Сәйяр икенче ягына әйләнеп ята, сәгать текелдәве көчәя, кызулый. Сәйяр сулышын тыеп тын гына ята, сәгать тавышы янадан бер көйгә тибә башлый. Әйтерсең лә вакытны кешеләргә ишеттерерлек итеп кемдер битараф кына керт-керт тураклап утыра.

Бу төн бүтән кабатланмаячак. Мин — синеке, син — минеке дияр ышанычка шушы төн шаһит булмаса, арада тагын икеләнүләр, озакка сузылган аңлашулар урын алачак.

Сәйяр йоклый алмый. Ак җәймәдән кар исе, кар салкынлыгы килә. Ул күрше бүлмәгә колак сала. Аңа калса, Мәдинә дә күрше бүлмәдә йоклый алмыйча ятадыр шикелле. Әнә, тирән сулап куйгандай булды.

Арага тагын сәгать текелдәве килеп керде.

Сәйяр әкрен генә торды да, аяк очлары белән генә басып ишеккә килде, сак кына әчкә сузылды. Ике араны бүлгән ай яктысы аша үтешли Сәйяр шәүләсе караеп стенага сугылып алды. Ул тахта кырыена килеп җитүгә, Мәдинә күзләрен ачты һәм үрелеп Сәйярны кочагына алды.

— Мин сине көттем, Сәйяр, кайтасыңны белеп көттем. Тик безгә сөйләшергә кирәк. Син бит әле...

— Кирәкми, Мәдинә, соңыннан... Мин сиңа ышанам...

Сәйяр аңында һәммә нәрсә кичерәеп калды. Дөнья, бөтен чынбарлыгы белән әллә кая, вакыт аръягына чигенде.

Ул Мәдинәнең тулган ай шикелле яктырып торган күкрәкләреннән, чәчләреннән тыелгысыз дәрт белән үбә башлады, һәм үзе дә шул кыргый хис дулкынында онытылды...

... Каян соң әле бу кипарислы яр? Рәсем түгелме соң? Сәйяр аны үрелеп сөртеп алырга тели, ләкин ярда басып торган Мәдинәне күреп туктап кала. Мәдинәнең тавышы шул кадәр якын да һәм ерак та кебек.

— Син мәхәббәттә бер ни дә аңламыйсың бит әле.

Сәйяр бу ягымлы тавышның сүнә баруын тыңлый.

«Бер ни дә аңламыйсың бит әле.»

«Аңламыйсың бит әле.»

«Әле, әле-е, әле-е.»

— Аңлагач мәхәббәт буламени ул?

— Син тагын, мин синсез яши алмыйм да диярсең.

— Мин синсез яши алмыйм.

— Һа-һа-һа, — Мәдинә көлә, аңа кушылып диңгез көлә. — Кабатлама син, күпләр шулай дигән, ә яшиләр. Хәзер аларны ышандырып кара — таначаклар. Әйтмәдем диячәкләр.

— Мин аларча түгел, ә үземчә уйлыйм.

— Һәммә кеше мин беренче тапкыр шулай яратам дип уйлый.

— Ә син?

— Мин синсез яши алам.

— Димәк, яратмыйсың?..

— Яратам дисәм, синең өчен кызыксыз калыр идем.

«Калыр идем... Идем... Идем...».

Мәдинәнең тавышы ераклаша, ераклаша бара. Сәйяр ул тавышның яңадан кабатлануын теләми, ул талгын бер рәхәтлеккә чума.

Сәйяр уянып киткәндә инде кояш чыккан иде. Ачык тәрәзәдән кергән талгын җил пәрдәләрне сизелер-сизелмәс кенә дулкынлата. Сәйяр урыныннан кузгалуга, Мәдинә йомшак кына ыңгырашып куйды, иркәләнеп мендәргә сыенды. Сәйяр шушы таңда беренче кат күргәндәй аңа гаҗәпләнеп карап торды. Мәдинә ул уйлаганча ук чибәр түгел икән бит. Бу нәтиҗәдән Сәйяр үз алдына елмаеп куйды. Чынлап та, алай ук чибәр түгел икән шул... Сәйяр уңайсызланып күзләрен читкә алды, әйтерсең лә йоклаган кешенең тәне генә йоклый, ә җаны, рухы сиздермичә генә сине читтән күзәтә кебек.

Сәйяр торып киенә башлады. Күңелендә әллә нинди шом, сәер дулкынлану иде аның. Бүлмә — ят, стеналар — ят иде. Кичәге халәтне, серлелекне иртәнге җил үзе белән йолып алган кебек. Сәйяр Мәдинәне уятмаска тырышып аяк очлары белән генә баса-баса бүлмәдән чыкты.

Калтырый-калтырый тышкы ишек йозагын ачты һәм җиңел сулап урамга атылды.

Ул ашлык арасыннан салынган тар сукмактан авылга якынлашып килә. Әнә киртә казыклары. Авыл читендәге тугайдан салмак кына ак томан күтәрелә. Юеш үләнне утлап йөргән атларның нелгән башлары һәм аяклары гына күренә, гәүдәләре исә томан эчендә. Томан күзгә күренеп ераклаша, урман ягына таба шуыша бара.

Сәйяр күңелендә тармакланган уйларның очына чыга алмыйча бара. Нигә болай качкын кебек чыгып китте соң әле ул? Вакыты да калмаган югыйсә. Иртәгә имтиханнар бирергә китеп барачак. Училищега керү насыйп икән, бу якларга инде сагынганда бер генә кайтылыр. Нигә дип Мәдинә белән хушлашмыйча да китеп барды соң әле ул?.. Еракта чакта сагыну, күрешәсе килү, ә күрешкәч аерылышасы килү — мәхәббәтнең шундые насыйп булды микәнни Сәйяргә?...

Ул бакча башларыннан үтеп, олы урамга төшәсе тыкрыкка борылган гына иде, арттан машина кычкырткан тавыш ишетелде.

Мәдинә «Москвич»ының тормозларын сызгыртып, Сәйярнең аяк очына китереп туктатты. Ишеген төбенә кадәр ачып ташлады, терсәкләре белән рульгә таянып Сәйяргә төбәлде. Аның салкын-сынаулы карашына каршы тора алмыйча, Сәйяр күзләрен түбән төшерде.

— Мин синең ни өчен саубуллашмыйча да китеп баруыңны аңлыйм, Сәйяр. Сизеп тордым мин. Башта ышанасым килмәде, ышангач — мена үзем килдем. Синең каршыда бөтен гаебем — сине яратуда. Аңа хакым бар дип уйлый идем мин. Кайчандыр кияүдә булуым өчен мин гаеплемени. Үткән — үткән инде. Ул хакта мин сиңа аңлата да алмадым. Ничектер туры килмәде. Бу машина да, квартира да — аныкы. Үзе чит илгә эшкә киткәндә, аларны миңа калдырып торды. Тиздән ул кайтырга тиеш. Хатларында яңадан бергә кушылуыны үтенеп яза. Шуна күрә...

Мәдинә күз кабакларын бармаклары белән кысып бер мәл тын торды. Сәйяр аның чәчләренең юньләп тарамаганын искәреп алды, ашыккан, күрәсең. Һәрвакытта да пөхтә, хәтта артык җыйнак итеп күрергә күнеккән Сәйяр өчен аның нәкъ менә шушы үз-үзен оныткан кыяфәте гади булып, якын булып тоелды.

— Син гафу ит мине, Сәйяр, вакытыңны алам. Боларны шуңа сөйлим: ул кайту белән мин моннан бөтенләйгә китәчәкмен. Синең — имтиханнар, без бүтән күрешмәячәкбез дип уйлыйм. Сиңа да, миңа да шулай әйбәтрәк булыр... Ләкин син шуны бел: мин үз намусыма беркайчан да хыянәт итмәдем. Син әйткән «дуслар» аны аңлады. Һәм син дә минем турыда ялгыш уйда калма... Мин сиңа үпкәләмим. Һәм бер нәрсәгә дә үкенмим. Хуш, Сәйяр, егет бул!

— Мәдинә...

Ишек шапылдап ябылды, машина калтырап кабынды. Юеш үләнне шыгырдатып тәгәрмәчләр текә генә борылдылар.

Сәйяр талпынып куйды. Гүя күңелендә нечкә генә кыл өзелде дә, Мәдинәнең сүзләре буталды, һәм шул мәгънәне ачыкларга теләп, ул чарасыз басып калды. Бер кайнап чыккан тузан алдыннан томырылып барган машинага, бер ярдәм эзләгәндәй авыл ягына карады. Машина зират ягыннан борылып, асфальт ягына юл алды һәм куаклар эченә кереп бөтенләй күмелде. Сәйяр авылга карады. Беренче тапкыр күргәндәй күзләре өйдән-өйгә, капкадан-капкага шуып үтте. Әнә абыйсы кичкенә капкадан мотоциклын урамга чыгарып маташа. Эшкә барырга җыенадыр. Сәйяр капылт кына бер уйга килеп авылга таба йөгерде.

Сәйяр килеп җиткәндә, абыйсы рульгә ашамлыклар салынган сумкасын беркетеп маташа иде. Иртә таңнан каяндыр йөгереп кайтып төшкән Сәйярнең еш-еш сулу алуын, шашкан күзләрен, сүзен әйтә ал-

мыйча торуын күреп тә ул гаҗәпләнмәде. Ирен читендә канәгать елмаю гына кыегаеп куйды. Сәйяр аның беләгенә ябышты.

— Абый... мотоциклыңны биреп тор әле, хәзер кайтарам, зинһар дим. — Сәйяр күңеленнән шундый җүләр уй йөгереп узды. Абыйсын нигә яратмаганын белми бит ул, әгәр менә хәзер биреп тормаса, мәңгегә ачуланырга бер сәбәп булачак иде.

Ләкин абыйсы каршы килмәде. Нигә икәнен дә белешмәде. Сәйярның шундый инәлеп соравына күңеле булдымы, утыргыч кырыена чүпрәккә төреп бәйләгән чалгысын суырып алды да:

— Бар,— диде.— Беренче тизлек эшләми, икенче белән кузгат!

Сәйяр кузгалып киткәндә арттан кычкырып калды.

— Ипле генә йөр, малай!

Авыл өйләре сызылып кына артта калды. Як-якта кырлар йөзә. Өстә болытлар йөзә. Барысы да каршыга, каршыга, каршыга. Су буеннан барсаң асфальтка туры. Мәдинәнең каршысына чыгып өлгерергә була. Өлгерәчәк. Юл тигез. Зур тизлек белән барган тәгәрмәчләр урыны-урыны очрап куйган вак сикәлтәләрне санга санамый, очып кына үтә.

Кырыйда иске тегермән шәйләнеп калды. Торна сазы. Әнә, санаторий корпусы.

Кайчандыр Мәдинә турында әбисе: «Әйбәт кешедер, күзләре бик чиста күренә», — дигән иде. Әбисенең шул сүзләреннән соң икеләтә якын тоелган иде ул Сәйярга.

Бу юлдан күрше авылга, сигезенче класска укырга йөргәннәр иде. Хәзер Җайлы яр чокыры булачак. Юл бу чокырны көянтә шикелле бөгелеп үтә. Сәйяр газны киметте дә, гәүдәсе белән янтая төшеп, мотоциклга борылырга җай бирде. Җайлы яр чокыры шул ук, электәгечә!

Мәктәптән кайтышлый, шушы ярда этешә-төртешә уйнап алалар иде. Шул елны күрше партада утыручы кызга Сәйярның күзе төшкән иде. Җае чыккан саен аны үчекләргә, ачуландырырга, игътибарын алырга тырыша иде ул. Капрон оек кигән озын аякларын вазага охшата иде. Һәм бер көнне... парта астына күзе төшсә, ни күрсен: әлеге кыз аягын салып туфлие өстенә куйган, баш бармагы өеннән башын тыккан йомран кебек ертык оек эченнән сураеп чыгып тора иде. Шуннан бирле Сәйяр аны күралмады. Шуннан бирле Сәйярда хатын-кызга карата ошату-ошатмау кечкенә генә нәрсәләрдән тора микәнни дигән курку калды. Үсмер чакка хас керләнмәгән күңелнең артык нечкәлеге түгел иде микән ул? Ә хәзер? Бу вакыйганың нигә дип әле хәтергә төшүен аныклаганчы, Сәйяр күңелендә нидер чишелеп китте. «Таптым, таптым!» — дип уйлады ул, хәтта мотоцикл тавышын күмеп кычкырып җибәрә язды. Бүген Мәдинә яныннан чыгып китүнең сәбәбе әлеге курку, нәфислекне җуюдан куркуда булган бит. Гомер буе бергә яшәгән шикелле, иртән бергә уянып, гади генә сөйләшеп, чәй эчеп утырсаң, ул төннең илаһилыгы югалыр иде бит. Сәйяр бераздан аны сагынып килер өчен, вакытлыча гына китеп барган булган.

Сәйяр үз алдына елмаеп бара.

Үрдән асфальт йөзе ялтырап күренеп китте. Ни бары ярты чакрым ара калды дигәндә, бер көйгә җырлап барган мотоцикл моторы кинәт үзгәреп китте, саңгырау гөрелтегә әйләнеп бөтенләй сүнеп калды. Җәяүле тизлегенә күчеп әкренәя башлагач, Сәйяр түзмәде, тормозга басып кырт туктатты да, сикереп төште. Белгән кадәресе җирләренә тотынгалап, өстән-өстән генә тикшереп чыккан булды. Хәтсез азаплангач кына ул, мотоцикл багында тамчы да бензин калмаганын белде. Сәйяр, ачу белән, җансыз калган машинаны үләнлеккә аударды да, чыклы арыш арасыннан олы юлга таба йөгерде.

## Рәфикъ Юнысов

### Элемтәчеләр

Ташта язу: «Монда элемтәче
Рядовой Н. Н. күмелгән».
Әллә нишләп киттем. Чыбык аша
Тоташтым күк бүтән гомергә...

Кан тамыры кебек зәңгәр шнур.
Ике очы — ике яр сыман.
Ә арада, кайнап, актарылып,
Дулкын түгел, үлем ярсыган!..

«Тюльпан» дәшә! «Тюльпан» боерык бирә!
«Роза» тыңлый! — чыбык ялганган!
Рядовой Н. Н. ничек үткән —
Сорашырга вакыт калмаган!

Гаҗәпмени! Шартлау булып килгән
Һәр яңа көн яшәү йөзенә.
Тормыш үзе кинәт туктап калган,
Тормыш үзе шартлап өзелгән!..

Тормыш дәвам итте! Бу — әтиләр...
Яңгырагач кырыс команда,
Алга чыккан алар һәм заманны
Ялгаганнар алар заманга!

Кайткан алар берни булмагандай.
Сөйли безгә солдат хакында:
Берничә юл — биографиядә,
Берничә сүз — кабер ташында.

### «КамАЗ»лар эштә

Кайчан гына яңгыраган иде
«Даешь «КамАЗ»!» дигән авазлар.
Күрегезче, инде тыз-быз килеп
КамАЗ төзеп йөри «КамАЗ»лар!

Адашмыйлар, бутамыйлар юлны!
Монда һәрбер «КамАЗ» колыны
Һәр урамны алдан белә — тургай
Белеп туган кебек болынын.

Һәркайсында, Чаллы кешеләре,
Сезнең холык ята ярылып.
Күпме салсаң шуны тарта алар,
Яши алар йөкне сагынып.

Көязлек тә бар бит үзләрендә!
Чаба алар... бераз кыланып.
Сизәләр бит, каһәр, һәр карашның
Арттан сөеп, назлап калганын...

Конвейердан төшә яңалары.
Иркә алар, шаян, сөйкемле!
Каударланып җирне күзли алар,
Утардагы тайлар шикелле.

Дәшеп уза әнә туганнары.
Килер алар, килми калмаслар!..
Хуҗалар күк, бөтен җиргә үтеп,
КамАЗ төзеп йөри «КамАЗ»лар!

## Юлда

Ком бөртеген аерырга куркам комнан —
Кемнәрнедер мәңге ятим итәрмен күк.
Ыргытам дип алган ташны кире куям —
Эчендә ул мең-мең галәм йөртәдер күк.

«Ишет!» диеп ялварадыр мең-мең аваз,
Кемдер хөкем, кемдер ярдәм көтәдер күк.
Минем өчен мизгел булган талгын җилдә
Кемнәрнеңдер дәверләре үтәдер күк.

Олы уйлар, искитмәле уйлар уйлап,
Мин сак кына атлап барам дөнья буйлап.
Бар күзләрен ачып тормыш карап кала.

Ак болытлар ага ике күзгә тулып.
Тереклекне сыендырган урман булып,
Аста куе яшел үләннәр чайкала.

## Җибәрәмен шәҗәрә

Уртак булыр әҗере —
Күчсен кулдан-кулларга.
Гомер дигән юлларда
Югалтмагыз, оланнар —
Җибәрәмен шәҗәрә!

Мине һәр көн һаҗәрем
«Көн туды!» дип уята...
Болар нинди еракта
Сезнең өчен, балалар!
Баксын сезнең кояшны —
Җибәрәмен шәҗәрә!

Бәхет дигән шаһзадә
Качып йөри күптәннән.
Көннәр караңгы төннән.
Якты көнгә җиткәннәр
Искә алсын безләрне —
Җибәрәмен шәҗәрә!

Һәр көнебез маҗара
Дөнья дигән урманда
Тормыш-оя корганда.
Югалмасын мизгелләр —
Җибәрәмен шәҗәрә!

Үткер вакыт хәнҗәре!
Мин санаган кешеләр
Бар да тере иделәр!
Югалмасын исемнәр,
Оныкм белсен бабасын —
Җибәрәмен шәҗәрә!

Яшибез бит бер Җирдә:
Уртак — тузанга кадәр!
Кулымны сузсам әгәр,
Орынырмын күк сезләргә!
Сузылган кулым булсын —
Җибәрәмен шәҗәрә!

## Сагыш

Кояштандыр шатлык: анда
Якты, җылы — бергә!
Кайгым — Җирдән. Гади, гүя
Туфрак белән тергән.

Ә син бүтән. Таныш түгел
Синең чалымнарың.
Бии, бии соры ялкын,
Ишеп күңел ярын!..

Айга өргән эт шикелле,
Нәрсә даулап һаман,
Син үртәлеп тибәләсең
Ят тарафка табан?

Кай истәлек борчый сине,
Нинди ерак тавыш?
Галәмнең кай бушлыгыннан
Килдең миңа, сагыш?

## Бәйрәм көнне

Зәңгәр шар тоткан. Ә шары
Кабарып та җитмәгән.
Астан тотып бара. Гүя
Кемнедер җитәкләгән...

Бәйрәм төсе чыксын диеп
Пешеренгән булгандыр.
Һиндидер өметсез өмет
Аны тышка кугандыр...

Җыр-биюле төркемнәрнең
Эченә китә керәп.
Ә бәйрәм гел читтә кала,
Кача үчекләп, көлеп...

Буш куңелдә нык яңгырый —
Барабаннар ник кактым?
... Олы бәйрәм уртасында
Шар тоткан ялгыз хатын.

## Һава юлы

Аэропорт — һава порты, сагыш йорты!
Зур юл юрый маякларның кызыл уты!
Шундый сәер бу аерылу. Соңгы сүзләр...
Саубуллашып өлгерәләр бары күзләр!..
Кайсы куллар хәерле юл тели кемгә?
Томан кебек зәңгәр яулык — бәлкем синдер?
Соңгы сәлам юллыйм сиңа, ике кулым
Болгыйм сиңа — күрмисеңдер, күрмисеңдер!..
Иң туры юл — һава юлы!
Көмеш кораб оча инде әллә кайда!
Араларны ул шундый тиз ерагайта!
Йөрәккә моң булып ята мотор җыры.
Иң туры юл — һава юлы!

Сагынулы көннәр үтте, айлар үтте,
Мин яңадан, мин яңадан юлда бүген!
Болытлар да таныш кебек. Тиздән безне
Кабул итәр, кабул итәр Казан күге!
Аэропорт — шатлык порты, кавышу йорты!
Котлар безне маякларның кызыл уты!
Беләм, күптән күктә инде синең күзләр.
Күпме яңа шатлык, күпме яңа сүзләр!
Иң туры юл — һава юлы!
Канатлы дус мине өйгә алып кайта!
Араларны ул шундый тиз якынайта!
Йөрәккә май булып ята мотор җыры!
Иң туры юл — һава юлы!

Мәгъсүм Гәрәев

# АКАДЕМИК

## 1


Самолет Новосибирскига оча. Яңа ел алдыннан без анда танылган галим, илдә иң яшь академикларның берсе Роальд Зиннурович Сәгъдиев белән очрашырга тиеш.

Биек Урал таулары, Көнбатыш Себер шәһәрләре һәм авыллары, иксез-чиксез урманнар һәм кырлар өстеннән нибары дүрт сәгатьлек ара үтәргә кирәк.

1890 елның язында Сахалинга юл тоткан А. П. Чехов исә Төмәнгә хәтле пароходта һәм поездда бара. Аннары Себер тракты буйлап китә һәм аны Җир шарындагы иң озын һәм иң тәртипсез юл дип атый. Язучы сәяхәте өч айга якын дәвам итә. Тагын җиде елдан соң В. И. Ленин яңа тимер юл буенча Мәскәүдән Красноярскига унынчы тәүлектә генә барып җитә. Бу җирләрдә үзе күргәннәр турында Владимир Ильич әнисенә Көнбатыш Себер тимер юлының тирә-ягы гаҗәеп бер төрле: буш һәм тын икәнлеге, шәһәрләрнең бөтенләй булмавы, авылларның анда-санда гына очраштыргалавы турында хат язып җибәрә.

Себер киңлекләре СССРның яртысыннан күбрәк, ә Азиянең биштән ике өлеш мәйданы хәтле, ул Америка Кушма Штатларына караганда бер ярым тапкыр зуррак. Аның елгалары буйлап электр энергиясе ташкыны ага. Себернең «кара алтын» океанындагы гаять зур утрау белән тиңләштерелүе бик урынлы.

Ә бит моннан бер гасыр элекке иске Себердә яшәгән буын кешеләре аны салкынлык һәм караңгылык иле, төньяктан көньякка күчә баручы арктик тундра иле, ак аюлар, бүреләр иле дип йөрткәннәр. Соңгарак ул каторгалар һәм сөргеннәр урыны ителәә — бирегәге казаматларга акыллы фикер ияләрен, атаклы рус сәяхәтчеләренең балаларын сөрәләр. Үзләре белән Урал аръягына сука,



тубалга салып ашлык алып килүчеләр тирәсендә Себер үзгәрә, яңара һәм яшәрә, монда революцион идеяләр белән сугарылган эшчеләр сыйныфы барлыкка килә...

Шундый бай, киң һәм үзенчәлекле край турында прогрессив фикер элек тә бөтенләй башкача була. Бөек рус галиме М. В. Ломоносов, Россиянең куәте Себер белән үсәчәк, дип яза. А. И. Герцен бу якты киләчәкне шулай ук үзенчә күзаллый: «Барысын да көч һәм таяк ярдәмендә эшләүче үле рус хөкүмәте Себергә американча тизлек белән алга җибәрүче тормыш этәргече бирә белми. Күрербез, нәрсә булыр!..» А. П. Чехов нәкъ шуңа җавап биргәндәй: «Вакыт җиткәч, бу ярларны тулы, акыллы һәм тулы тормыш яктыртачак»,— дип, Себерне бүгенгечә күреп әйтә.

Капитан-командор Витус Беринг юлдашлары, Себер аша үтеп, Охот диңгезе ярларына чыгу өчен ике елга якын вакыт сарыф итәләр.

Ә хәзер?

Себер бөтенләй якын ул!

Новосибирскидан Академия шәһәрчегенә кадәр утыз километрны автобус таба кебек ялтырап яткан асфальт буйлап уза. Һәр ике якта — урман, урман... Аның очы-кырые юк кебек. Менә юл читындә «Университет урамы» дип күрсәткеч такта күзгә чагылып китте.Без шәһәрчеккә килеп керәбез. Беренче тәэсирләрне үк әйтеп бирү өчен бер генә сүз кирәк: «Яшьлек!» Кая карама, анда яшьләр. Тышкы кыяфәтләре дә үзенчәлекле — спортчыларны хәтерләтә.

1961 елда бирегә беренче тапкыр килүендә, ихтимал, яшь физик Роальд Сәгъдиев тә шулай уйлагандыр.

Академия шәһәрчегенә кергәндә зур панно тора. Анда «СОАН» дип язылган. Бу — СССР Фәннәр академиясе Себер бүлегенең кыскартылган исеме. Эмблемада борынгы грек хәрефе «сигма» ясалган. Фән шәһәре өчен аның мәгънәсе гаять тирән һәм эчтәлекле. Математика формулаларында «сигма» сумманы аңлата. «Сумма Суммарум» — барча суммалар суммасы! Бу — Себердәге фәнни үзәк өчен бигрәк тә характерлы булган фән һәм иҗади талант бердәмлеге кебек яңгырый.

«Сумма»га автобус тукталышларының исемнәре дә килеп кушыла һәм гүя аны бер бөтен итә: «Җылылык физикасы», «Хи-

мия», «Геология», «Хисаплау үзәге», «Гидродинамика», «Атом-төш физикасы».

Обь диңгезе ярыннан күтәрелеп, академиклар коттеджларын узгач, дүртәр, бишәр, тугызар катлы йортлары белән торак массивлар башлана. Урамнарның күбесенә романтик исемнәр бирелгән: «Алтын үзән», «Энҗе», «Диңгез проспекты», «Фән проспекты»...Шәһәрчектә бер урам герой-шагыйрь Муса Җәлил исемен йөртә.

Академия шәһәрчегенә нигез 1957 елда салына. Обь диңгезе буендагы урман эчендә нарат бүрәнәләрдән йорт салып куялар. Озак та үтми, семьясы белән Мәскәүдән килеп, анда СССР Фәннәр академиясенең Себер бүлеге председателе Михаил Алексеевич Лаврентьев урнаша. Себер һәм Ерак Көнчыгыш фәне үзәге — Академия шәһәрчегенең тарихы менә шушы вакыйгадан башлана. Ун ел дигәндә төзүчеләр урман эчендә 4 меңнән артык кеше яши торган яңа шәһәрчек корып өлгертәләр. Гадәти шәһәр генә түгел ул. Фән шәһәре, гыйльми ачышлар, дөньяда моңа кадәр күрелмәгән экспериментлар шәһәре.

Бер француз язучысы Академия шәһәрчегендә булгач, аның фән сарайларын күреп таң кала.

— Шундый гүзәл каланы тагын кайда күрергә була?! — ди ул, йөрәгеннән ташып чыккан тәэсирләрен яшермичә. — Новосибирск янында галимнәр шәһәре дөньядагы менә дигән фәнни үзәкләрнең берсе дип саныйм. Ул — бөтен Себер краеның фәнни мие.

Үзәкне корганда проектчылар, архитекторлар, төзүчеләр һәм монтажчыларга бик күп кыен мәсьәләләрне яңача, фәнни нигездә хәл итәргә туры килә. Җир шарында төрле шәһәрләр бар. Әйтик, Франциядәге Варден кебек крепость-шәһәр, Ленинград һәм Роттердам шикелле порт-шәһәрләр, Пушкин һәм Суздальга охшаш музей-шәһәрләр, Сочи һәм Ялта төсле курорт-шәһәрләр. Ләкин фән шәһәре юк. Аның турында бөек пролетар язучысы Алексей Максимович Горький күптәннән хыялланган. Әдип аны гыйльми сарайлары, фәнни сотрудниклар белән тулы зур бер учреждение төсендә күз алдына китергән. Һәм ул ялгышмаган.

Шундый шәһәр Себер җирендә үсеп чыга. Халык аны үзенең «кан» һәм «нерв» системалары коммуникацияләре булган катлаулы техник организм дип атый. Өстәвенә, ул — социаль организм да. Аны 20 дән артык фәнни-тикшеренү институты һәм университет, төзелеш оешмалары һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре, мәктәпләр һәм кече яшьтәге балалар учреждениеләре тәшкил итә. Бу җанлы организм йөзләрчә молекула — семья, меңнәрчә атом — аерым кешеләрне, төрле профессия һәм буын вәкилләрен гармоник урнаштыру турында уйларга мәҗбүр итә. Фәнни лабораторияләрне һәм торак йортларны ничек урнаштырырга? Алар бер-берләренә комачауламасын да, шул ук вакытта эшкә йөрергә дә ерак булмасын. Галимнәр йортларын урам тавышыннан ничек азат итәргә? Балалар укырга барганда, урамнарны аркылы чыкмасыннар өчен мәктәпләрне кайдарак һәм ничек төзергә? Фәнни учреждениеләрнең һәм шәһәрнең архитектурасы җирле табигый үзенчәлекләргә җавап бирсен һәм халыкта эстетик канәгатьләнү тудырсын өчен нәрсәләр эшләргә? Чишәсе мәсьәләләр бик күп була, әмма аларның асылы бер нәрсәгә кайтып кала: Себердәге Фән шәһәре нинди булырга тиеш?

СССР Фәннәр академиясенең Себер бүлеге Президиумы конференц-залында шәһәрнең зур картасы эленгән. Академик Михаил Алексеевич Лаврентьев аның янына килеп кыскача гына аңлатма бирә. Себер бүлеге — Советлар Союзында, Мәскәүдән кала, икенче

фәнни үзәк. Биредәге һәр институтның үз юнәлеше, үз бурычы бар. Ләкин алар уртак бер проблеманы хәл итү өстендә эшлиләр. Михаил Алексеевич образлы чагыштыру белән болай ди: «Ул проблема — өчпочмак формасында. Өчпочмакның почмаклары — производство, фән һәм кадрлар хәзерләү. Шушы почмакларны бер-берләренә мөмкин кадәр якынайту — Себер бүлеге фәнни үзәгенең төп бурычы».



## 2

Һәр чәршәмбе саен Себер бүлеге институтларында эшләүче академиклар, член-корреспондентлар, фәнни-учреждениеләрнең җитәкчеләре, түгәрәк өстәл янына җыелып, информация алышалар. Һәр галим үзе эшли торган өлкәдә ил, дөнья күләмендә нинди яңалыклар булуын, ачышлар ясалуын хәбәр итә. Ә бүгенге утырышта бу традиция бераз бозылды. Академия шәһәрендә Америка Кушма Штатларыннан һәм Франциядән кунак-галимнәр бар иде. Михаил Алексеевич Лаврентьев чит ил галимнәрен алар белән таныштырырга булды.

— Мәскәүдән еракта, Урал артында Советлар Союзындагы иң эре фәнни үзәкләреннән берсенең шулай тиз үсүе бәлки сәеррәк кебектер, — дип сүз башлый академик. — Монда гаҗәпләнерлек бер нәрсә дә юк. Себернең һәм Ерак Көнчыгышның гаять зур мәйданы (ул 13 миллион квадрат километрга якын һәм планета территориясенең 9 процентын алып тора), аның рельефы үзенчәлеге, казылма байлыгының күплеге байтак проблемаларны комплекслы хәл итүдә уңай мөмкинлекләр тудыра. Илебезнең көнчыгыш районнарында җитештерү көчләрен файдалануда яңа перспективалар ача. Себер — ул үзе гаять зур тормыш академиясе һәм безне күп нәрсәгә өйрәтә. Бездә, тиз фикер йөртеп, һәр галим яки белгеч фәннең иң яңа мәгълүматларын һәм дөнья күләмендәге ачышларын оста файдалана, билгеләнгән планны бу бай крайның катлаулы үзенчәлекләрен искә алып тормышка ашыра. Шуңа күрә дә аларның ил тормышында роле бигрәк тә зур...

Минем өчен шунысы аеруча куанычлы иде: һәр күренекле галимнең фамилиясе аталуга «Казан» исемен ишетергә туры килде. Алар фәннең олы юлына безнең республикабыз башкаласында аяк басканнар. Шул ук Михаил Алексеевич Лаврентьев Татарстаннан, Тәтеш ягыннан. Аның әтисе Алексей Лаврентьев Казан университеты профессоры була, студент Михаил Алексеевич аңардан дәресләр ала. Әле сугышка кадәр үк М. А. Лаврентьев су агымы һәм аның үз юлындагы каршылыкларга йогынтысы турында теорияне Казанда эшли башлый. Ул чагында бу эш бик күпләргә перспективасыз булып күренә. Гади су агымы белән янгынны сүндерергә мөмкин, әмма скептиклар шиген сүндереп булмый. Яшь галим үз шәкертләре белән махсус установка ясый. Аның ярдәмендә көчле басым астында су белән юка калайны да тиштерәләр. Скептиклар чигенә чигенүен, ләкин алар су көченең чикле икәнен, басымны 2 мең атмосферадан арттырып булмаячагын ышандырмыйлар. Су куәтенең шулай чикләнгән булуы яшь галимне дә икеләндереп куя. Әмма ул тикшеренү эшләрен туктатмый. Ике мең атмосфера — бик үк кечкенә басым түгел инде. Аның ярдәме белән дә тау токымнарының кайберләрен җимереп була.

Казанда башлаган эшен галим Себердә дәвам итә. Шәкерте Б. В. Войцеховский белән бергә Гидродинамика институтында лаборатория оештыра. Теоретик тикшеренүләр тәҗрибә белән бергә алып барыла. Ниһаять, алар 5 мең атмосфералы импульслы суыт-

кыч төзиләр. Бу нәрсәне аңлата соң? Беренчедән, тау токымнарын эшкәрткәндә су аларны юу ролен генә үтәми, бәлки токымнарны тишүче прибор — перфоратор булып хезмәт итә. Икенчедән, су агымы өчен «ике меңле» чик юк. Академик М. А. Лаврентьевның соңгы казанышы — 70 мең атмосфералы гидроимпульслы установка. Биредә аны су пушкасы дип атыйлар: суны ул секундына 4 километр тизлек белән куа. Су пушкасы теләсә нинди катылыкта булган тау токымын җимерә. Аның белән «атуы да» җиңел, һәм арзан, шундый басым һәм тизлек булдыру өчен кысылган һава гына кирәк. Су пушкасын Кузбасс шахталарында сыныйлар, ул горнякларның хезмәт җитештерүчәнлеген биш мәртәбә күтәрә.

Геология һәм геофизика институтына икенче якташыбыз — Социалистик Хезмәт Герое академик Андрей Алексеевич Трофимук — җитәкчелек итә. Күренекле галимнең фәнни биографиясе шулай ук Казанда языла башлый һәм аның исеме «Икенче Баку» белән тыгыз бәйләнгән. Казан университетын тәмамлагач, А. Трофимукны аспирантурада калдыралар. Биредә ул хатыны Әминә Тәүфиковна белән бөтен тормышын геология фәненә, җир асты байлыкларын өйрәнүгә һәм ачуга багышлый. Андрей Алексеевич бер елдан соң аспирантурада укуын читтән торып дәвам иттерергә була, производство ихтыяҗларын тәэмин итүче лабораториягә эшкә күчә. Ләкин киң колач җәеп эшләү өчен лаборатория аңа ничектер кысан тоела. Производствоның үзенә — Башкортстанның нефть районнарына китә. Яшь галим нефтьчеләр арасында бик тиз танылып өлгерә. А. А. Трофимукны «Башнефть»нең баш геологы итеп билгелиләр. Аннан Мәскәү, ул — Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү нефть институты директоры. Нәкъ менә шушында эшләгәндә Андрей Алексеевич Татарстандагы Ромашкино нефть ятмасын ачуда һәм эшкәртүдә актив катнаша. Академик А. П. Крылов белән бу ятмага тирәли су кудыру методикасын эшли. Шушы зур хезмәте өчен Дәүләт премиясенә лаек була.

Академик А. А. Трофимук Себернең җир асты хәзинәләрен ачуга зур көч куя. Биредә шактый озак бәхәс бара — кайберәүләр Көнбатыш Себердә нефть юк, «кара алтын»ны Беренче һәм Икенче Баку районнарыннан эзләргә кирәк дигән фикердә торалар. Андрей Алексеевич һәм аның хезмәттәшләре үз карашларын исбатлау өчен зур тырышлык куялар. Себер нефтьтә «йөзә» дигән кыю гипотеза, Академия шәһәрендә фәнни үзәк төзелгәч, Төмән нефтен ачу белән раслана.

Ул җитәкли торган Геология һәм геофизика институты Себер бүлегендә киң диапазонлы фәнни учреждениеләрдән санала. Аның геологик юнәлештәге 12 филиалы Иркутскида, Хабаровскида, Владивостокта, Сахалинда, Улан-Удэда, Курил утрауларында, Магаданда, Якутскида урнашкан. Фәнни составы буенча ук ул Союзда иң көчлеләр исәбендә. Биредә, А. А. Трофимуктан кала, академиклар В. С. Соболев, Б. С. Соколов, А. Л. Яншин, Ю. Кузнецов, СССР фәннәр академиясенең 7 член-корреспонденты, 21 фән докторы, 173 фән кандидаты эшли. Күренекле галимнәр җитәкчелегендә институт геологлары Себердә һәм Ерак Көнчыгышта сирәк металларның күп кенә ятмаларын ачалар.

А. А. Трофимукның урынбасары Элимир Галимҗанович Дистанов та — Казан кешесе. Университет тәмамлагач ук, фәнни эшен дәвам иттерү өчен Академия шәһәрен сайлый. Себер — аның башта кандидатлык, аннары докторлык диссертациясе яклаган җире.

Профессор Александр Михайлович Дымкин, фән кандидатлары Мира Яковлевна Щербакова һәм Ирина Ивановна Зоткова да Себернең фәнни үзәгенә Казан вузларын тәмамлап килеләр.

## 3

Академия шәһәрендә яңа ел алды көннәре.

Урамнарга кояш нуры сибелгән. Агачларга кунган кар аз гына җил искәндә дә кешеләр өстенә коела һәм аларны Кар бабай төсле итә. Беренче килгән кешеләргә климаты да аңлашылмый бу якларның. Өченче көн күз ачкысыз буран булды. Кичә минус 40 градус иде, ә бүген — ноль. Чыннан да, кискен үзгәреш бит. Салкыннары исә чын Себернеке, битләрне чеметеп-чеметеп ала. Яшь галим Роальд Зиннурович та баштарак Себер салкыннарына күнегә алмаган.

Атом-төш физикасы институты директоры академик Андрей Михайлович Будкер бу турыда кызыклы бер вакыйганы сөйләде:

— Институт сотрудникларыннан мин яшь галимебезнең туңуы турында ишеттем һәм аңа материя белән тышланган мех кием табып бирдем. Роальд Зиннурович үзенең туган Казаны җылысына икеләтә шатланды: тун Татарстан мех берләшмәсендә тегелгән икән.

Яшь физикның шундый кырыс табигатьле Себергә Мәскәү хәтле Мәскәүдән күченүенә нәрсә сәбәп булган соң? Экзотикамы? Тынлыкмы? Бәлки романтикадыр? Юк, берсе дә түгел. Ул бирегә салкын Себердәге лаборатория шартларында планетабызны, аның экваторын, полюсларын җылытучы иң зур күк җисеме Кояштан күп тапкыр кайнаррак — йөз миллион градуслы «ясалма кояш» алу мөмкинлеген исбатларга килә.

Әти-әнисе Зиннур абый белән Фәрхия апа 1932 елның салкын декабренда туган малайларына Роальд исемен Котыпны ачучы Амундсен хөрмәтенә кушалар. Дөрес, Роальд Сәгъдиев котыпчы булмады булуын, әмма плазманы өйрәнүдә бөтен дөнья фәне күләмендә танылды, бу эшкә юл салучыларның иң күренеклесе иде.

Бу юлга ул Мәскәү университетының физика факультетында укыганда ук аяк баса. 1953 елда күренекле галим академик Лев Давыдович Ландау аксыл чәчле, урта буйлы, матросларныкыдай киң җилкәле 20 яшьлек Казан егете Роальд Сәгъдиевнең — Мәскәү дәүләт университеты студентының «дәресләкләрдә язылганнан йөз тапкыр күбрәк белүенә» таңга кала. Нәкъ менә студент чагында плазма Роальд өчен тормыш мәгънәсенә әверелә дә инде. Ул фәндә баганалы юллар юклыгын бик яхшы аңлый. Альберт Эйнштейнның яшьләргә киңәшен һәр вакыт исендә тота. «Фәнни тикшеренүләргә омтылучы кеше дөрес юлны үзе таба. Монда киңәш белән ярдәм итү мөмкин түгел, үз үрнәгең, үз инициативаң булырга тиеш... Җиңүгә аз гына ышанычың булганда да, фәнгә тормышыңның һәр сәгатен багышларга, үзеңнең бөтен көчеңне бирергә кирәк», — ди бөек галим. Һәм студент Роальд үзенең юлын, юнәлешен дөрес сайлый. Физиканың барлык бүлекләре буенча, университет программасыннан тыш, югары белемле физик белергә тиеш булганнан артыграк күләмдә Л. Д. Ландауның үзенә 9 имтихан тапшыра.

Соңгы имтиханны тапшыргач, алар Лев Давыдович квартирасында дүрт сәгать сөйләшеп утыралар.

— Кадерлем, мин сезнең фән кешесе булачагыгызга ышанам. Аспирантурага керергә уйласагыз, сезгә махсус предмет буенча кандидатлык минимумы тапшырырга туры килмәячәк. Миңа әйтерсез һәм мин сезгә имтихан тапшырды дигән белешмә бирермен, — ди күренекле галим үз шәкертенә.

Әмма Л. Д. Ландау киңәшләренә дә карамастан, Р. Сәгъдиев аспирантурага керми. Мәскәү университетын тәмамлагач, теоретик

белемен практикада тикшереп карау максаты белән, ул академик И. В. Курчатов җитәкчелегендәге Атом энергиясе институтында гади лаборант булып эшли башлый — шунда Роальд фәнни-тикшеренү эшләренә муеннан чума, физика проблемалары институтына Л. Д. Ландау семинарларына йөри, беренче гыйльми хезмәтләрен бастыра, кандидатлык диссертациясе өстендә эшли. Бер елдан ул институтта кече фәнни сотрудник була. Роальдның ташып торган энергиясе һәм һәр мәсьәләне җитди, уйлап хәл итә белүе академик И. В. Курчатовның да игътибарын җәлеп итә. Галим Роальдны берничә тапкыр үз янына әңгәмәгә чакыра.

— Академик Курчатов яшьләргә бик игътибарлы һәм таләпчән, аларга зур өмет баглый иде, — дип искә төшерә Роальд. — Минем планнарым һәм фәнни эшләрем белән дә кызыксынды. Сөйләгәннәремне аерым блокнотына язып алды. Икенче тапкыр килүемдә, блокнотын ачып, беренче чиратта, шул планнарны ничек эшкә ашыруымны сорады.

Атом энергиясе институтында эшләгәндә үк Р. Сәгъдиев фәнни дөньяда үзен танытып өлгерә. 24 яшендә атом энергиясен тыныч максатларда куллану буенча икенче Женева конференциясендә совет галимнәренең фәнни эшләре турында инглиз телендә доклад белән чыга. Дөньяның плазма өлкәсендә эшләүче күренекле галимнәренә бу вакытта Р. Сәгъдиев исеме инде яхшы таныш була, алар аның гыйльми эшен югары бәялиләр. Бер елдан «титулсыз» галимне Швециягә халыкара конференциягә чакыралар. Ул анда кисәкчәләрне тизләтүче механизмнарга багышланган доклад ясый.

1960 ел Роальд Зиннуровичның фәнни биографиясенә кызыл хәрефләр белән беренче юлларны яза. Халыкара аренада танылып өлгергән яшь физик, аспирантураны читләтеп, СССР Фәннәр академиясенең гыйльми советында «Сирәкләндерелгән плазмада динамика мәсьәләләре» дигән темага физика-математика фәннәре кандидаты дигән дәрәҗәне алу өчен диссертация яклый. Гыйльми совет утырышында Роальдның зирәк таланты, искиткеч сәләте тагын да ачыла төшә. Академик М. А. Леонтович, диссертантның оппоненты буларак, болай ди:

— Мин Р. З. Сәгъдиевнең безнең бүлектәге гаять зур роле турында әйтергә телим. Ул плазмага бәйле эшләрдә теоретик кына түгел, экспериментаторларның эшендә дә стимул тудыручы кеше. Аларга һәр вакыт яңа идеяләр әйтә, тәҗрибә нәтиҗәләрен сотрудниклар белән бергә тикшерә. Ул — безнең лаборатория өчен гаять кыйммәтле теоретик.

Менә академик Л. Д. Ландау фикере:

— Диссертант буларак китергән мәгълүматларын Р. Сәгъдиев чит илләрдәге башка авторларга караганда элегрәк үзләштерә алды. Бу — аның, һичшиксез, зур фәнни казанышы. Аның физиканың бөтен өлкәсендә искиткеч хәбәрдар булуы мине таңга калдыра.

Йомгакны С. И. Вавилов исемендәге физика проблемалары институты директоры академик П. Л. Капица ясый:

— Әгәр диссертант тагын бераз тырышса һәм ике-өч ай эшләсә, мин ышанам, ул докторлык диссертациясе дә яклаган булыр иде. Ләкин диссертант начальство сүзен начар «тыңлый...» Тиздән безгә яңадан җыелырга һәм аңа докторлык дәрәҗәсе бирергә туры киләчәк.

Атаклы өч физикның кыска-кыска гына итеп әйтелгән бу фикерләрендә никадәр тирән мәгънә, 28 яшьлек галимнең олы киләчәгенә нинди зур өмет ята!

Оппонентларына рәхмәтен белдереп:

— Миңа сезнең шундый югары дәрәҗәле гыйльми совет белән тагын бер тапкыр очрашу, әлбәттә, күңелле булыр иде. Ләкин кабат кандидатлык диссертациясе яклау өчен түгел инде,— ди Роальд Зиннурович җавап сүзендә.

Шуннан соң фәнни дөньяда Сәгъдиев турында физика-математика фәннәре кандидаты, совет фәненең яңа кабынып килә торган йолдызы дип сөйли башлыйлар.

Аннары Себер, Академия шәһәре. Роальд Зиннурович, Атом-төш физикасы институтында яңа лаборатория оештырып, фәнни эшкә чума. Яшь галим Новосибирск дәүләт университетында физика факультеты ача, аның деканы буларак, фәнни кадрлар хәзерләү эшенә керешә.

Роальд Зиннурович башкаладан киткәч, идарә итеlә торган атом-төш реакцияләре буенча «баш теоретик»тан көтмәгәндә кемдер сорап куя:

— Михаил Александрович, Сәгъдиевне җибәрергә ничек ризалык бирдегез? Сез үз фронтыгызны көчсезләндерәсез түгелме соң?

— Ни дигән сүз ул «үз фронтыгыз?» Фәнни ачыш Мәскәүдәме, Новосибирскидамы ясала — барыбер түгелмени? Ул — барыбер безнең уңыш. Сәгъдиев иркенлекне ярата. Монда ул башкара торган эшкә берничә теоретик тотына ала, ә Себердә ул теләгәненә колачын җәячәк.

Галим ялгышмый. Роальд Зиннурович Себердәге яңа фәнни үзәктә М. А. Леонтовичның ышанычын тулысынча аклый, совет фәнен яңа ачышлар белән баета.

...1962 елның 11 апреле — СССР Фәннәр академиясенең Себер бүлегендә иң истәлекле көннәрнең берсе. Ул көнне бередә берьюлы ике кеше докторлык диссертациясе яклый. Гыйльми совет утырышы университетның актлар залында бара. Яңа «туган» докторларның берсе — Роальд Сәгъдиев, икенчесе — Валерий Покровский. Роальд Зиннурович «Плазмада коллектив процесслар һәм удар дулкыннар» дигән темага докторлык диссертациясен фәнни җитәкчедән башка яза. Оппонентлар Мәскәүдән Сәгъдиевнең элек эшләгән институтыннан, Харьковтан Покровский укыган вуздан киләләр. Роальд Зиннурович оппонентларының берсе совет атом-төш реакцияләре «атасы» академик Игорь Евгеньевич Тамм була. Диссертация яклау залында Роальдның әтисе Зиннур Закирович та утыра. Һәм ул хәзер менә нинди кызыклы бер детальне сөйләде:

— Тәтеш педтехникумын тәмамлагач, мин Мәскәүдәге 2 нче университетның физика-техника факультетына укырга кердем. Ул чагында анда яшь галим Игорь Евгеньевич Тамм безгә физика буенча лекцияләр укый иде. Мин аның элекке студенты, профессорга имтиханнар тапшырган кеше, ә ул бүген танылган академик улымның оппоненты. Нинди кызыклы очрашу!

Докторлык диссертацияләре яклау зур иҗади бәйрәм төсендә уза. Яклауның уңышлы үтәчәгенә берәү дә шикләнми. Чөнки диссертантларның сәләтле яшь физиклар, олы талантлар һәм зур эрудицияле кешеләр икәнен һәркем яхшы белә. Тагын шунысы характерлы, монда — үзләренең яңа йортларында, яңа семьяда — физиклар тагын бер баскычка югары күтәреләләр. Алар фәнни хезмәтләренә карап бүләкләнәләр, белемнәренә карап гыйльми дәрәҗә алалар. Шулай итеп, фәнни үзәктә «өзлексез» реакция барлыкка килә: һәркем үз шәкертләрен хәзерләргә, Себердә физикларның яңа буыны тууга ярдәм итәргә тиеш.

Роальд Зиннурович бу яктан да башкаларга үрнәк. Ул Урал һәм Себер вузларыннан талантлы яшьләрне эзли, аларны фәнгә гашыйк итә, физика өлкәсендә яңа ачышлар ясарга юнәлтә. Аның белән

бер көнне физика-математика фәннәре докторы булган В. Покровскийның фәнни хезмәтендә дә Р. Сәгъдиевнең катнашы бар.

— Академия шәһәренә Сәгъдиевнең килүе генә мине докторлык диссертациясе өстендә эшләргә этәрде,— ди Покровский.

Әйе, СССР Фәннәр академиясе Себер бүлегенең яшь талантларны үстерү эшчәнлеге белән, аларның фәнни казанышлары белән мактанырга, горурланырга, чыннан да, зур нигезе бар. Мисалга шул ук Р. Сәгъдиевне генә алыйк. Ул Себернең гыйльми үзәгенә фән кандидаты булып килгән иде. Бер ел дигәндә доктор булды, 32 яшендә Роальд Зиннуровичны СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты итеп сайлыйлар, 36 яшендә ул — СССРдагы иң яшь академик.

Р. З. Сәгъдиев Академия шәһәрендә җиде ел эшләү дәверендә үзе дә күп кенә фәнни кадрлар хәзерләүдә катнаша. Бирегә гади фәнни сотрудниклар булып килгән А. Галиев һәм В. Карпман, мәсәлән, башта кандидатлык, аннары докторлык диссертацияләре яклыйлар, профессор буларак. Д. Сәгъдиев теориясе буенча экспериментлар алып баручы Р. Куртмуллаев һәм В. Захаров шулай ук аның җитәкчелегендә физика өлкәсендә докторлык диссертацияләрен уңышлы яклап чыктылар. Академик Р. Сәгъдиев шәкертләреннән 15 кеше физика-математика фәннәре кандидаты булды. Чын галим генә үзенең үлемсезлеген, үз мәктәбенең яшәешен аны туктаусыз үстерүдә, алга этәрүдә күрә белә. Бер урында таптану — галим өчен үлем ул.

## 4

Унтугызынчы йөзне пар гасыры дип атадылар. Хәзер исә атом гасыры, космос гасыры. Водород бомбасы, атом реакторы, синхрафазатрон, лазер, космик корабльләр һәм галәмгә очу — безнең өчен бу төшенчәләр реаль күренеш инде. Ләкин плазманың үз өстенә нинди нагрузка алуын, идарә ителә торган атом-төш реакцияләрнең киләчәген белүчеләр бөтен җир шарында да бармак белән генә санарлык әле. Илленче елларда матдәнең плазма хәлен ачу хәтта фәнни әдәбиятта да бик аз яктыртылды. Плазма җир шарында гына түгел, бәлки космоста мәңге яшәсә дә, ул — реальлек дип ныклап раслау өчен фәнни-тикшеренү дәлилләре җитәрлек түгел иде. Роальд Зиннурович фәннең менә шушы катлаулы өлкәсендә эшли, әледән-әле уңышка ирешә.

Чыннан да, нәрсә соң ул плазма?

Мәктәп дәреслекләрендә дә бу турыда бик саран язылган. Плазма — каты әйбер дә, сыеклык та, газ да түгел ул. Дәреслектә моңа мисал рәвешендә Кояшның плазма шары китерелә. Чөнки плазманы тикшерү һәм аңа бәйле атом-төш реакцияләрен идарә итү проблемаларын популяр телдә аңлатып бирү җиңел эш түгел. Роальд Зиннурович үзе дә моны яхшы белә һәм киң катлау укучыларга аңлаешлы сүзләр эзли.

— Һәр әйберне ун мең градуска кадәр җылытасың икән, ул плазмага әверелә,— ди академик.— Молекулалар һәм атомнар таркала, электроннар һәм ионнар хасил була. Матдәнең менә шушы хәле плазма дип атала. Югары температурадагы бу матдә тиешенчә өйрәнелмәгән. Галәмдәге материянең 90 проценттан артыгы плазма хәлендә.

Физиклар матдә төшенең төзелеше серләрен ачтылар һәм төш эчендәге энергияне практик файдалану юлларын билгеләделәр. Энергия матдәнең бер хәлдән икенче хәлгә күчкән чагында бүленеп чыга. Авыр элементлар — уран, радий, плутоний төшләре үзләрен-

нэн-үзләре таркала ала, алар җиңелрәк элементлар төшләренә бүленәләр. Бер килограмм уранның бүленү реакциясе, мәсәлән, уннарча мең тонна ташкүмер ягудан алынган кадәр энергия бирә ала. Уран энергиясе фән тарафыннан үзләштерелде инде. 50 нче елларда ук безнең су асты атом көймәләребез бернинди заправкасыз, портларга кермичә һәм су өстенә чыкмыйча, 40 мең километр йөзеп үттеләр!

Академик Р. З. Сәгъдиев Академия шәһәрендә кояш температурасы алу өчен лабораторияне чит ил коллегаларыннан бераз соңрак оештыра. Бу вакытта Швейцариядә тизләтелгән кисәкчәләрнең энергиясе 30 миллиард электрон-вольтка җиткән установка берничә ил средствосына эшләнә. Соңрак АКШта шундый ук установка төзелә. Советлар Союзында Швейцария һәм АКШ установкаларының икесенә тиң тизләткеч эшләнелде. Чит ил галимнәре тагын да куәтлерәк — 300 һәм хәтта 1000 миллиард электрон-вольтлы установкаларның проектларын сыздылар. 60 нчы елларда алар проектта гына калды. Себер галимнәре исә бөтенләй яңа юл сайлыйлар. Академия шәһәрендә Роальд Зиннурович безгә тизләтелгән кисәкчәләрнең энергиясе ике триллион электрон-вольтка тигез булган установканы күрсәтте.

— Плазма физикасы матдәнең иң кайнар хәлен өйрәнә, — ди Роальд Зиннурович, лабораториядәге җайланмаларны күрсәтеп. — Аны без температураның шартлы бүлемнәре ярдәмендә ачыклыйбыз: берничә йөз миллион градуста плазма кайнар була, миллион градуска кадәр ул салкын. Йөз мең градус кайнарлыктагы плазма бу өлкәдә эшләүчеләрне хәзер бөтенләй кызыксындырмый.

Монда шундый кайнар матдәне нинди савытта саклыйлар икән дигән бик урынлы сорау туа. Секундның миллионнан бер өлешендә дә ул теләсә нинди металлны эретә. Моның өчен магнит кырларын файдаланалар. Себер галимнәре магнит кыры савытында үтә югары температуралы — миллиард градуска җиткән плазманы 15—25 секунд дәвамында тотып тора алдылар.

Идарә ителә торган атом-төш реакцияләре кешелек дөньясына моңарчы күрелмәгән күләмдә энергия бирерләр иде. «Бу гаять катлаулы фәнни-техник проблеманы хәл итү кешелек дөньясын энергетика кытлыгы куркынычыннан мәңгегә коткарыр иде, — дип язды 1969 елда академик Р. Сәгъдиев «Известия» газетасында. — Диңгезләрдә һәм океаннарда атом-төш ягулыгы — авыр водород запаслары бетмәстөкәнмәс. Авыр водородның бер төше гади матдәләрнекенең меңенә туры килсә дә, галимнәр диңгез һәм океан энергия запасларының миллион елларга җитәрлек икәнен исәпләп чыгардылар».

Диңгез һәм океан суларында, башка бик күп байлыклардан тыш, гаҗәп күп күләмдә энергия дә яшеренгән ләбаса. Җир шары картасына күз салсак, без моңа тагын бер кат ышанабыз. Планетаның 71 проценты, ягъни 361 миллион квадрат километры, су белән капланган. Менә ул кайда энергия чыганагы! Моның өчен идарә ителә торган атом-төш реакцияләрен генә «йөгәнлисе» бар. Себердә үткәрелгән фәнни-тикшеренү эшләренең беренче нәтиҗәләре ул реакцияләрне буйсындырырга күп вакыт калмавы турында сөйли.

5

Роальд Зиннурович белән без Казанда да очраштык. Ул вакытта Р. З. Сәгъдиев Мәскәүдә космосны өйрәнү институты директоры булып эшли иде инде. Академик Казан дәүләт университетында плазма физикасына, идарә ителә торган атом-төш реакцияләренә багышланган лекция укыды, республикабыз башкаласының башка вузла-

ры галимнәре белән очрашты, үзе укыган 19 нчы мәктәптә булды. Мәктәп бусагасын атлап кергәч Роальд Зиннуровичның балалык еллары күз алдына килеп баса. Ул пионерларга Бөек Ватан сугышы елларында укулары, фронт геройларын мәктәптә ничек каршы алулары, җәмәгать эшләре турында мавыктыргыч итеп сөйли.

...Аның фәнгә мәхәббәте мәктәптә укыганда ук башлана. Соңгы дәрес тәмамлангач, кечерәк кенә буйлы, җитди карашлы бу малай ялт итеп физика кабинетына килеп керә торган була. Физика укытучысы Ольга Васильевна Юшканцевадан кичә эшли башлаган тәҗрибәләрен дәвам иттерергә рөхсәт сорый. Бер көнне Роальд тәҗрибәләр белән шул кадәр мавыгып китә, хәтта кабинетны бикләүләрен дә сизми кала. Төнлә генә ачып чыгаралар үзен. Ул көнне малайның дәресләрен әзерләргә бөтенләй вакыты калмый. Икенче көнне мәктәпкә бөтенләй әзерлексез бара. Җитмәсә, беренче дәрес — физика. Ольга Васильевна, үч иткәндәй, җавап бирү өчен Сәгъдиев фамилиясен атый.

— Физика һәм тәҗрибәләр белән мавыгуың бик әйбәт. Дәреслекне дә онытырга ярамый,— ди укытучы һәм Роальдка «2»ле куя.

Бу аның ун ел дәвамында бердәнбер «2» лесе була һәм Роальдны физика фәнен тагын да тырышыбрак өйрәнергә мәҗбүр итә.

Тарихта бәләкәч Амадей Вольфганг Моцартның эскәмиягә үрмәләп менә башлаганда ук клавесинада уйнарга өйрәнүе билгеле. Ул гадәти арифметик мәсьәләләрне авыр чишә, ләкин сонаталарны бик җиңел иҗат итә, ә 11 яшендә опера яза һәм, табигый ки, Моцарт бөек композитор булып танылa.

Физикага талант та шулай иртә ачыла аламы икән? Әлбәттә, баланың сәләтен кечкенәдән үк күрергә мөмкин. Монда шунысы әһәмиятле: аның нәрсә белән, ничек мавыгуын вакытында бәяләргә һәм дөрес юнәлеш бирә белергә кирәк. Роальд бик яшьтән музыка, рәсем сәнгате һәм шахмат белән мавыга башлый. Рәсем сәнгатендә һәм шахматта уңышлары да кечкенә булмый. Кичләрен укып балалар художество мәктәбен тәмамлый. Рәсемнәрен шәһәр күргәзмәләренә дә куялар. Тренеры Рәшит Нәҗметдинов җитәкчелегендә үсмерләр арасында бер елны Казан чемпионы да була. Шагыйрь Шәйхи Маннур белән шахмат уйнарга ярата.

— Әмма Роальдтан оста художник та, танылган шахматчы да чыкмаячагын без тиз аңладык,— ди галимнең әтисе Зиннур ага.— Малай күбрәк физика, математика белән мәшгуль була иде: өйдә дә тәҗрибәләр ясый, бөек галимнәр турындагы китапларны йотлыгып укый. «2»ле алу вакыйгасыннан соң, Ольга Васильевна Юшканцева белән бигрәк тә дусланып китте. Физикадан һәм математикадан «4» ле алганын да хәтерләмим, гел «5»ле дә «5»ле генә ташый иде. Укытучысыннан да бик уңды. Ольга Васильевна Роальдка дөрес юнәлеш бирә алды. «Синең юлың — физика, Роальд. Син физика факультетында укырга тиеш»,— дия торган иде.

Роальд укытучысы сүзләренә колак сала. 19 нчы мәктәпне көмеш медаль белән тәмамлагач, һич шикләнмичә, Мәскәү университетының физика факультетына укырга керә.

Аның зур фәнгә беренче адымы шушы була һәм Роальд Зиннурович Сәгъдиев үз бәхетен шунда таба.

**Мансур Хәсәнов,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНӘ ҺӘМ ТЕАТРЫНА НИГЕЗ САЛУЧЫ

Йөз еллык!


Республикабыз хезмәт ияләре, әдәби җәмәгатьчелек яңа татар әдәбияты белән бәйләнешле мондый олы юбилейны беренче тапкыр билгеләп үтә. Бөек шагыйрь Г. Тукайның, татар әдәбияты классигы Ф. Әмирханның, язучы-революционер Г. Ибраһимовның 90 еллыклары үткәрелде. Г. Камалның 100 еллыгы белән бездә революцион көрәш, демократик әдәбият һәм иҗтимагый фикер үсешенә зур өлеш керткән күренекле язучы, революционер һәм җәмәгать эшлеклеләренең йөз еллык юбилейлары башлана: 1980 елда шагыйрь М. Гафури, ә 1981 елда пролетариат язучысы Г. Коләхметов туугa 100 ел тула. Алга таба Х. Ямашев (1982), Ш. Камал (1984), М. Вахитов (1985) йөз еллыклары. Аннан соң, ниһаять, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимовларның шундый ук олы юбилейлары. XX гасыр башында, турыдан-туры 1905 ел революциясе йогынтысы белән, иҗтимагый көрәш һәм әдәбият мәйданына чыккан бу олы шәхесләр арасында иң өлкәне, иң әүвәлгесе Галиәсгар Камал иде.

Г. Камал — күренекле татар мәгърифәтчеләре К. Насыйри һәм Ш. Мәрҗани традицияләрен турыдан-туры дәвам иттерүче, XIX гасыр мәгърифәтчел әдәбиятын 1905 ел революциясе чорында формалашкан яңа, реалистик әдәбият белән бәйләүче, татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучы, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм башкалар белән бергә бездә демократик матбугатны оештыручы, татар социал-демократлары Х. Ямашев, Г. Коләхметовларның дусты һәм көрәштәше, Бөек Октябрьдан соң татар совет әдәбиятын һәм театрын актив төзүчеләрнең берсе. Аның исеме туган халкының рухи үсеш тарихына җуелмас хәрефләр белән язылган. Шуңа күрә Г. Камалның 100 еллыгы — гомумән, татар совет культурасының олы бәйрәме ул.

1

Галиәсгар Камал әдәбият мәйданына тарихи бер чорда — ике гасыр арасында килеп керде. Бу бер гасырның икенчесе белән гади алмашынуы гына түгел, бәлки заман үзгәрүе, тормыш нигезләрен, тарихи барышны бөтенләй үзгәртеп кору, илнең социаль-политик һәм рухи үсеш перспективаларын яңача билгеләү дәвере иде. Кешелек җәмгыяте үсешендә XX гасыр үзе белән бөтенләй яңа тарихи вакыйгалар, яңа идеяләр һәм максатлар, алар өчен көрәшкә күтәрелгән яңа көчләр алып килде. Ул, барыннан да бигрәк, пролетар революцияләре чоры башлануын, революцион хәрәкәт үзәгенең Россиягә күчүен хәбәр итте.

1905 ел революциясе татар халкы өчен җир өстеннән күкрәп үткән язгы яңгыр шикелле була. Ул гасырлар буе йокымсырап яткан татар дөньясын уята, төрле социаль катлауларны хәрәкәткә китерә, аларны гомум ил ку-



ләмендә җәелгән революцион-азатлык көрәшенә китереп куша. Мондый шартларда, табигый, элеккечә яшәеш, схоластик укыту һәм тәрбия, иске идеология һәм әдәбият яңа заман таләпләренә җавап бирми иде. Яңа чор үзенең яңа җырчыларын һәм идеологларын, яңа талантларны сорый иде. Г. Камал әнә шул шартларда тарихи аренага олы миссия белән чыккан яңа тип әдипләрнең, татар халкының яңа, европача рухи культурасын иҗат итүчеләрнең берсе.

Яңа татар әдәбияты XIX гасыр азагында — XX гасыр башларында милләт булып формалашып җиткән татар халкының үзенең сүз сәнгатен яңа шартларда, чорның тарихи таләпләре югарылыгына күтәрү, милли эстетик аңны, халыкның күп гасырлык әдәби традицияләренә, көнчыгышның гуманистик поэзиясе һәм прогрессив философиясенә таянган хәлдә, бөек рус һәм Көнбатыш Европа әдәбияты казанышлары белән сугару, шуның белән кушу, синтезлау нәтиҗәсендә барлыкка килде. Әдәбиятны яңа социаль-тарихи эчтәлек, революцион рух белән сугаручылар, милли сүз сәнгатен тудыручылар, критик реализмны нигезләүчеләр Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һәм Г. Камал булдылар. Бөек шагыйрь Г. Тукай иҗатында татар халкының гасырлар буе тупланып килгән поэтик таланты гәүдәләндерелсә, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал прозаны яңа югарылыкка күтәрделәр, ә Г. Камалга татар драматургиясен һәм милли театрны нигезләү насыйп булды.

Татар халкында театрга ихтыяҗ, билгеле, яңа гасыр башында гына тумады, ул элек-электән үк килә. Аның һәртөрле уеннары, ярминкә кәмитләре, ниһаять, татарларда йорт спектакльләре — әнә шул ихтыяҗның ачык бер гәүдәләнеше. Ә татар телендә беренче драма әсәрләре, мәгълүм булганча, XIX гасырның соңгы чирегендә генә (Г. Ильясиның «Бичара кыз»ы 1887 елда, Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз»ы 1889 елда, билгесез авторның «Комедия Чистайда» пьесасы 1895 елда) барлыкка киләләр.

Олы драматургия һәм профессиональ театр таләпләреннән чыгып караганда, бу әсәрләрнең әдәби-эстетик кыйммәте зур түгел. Аларның тарихи әһәмияте халыкның театр сәнгатенә булган ихтыяҗын чагылдыруда. Шуның белән бергә, алар милли драматургиягә, аерым алганда, Г. Камал иҗатына хәзерлек этабын үтәделәр.

«... Ильясиның китабын ничә кат укыганымны белмим, әмма Халидинең «Рәдде бичара кыз»ын кырык-илле тапкыр укыганмындыр. Хәтта мин аны күңелдән... белә идем», — дип язды соңыннан Г. Камал үзенең «Яза башлавымның тарихы» исемле истәлегендә.

Сүз татар драматургиясе һәм театр сәнгатенең барлыкка килүе турында барганда, бөек рус драматургиясе һәм театрының зур ролен аеруча билгеләп үтәргә кирәк. Казан — Россиянең мәшһүр театр шәһәрләреннән берсе, зур культура һәм мәгърифәт үзәге. Анда әле XVIII гасыр ахырларында ук беренче Казан гимназиясендә укучылар тарафыннан спектакльләр куела торган була, аларда, аерым алганда, Г. Р. Державин, С. Т. Аксаковларның актив катнашуы мәгълүм. Казанда рус драма театрының 175 еллык тарихы бар һәм бу театр татар культурасына, татар халкының театр сәнгате ихтыяҗлары формалашуга зур йогынты ясый. «Татарча спектакль кую — Казан мөселман җәмәгатьчелегенең алдынгы өлешенең күптәнге хыялы», — дип яза 1898 елда «Казанский телеграф» (1737 сан) газетасы.

Г. Камал да әле Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган чагында ук рус театрына даими рәвештә йөри, Көнбатыш Европа драматургларының әсәрләрен зур кызыксыну белән карый. Нәкъ шул чакта ул Гетеның «Фауст»ы белән таныша. Боларның һәммәсе, әлбәттә, Камалда яшеренгән драматурглык талантының уянуына көчле этәргеч ясый. Аны, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, «Ни өчен башкаларда драмалар, театр бар, ә бездә юк», — дигән сорау борчый.

Хәер, бер Г. Камалны гына борчыган сорау түгел бу, һәм мондый борчуларның тарихи мәгънәсе бар. Ул илдә революцион-азатлык хәрәкәтенең пролетар этабы башланган чорда татар халкының эстетик үзаңы чагылышы, халыкта үз рухи культурасының мөһим бер тармагын булдыруга үсә барган ихтыяҗның объектив гәүдәләнеше иде. «Национальный театр есть признак совершеннолетия нации, так же как и академии, университеты, музеи, — дип яза А. Н. Островский. — Иметь свой родной театр и гордиться им желает всякий народ, всякое племя, всякий язык»...[1] Г. Камалның татар культурасы каршындагы **тарихи роле** әнә шушы ихтыяҗны иң беренче булып аңлавында, аны практик тормышка ашыруында булды.

Г. Камалның беренче әсәре — «Бәхетсез егет» пьесасы 1898 елда язылган. Яңа гасырны ул инде өч әсәр авторы буларак каршылый. Аның «Бәхетсез егет», «Кызганыч бала» (прогрессив төрек драматургы Намикъ Камалның «Зәваллы чуҗык» исемле әсәренең татарчага тәрҗемәсе), «Өч бәдбәхет» пьесалары 1900 елда Казанда басылып чыгалар.

Г. Камал иҗатының башлангыч этабын чагылдырган бу әсәрләрнең, табигый, художество эшләнеше югары түгел. Әмма аларда XX йөз башы тормышы өчен гаять актуаль мәсьәләләр — кеше язмышы, шәхес белән патриархаль тормыш арасындагы каршылык, аталар һәм балалар проблемасы, семья тәрбиясе белән яңа заман таләпләре арасында конфликт һ. б. проблемалар куелган. Яшь драматург үзенең беренче әсәрләре белән үк татар дөньясындагы патриархаль тормыш калдыкларына, рухи торгынлыкка каршы кискен көрәш ачты.

Театр драматургиясез була алмаган кебек, драматургия дә театрсыз яши һәм үсә алмый. Татар драматургиясенең барлыкка килүе һәм үсүе милли театр таләпләре белән аңлатыла. Драматургия кебек ук, бездә театрның тууы да турыдан-туры Г. Камал исеме белән бәйләнгән.

Татар телендә беренче публичный спектакль, мәгълүм булганча, 1906 елның 22 декабрендә Казанда «Новый клуб» бинасында куелып, анда Г. Камалның «Кызганыч бала» исемле тәрҗемә әсәре уйнала. Нәкъ шушы көннән башлап Г. Камал үзенең пьесалары белән генә түгел, режиссер һәм артист, оештыручы буларак та татар театрының формалашуына һәм үсешенә зур хезмәт күрсәтә.

Профессиональ театр труппасы «Сәйяр»ның эшчәнлеге турыдан-туры Г. Камал һәм Г. Кариев исеме белән бәйләнгән.

«Татар театрына гражданлык алу өчен «Сәйяр»ның бу көрәшендә, — ди РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты Зәйни Солтанов, — иң күренекле драматург һәм театр белән һәр вакыт бәйләнештә булган Галиәсгар Камал һичшиксез зур роль уйнады. Г. Камал үзенең бөтен көчен, драматурглык талантын театрга багышлады... Аның хезмәтләре татар театры фундаментының нигез ташлары булдылар»[2].

Шуның белән бергә, милли театрның барлыкка килүе Г. Камалның иҗат эшчәнлегенә дә көчле стимул булды.

Аның драматург буларак танылуы 1905—1907 еллардагы революцион күтәрелеш чорына туры килә. 1907 елда ул үзенең атаклы «Беренче театр» комедиясен яза һәм «Бәхетсез егет» пьесасының яңа вариантын бастырып чыгара. Бу әсәрләр авторга лаеклы уңыш китерү белән бергә, татар драматургиясенең формалашуын, аның олы юлга чыгуын расладылар.

«Беренче театр» комедиясе 1905 ел революциясе дулкыны белән барлыкка килгән әһәмиятле тарихи вакыйганы — Казанда беренче татарча спектакль куелу фактын һәм шул уңай белән килеп чыккан көрәшне — тарих тарафыннан бетүгә дучар ителгән һәртөрле искелек тарафдарлары — консерватив карашлы байлар, надан сәүдәгәрләр, кадим муллалар һәм башкалар белән яңача тормыш-көнкүреш, мәгърифәт

---

[1] А. Н. Островский. Полное собрание сочинений. Т. XII, М., 1952, 160 бит.
[2] Х. Хисматуллин. Галиәсгар Камал. Казан, 1969, 33—34 битләр.

һәм культура төзү өчен күтәрелгән социаль көчләр арасындагы көрәшне — нәтиҗәдә беренчеләрнең каты җиңелүен, тарих көлкесенә калуын күрсәтә.

Г. Камалның драматург буларак зур уңышы беренче карашка бик гади тоелган бу конфликтны классик комедия югарылыгына күтәреп гәүдәләндерүендә, феодализм калдыкларын, патриархаль карашларны һәм гадәтләрне гомум халык алдында мәсхәрә итүендә иде. «Беренче театр» язылу белән үк милли театр сәхнәсенә күтәрелде, искелекне, торгынлыкны камчылаучы җитди иҗтимагый көчкә әверелде. Ул татар тамашачысын театр сәнгатен кабул итәргә хәзерләде, аның чын-чынлап мәхәббәтен казанды, тарихка татар драматургиясенең һәм милли театрның классик әсәре булып керде.

Г. Камал, татар театрының үсә барган репертуар ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатыннан чыгып, «Бәхетсез егет», «Беренче театр» әсәрләреннән соң «Бүләк өчен», «Уйнаш», «Дәҗҗал», «Кайниш», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» пьесаларын иҗат итә.

Аларда XX гасыр башы шартларындагы иҗтимагый тормышта, семьяда, көнкүрештә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә сакланып калган һәм яшәгән һәртөрле искелек — феодализм калдыклары, дини торгынлык, наданлык камчылана, иске байлар, тупас һәм надан муллалар, шәһәр мещаннары һәм аферист сәүдәгәрләр, эшсез байбикәләр һәм байбәтчәләр, алдакчы яучы карчыклар һ. б. фаш ителә. Бу әсәрләр татар драматургиясенең формалашуында, аның тормышчан нигездә, реализм һәм халыкчанлык юлыннан үсүендә әһәмиятле роль уйнадылар, ә кайберләре аның классикасына керде.

Г. Камалның тарихи миссиясе драматургияне һәм милли театрны иске тормышны җимерүгә, халыкның революцион энергиясен, иҗат көчләрен тоткарлап торучы феодализм калдыкларын себереп түгүгә, тарихи прогресс, киләчәк революция өчен юл әрчүгә мобилизацияләвендә булды. Бу татар драматургиясе һәм театрының киләчәктә югары баскычка күтәрелүе, революцион рух белән сугарылуы, социализм өчен көрәштә көчле идея коралы булуы өчен хәзерлек этабы иде.

Татар театрының әһәмиятле бер үзенчәлеге шунда, ул беркайчан да милли рамкалар белән генә чикләнеп калмады, аның эшчәнлегендә интернационализм рухы көчле булды, ул туган көненнән башлап үзенең репертуарын бөек рус һәм дөнья драматургиясе классиклары әсәрләре белән баетып килде, шуның белән үзенең иҗат офыкларын киңәйтте. Октябрьгә кадәрге чорда бу өлкәдә аеруча актив һәм нәтиҗәле эшләүче шулай ук Г. Камал булды. Язучы һәм әдәбият тарихчысы М. Гали билгеләп үтүенчә[1], аның тарафыннан рус һәм башка телләрдән барлыгы 50 дән артык сәхнә әсәре тәрҗемә ителгән. Алар арасында классик пьесалардан Н. В. Гогольнең «Ревизор»ы, А. Н. Островскийның «Гроза»сы һәм «Гаепсездән гаепleләр»е, А. М. Горькийның «Тормыш төбендә» һәм «Мещаннар»ы, Мольерның «Саран»ы, Лопе де Веганың «Сарык чишмәсе», Г. Хәмиднең «Һинд кызы» һ. б. бар.

Г. Камал зур осталык белән тәрҗемә иткән бу әсәрләр татар театры репертуарында ныклы урын алдылар, халыкның театр культурасын формалаштыруда, аны интернациональ рухта тәрбияләүдә, татар артистларының сәхнә осталыгын үстерүдә гаять зур роль уйнадылар. Аның оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләрен сәхнәдә уйнап, Габдулла Кариев, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Нури Сакаев, Зәйни Солтанов, Гөлсем Болгарская, Касыйм Шамил кебек беренче буын татар артистлары җитеште.

«Безнең дөньяга чыгуыбызга Сез, Галиәсгар әфәнде, сәбәп булдыгыз[2], — дип яздылар 1910 елда Г. Камалның 10 еллык иҗат юбилее уңае белән «Сәйяр» труппасы артистлары.

## 2

Г. Камал күп кырлы талант иясе иде.

Күренекле татар мәгърифәтчесе К. Насыйриныкы кебек, аның эшчәнлеге дә энциклопедик характерда. Ул милли матбугатны нигезләүче һәм актив төзүчеләрнең

---

[1] М. Гали. Г. Камал. Казан, 1941, 117 бит.
[2] «Йолдыз», 1910, 27 ноябрь.

берсе. Г. Камал, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимов белән берлектә, демократик татар журналистикасын һәм публицистикасын үстерүгә зур өлеш кертте.

Аның бу өлкәдәге иң зур тарихи хезмәте татар матбугатын революция максатларына хезмәт иттерүендә булды. Г. Камал редакторлыгында һәм нәширлегендә яки аның катнашы белән чыгарылган газета-журналлардан татар халкының революцион көчләре һәм милли әдәбиятның алдынгы вәкилләре киң файдаланалар, аларда революцион эчтәлекле мәкаләләр, большевиклар партиясенең программ документларын бастыралар.

Әле 1905 ел революциясенә кадәр үк татар социал-демократлары революцион брошюралар таратуда Г. Камал тарафыннан оештырылган китап басу һәм тарату ширкәтен («Мәгариф» китапханәсе) файдаланалар. Ә 1905 ел революциясе көннәрендә исә ширкәт үзе дә мондый әдәбиятны бастырып тарату эшенә керешә. Профессор Р. И. Нәфыйков раславынча, «Чын азатлык кайчан килер?», «Крестьяннарга җирне ничек үз кулларына алырга?», «Халык акчалары ничек җыела һәм нәрсәгә тотыла?», «Налоглар турында» кебек брошюралар Г. Камал заказы буенча бастырылган[1].

Халык арасында революцион идеяләрне пропагандалауда Г. Камал редакторлыгында чыгып килгән «Азат» газетасы зур роль уйнады. Анда, мәсәлән, «Россия социал-демократларының максатлары» дигән мәкалә бастырыла. Бу газетаның 1906 ел 51 санында татар матбугатында беренче мәртәбә В. И. Ленин исеме телгә алына.

Г. Камал редакторлыгында һәм нәширлегендә, Г. Коләхметов катнашы белән чыгарылган «Азат халык» газетасы татар революцион демократиясенең төп органы хезмәтен үтәде, анда социал-демократлар да үзләрен нәкъ үз өйләрендәге кебек хис итәләр. Патша хөкүмәтенең вакытлы матбугат цензурасы аны юкка гына социал-демократик газета дип бәяләми. Газета үзенең битләрендә турыдан-туры марксистик идеяләрне пропагандалый, буржуаз-милләтчеләргә, аерым алганда, «Мөселман иттифакы» партиясенә, пантюркистик «Тәрҗеман» газетасына каршы көрәш алып бара. Нәтиҗәдә патша властьлары тарафыннан газета ябыла, ә аның редакторы судка бирелә.

Г. Камалның турыдан-туры татар социал-демократлары белән тыгыз элемтәдә булуын Казан губернаторының 1907 ел 6 сентябрь боерыгы да раслый[2]. Анда ул, «Безнең якында булдырырга теләгән нәрсәләребез һәм максатыбыз» исемле большевистик брошюра таратканы өчен, «яшәп килә торган режимны көч белән бәреп төшерергә өндәүдә» гаепләнә. Губернатор аны судка бирүне таләп итә.

Г. Камал татар телендә иллюстрацияле сатирик журнал чыгаруга нигез салучыларның берсе. Ул 1908 елның августында Казанда Г. Тукай белән берлектә «Яшен» исемле журнал чыгара башлый. Аның редакторы да, нәшире дә Г. Камал була. Журнал эшендә шулай ук Ф. Әмирхан актив катнаша.

Бу журнал югарыда әйтелгән газеталар башкарган эшне үк дәвам итә. Ләкин, кызганычка каршы, аңа Столыпин реакциясе чорында озак яшәргә туры килми, 1909 елның июнендә ул яптырыла.

Г. Камалның журналистлык иҗаты турында сөйләгәндә «Йолдыз» газетасындагы эшчәнлегенә тукталмый мөмкин түгел.

«Йолдыз» революцион көрәштән читтә торган, иҗтимагый-политик яктан ачык йөзле булмаган либераль буржуаз орган иде. Ләкин ул үзенең саф татарча теле, ачык стиле һәм журналистлык культурасы белән башка күп кенә татар газеталарыннан аерылып торган, татар халкы арасында иң нык таралган газеталарның берсе. Нәкъ менә шуңа күрә дә демократик татар язучылары бу трибунадан үз максатларында нык файдаланалар.

Г. Камалның озак еллар газетаның җаваплы секретаре булып эшләве, анда үзләренең мәкаләләре белән татар революцион-демократ язучыларыннан Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Камал, Ш. Әхмәдиевләрнең актив катнашуы, газета битләрендә әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә киң урын бирелүе һәм башка кайбер факторлар бу газетаның татар матбугатындагы үзенчәлекле урынын билгели.

Г. Ибраһимовның Октябрьга кадәрге чор әдәби-тәнкыйть әсәрләренең күбесе, аның «Каһарман шагыйрь» исемле мәшһүр мәкаләсе, Г. Тукайның күренекле татар

[1] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казан, 1964, 244 бит.
[2] Татарстан Дәүләт архивы, 1 фонд, 4606 акт, 329 бәйләм.

большевигы Х. Ямашевка багышланган «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре» шигыре, Ш. Камал, Н. Думави һәм Җ. Вәлиди тәнкыйть мәкаләләре нәкъ шушы газетада, Г. Камал җаваплы секретарь булып эшләгән елларда басылганнар. Алар татар демократик әдәбияты үсешендә, әдәби тәнкыйть һәм публицистиканың формалашуында зур роль уйнадылар.

Шуның белән бергә, газета битләрендә югарыда әйтелгән демократик язучыларның әсәрләреннән тыш буржуаз-милләтчел характердагы мәкаләләр дә урын ала. Димәк, газетага бәя биргәндә, аның битләрендә алдынгы иҗтимагый-политик идеяләр, революцион-демократик эстетика белән консерватив карашлар, буржуаз-милләтчелек, әдәбиятта эстетлык һәм декадентлык юнәлеше арасында кискен көрәш баруын истән чыгармаска кирәк. Анда катнашкан авторларның политик позициясен, газетада басылган аерым мәкаләләргә бирелгән бәяне механик рәвештә бөтен газетага күчерү һич тә ярамый. Болай эшләү Октябрьга кадәрге чорда иҗтимагый-политик тормыштагы һәм әдәби хәрәкәттәге идея-эстетик каршылыкларны, аларның хәтта бер үк газета яки журнал битләрендә дә урын алуын танымау, һәрбер милли культурада капма-каршы ике культура турындагы В. И. Ленин методологик өйрәтмәләрен дөрес кулланмау булыр иде. «Йолдыз» газетасына, аның татар журналистикасы тарихында тоткан урынына берьяклы гына бәя биреп булмый.

Г. Камалның революциягә кадәрге әдәби-тәнкыйть һәм публицистик эшчәнлегенең шактый өлеше «Йолдыз» газетасы белән бәйләнгән.

Аның тәнкыйть мәкаләләрендә һәм рецензияләрендә татар драматургиясе һәм театры үсешенең актуаль проблемалары куелган, репертуар мәсьәләләре тикшерелгән, татар драматургларының аерым әсәрләренә анализ ясалган, беренче буын артистларыбызның сәхнә осталыгы турында әһәмиятле фикерләр әйтелгән. Аларда шулай ук драма һәм комедия жанрының үзенчәлекләре, хәрәкәтнең роле, характерлар динамикасы, сәхнә коллизияләре һ. б. әһәмиятле мәсьәләләр куелган булуын билгеләп үтәргә кирәк. Тәнкыйть эшчәнлеге Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовларныкы шикелле үк киң колачлы булмаса да, аның мәкаләләрендә эстетиканың һәм әдәби тәнкыйтьнең гомум теоретик мәсьәләләре махсус куелмаса да, Г. Камалның бу өлкәдә дә шактый хезмәте зур, бигрәк тә драматургия һәм театр сәнгатенең спецификасын тирән аңлавын, татар театрының көчле һәм йомшак якларын йөрәге белән тоюын, аның үсеш перспективаларын дөрес билгеләвен күрүе кыен түгел. Монда аңа барыннан да бигрәк практик тәҗрибәсе, әдәби сизгерлеге ярдәмгә килде.

Бөек рус һәм Көнбатыш Европа драматургиясен яхшы белү, аларның классик үрнәкләрен татарчага тәрҗемә итү, һичшиксез, Г. Камалны тәнкыйтьче буларак та үстергән, аның әдәби-эстетик карашларын баеткан, тирәнәйткән. Аның 1907 елдан соң язган рецензияләре татар драматургының бөек рус классиклары Н. В. Гоголь һәм А. Н. Островскийның халык арасында популярлыгының серен аңларга, иҗат принципларын үзләштерергә, татар драматургиясе һәм театры үсеше өчен көрәштә аларны нигез принциплар итеп алырга омтылышы турында сөйлиләр.

Г. Камал драматург, артист һәм режиссер буларак кына түгел, үзенең тәнкыйть эшчәнлеге белән дә татар драматургиясе һәм милли театр үсешенә мәгълүм бер өлеш кертте.

Әдипнең тәнкыйть эшчәнлеге драматургия һәм театр өлкәсе белән генә чикләнми, билгеле. Ул поэзия, проза өлкәсенә үтеп керә, анда да кызыклы фикерләр әйтә. Г. Камалның, мәсәлән, 1908 елда, татар тәнкыйтендә беренчеләрдән булып, Г. Тукай шигырьләрен югары бәяләве әһәмиятле. Ул татар поэзиясенә обзор ясый, Г. Тукайдан кала М. Гафуриның күренекле шагыйрь булуын билгеләп үтә. Г. Камалның бу ике татар шагыйренә биргән бәясе тарих тарафыннан расланды.

Г. Камалның татар пролетар әдәбиятының беренче үрнәкләрен хуплап каршы алуы, аларны яклавы һәм ачыктан-ачык пропагандалавы тарихи әһәмияткә ия. Ул Г. Коләхметовның «Яшь гомер» драмасы турында махсус рецензия язып чыкты, үзәгендә эшче-революционерлар торган бу әсәрнең перспективалы булуын күрсәтте. Бу — заманы өчен кыю адым иде. Г. Камал шулай ук Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасын югары бәяли, аның татар сәхнәсендә зур уңыш казануының сәбәбе — әсәрдә тормышчан образлар бирелүендә, аларны иҗат итүдә авторның художество осталыгында булуын әйтә.

Г. Камал — революциягә кадәрге чор татар публицистикасын нигезләүчеләрнең берсе. Аның публицистик мирасы иҗтимагый тормышның, татар халкының рухи үсешенең күп кенә тармакларына карый. Ул шулай ук үзенең атаклы замандашлары Х. Ямашев, Г. Тукай турында истәлекләр язды, киләчәк буыннар өчен аларның якты образларын саклап калуга зур өлеш кертте.

Ниһаять, Г. Камалның күп кырлы иҗат эшчәнлеге хакында сөйләп тә, аның татар әдәби теле үсешенә керткән зур өлешен аеруча билгеләп үтми мөмкин түгел.

Г. Ибраһимов бу турыда: «Галиәсгар Камал безнең әдәбиятта татарның масса әдәби теле өчен моннан 35 ел элек ачыктан-ачык көрәшкә чыккан беренче язучы»[1],— дип аеруча басым ясап әйткән иде.

Әдип үзенең иң беренче әсәрен үк — «Бәхетсез егет»не — халыкчан телдә язды, ә китап ахырында бу мәсьәләгә принципиаль карашын әйтеп чыкты, һәм шул көннән алып башка революцион-демократик язучылар белән бергә татар милли әдәби телен нигезләүче, актив төзүче булды. Г. Тукай татар теленең поэтик мөмкинлекләрен, шигърият көчен ачып бирсә, прозада аның фикерләү куәтен һәм эмоциональ байлыкларын Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һәм Ш. Камаллар иҗаты күрсәтте, драматургия өлкәсендә татар телен беренче булып чын-чынлап эшкә җигүче Г. Камал булды.

## 3

Г. Камалның утыз биш ел дәвам иткән әдәби иҗат һәм иҗтимагый эшчәнлегенең унбиш елы совет чорына туры килә.

Бөек Октябрь социалистик революциясен ул ихлас күңелдән, һичбер икеләнүсез кабул итте, аның беренче көннәреннән үк үзенең талантын һәм бай иҗат тәҗрибәсен революция максатларына, яңа культура төзү эшенә багышлады.

«Галиәсгар Камалның тормышында иң кыйммәтле ягы шунда, — дип язды Г. Ибраһимов, — ул 1917 елда — сыйнфый көрәшнең иң кискен чорында, икеләнеп тормастан, пролетариат революциясе ягына басты, бөек Ленин партиясе җитәкчелеге астында актив рәвештә совет матбугатында эшләде»[2].

Татар драматургиясе һәм театры классигы, аның атасы булып танылган бу өлкән татар әдибенең бөек тарихи борылыш чорында революция һәм халык ягында булуы милли әдәбиятның һәм гомумән культураның революция белән кушылуы, өлкән буын татар язучылары һәм сәнгать әһелләренең совет платформасына күчүе, киләчәктә татар халкының социалистик культурасын актив төзүчеләр булып җитешүе өчен гаять зур әһәмияткә ия булган тарихи факт. Бу шулай ук бөек революциянең иҗади көчен, гуманистик характерын раслый. Г. Камалның исеме хаклы рәвештә Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Камал, Һ. Такташ, К. Тинчурин, К. Нәҗми кебек татар совет әдәбиятын нигезләүчеләр, аның классиклары сафында тора.

Революциягә кадәрге авыр тормыш шартларында интенсив иҗат һәм җәмәгать эшчәнлеге нәтиҗәсендә сәламәтлеге шактый какшаган булуга да карамастан, Октябрьдән соң да әдипнең иҗат энергиясе сүрелмәде, ул элеккечә заманның алдынгы идеяләренә йөз тотып өзлексез эзләнде, үзен тулысынча әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеккә бирде. Журналист, драматург һәм публицист буларак, аның каләме сыйнфый көрәш эшенә, революция казанышларын саклауга хезмәт итте.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң Г. Камал, «Йолдыз» газетасында секретарьлык эшен дәвам иткән хәлдә, күренекле татар революционеры Мулланур Вахитов тарафыннан оештырылган Мөселман Социалистлар комитеты органы «Кызыл байрак» газетасы редакциясе белән иҗади элемтәдә тора, кайбер чыганакларда расланынча, бу газета өчен мәкаләләр тәрҗемә итә. Ә Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң ул Казан губерна башкарма комитеты органы «Эш» газетасы редакциясендә эшли. 1918 елның җәендә Казанны чехлар алгач, Г. Камал татар милләтчеләренең контрреволюцион буржуаз матбугатка эшкә чакыруын кире кага һәм семьясы белән шәһәрне ташлап китәргә мәҗбүр була.

1918 елның сентябрь башында Казан ак интервентлардан азат ителгәч, Г. Камал яңадан совет матбугатына — «Эш» газетасына кайта. Нәкъ әнә шул чорда ул үзенең

[1] «Совет әдәбияты», 1933, 4—5 сан, 96 бит.
[2] Шунда ук.

революция һәм гражданнар сугышы темасына багышланган мәшһүр «Көйле шигырьләр»ен, үз сүзе белән әйткәндә, «декламацияләр»ен иҗат итә.

Игътибарны, иң элек, заманча актив һәм сугышчан эчтәлекле булулары белән җәлеп иткән, көн кадагына сугып, конкрет чорның аеруча актуаль һәм җитди мәсьәләрен кыска, әмма киң массалар арасында үтемле итеп пропагандалаган ул әсәрләр әдипнең Октябрьдан соңгы иҗатында махсус игътибарга лаек әһәмиятле урын алып торалар. Аларда өлкән драматургның олы гражданлык хисләре, революция һәм хезмәт халкына ахыргача бирелгәнлеге ачык чагылыш тапты. Форма күзлегеннән генә түгел, эчтәлекләре белән дә «декламацияләр» шул чор рус совет поэзиясе үрнәкләрен, аерым алганда мәшһүр В. Маяковский һәм Д. Бедный иҗатларында өстенлек иткән тенденцияләрне хәтерләтә. Бер үк вакытта алар Г. Камалның революция елларындагы идея эволюциясен ачык чагылдырулары белән дә җитди кызыксыну уяталар.

Тематик яктан әлеге әсәрләр татар тормышы белән генә чикләнеп калмыйлар, бөтен ил, дөньякүләм әһәмиятле политик вакыйгаларны чагылдыралар, революция һәм интернационализм рухы белән сугарылганнар. «Көйле шигырьләр»нең ни сәбәпле һәм нинди шартларда тууы турында әдип үзе болай дип язган иде: «Гражданнар сугышының кызган чоры. Деникин, Колчак һәм башка ак бандалар яшь Совет иленә төрле яктан һөҗүм итәләр. Шуңа күрә дә мин кыска әсәрләр (шигырьләр) язып, көннең кадагына сугып барырга тиеш идем. Ул вакытларда мин икешәр көн өйгә кайтмыйча, редакциядә куныл эшли идем»[1].

Г. Ибраһимов аларны «революция бәетләре» дип атады һәм иске тормышны җимерүдә, революция дошманнарын фаш итүдә әһәмиятен күрсәтте, аларның «ярлы татар дөньясының иң караңгы подвалларына төшәргә, таралырга тиешлеген» әйтте.

Г. Камалның ул әсәрләре эшче клубларына һәм солдат казармаларына үтеп керде, театр сәхнәләрендә һәм концерт залларында укылды, киң халык массалары арасында популярлык казанды.

Театр сәнгате алдында торган яңа, революцион бурычларны тирән аңлап, сәнгать көчләрен шул бурычлар тирәсенә туплаучы, совет властеның беренче елларыннан башлап татар совет театры бинасын төзүгә керешүчеләрнең дә иң күренеклесе Г. Камал була. Гражданнар сугышы чорында ук Казанда эшчеләр клубларында, солдат казармаларында оештырылган концерт һәм спектакльләр аның булышлыгы белән уза.

Егерменче еллар башында Казанда берничә татар театр труппасы оештырылуы һәм эшли башлавы да Г. Камалның тынгысыз эшчәнлеге нәтиҗәсе. Мәсәлән, «Беренче күргәзмә дәүләт труппасы» составында үзе үк катнашып, ул анда башка талантлы татар артистларын тарта.

Г. Камалның совет чоры эшчәнлегенең характерлы үзенчәлеге шунда, ул театр труппалары оештыру белән генә чикләнми, аларда режиссерлык эшчәнлеген артистлык унеы белән тыгыз бәйләп алып бара.

Совет чорында Г. Камалның сәхнә осталыгы тагын да югарырак баскычка күтәрелде, аның артистлык таланты бигрәк тә бөек рус һәм Көнбатыш Европа драматурглары иҗат иткән классик образларны сәхнәдә башкарганда ачык чагылды. Аның артист буларак унеы турында энесе Габдрахман Камал түбәндәгеләрне яза: «Классик образлар тудыруда бик нык эшләде. Шиллерның «Юлбасарлар» трагедиясендә Патер, «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендә музыкант Миллер, Максим Горькийның «Тормыш төбендә» драмасында Актер ролен тиңдәшсез башкара иде. Бу бөек драматургларның образларын сәхнә аша гәүдәләндерер өчен, аларның бөтен әсәрләрен укып чыкты. Әсәрнең куелышы турында ясалган тәнкыйтьләрне эзләп тапты, аларны җентекләп тикшерде, аларда күрсәтелгән кимчелекләрне үзе эшли торган образларда булдырмаска тырышты»[2].

Г. Камалның оста унеы, аның артистлык таланты белән тудырылган образлар татар совет сәхнәсе тарихына гүзәл сәхифә булып кергәннәр.

Ул милли театр репертуарын оригиналь пьесалар белән баету буенча да актив эшләде. Совет чорында да ул, нигездә, комедия жанрында иҗат итте.

Г. Камалның Октябрьдан соң язган әсәрләреннән «Көндәш» (1918), «Өйләнәм —

[1] М. Гали. Г. Камал, Казан, 1941, 47 бит.
[2] «Казан утлары» журналы, 1969, 1 сан, 136—137 битләр.

ник өйләндем» (1918), «Җан Таһир белән Җан Зөһрә», «Могҗиза» (1930), «Тәкый газҗәп яки ахыр заман» (1931) комедияләрен күрсәтергә кирәк.

Бу әсәрләр искелеккә каршы көрәшнең мөһим аспектларын чагылдырдылар, шул чор өчен актуаль иҗтимагый, семья һәм мораль-этик проблемаларны күтәреп чыктылар, Г. Камал талантының характерлы үзенчәлеген — сатирик көчен күрсәттеләр. Алар капиталистик тормышны, иске гадәтләрне кире кагуы белән көчлеләр.

Г. Камалның совет чорында иҗат иткән оригиналь әсәрләренең иң күренеклесе «Хафизалам иркәм» исемле дүрт пәрдәлек комедия. Бу әсәр татар әдәбиятында М. Фәйзи башлап җибәргән музыкаль драма жанрын дәвам иттерде һәм Г. Камал драматургиясенең социалистик реализмга таба үсүен күрсәтүче факт булуы белән әһәмиятле.

Г. Камалның бөтен иҗаты әдәбиятның халык белән аерылгысыз бәйләнешен күрсәткән бер үрнәк булып тора. Драматургның халыкчанлыгы һәм партиялелеге, шәхес буларак принципиальлеге, аерым алганда, аның буржуаз-милләтчеләр белән көрәшендә ачык чагылды. Әдипнең 1929 елда татар буржуаз ак эмигрантларына биргән катгый җавабы шуның характерлы бер мисалы булды.

Г. Камал тәрҗемә өлкәсендә дә элеккечә актив эшләде, татар совет театрын бертуктаусыз бөек рус, Көнбатыш Европа драматургиясе классикларының әсәрләре белән баетып килде. Тынгысыз әдип журналист буларак та татар совет публицистикасы үсешенә зур өлеш кертте.

*

* *

Талантын һәм бөтен эшчәнлеген халык массаларына хезмәткә багышлаган әдипләрнең гомере озын була. Халык күңелендә, халык рухында алар кылган эшләре, иҗат җимешләре белән мәңгелек урын алалар. Талантлы драматург, милли театрыбызның нигез ташларын салучы Галиәсгар Камал шундый әдипләребезнең берсе иде. хезмәт халкының иҗтимагый һәм рухи омтылышларын киң чагылдырган әдәби мирасы белән бергә аның үз исеме дә халык хәтерендә мәңге җуелмас урын алды. 1909 елда ук, әдипнең ун еллык хезмәт бәйрәме көннәрендә, шул еллардагы демократик җәмәгатьчелек фикерен чагылдырып, халык шагыйре Г. Тукай аны «татар Островские» дип атады. 1923 елда, совет матбугатының биш еллык бәйрәме уңае белән, татар әдипләреннән беренче буларак, Г. Камалга «Хезмәт батыры» дигән мактаулы исем бирелә. Тагы алты елдан, 1929 елның язында, республикабыз хезмәт ияләре, совет җәмәгатьчелеге Г. Камалның 30 еллык әдәби иҗат бәйрәмен тантаналы төстә билгеләп үтә. Һәм шул уңай белән аңарга «Халык драматургы» дигән почетлы исем бирелә.

1939 елда Татар дәүләт театрына Г. Камал исемен бирү турында махсус карар кабул ителә. Бу — бөтен гомерен һәм иҗатын сөекле халкына хезмәткә багышлаган өлкән драматургның исемен олылау һәм мәңгеләштерү иде. Күренекле драматург исемен йөрткән җитмеш еллык бай тарихлы театрыбыз илебезнең иң алдынгы театрлары сафына басты. Үзенең чишмә башында Г. Камал һәм талантлы артист, режиссер Г. Кариев, К. Тинчуриннар торган татар совет театры 1927 елдан алып академия театры исемен йөртә. Ул дәүләтебезнең иң югары бүләге — Ленин орденына лаек булды. Анда берничә буын талантлы драматурглар, режиссерлар һәм артистлар үсеп чыкты. Аның сәхнәсендә СССР халык артистлары Х. Әбҗәлилов, Ф. Халитов, Ш. Биктимеров, РСФСРның һәм Татарстанның халык артистлары Х. Уразиков, Г. Болгарская, Ф. Ильская, Г. Камская һәм күп кенә башка талантлы артистлар уйнады һәм уйный. Г. Камал драматургиясе традицияләрен яңа шартларда М. Фәйзи, К. Тинчурин, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт кебек күренекле драматурглар өзлексез үстерә килделәр, соңрак чорларда алар Х. Вахит, А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин, Д. Вәлиев, Ш. Хөсәенов һ. б. драматурглар иҗатында дәвам иттерелде.

Шушы ук театрда татар халкының сөекле композиторы С. Сәйдәшев иҗаты чәчәк атты. Аның бүген дә яратып җырлана, уйнала һәм тыңлана торган күп санлы җырлары, инструменталь әсәрләре беренче тапкыр шушы театрда яңгыраш алган.

Партиябезнең тарихи XXV съезды әдәбият һәм сәнгать алдында, аерым алганда театр алдында, совет гражданнарына коммунистик тәрбия бирү юлында яңа һәм зур бурычлар куйды. Г. Камалның иң күренекле әсәрләре бүген дә заманча актуаль яңгырыйлар, совет халкын коммунистик идеалларга бирелгәнлек рухында тәрбияләүгә үзләреннән зур өлеш кертүләрендә дәвам итәләр.

**Шәмси Хамматов,**
«Социалистик Татарстан» газетасы редакторы, тарих фәннәре кандидаты.

**Фазыл Мөбәрәкшин,**
СССР Журналистлар союзы члены

# ӘДИП ҺӘМ ТАТАР МАТБУГАТЫ

Соңгы елларда Г. Камал иҗатын өйрәнүгә галимнәр, язучылар, тәнкыйтьчеләр тарафыннан шактый зур өлеш кертелде. Бу өлкәдә Г. Кашшаф, Х. Хәйри, Г. Халит, М. Гали, Х Хисмәтуллин, М. Гайнуллин, Җ. Вәзиева кебек галимнәр хезмәте махсус игътибарга лаеклы. Аларның хезмәтләрендә, аерым алганда, Г. Камалның матбугат, публицистика эшчәнлеге дә күрсәтелә. Ләкин Г. Камалның матбугатта, журналистикада эшләвен тулаем колачлап, тирәнтен өйрәнеп язылган махсус фәнни хезмәт әлегә юк. Олы драматург, әдип Г. Камалның журналист, публицист һәм редактор буларак күп кырлы эшчәнлеген тулы, киң яктырту киләчәк эше. Һәм ул, беренче чиратта, журналистика белгечләре өстенә төшә.

Г. Камалның 100 еллык юбилее уңае белән язылган бу мәкаләдә күренекле драматургның милли матбугат һәм журналистика өлкәсендәге эшчәнлеген чагыштырмача тулы итеп күз алдына китерүгә омтылыш ясала.

* * *

1905 ел революциясе культура, идеология тормышына зур яңару һәм үзгәрешләр кертеп, күп милләтле Россия халыкларының алдынгы вәкилләре эшчәнлеген бермә-бер активлаштырып җибәрде. Татар халкының әнә шундый прогресссив вәкилләреннән берсе — Г. Камал киң колачлы әдип һәм журналист буларак мәйданга чыкты. Егерменче йөз башларында ук ул китап бастыру максаты белән полиграфия эшен өйрәнә. Халыкны агарту нияте белән 1901 елны «Мәгариф» исемле китап, газета-журналлар сату магазины ачып җибәрә. Бу магазин 1905 ел революциясе көннәрендә халыкка, бигрәк тә яшьләргә, китап, вакытлы матбугат аша революцион идеяләр тарату учагына әверелә. РСДРПның Казан большевиклар комитеты члены Хөсәен Ямашев «Мәгариф» китапханәсеннән марксистик әдәбиятны саклауда, көрәштәшләре Гафур Коләхметов, Галимҗан Сәйфетдинов тарафыннан тәрҗемә ителгән революцион листовкалар, прокламацияләр һәм брошюраларны таратуда файдалана.

Өлкән ветеран-журналист Гариф Латыйпов «Г. Камал турында истәлекләр» дигән мәкаләсендә болай дип яза: «1905 елгы революция көннәре килеп җитте. Бер көнне Г. Камал «Мәгариф» кибетендә татар большевигы Хөсәен Ямашев белән мине таныштырды. Озак та үтмәде, Х. Ямашев шәкертләр арасында агитация эшләре алып бара башлады. Ямашев аркылы без прокламацияләр ала идек. Ул прокламацияләрне «Мәгариф» кибетендә чүп-чар кәгазьләр арасында саклый идек»[1].

[1] «Кызыл Татарстан», 6 январь, 1939 ел.

Х. Ямашев һәм Г. Коләхметов кебек көрәштә чыныккан революционерлар белән аралашу Г. Камалны демократик рухта тәрбияли, аңарда булган халыкка хезмәт итү дәртен көчәйтеп җибәрә. Г. Камал 1905 елгы революция тарафыннан яулап алынган матбугат ирегеннән файдаланып, үзенең күптәнге хыялын тормышка ашыру — татар газетасы чыгару эшенә җиң сызганып тотына. Башта бераз либераль газетада — «Казан мөхбире»ндә эшләгәннән соң, аның политик юнәлеше белән килешә алмый, аннан китәргә мәҗбүр була.

1905 елда Казанда эшчеләрнең Октябрь стачкасы була. Ләкин ул патша гаскәрләре тарафыннан рәхимсез бастырыла. Революцион оешмаларга, шул исәптән демократик матбугатка, һөҗүм башлана. Революционерлар кулга алына, прогрессив интеллигенция вәкилләре эзәрлекләнә. Казан партия оешмасы, партия Үзәк Комитеты күрсәтмәләрен үтәп, профсоюз, матбугат кебек демократик органнарда торып, пролетариат интересларын якларга кирәк дип чакыра. Әнә шундый шартларда большевиклар, бигрәк тә Хөсәен Ямашев йогынтысы белән, Гафур Коләхметов, Мөхетдин Корбангалиев шикелле демократик әдип-публицистларның ярдәме һәм катнашында Г. Камал 1906 елның 1 февраленда «Азат» исемле демократик газета чыгара башлый. Ул аның төп оештыручысы һәм фактик редакторы да була. (Газетаны бастыру өчен зур средство кирәк булганлыктан, ул мулла Г. Апанаев белән бергәләп чыгарыла).

Г. Камал һәм аның прогрессив карашлы иптәшләре газетаны халыкны политик тәрбияләү, демократик идеяләрне пропагандалау, революцион көрәш мәйданы итәргә тырышалар. Газета битләрендә марксизм рухы белән сугарылган публицистик мәкаләләр, партия документларының, листовкаларының тәрҗемәләре басыла. Г. Камалның үткен политик шигырьләре, фельетоннары чыгып тора

Кара реакциянең каты һөҗүменә карамастан, «Азат» газетасында большевиклар партиясенең ленинчыл программасы тәрҗемәсе басыла. Бу газетада татар телендә беренче тапкыр Владимир Ильич Ленин исеме атала. «Россия социал-демократларының максатлары» дигән мәкаләдә татар телендә беренче мәртәбә халыкка аңлаешлы итеп большевиклар партиясенең программасы турында сөйләнелә. Газетада шулай ук РСДРПның Казан комитеты прокламацияләре аерым мәкалә итеп бирелә. «Азат» газетасында «Хатыннар мәсьәләсе», «Государственная думага пассив байкот ясау», «Эш юктан», «Сословия, класс һәм партия», «Халыкка ниләр кирәк», «Җир һәм халык» кебек бик күп публицистик мәкаләләр, фельетоннар самодержавие строеның, буржуаз җәмгыятьнең черeклеген фаш итәләр.

Сул фикерле, революцион рухта язылган мәкаләләр өчен Г. Камал белән мулла Г. Апанаев арасында идея каршылыгы көчәя, Г. Апанаев газетаны чыгаруга средство бирүдән баш тарта. Г. Камал газетаны тулысы белән үз җаваплылыгына ала һәм аны «Азат халык» исеме белән чыгара башлый [1].

«Азат халык» газетасының беренче саны 1906 елның 4 июнендә басылып тарала. Патша самодержавиясе революциягә ярсып һөҗүм иткән көннәрдә, халык бәхете өчен, аны азат итү өчен «Азат халык» исемендә газета чыгару үзе зур батырлык! Буржуаз милләтчеләр хезмәт ияләрен революцион идеяләрдән читләштерергә азапланган дәвердә газетаны «Азат халык», ә җәяләр эчендә русча «Свободный народ» дип исемләү ул турыдан-туры азатлыкка өндәү, халыклар дуслыгын ныгытуга, рус теленең бөеклеген күрсәтүгә омтылыш иде.

Ул елларда чыгып килгән большевистик рус газеталары тәэсирендә Г. Камал чыгарган һәм редакцияләгән «Азат халык» газетасы революцион юнәлештәге матбугат органына әверелә. Ул «Вакыт», «Тәрҗеман», «Казан мөхбире» кебек либераль буржуа органнарын фаш итә, мөселман иттифакчылары, татар монархистлары һәм кадетларының чын йөзен ача. Патша цензурасының өзлексез күзәтүенә карамастан, аның битләрендә марксизм нигезләре аңлатыла, пролетариат диктатурасының җиңәргә тиешлеге исбатлана.

«Һади» псевдонимы белән басылган «Вакыт җитте» шигырендә Г. Камал ул заманда урнаштырылган тәртипләр белән килешеп тормаска, риза булмаска өнди:

Туганнар, тырышаек котылырга,
Риза булмыйк һаман болай сытылырга.

[1] М. Гали. Сайланма әсәрләр. Татгосиздат, Казан, 1956, 195—296 битләр.

Җитәр инде күп чыдадык, сабыр иттек
Читлектәге кортлек кебек тотылырга [1].

«Азат халык» газетасында «Социал-демократлар нәрсәгә өйрәтәләр» [2] исемле берничә санга сузылган пропагандистик мәкалә басыла. Бу мәкаләдә фәнни социализм нигезләре ачыла, К. Маркс һәм Ф. Энгельс эшчеләр сыйныфының остазлары дип атала.

«Пролетариатның диктатурасы,— диелә ул мәкаләдә,— ягъни эшчеләр Государственный властьны үз кулларына алу, капиталистический стройны бетереп, аның урынына социалистический строй ясау өчен, эшчеләр партиясе политический властьны үз кулына алуы лаземдер». Самодержавие шартларында матбугатта мондый фикерне үткәрү үзе нинди зур кыюлык!

Шулай итеп, «Азат халык» газетасы, аның редакторы Г. Камал большевистик идеяләрне пропагандалый. Казан цензура комитетының бу газетаны социал-демократик юнәлештәге орган, «Мөселман иттифакы»ның дошманы дип атавы бик урынлы иде. «Азат халык» газетасы, 15 саны чыкканнан соң, 1906 елның көзендә һатша властьлары тарафыннан туктатыла. Редакторы Г. Камал судка тартыла.

Большевиклар, революционер язучы Г. Коләхметов белән демократик матбугатта уртак тел табып, фикердәш булып бергә эшләү Г. Камалның самодержавиегә, буржуаз җәмгыятькә карашын бик нык үзгәртә, ул заманның пычрак күренешләренә каршы көрәшү омтылышын тагын да ныгыта. «Азат», «Азат халык» газеталарында революцион социал-демократлар йогынтысында марксистик идеяләрне пропагандалау, матбугатны демократик юнәлештә алып бару беренче татар большевистик газета «Урал»га нигез ташлары салды.

Күп вакыт та үтми, Г. Камалның фельетоннары, очерклары, тәнкыйть мәкаләләре, редакциянең махсус корреспонденты сыйфатында язган юл язмалары «Йолдыз»-да басыла башлый. 1907 елның 20 январенда «Яшенче» псевдонимы белән «Йолдыз»-да дөнья күргән «Ләкми калды» исемле кечкенә фельетонда ул илдә реакциянең көчәя баруын чагылдыра, өстен сыйныф вәкилләренең үзләрен Дәүләт думасына член итеп сайлату өчен крестьяннарга бик күп вәгъдәләр бирүеннән көлә.


Матбугатта чыгып торган фельетоннар, чәнечкеле әсәрләр авторы күңелендә «Яшен» исемле сатирик журнал оештыру нияте уяна. Кара болытларны таратып, хәерле яңгырлар яудырырга тели Г. Камал. 1907 елның 1 маенда «Йолдыз» газетасында ул мондый белдерү ясый: «Яшенче үзе сәламәт һәм хезмәтендә хәзердер. Яшенне яшьнәтмәк өчен омтылып караса да, һаман теләгенә ирешә алганы юктыр. Һавада кара болытлар күп булса да, яшен яшьнәмидер, хәерле яңгырлар яумыйдыр. Бер көн килер, шаять һавалар да үзгәрер... Шул заман яшен дә ялтырар».

Ниһаять, 1908 елда Г. Камал һәм Г. Тукай «Яшен» журналы чыгара башлыйлар. Журнал «салам торханнарга, прэфаннарга», «милләт хакын ашаучы куштаннарга, калын корсак байларга, эшлексез муллаларга, хыянәтчеләргә» каршы аяусыз көрәш алып баруны максат итеп куя. Журналда басылган күпчелек мәкаләләрне Г. Тукай, Г. Камал яза. Рәсемнәр, карикатураларның да күп өлешен Г. Камал ясый.

1908 елны «Әльислах» газетасының 41 санында «Яшен» журналы исемле мәкалә басыла. Анда Г. Камалның журналистлык, редакторлык эшчәнлегенә югары бәя бирелә. «Казанда,— диелә мәкаләдә,— беренче көлке журналы «Яшен», күп көтелгәннән соң, ахры чыга башлады. Баш мөхәррире чибәр әсәрләре илә яшь мөхәррирләребез арасында мөһим урын алган Галиәсгар әфәнде Камалдыр. Г. Камал әфәнде әсәрләрендә, хосусан, «Беренче театр» да, үзенең көлүче икәнен күрсәткән һәм Казанда татарча газета чыга башлаганнан бирле газетачылык илә шөгыльләнгән егерменче гасырның татарча яңа әдәбияты чыга башлау илә шуның хезмәтенә бирелгән көнҗ мөхәррирдер». Ун саны чыкканнан соң «Яшен» туктатылып, аның урынына «Ялт-йолт» сатирик журналы чыга башлый. Анда да Г. Камал публицист һәм художник буларак актив катнаша. Әдәбият белгечләре М. Гайнуллин һәм Җ. Вәзиева Г. Камалның ул эшчәнлеге турында болай дип язалар: «Үзе чыгарган һәм редакторы булган «Яшен» журналында, Г. Тукай секретарьлык иткән «Ялт-йолт» журналында һ. б.

---

[1] «Азат халык», 4 сан, 1906 ел.
[2] Шунда ук, 9, 11, 12, 13 саннар, 1906 ел.


№ 93 (2463)

*Г. Камалның 1929 елда «Кызыл Татарстан» газетасында басылган хатының фоторепродукциясе.*

газеталарда Г. Камалның татар буржуа җәмгыятендә булган тискәре, социаль зарарлы күренешләрне тәнкыйть иткән 200 гә якын карикатуралары басылып чыктылар. Алар Г. Камалның үзенең һәм күбрәге халык шагыйре Г. Тукайның сатирик әсәрләренә иллюстрация рәвешендә бирелгәннәр. Һәм шул чордагы иҗтимагый-политик күренешне чагылдыручы әсәрләр буларак, реакцион көчләрне фаш итүдә зур урын тотканнар»[1]. Гомумән, Г. Камал сатирик журналларда эшләп, татар журналистикасының юмор жанрын үстерүгә зур өлеш кертә. Сатира коралы белән буржуаз тормышның тискәре, социаль зарарлы якларын бик оста тәнкыйть итеп килә.

---

[1] М. Х. Гайнуллин, Ж. Г. Вәзиева. Татар әдәбияты. XX йөз. II кисәк. Татгосиздат. 1954, 109 бит.

Г. Камал әдип-журналист буларак матбугат һәм әдәбиятның теле үсешенә дә игътибар бирә. Үзенең әсәрләрендә ана теленә кешеләрне куандыра торган байлык, халкыбыз җәүһәрләре итеп карый.

XX йөз башларында атаклы мәгърифәтче Каюм Насыйри тарафыннан алга сөрелгән «татар телендә язу» лозунгысын, «без — татарлар, безнең телебез — татар, үйфикерләрне әйтеп бирүдә һич тә башка теллрдән түбән тормый» дигән карашны тормышка ашыруда гаять зур эш башкара Г. Камал. Бу турыда Бөек Ватан сугышы алдыннан чыккан хезмәтләрендә галим Мөхәммәт Гали шактый тулы яза.

Әсәрләр гарәп, фарсы һәм госманлы сүзләре белән чуарланган бер вакытта, аның белән мавыккан кешеләргә капма-каршы буларак, Г. Камал саф татар телендә язарга мөмкин дигән фикерне басым ясап, ассызыклап әйтә. Г. Камалның моннан 79 ел элек «Бәхетсез егет»нең беренче басмасына язган сүз ахыры ул вакытларда Каюм Насыйриның «татар әдәби теле» дигән фикерен кире каккан, аны «юләрлек» дип, татарның сөйләү телендә язу һич мөмкин нәрсә түгел, дип караган кешеләргә — буржуаз милләтчеләргә олы гаепләү акты булып яңгырый. Г. Камал анда саф татар телендә болай дип яза: «Бәгъзы кешеләр бу китапны бигрәк урам телендә чыгарган икән дип көләрләр, бәлкем. Әмма ни зыян? Көлсеннәр. Дәхидә, шундый бар кеше дә аңларлык, урам телендә булган китаплар булучылыгы насыйп булсын. Ярый ла бар кеше дә галим булып бетсә, ул чагында фарсыча һәм гарәпчә чыгарсак та зыян юк»,— ди. Реакцион, пантюркистик карашларда торучыларга көчле удар була бу!

«Азат», «Азат халык» газеталарында рус теленнән кергән сүзләр, интернациональ терминнар публицистик мәкаләләрдә, тәрҗемә материалларында бик күп кулланыла.

Реакция елларында буржуаз милләтчеләр татар телен, матбугатны гарәп-фарсы, Г. Тукай әйткәнчә, «төрекләрнең чирканыч соңгый телләре белән» чуарларга омтылган вакытта «Азат» һәм «Азат халык» газеталарының фактик редакторы Г. Камал халыкка аңлашыла торган русча, интернациональ сүзләрне, төшенчәләрне телебезгә актив кертә. Аларда «класс», «партия», «сословие», «пролетариат диктатурасы», «строй», «программа», «социал-демократ», «эксплуатация», «социализм», «власть», «политика» кебек сүзләрне бик еш очратырга мөмкин.

Г. Камал шул чактагы вакытлы матбугат органнарына, әдәби китапларга, спектакльләргә оператив рецензияләр, тәнкыйть мәкаләләре, кечкенә фельетоннар да яза килә, җәмгыятьтә булган җитди вакыйгаларга карата үзенең публицистик сүзен әйтә.

1907 елда «Әльислах» газетасы чыгу уңае белән «Бер-ике сүз» исемле күзәтү язып, анда әлегә кадәр чыккан газеталар шәкертләр тормышына аз игътибар итәләр, аларның ихтыяҗларын үтәмәделәр дип күрсәтә Г. Камал. Һәм «Әльислах» газетасының чыгуын тәбрик итеп, болай ди: «Әльислах» газетасы шәкертләр өчен булганлыктан, аның хезмәте шәкертләрне химая (яклаучы), аларның мәгълүматларыны арттыру, вә аларның ихтыяҗәтеннән бәхәс итү, вә аларга кулыннан килгән кадәр тәрәккый (алга бару) юлларына күрсәтү улачактыр».

Ул Г. Тукай, М. Гафури, Г. Коләхметов, Ф. Әмирхан әсәрләренә әдәби тәнкыйть материаллары белән чыга.

1907 елның 5 декабрендә ул «Йолдыз» газетасында «Габдулла Тукаев шигырьләре» исемле рецензия бастыра. Олы милли горурлык хисе белән язылган бу мәкаләдә Г. Камал татар әдәбиятының да мөстәкыйль үсүен күреп чын күңелдән шатлана. Аның «язучыларымызның күңелләрене күтәрә төшү тиештер. Шулай да булса, әдәбиятымызны төрекләргә яхуд башкаларга кияүгә бирүдән ихтираз (саклау) лаземдер» дигән сүзләре пантюркистлар, панисламистларның татар әдәбиятын гарәп һәм төрек әдәбияты тәэсиренә бирергә омтылуларына каты кисәтү иде. Г. Камал шагыйрь Г. Тукай иҗатына беренчеләрдән булып объектив, дөрес бәя бирә. «Габдулла әфәндenең язган нәрсәләре арасында хакыйкатьтән шигырь итлакына мөстәхыйк булган гали тасвирлар, гүзәл тәрсимнәр (рәсемләүләр) күренәдер. Шуның өчен Габдулла әфәндене бу әсәре илә тәбрик итәбез»,— дип яза ул. Шагыйрь Мәҗит Гафурига да уңай фикерен әйтә. Г. Тукай белән М. Гафурины күз алдында тотып, «хәзерге көндә шагыйрь исемене итлак кылырга (бирергә) шул икесе лаектыр»,— дип белдерә.

Г. Камал әдипләрне, драматургларны, журналистларны рус классик әдәбиятыннан, публицистикасыннан үрнәк алырга өнди. Үзе дә Н. Гоголь, А. Островский, Л. Толстой, И. Крылов, М. Горький әсәрләрен өйрәнә, тәрҗемә итә. Мәкаләләренең берсендә И. Крылов әсәрләреннән алган тәэсире турында болай дип яза: «Крылов бабайның баснялары һәрвакыт, һәркемнең кыланышын тәмсил (ошатып) итеп күрсәтер өчен кыяматкә кадәр ярарлык бер көзге дисәң, ялган түгелдер». Г. Камал үзенең идея дошманнарын, демократик матбугатка каршы өреп йөрүче буржуаз милләтче журналистларны, И. Крылов алымнарын файдаланып, сатира уты белән камчылый.

«Йолдыз» газетасының 1908 ел 5 июнь санында әдип Гафур Коләхметовның «Яшь гомер» пьесасына рецензия белән чыга. Эшче сыйныфының буржуаз милләтчелеккә, самодержавиегә каршы көрәш идеяләрен чагылдырган «Яшь гомер» әсәрен югары бәяләп, ул бу рецензиясе белән үзенең политик активлыгы үсүен, революцион демократик фикердә булуын тагын бер кабат раслый.

Г. Камал большевик Хөсәен Ямашев үлеменә багышлап «Хөсәен әфәнде Ямашевның җиназа мәрасиме» (шествиесе) исемле публицистик мәкалә яза. («Йолдыз»ның 1912 ел, 20 март санында басыла). Мәкаләдә мәрхүм большевик Х. Ямашев шәхесенә, аның гаять зур эшчәнлегенә әйтеп бетергесез симпатия, теләктәшлек фикере һәм хисләре көчле.



*

*   *

Бөек Октябрь социалистик революциясенең беренче көннәреннән үк Г. Камал иҗатын бөтенләе белән халык бәхете өчен багышлый. Үзе үлгәннән соң, 1933 елда «Кызыл Татарстан» болай дип язды:

«Бөек Октябрь.

Карт әдип, журналист, драматург Галиәсгар ага тирбәнеп тормый. Советлар, пролетариат диктатурасы лагерына күчә. Казан социалистлар комитетының «Кызыл байрак» газетасында эшли. Чехлар куылганнан соң коммунист большевиклар органы «Эш», «Эшче», фронт газетасы «Кызыл көрәшче», «Безнең байрак» һәм «Татарстан» газетасының беренче санынна (1920 ел, 2 июльдән) башлап 1931 елның 20 нче июленәчә «Кызыл Татарстан»да эшли»[1].

Г. Камал революционер, ленинчы Мулланур Вахитов җитәкчелегендә чыккан «Кызыл байрак» газетасында хезмәт итә. 1918 елның язында чыга башлаган татар большевистик матбугат органы «Эш» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасын актив оештыручыларның, аның төп сотрудникларының берсе Г. Камал була. «Эш» газетасының исеме — башы аның тарафыннан языла. «Эш» газетасындагы эшчәнлеге турында Г. Камал үзе болай дип сөйли: «Кайвакыт мин бөтен редакциядә бер үзем утырып калам. Редактор да, секретарь да, корректор да, экспедитор да үзем булам, кирәк була икән, курьер да булам, икешәр, өчәр көн өйгә кунарга кайтмыйча, көнетөне шунда эшләп уздырам»[2].

Большевистик «Эш» газетасының дөньяга чыгуын Казанның буржуаз газеталары, бигрәк тә «Корылтай», «Безнең тавыш», котырынып каршы алалар, аңа каршы агулы мәкаләләр бастыралар. Алар Совет властеның, Коммунистлар партиясенең политикасын бозып күрсәтәләр. Әнә шундый шартларда журналистларга, әлбәттә, большевистик газетада эшләү җиңел булмый. Яңа чыга башлаган «Эш» газетасы буржуаз милләтчеләрнең чын йөзен, чын максатларын фаш итә, хезмәт ияләрен Ленин партиясе тирәсенә туплый.

«Эш» газетасы партия һәм хөкүмәт документларын киң пропагандалый. Совет властеның әһәмиятле декретлары, Советларның, Коммунистлар партиясенең съездлары һәм конференцияләре турында отчетлар бирә, дәүләт җитәкчеләренең чыгышларын яктырта. «Правда», «Известия» газеталарының бик әһәмиятле мәкаләләрен күчереп баса. Боларның барысы да диярлек журналист Г. Камал тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә. Ул ана теленең үзенчәлекләрен, кануннарын саклап, сүзгә-сүз түгел, ә ирекле рәвештә, халыкка җиңел аңлаешлы итеп тәрҗемә итә торган булган.

---

[1] «Кызыл Татарстан», 18 июнь, 1933 ел.
[2] М. Гали. Сайланма әсәрләр. Татгосиздат, Казан, 1956, 365 бит.

Гражданнар сугышының иң кызган чагында әдип-публицист Г. Камал матбугатта чын йөрәктән бирелеп эшли. «Гражданнар сугышының кызган чоры, Деникин, Колчак һәм башка ак бандалар яшь совет иленә төрле яктан һөҗүм итәләр. Шуңа күрә дә мин, кыска әсәрләр (шигырьләр) язып, көннең кадагына сугып барырга тиеш идем»[1],— дип искә ала ул җаваплы көннәрне Г. Камал. Үзенең талантын, сатира угын, утлы шигырьләрен, декламацияләрен совет дошманнарына каршы юнәлтә. Аның бу елларда язган политик лирикасы, сатира әсәрләре үзе эшләгән «Эш» газетасында даими рәвештә басылып килә. Шунысы характерлы: Г. Камалның газетада шул вакытта басылган шигырьләрен, декламацияләрен Октябрь социалистик революциясе җиңүгә бер ел тулу хөрмәтенә «Эш» газетасы редакциясе махсус җыентык итеп чыгара, аны укучыларга бәйрәм бүләге итеп тарата. Алар икенче тапкыр 1921 елда «Декламацияләр» дип исемләнгән җыентыкка туплап чыгарыла. Совет власте елларында бу җыентыкларының чыгуы әдип-журналист Г. Камалның иҗат хезмәтен ихтирам итү, аның тарихи кыйммәтенә бәя бирү иде.

Г. Камал «Эш» газетасының редакторы Вәли Шәфигуллин белән берлектә «Әүлия һәм компаниясе», «Ишан Гали» псевдонимнары астында, көннең кадагына суга торган сатирик парчалар, шигъри фельетоннар да биреп бара. Әсәрләрнең күпчелеге Октябрь казанышларын, социалистик Ватанны саклап калырга, халыклар дуслыгын ныгытырга өнди. Менә «Эшчегә» дигән шигыре:

Инде шатлан, ярлы халкым, якты дөнья киң сиңа!
Дүрт ягың нур, алсу сахра, дөньяда юк тиң сиңа!..
Изге ак көн — киң бәхеткә тезләнеп пакь тез белән
Алга, эшче дустым, ил юлы — ак эз белән!..[2]

Ул ярлыларны, эшчеләрне хезмәт сөяргә чакыра.

Иптәш, кызыкма данга һәм малга,
Атла аякны алга да алга.
Мин сөямен ярлыны, ярлыны,
Мин сөямен эшчене, эшчене,
Эш тормышның иң чыны, иң чыны[3].

«Ак»ка шөкер китабы» исемле шигырендә Г. Камал кызыл гаскәрнең җиңүенә, ә акларның — «ак сөякләрнең» тар-мар ителүенә шатлыгын белдерә.

«Ак»ка шөкер идәлем һәр ан
Түгә алмады әле күп кан,
Кызыл гаскәр җиңү белән
Исән калды ничә мең җан...
Тыгыз иде безнең сафлар,
Тырышты күп яулы халык —
Сугыш сафларына барып
Тырыштылар көне, төне...
«Ак сөяк» калды тапталып[4].

«Большевизм көрәше» исемле шигырендә Г. Камал Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә совет халкының җиңүен мактый:

Союзниклар большевизмны телиләр буарга,
Ләкин үзләренә туры килә эчләрен уарга.
Сүндерергә маташканда большевизмның утын,
Яңа утның кабынуы ала союзникның котын...

Г. Камал агитацион шигырьләрен, декламацияләрен эшче клубларында, кызылармеецларның запас частьларында укый. Ул тиз арада популяр публицист-юморист булып китә. Юмор-сатира белән язылган декламацияләр бик җылы кабул ителә.

---

[1] Г. Камал. Әсәрләр. 2 том, Татгосиздат, Казан, 1951, 19 бит.
[2] «Эш», 44 сан, 4 июль, 1918 ел.
[3] «Эш», 74 сан, 12 октябрь, 1918 ел.
[4] Шунда ук, 67 сан, 3 октябрь, 1918 ел.

Г. Камал тәэсирендә «Эш» газетасы редакциясе әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрен яктыртуга бик нык игътибар итә. Газета редакциясендә еш кына шигырьләр укыла, әдәби бәхәсләр үтә. «Эш» газетасында инде танылган публицист-әдипләр Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи, Ш. Әхмәдиев, В. Шәфигуллин, Г. Кәрам, И. Кули, М. Сөбхиләр белән беррәттән әле үсеп килә торган яшь әдәби көчләр дә чыгыш ясыйлар. Аларга Г. Камалның йогынтысы гаять зур була. Яшь каләм ияләреннән К. Әмири, Б. Рәхмәт, А. Шамов, М. Максуд «Эш»тә актив катнашалар. А. Шамовның хәбәрләре, беренче хикәяләре бу газетада әледән-әле басылып тора. «Социалистик Татарстан» газетасының илле еллык юбилее уңае белән язган истәлекләрендә өлкән әдип А. Шамов «Эш» редакциясендә эшләүче Г. Камал турында олы ихтирам белән искә ала. Ул редакциянең «иң өлкән, иң абруйлы кешесе. Аның белән Вәли Шәфигуллин да, Ибраһим Кулиев та санаша. Әбез — килеп, итекләребез белән редакция идәнен таптап китүче яшьләр, аны күңелебез белән күкләргә күтәрәбез. Революциягә кадәр без, аның драма әсәрләрен укып, атналар буенча уйланып, саташып йөри идек. Хәзер без аның «Ишан Гали» имзасы белән язган шигырьләренә гашыйк. «Эш» газетасының буяу исе аңкып торган яңа санын кулыбызга алган саен, беренче чиратта, фронт хәбәрләре белән беррәттән аның шигырен күздән кичерәбез. Көн тәртибендә торган иң актуаль темаларга язылган, революциягә хезмәт итә торган шигырьләр алар. Ул шигырьләрне без авылларда, әдәби кичәләрдә декламация итеп сөйли идек, мәктәпләрдә балалардан ятлата идек, хәрби частьларда, аларны укытып, кызылармеецларның укый-яза белмәүләрен бетерә идек. Заманы өчен шундый кирәкле шигырьләр иде алар»[1].

1919 елның көзендә, 1920 елның кышында, Казанда утын кытлыгы, ачлык, тиф хөкем сөргән чакта, «Эш» редакциясе Г. Камал квартирасына күчә, аның белән бергә газета редакторы Вәли Шәфигуллин, җаваплы секретарь Ибраһим Кулиев шунда газета чыгару өчен материаллар әзерлиләр. Бу йортка хәбәрчеләр, авторлар, әдипләр редакция бинасына килгәндәй зур өметләрне тормышка ашыру юлларын эзләп киләләр.

«Эш» — «Кызыл Татарстан» газетасында, башка матбугат органнарында күренекле әдипләр, публицистлар, журналистлар эшли. Г. Камал белән бергә ул елларда «Кызыл Татарстан»да М. Җәлил, Ш. Камал, һ. Такташ, К. Мотыйгый-Төхвәтуллин, Г. Нигъмәти, М. Гали, С. Фәйзуллин, Г. Кутуй һәм башка бик күпләр иҗат итә. Алар арасында татар матбугатына нигез салучыларның берсе һәм алдынгы әдип Галиәсгар Камал якты маяк булып тора. Бу уңайдан әдәбият белгече Мөхәммәт Галинең Бөек Ватан сугышына кадәр Г. Камал турында язган сүзләрен искә аласы килә. «Публицистика һәм журналистика өлкәсендә,— ди ул,— Г. Камалның хезмәтләре аерата зур. Ул 1905 елдан башлап үлгәнгә кадәр (25 елдан артыграк вакыт) тоташ газета, журнал редакцияләрендә эшләп килә. Шул еллар эчендә газетачылык эше аның төп хезмәте булып санала... Татарның вакытлы матбугат эшчеләре арасында ул иң күп стажлыларыннан берсе. Аның газетачылык эшендәге хезмәтләре корректорлыктан һәм гади тәрҗемәчелектән башлап, редакторлыкка кадәр барып җитә»[2].

Г. Камал яшь каләм ияләренә, язучыларга, журналистларга ярдәм итә, аларның әсәрләре турында принципиаль фикерләрен әйтә торган була. Мондый олы йөрәкле булуын аның белән бергә эшләгән кешеләр ихтирам белән искә алалар.

«Кызыл Татарстан» газетасында эшләгән әдәбият белгече М. Гали үзенең Ш. Камал, Г. Камал, һ. Такташ белән бергә эшләве турында болай дип яза:

«Шәриф Камал 1925 елны Оренбургтан Казанга күчеп килеп «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә эшләргә керде. Ул вакытта мин дә анда эшли идем... Без үнләп кеше ишек кергәч тә зур бүлмәдә эшли идек. Атаклы язучы һәм шагыйрьләрдән Галиәсгар Камал, һади Такташ һ. б. лар да шул бүлмәдә эшли иделәр...

Бер көнне обед вакытында бөтен бүлмәдәге иптәшләр көлешеп, сөйләшеп утырганда, Галиәсгар Камал Шәриф Камалның һаман язулар актарып сүзгә катнашмый утырганын карап торды да:

---

[1] «Социалистик Татарстан», 7 март, 1968 ел. А. Шамов. «Яшьлек елларына сәяхәт».
[2] М. Гали. Г. Камал. Татгосиздат, Казан, 1941 ел, 111—112 битләр.

10*

— Хикәяләреңдә геройларыңны бик күп сөйләштерәсең син, Шәриф, ә үзең сүзгә катнашмыйсың. Әллә бөтен сүзеңне геройларыңнан сөйләтеп бетердеңме соң син?! — диде көлеп.

Ш. Камал бераз кызара төште дә:

— Дөрес, Галиәсгар абзый, мин сүзгә авыррак кеше, яңа күреп танышкан кешеләр белән тиз генә үзләшеп китә алмыйм. Сезгә бер ияләшеп китсәм, мине сүздән туктата да алмассың әле,— диде.

Такташ гадәттәгечә башын артка ташлап кычкырып көлде дә:

— Оренбургта вакыттан белəм мин Шәриф абзыйны. Бер сөйли башласа, дөрестән дә, сез аны туктата да алмыйсыз инде. Бигрәк тә сәнгать, әдәбият мәсьәләләренә кереп китсә, йөзә инде,— диде ул»[1].

Ә бусы Г. Камал турында журналист Фазыл Мөбәрәкшин истәлеге: «1926 елның язгы айлары. Газета һәм журнал редакцияләре хәзерге Ленин урамындагы почтага каршы йортка урнашканнар. Зур бүлмәдә «Авыл яшьләре» журналы секретаре Һади Такташ, «Кызыл яшьләр» газетасы әдәби сотрудниклары Габдрахман Минский, Исхак Хәйруллин, «Яшь ленинчы» газетасы секретарьлары Фатих Кәрим һәм бу юлларны язучыларның берсе Ф. Мөбәрәкшин яшьләр һәм балалар өчен газета, журнал чыгарабыз.

Бүлмәнең икенче ягында «Кызыл Татарстан» газетасы работниклары. Аның беренчесе — редакциянең консультация бүлеге (ул вакытта аны ходатай бүлеге дип йөртәләр) мөдире, Беренче рус революциясе елларында ук газета-журналлар бастырып чыгарган нашир, журналист, җырчы Камил Мотыйгый-Төхвәтуллин өстәле, икенчесе «Кызыл Татарстан» газетасының игъланнар бүлеге мөдире, драматург, өлкән журналист Галиәсгар Камал ага өстәле. Ул вакытта газеталарның тиражы аз, акча кереме җитәрлек түгел иде. Шуңа күрә игъланнар җыю һәм аларны эшкәртеп, кирәк булса русчадан тәрҗемә итеп чыгару редакциядә җаваплы эш, ул оста куллы журналистларга гына тапшырыла торган иде. Газета, шуны исәпкә алып, игъланнар бүлеге мөдире итеп журналист-язучы Г. Камалны куя.

Шулай, бер бүлмәдә картлар һәм яшьләр дусларча эшлибез. Һәр ике редакциягә кешеләр килеп тора. «Кызыл Татарстан» газетасына килгәндә Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи, Мөхәммәт Гали кебек язучылар безнең дә хәл-әхвәлләрне сорашалар, киңәшләр бирәләр. Үзебез дә редакциягә кергән теге яки бу материалда аңлашылмаган мәсьәләләр булса, Галиәсгар Камал агага мөрәҗәгать итәбез. Аның фикерен сорыйбыз. Ул безнең кебек редакция бусагасын әле генә атлап керүчеләргә ихлас күңелдән ярдәм итә иде.

Әле дә хәтеремдә, бер көнне Г. Камал белән К. Мотыйгый ашханәдән кәефсезләнеп кайтып керделәр. Алар ниндидер мәсьәлә турында бәхәсләшкәннәр булса кирәк, ике ара шактый кискенләшкән иде. Безгә үзләрен ничектер татулаштырырга кирәк иде.

«Камил ага, сезнең дә ике арага кара мәче кергән, кәефегез бозылган, без дә эшләп ардык, җырла әле, ичмасам, бераз ял итик»,— дип тәкъдим ясадык. Карыйбыз, Галиәсгар ага җырла да, җырлама да дип тә әйтми. Шулай да Камил ага җырларга булды. Түр тәрәзәне ачып җибәрдек, урам тулы халык. Камил ага калын һәм моңлы тавыш белән бер-бер артлы иске халык көйләрен җырлый. Почта янына җыелган халык төркемнәренең күзләре безнең тәрәзәгә юнәлгән. Җыр бетте, без генә түгел, урамдагы халык та кул чаба. Галиәсгар ага Камалның кәефе ачылды: «Әй, карт юләр, яхшы концерт бирдегез»,— дип көлеп җибәрде».

1929 елның язында республикабыз хезмәт ияләре, совет җәмәгатьчелеге Галиәсгар Камалның 30 еллык әдәби хезмәт бәйрәмен тантаналы төстә билгеләп үтә. Шул көннәрдә Германиядә көнбатыш империалистлары акчасына чыгарыла торган «Милли юл» редакциясе, халык дошманы Гаяз Исхаков җитәкчелегендәге татар буржуаз ак эмигрантлары — фашист ялчылары Г. Камалның 30 еллык хезмәт бәйрәменә «котлау» телеграммасы җибәреп, «тыкшынганнар» иде. Бу уңай белән Г. Камал «Кызыл

[1] М. Гали. Сайланма әсәрләр. Татгосиздат, Казан, 1956, 362—363 битләр.

Татарстан» газетасының 26 апрель санында аларга җавап биреп, протест хаты белән чыга. Менә ул:

«Шуның белән бергә, Германиянең Берлин шәһәрендә ирекле совет иленең дошманнары, контрреволюцияче татар ак эмиграциясе тарафыннан чыгарыла торган «Милли юл» журналы редакциясе тарафыннан җибәрелгән тәбрик телеграммасының үзем өчен тәбрик түгел, бәлки хурлык санаганымны әйтеп үтәргә тиеш табам. Бигрәк тә телеграмманың «Ирекле көннәр җиткәнгә тикле» дигән урыннары бу телеграмманың пычрак ният белән язылган икәнлеген күрсәтәләр. Минем 30 еллык хезмәтемнең 12 елы тулы ирекле Совет дәүләтендә үтте. Шул 12 елның киң мөмкинлекләр бирү ягыннан башкаларга чагыштырмаслык аермалары бар. Шуңа күрә Гаяз әфәнделәр көткән «ирек»нең минем өчен һич кирәге дә булмаганлыгын, үземнең андый «ирек»ләрнең чын дошманы булуымны белдерәм.

**Галиәсгар Камал.** Казан, 1929 ел, 24 апрель».

Г. Камалның газетада басылган бу ачык хаты фашист ялчыларына политик гаепләү акты, үзе яшәгән Совет властена мактау гимны иде. Татар революцион-демократик матбугатына нигез салучыларның иң өлкәне — Г. Камал Бөек Октябрь социалистик революциясенә, үз халкына гомеренең соңгы минутларына хәтле турылыклы булып калды.



Мөхәммәт Мәһдиев

# Г. КАМАЛ «ЙОЛДЫЗ»ДА

Гомеренең мәгълүм бер өлешен Г. Камал «Йолдыз» газетасында уздырды, газетаның хатлар, информация, әдәби бүлекләрендә катнашу белән бергә, ул «Йолдыз»да күп төрле темаларга мәкаләләр бастырды. Г. Камалның журналистлык таланты бу темаларда бертигез чагылмады, әмма басылган мәкаләләренең сан һәм күләм ягыннан күплегенә, зурлыгына игътибар итсәң, аның «Йолдыз»дагы эшчәнлеге аерым алып тикшерену сорый торган бер өлкә.

Бу мәкалә Г. Камалның «Йолдыз»да эшчәнлеген тулысы белән яктыртуны үзенә йөкләми — һәм бер мәкаләдә бу мөмкин дә түгел — бирелә Г. Камалның «Йолдыз»да басылган мәкаләләренә классификация ясап чыгу гына максат итеп куелды.

Яңа чыккан китапларга, куелган спектакльләргә матбугатта рецензия биреп баруны татар әдәбияты тарихында Галиәсгар Камал башлап җибәргән һәм бу жанрга нигез салган дип ышанып әйтә алабыз. Игътибар итик, бу жанр безнең көндәлек рухи тормышыбыз өчен хәзер гадәти бер хәлгә әйләнгән, хәзер бездә дисталәгән әдәбият тәнкыйтьчесе, дисталәгән театр тәнкыйтьчесе бар. Әмма 1907 елда — Г. Камал «Йолдыз»га языша башлаганда — аларның саны бик аз булган әле. Г. Камал «Йолдыз» битләрендә 1907 елдан башлап даими рәвештә рецензияләр рубрикасын алып бара. Әйтергә кирәк, бишенче-унынчы елларда татар әдәбиятына килеп кергән күп шагыйрьләр арасыннан Г. Камал, тәнкыйтьчеләрдән беренче буларак, Тукайны һәм Гафуриның аерып ала алды. «...Арада фәкать өч кеше калды. Боларның берсенә (Нәҗип Думавига) нинди тамга (проба) сугарга хәзергә мин булдыра алмыйм. Минем каршымда Габдулла әфәнде илә Габделмәҗит әфәнде алга чыгалар. Хәзерге көндә шагыйрь исемен йөртергә икесе дә лаектыр»,— дип язды Г. Камал [1].

Г. Камал газета битләрендә Тукайның һәр яңа китабына диярлек мөнәсәбәтен белдереп бара. Шагыйрьнең беренче китабына кергән шигырьләрен, бераздан «Алтын әтәч» поэмасын югары бәяли. «Алтын әтәч» турында Г. Камал болай дип яза: «Назымы гаять җиңел булу өстенә тасвирлары да гаять шагыйранәдер». [2]

[1] «Йолдыз», 1907, 201 сан.
[2] «Йолдыз», 1909, 406 сан.

Г. Камал әдәби тәнкыйтьтә объектив булуны күп нәрсәдән артыграк күрә. 1907 елда шагыйрь буларак М. Гафуриға зур бәя биргән һәм өмет баглаган Г. Камал, мәсәлән, аның кайбер проза әсәрләрен кабул итә алмый. «Хикәя,— дип яза ул М. Гафуриның 1908 елда чыккан «Үги балалар» исемле китабына рецензиясендә,— хикәялектән бигрәк заказ буенча «Милли шигырьләр» шикелле подрәт эшләнгән нәрсәгә бик ошыйдыр. Хикәя... ашыгып эшләнгән, авторы «тасвир кыйлган вакыйгаларның һәммәсенә үзенең фарзыны иярттедер»[1]. Югарыда китерелгән өзек Г. Камалда тәнкыйтьче өчен бик кирәкле сыйфат — әсәрнең авторына карата шәхси мөнәсәбәтләрдән югары тора алу сыйфаты булганлыгын күрсәтә. Дөрес, әдәби тәнкыйть эшчәнлегендә Г. Камалның аяк-кулын богаулап торган бер нәрсә бар иде: ул — тәнкыйтьченең әлегә мәгърифәтчелек карашлары басымы астында булуы. Әнә шуңа күрә ул кайвакытта үгет-нәсихәтчелеккә корылган дидактик әдәбият турында зур мактау фикерләре белән чыкты, шактый төссез, нәсихәтле әдәби әсәрләрне күкләргә күтәреп мактады. Күренекле журналист, әмма шактый урта кул әдәби әсәрләр авторы Ф. Кәриминең реализмнан бик тә ерак торган «Хыялмы, хакыйкатьме?» әсәре Г. Камал тарафыннан әнә шулай югары бәя алды. Г. Камал бу әсәрне: «Туя алмаслык ләззәт илә укылачак әсәрдер»[2],— дип бәяләде.

«Фатих әфәнде аз яза, ләкин матур яза», дип авторның художниклык сәләтенә югары бәя бирде. Шундый ук югары бәягә Ф. Кәриминең урта кул әсәре — «Мирза кызы» да лаек булды. Г. Камал үзенең рецензиясендә әсәрнең әдәби эшләнешенә, образлар системасына кагылып тормаган көе эчтәлеген мактады[3].

Драматургия тәнкыйтендә ул, киресенчә, дидактизмга каршы чыкты, реалистик әсәрләргә генә югары бәя бирде. Ярулла Вәлинең үгет-нәсихәтчелеккә һәм рационализмга корылган ясалма әсәре — «Ачлык кушты» драмасын Г. Камал каты тәнкыйть итте. Моңарчы, диде ул, «милләтче сала карчыклары илә философ дворниклар дөньяда күренгәне юк. Булмагач язмаска кирәк»[4].

Шул ук вакытта ул Г. Коләхметовның «Яшь гомер», Ф. Әмирханның «Яшьләр» драмаларын яклап чыкты[5]. «Арада иң сәламәт туганнарыннан берсе «Яшь гомер» исемендәге драма рисаләседер,— дип язды ул үзенең бер рецензиясендә.— Драманың тасвир җәһәтләре хили гүзәлдер. Икенче, өченче вә бишенче кисәкләре бик маһиранә тасвир иделгән. Хосусан, икенче пәрдәнең, гәрчә уенга тәгаллеге бик аз исә дә, хикәядәге каһарманнарның хәрәкәтләренә даир бу пәрдәдә дә һичбер нәрсә булмаса да, тасвиры бик табигый һәм вакыйга мәтабыйк рәвештәдер»,— дип, татар пролетар әдәбиятының беренче үрнәкләреннән булган «Яшь гомер»гә уңай бәя бирде.

Г. Камал Ф. Әмирханның «Яшьләр» драмасы персонажларының тормыштан алынган булуына да сокланып язды. Бүгенге көндә, диде ул, андый типларны Казанда табарга мөмкин. Шул ук вакытта, татар укучыларының үзенчәлекле-самими бер сыйфатын истә тотып, Г. Камал, «һәрбер язылган әсәрләрне «бу фәлән кеше хакында язылган икән дип тәэбил кыйлырга яратучылар» бу да фәлән бай балалары хакында язылган икән дип әйтерлек дәрәҗәдә якын тормыштан алынган типлардыр», дип күрсәтте[6].

Г. Камал «Йолдыз» битләрендә татар театрының репертуары, французча, русча, төрекчәдән тәрҗемә ителгән сәхнә әсәрләре («Галимнәр илә наданнар», «Саран», «Явызлыкның җәзасы») турында бик тәфсилле, тирән анализлы рецензияләр бастыра[7]. Театр репертуарына, сәхнә әсәрләренә багышланган рецензияләр белән бер рәттән, ул татар артистларының иҗат портретларын тудыруга да беренче омтылыш ясый. Мәсәлән, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина, Габдулла Кариев, Мортазин һ. б. артистларның сәхнә үзенчәлекләре, амплуалары турында фикер йөртә[8].

Г. Камалның әдәби-тәнкыйть эшчәнлегендә шулай ук «Гасыр», «Сабах», «Мәгариф», «Милләт», «Вакыт» һ. б. көтепханәләр чыгарган китапларга рецензияләр дә байтак. Рецензияләр арасында мәктәп дәреслекләренә (мәсәлән, Гали Рәхим

---

[1] «Йолдыз», 1908, 243 сан.
[2] «Йолдыз», 1908, 243 сан.
[3] «Йолдыз», 1907, 177 сан.
[4] «Йолдыз», 1908, 274 сан.
[5] «Йолдыз», 1910, 514 сан; 1912, 822 сан һ. б.
[6] «Йолдыз», 1910, 514 сан. Сүзлек: тәэбил кыйлу — юрау.
[7] «Йолдыз», 1907, 120 сан, 1909, 373 сан; 1915, 1530 сан.
[8] «Йолдыз», 1909, 408 сан.

чыгарган «Җир йөзе» дигән география дәреслегенә), балалар өчен уку китапларына («Балалар дөньясы») багышланганнары да бар.

Югарыда китерелгән мисаллар гына да Г. Камалны XX йөз башы әдәби тәнкыйтьчесе дип атарга тулы хокук бирәләр. Әмма Г. Камалның «Йолдыз»да эшчәнлеге күп кырлы, күп тармаклы булды. Ул үз чорының бер генә вакыйгасына да битараф калмады, иҗтимагый хәрәкәт, әдәби процесска кагылышлы һәр вакыйгага көнендә аваз салып, мөнәсәбәтен белдереп барды. Большевик Хөсәен Ямашев үлгәч, аның турында зур мәкалә белән чыгучы да Г. Камал булды.

Либераль газетада большевик Ямашевны күмү турында зур мәкалә бастыру — Г. Камалның гражданлык батырлыгы иде [1]. Бу — политик акт. Моның шулай икәнлеген аңлау кыен түгел: «Йолдыз»— Казан сәүдәгәрләренең, либераль байларның, либераль укымышлыларның ышанычлы органы булып килде. Әмма либераль редакторның кайбер якларыннан Г. Камал, Г. Тукай, Г. Ибраһимов кебекләр оста файдаландылар һәм «Йолдыз»да кыю-кыю гына мәкаләләр, әдәби әсәрләр бастырдылар. Ихтимал, бу кыюлыкта төп скрипканы Г. Камал уйнагандыр. Х. Ямашевның кинәт үлеме турында хәбәр итеп «Йолдыз» мондый сүзләр белән Ямашевка үз мөнәсәбәтен белдереп куя: «Хөсәен әфәнде бик аз кешеләргә генә мөяссәр була торган әхлакъ хәмидәләргә малик иде» [2]. Х. Ямашевның үлү хәбәре газетада басылган көннәрдә кайгы уртаклашкан хатлар белән редакцияне күмеп ташлыйлар. Редакция боларның бер өлешен баса һәм шуның өстенә бу турыда күп хатлар килүе турында да информация бирелә. Әмма «Йолдыз»ны укучылар арасында карагруһчылар, кадимчеләр, Печән базары каһарманнары да байтак бит әле. Алар да аваз сала: Хөсәен Ямашев турында язуыгызны туктатыгыз, дип дулап редакциягә хат язалар. Газета монысына да урын бирә [3]. Тик газета идарәсен гаепләргә ашыкмыйк: алдагы саннарында ул Тукайның мәгълүм шигырьләрен бастыра: «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре», «Янә бер хатирәм». Шулай итеп, большевик Хөсәен Ямашев турындагы материаллар газетада бер ай буена диярлек басылып баралар. Монда, әлбәттә, Г. Камалның тәэсире булгандыр дип уйларга тулы нигез бар.

«Йолдыз»да Г. Камал алып барган рубрикаларның тагын берсе — сәяси, халыкара мәсьәләләр турында. Газетаның 1912 елгы бер санында мондый хәбәр басылган: «Мөхәррирләремездән Галиәсгар Камал әфәнде Балкан вакыйгалары хакындагы хәбәрләрне тәхкыйкъ кыйлу өчен Төркия вә Болгария мәмләкәтләренә сәяхәткә китте» [4]. Төркиядә Г. Камал хәбәрче сыйфатында 1912 елның ахырыннан 1913 елның февраленә кадәр була. Кыска гына вакыт эчендә Г. Камал Төркиянең эчке хәле турында «Йолдыз»да унике подвал хәбәр бастыра. Бу циклда кадимчеләр өчен изге саналган Төркиянең кайбер «изгелекләрен» ачкан мәкаләләр дә бар. «Истамбул мәктүпләре» яки «Истамбул хәбәрләре» исеме белән басылган бу мәкаләләрнең берсендә хаҗга баручы мөселманнарга Төркиянең мөнәсәбәте турында языла. Мәгълүм булганча, эчке Россия мөселманнары хаҗ сәфәренә бару өчен Одессага җыелып, шуннан диңгез пароходына утырып, Стамбулга килгәннәр. Стамбулдан соң алар чит ил компанияләренең судноларына утырып, Искәндәриягә (Александрия) юл тотканнар. Аннан ком сахралары аркылы мәшәкатьле, озын юл башланган. Хаҗилар юлда зур газап кичергәннәр, йогышлы авырулардан җәфа чиккәннәр, шуның өстенә чүл гарәпләре — бәдәвиләр «үз диндәшләрен» кычкыртып талаганнар, чүл «пиратлары» өчен хаҗиларның акча янчыгы зур чыганак булган. Әмма хаҗиларны изге хәлифәлек — Төркия маклерлары да бик нык талаган. Стамбулга исән-имин килеп төшкәннәренә Россиягә кайту өчен билет алу кыен булган, Стамбул портында Россия хаҗиларын талап яшәүче бәтен бер катлау мөселман спекулянтлары барлыкка килгән. Төркиягә зур ихтирам саклаган «Йолдыз» газетасында Г. Камал әнә шулай пәрдәне күтәреп «дин кардәшләр»нең чын йөзен күрсәткән [5].

1907—1912 еллар арасында «Йолдыз»да Г. Камал күтәреп чыккан мәсьәләләр гаять күп. Болар нигездә көнкүреш темасына кагылышлы мәсьәләләр. Г. Камалның бу

[1] «Йолдыз», 1912, 808 сан.
[2] «Йолдыз», 1912, 806 сан. Сүзлек: мөяссәр — җиңел үтәлешле; хәмидә — мактаулы.
[3] «Йолдыз», 1912, 812 сан.
[4] «Йолдыз», 1912, 909 сан. Сүзлек: тахкыйкъ — мәсьәләнең дөреслеген табу.
[5] «Йолдыз», 1912, 912—924 саннар; 1913, 925—937 саннар.

циклдагы мәкаләләренең нигезендә аның мәгърифәтчелек карашлары ята. Казан татарларының көнкүрешен яхшырту, культуралы ялларын оештыру максатында ул чын күңелдән ышанып үгет-нәсихәт бирә, дәүләт һәм шәһәр Думаларына да билгеле бер чорда зур өмет баглый. Аныңча, укымышлы, һөнәрле кешеләр күбәйсә, һәм әнә шундый кешеләрне шәһәр һәм дәүләт Думаларына сайлый алсак, тормыш шактый үзгәрер, яхшырыр иде. 1907 елда, мәсәлән, аны Думага сайланачак депутатларның «сыйфаты» борчый. «Бу ел Думага кемнәрне сайлаячакмыз?» дип сорау куеп, ул болай ди: «Әмма гыйлем вә мәгърифәттән бу кадәр дә хасты булмаган кешегә фәкать урын тутыру вә һәр көн саен ун сум жалунья алып кайтып баю өчен генә барырга тырышып йөрү бөтен ислам милләте каршында бик зур оятсызлык вә әхлакъсызлыктыр».[1]

Ләкин мәгърифәтче Г. Камал зур өмет баглаган Думага хезмәт халкының артык исе китми, битарафлык күрсәтә. Г. Камал халыкның сайлау эшенә битараф булуына пошынып газетада чыгыш ясап карый,[2] ләкин үзе дә күрә — халык кына түгел, депутатлар үзләре дә Думага бөтенләй икенче күзлектән чыгып карыйлар. Думага өмет баглаган мәгърифәтче журналист бер үк вакытта Дума һәм аның депутатларыннан ачы рәвештә көлә башлый, фельетоннар яза. Бу жанрда ул реалистка әйләнә дә кала. Үзенең фельетоннарында Думаның беренче әһәмиятле мәсьәләләрне чишә алмавыннан, ә аның вәкилләренең эшсезлекләреннән, депутатларның үз кесәләрен генә кайгыртып йөрүләреннән көлә. «Депутатлар озату» дигән фельетонның кыскача эчтәлеге мондый: халык депутатларны озатырга җыела. Арада бер депутат — мулла икән. Озатучыларның кайберләре мулланың кайсы партиядән депутатлыкка сайлануын сорыйлар. Мулла, эсерлар, социал-демократлар, иттифакчылар партияләре турында ишеткәне дә булмаганлыктан, сорауга дөрес җавап бирә алмый. Уенда бары тик депутатлыкка ала торган ун сум акча гына булганлыктан, ул аларга:

— Ун, ун,— дип җавап бирә.

Депутат мулла поездда да юл буе депутат булып тору вакытында күпме акча алачагы турында гына уйлап бара[3].

«Эләкми калды» исемле фельетонында да шул ук мәсьәлә күтәрелеп, анда депутат булырга хыялланып йөрүче надан мулладан көләнә.

Г. Камал «Йолдыз»да «Үз һәлемездән» дигән рубрика ачып җибәрә. Монда ул татар тормышына кагылышлы бөтен хәлләрне теркәп бара, әйтик, сабан туйлар, җыеннар ничек узган, Мәкәрҗә ярминкәсендә сәүдәләр ничек бара һ. б. һ. б. Кайвакытта ул гадәти хәлләр эчендә кызыклы гына мәсьәләләр дә күтәрә: мәсәлән, 1909 елда ул шәһәр мәктәпләрендә укучы балалар өчен җәйге лагерьләр ачу кирәклеген күтәрә[4], ак чәчәк бәйрәме уздыруның әһәмиятен яклап чыга[5], шәһәр читләрендә бакчалар, дачалар салуны пропагандалый һ. б. һ. б.

Татарларны мәгърифәтле итеп күрәсе килү аңарда шул кадәр көчле ки, «Үз хәлемездән» дигән рубрика астында ул татар тормышының бөтен өлкәләрен яктыртып барган. Безгә, ди ул, табибе дә, архитекторы да, агрономы да, учителе дә кирәк. «Мөселманнар үз телләрен белгән мөтәхәссис укыган зыялыларга мохтаҗлар»[6]. Туган халкын белемле итеп күрү теләгеннән тормышка ашыруда Г. Камал конкрет чаралар да күрә: 1911 елда ул, мәсәлән, Ибраһим Кули белән берлектә русчадан «Бухгалтерия» дигән китап тәрҗемә итеп чыгара[7]. Шул ук вакытта ул татарлар арасыннан рәссамнар хәзерләү өчен күп көч куя. 1912 елда катай башкортларыннан рәсемгә сәләте булган егерме ике яшьлек Сабит Яхшыбаев дигән егет Казанга килеп чыга. Бу егетне Казандагы художество училищесына урнаштыру мәшәкатен Г. Камал тулысы белән үз өстенә ала. Училищега аны үзе алып бара, рәсемнәрен директорга күрсәтәләр. Кызганычка каршы, училищеда вакансия булмый. Яхшыбаевның рәсемнәренә гаҗәпкә калган училище педагоглары аңа якшәмбе дәресләренә йөрергә тәкъдим итәләр һәм 1913 елгы группага алырга вәгъдә бирәләр. Г. Камал борчылып яза: стипендия фонды җитәрлек түгел, егетне югалтмаска иде, иганә җибәрсәгез — «Йолдыз» идарәсенә,

[1] «Йолдыз», 1907, 81 сан.
[2] «Йолдыз», 1907, 167 сан.
[3] «Йолдыз», 1907, 94 сан.
[4] «Йолдыз», 1909, 392 сан.
[5] «Йолдыз», 1912, 821 сан. Ак чәчәк бәйрәме — туберкулез авыруыннан җәфа чигүче кешеләргә ярдәм итү максатында татар укымышлылары оештырган бәйрәм. Чәчәк сатудан килгән бөтен доход авыруларны дәвалау фондына киткән. Моны оештыруда, пропагандалауда Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ф. Агеев, С. Рәмиев кебек язучыларның роле зур булган.
[6] «Йолдыз», 1912, 901 сан.
[7] Бу китапның тәрҗемәсенә рецензия: «Йолдыз», 1911, 766 сан.

ди[1]. Г. Камал аның язмышын һәрчак күзәтеп бара, ярдәм итә. Сабит Яхшыбаев Казанда шулай профессиональ белем ала. Совет власте елларында ул Башкортстан Дәүләт театрында художник булып эшли.

Г. Камалның «Йолдыз»да даими алып барган мәсьәләләренең тагын берсе — мәктәпләр, һөнәр мәктәпләре мәсьәләсе. Игътибар итик, мәдрәсәләр мәсьәләсе, аларның укыту программалары турында түгел, ә нәкъ менә татар балаларын мәктәпләргә бирү, реальный училищеларга бирү турында. Г. Камал еллар буе газета битләрендә татар яшьләренең дөньяви мәктәпләрдә укуын пропагандалаучы булды. Аның белемле кадрлар белән генә фән-техника казанышларына ирешергә мөмкин дигән тирән ышанычы, әлбәттә, мәгърифәтчелек карашларыннан килә иде. Ләкин уку-укыту мәсьәләләренә Г. Камал революцион-демократик карашлары нигезендә якын килә. Татарлар арасында дөньяви фәннәргә, дөньяви мәктәпләргә игътибар артуны Г. Камал турыдан-туры 1905 ел революциясе нәтиҗәсе буларак бәяләде. «Инде хәзерге яшьләргә ни димәк кирәк,— дип яза ул 1907 елда.— Анлар тәрәккъый пәрвәрләрнең сүзләрен игътибарга алып, укырга керештеләр, гимназияләрдә, тиҗарәт мәктәпләрендә укучыларыбыз була башлады. Боларның микъдары елдан-ел арта бара һәм барачак. Быел бер мәктәптә ун бала укыса, икенче елда егерме-утыз булачагына һич шөбһә юк».

Г. Камал яшьләрнең дин мәктәпләренә түгел, ә фән нигезләрен өйрәнә торган һәм тәмамлап чыккач тормышта практик рәвештә кулланырга мөмкин булган мәктәпләрдә укуларын ялкынлы рәвештә яклый. «Бер Казан шәһәрендә генә дә гимназиягә, реальный вә тиҗарәт мәктәпләренә керергә хәзерләнүчеләр күп булган шикелле, университетка керергә хәзерләнүче шәкертләрнең күплеге күз алдымыздадыр. Хәмед улсын: быел әүвәлдәге дүрт-биш студент урынына университетта егермегә кадәр мөселман студентлары бар. Болар замананың уку заманы икәнен белеп иҗтиһад итеп, университетка кергәннәр. Укыйлар, кеше булып чыгарга чын күңел илә тырышалар»,— дип яза ул[2].

Шул ук вакытта Г. Камал уку йортларында укуның кыйммәт булуын, анда һәркемнең дә укырга хәленнән килмәве, укучы-студентларга ярдәм оештыру кирәклеге мәсьәләләренә туктала. «Университетта уку өчен никадәр акча кирәк. Шәкертнең үзен тоту, тәрбия итү өчен күп мәшәкатьләр илә акча таба алуы өстенә, уку хакы улярак университетка елына йөз сум акча түләргә кирәк. Көз көнендә уку хакының беренче нисфын түли алмаганнары өчен инде йөз студент университеттан чыгарылганнар иде»,— дип яза.

Г. Камал публицистикасында тагын бер проблема — яңа дәреслекләр, карталар бастыру, укытучы кадрлар әзерләү, матбугат эшендә реформа уздыру — хәрефләрне камилләштерү мәсьәләләре әнә шул тарихи бурычка бәйле рәвештә яктыртылды. 1906 елдан башлап, ягъни «Йолдыз»ның беренче саннарыннан алып, Г. Камал татар хәрефен, татар имлясын төзекләндерү, типография хәрефләрен камилләштерү өчен матбугатта көрәш алып бара, еш кына татар газеталарының теле турында матбугатта рецензияләр белән чыга, «тел берләштерү» теориясен тәнкыйтьли. Аның «Хәрефләр исլахы», «Имля вә хәреф мәсьәләсе», «Матбагачылыкта тәрәккъый» һ. б. исемдәге күп санлы мәкаләләр циклы басыла. Бигрәк тә ул типография шрифтын камилләштерү өчен көрәшә. Бу өлкәдә Кәримовлар матбагасында тәҗрибәләр алып барган Габделмәннән Рахманкуловның эшчәнлеген мактап чыга[3]. Хәрефләрне камилләштерүдән төп максат — мәктәп дәреслекләрен яхшырту. «Мәктәп китаплары никадәр гүзәл тәртип ителеп басылса, балаларның фикере тәрәккъый ителүгә шул кадәр үк ярдәм бирер. Шул сәбәпләрдән балаларга укытылачак китапларның җиңеллегенә, өслүб-стиль, ифадәләренең садәлегенә бик игътибар ителергә тиештер»,— дип яза.

Г. Камал оста каллиграф буларак үзе дә яңа хәрефләр иҗат итә. М. Гали аның турында: «Революциягә кадәр татар басма хәрефләре арасында матурлыгы ягыннан беренче урын тоткан типографияче Харитоновның бик күп кегельдәге хәрефләре — һәммәсе дә Г. Камал эше иде»,— дип яза[4].

[1] «Йолдыз», 1912, 877 сан.
[2] «Йолдыз», 1910, 513 сан. Сүзлек: тәрәккъый пәрвәр — прогресс яклы кеше; тиҗарәт — сәүдә; хәмед — мактау.
[3] «Йолдыз», 1912, 787 сан.
[4] М. Гали. Г. Камал. Казан, 1941, 129 бит.

Китап басу, китап сәүдәсе мәсьәләләренә килгәндә Г. Камал бу өлкәдә очрый торган комагайлыкны кыю рәвештә тәнкыйть итә. Бу темага язганда ул капиталистик җәмгыятьнең төп сыйфатын — табыш алу өчен аяусыз көрәш сыйфатын ачыклап бирүгә кадәр күтәрелә. Наширлар, ди ул, һәр вакыт «халык файдасыннан бигрәк, үз кесәләрен якын күрәләр» [1].

Нәшрият, дәреслекләр, һөнәр мәктәпләре белән беррәттән Г. Камал «Йолдыз»да татар хатын-кызларын укыту мәсьәләләрен дә даими күзгатып тора [2].

1905—1907 еллар революциясе чорларында социаль-демократик хәрәкәткә шактый зур өлеш керткән Г. Камал болай да патша властьларының ныклы күзәтүе астында яши иде. Унынчы елларга таба аның өстеннән күзәтү тагы да көчәя. Г. Камал «Йолдыз»ның кайбер саннарына үзе дә кул куеп чыгара. «Мовакыт мөхәррир Г. Камал» чыгарган саннар цензураны әсәртә. Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы полковник Калинин 1911 елда Казан губернаторына адреслап язган кәгазендә Г. Камал һәм Ф. Әмирханны «бер дә шиксез, чын панисламистлар» дип атый [3]. Шуның өстенә Г. Камал «Йолдыз» битләрендә Казан миссионерлары белән бәхәскә керә. Ул елларда Казанда «Сотрудник братства святого Гурия» журналы чыга башлый. Журналда мөселманнар адресына шактый кимсетүле сүзләр языла. Миссионерларның бу журналы Казан татарларының прогресска таба атлаган теләсә нинди адымын «иттихад ислам» дигән реакцион шаукымга бәйләп аңлата. Г. Камал журналның әнә шул юнәлештәге эшчәнлеген тәнкыйть итә. Аларча, дип яза Г. Камал, «Мөселманнар тарафыннан кечкенә генә бер мәктәп ачылу — иттихад исламнан. Тәрекче жөзьи генә бер китап нәшер ителсә — иттихад исламнан. Хасли генә бер җирдә бер газитә яхуд журнал нәшер ителсә, бер китап язылса, бер җәмгыять ясалса, бер мөкәррә исламияткә кайтса — һәммәсе дә иттихад исламнан. Бонлар мөселманнардагы һәрбер тәрәккъыятне, һәрбер уйгануны вә мәдәнияткә таба үрелүләрне иттихад исламга хитап кылалар. Бонларча, мөселманнарның аз гына күзләре ачылуы, мөселманнарның аз гына язу танулары, аз гына фән вә мәдәнияттән хәбәрдар булулары — һәммәсе бик зур зарардыр» [4]. Г. Камалның бу ялкынлы мәкаләсе миссионерларга тәэсир итми калмый. Казан епископы Андрей бу уңайдан Г. Камалга җавап белән чыга һәм кыргыз, башкорт һ. б. халыкларга карата татарлар миссионерлык политикасы алып баралар дигән уйдырма гаеп ташлый. Без, ди Андрей, мөселман татарларга дус. Алар гадел, диндар, хезмәт сөючән һ. б. һ. б. Ләкин ачыктан-ачык әйтәбез: татарлар чуашларны, мариларны, кыргыз, башкортларны — татарлаштыралар. Без менә шуңа каршы [5]. Епископ Андрей үзенең мәкаләсен «Йолдыз»да басуны таләп итә һәм «Йолдыз» моны тәрҗемә итеп тулысы белән баса. Әмма Г. Камал епископка тагын җавап белән чыга һәм татарлар арасында башка төрле халыкларга мөнәсәбәттә миссионерлыкның бөтенләй булмаганлыгын исбатлый. Кыргыз белән башкортка нәрсә тага алабыз без? дип сорый Г. Камал. Без бит алар белән болай да тәрҗемәчесез сөйләшәбез. «Миссионерлар мөселманнарның тәрәккъыйләрен хөкүмәт өчен зур зарар итеп күрсәтергә тырышалар. Гүя алар фикеренчә, мөселманнар укыйлар һәм тәрәккъый итәләр дә, берләшеп хөкүмәткә әллә нинди зарар китерәләр, имеш. Мөселманнарның аңлы булуларыннан, мөселманнарның агаруыннан вә мәдәниятеннән хөкүмәткә файда гына хасил булачактыр» [6]. Г. Камал моның белән күп гасырлар Россия составында яшәгән татарларда уртак ватан төшенчәсенең инде ныклап урнашуын, үз милләтенең үсеше дәүләт, ватан өчен дә файдалы булуын әйтергә тели.

Г. Камал «Йолдыз»да, гомумән, патша властьларын шикләндерә торган мәсьәләләрне аз күтәрмәде. 1912 елда ул цензура һәм жандармерияне сагайта торган исем — Ш. Мәрҗани исемен күтәреп чыга. Мәрҗанинең тууына йөз еллыкны билгеләү өчен татар укымышлылары хәзерлек алып барган чор була бу. Г. Камал үзенең «Дамелла Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең намен таәбәд итү хакында» дигән мәкаләсе белән бу әзерлек процессында башлангыч адымны ясый [7]. Ахырдан Ш. Мәрҗани юбилее

---

[1] «Йолдыз», 1912, 13 май саны.
[2] Мәсәлән, «Йолдыз», 1907, 170 сан; 1912, 893 сан һ. б.
[3] ТАССР Дәүләт үзәк архивы, 199 фонд, 1 тасвирлама, 1961 эш, док. 10.
[4] «Йолдыз», 1910, 520 сан. Сүзлек: иттихад — союз; жөзьи — вак, кечкенә; мөкәррә — кин күцелле; хитап — юнәлтү.
[5] «Сотрудник братства святого Гурия», Казань, 1910, 22—23 саннар.
[6] «Йолдыз», 1910, 535 сан.
[7] «Йолдыз», 1912, 798 сан. Сүзлек: нам — исем; таәбәд итү — мәңгеләштерү.

мәсьәләсе туп-туры губерна жандармерия идарәсе карамагына килеп керә. Юбилейны тыеп кына калмыйлар, бәлки Мәрҗанинең улы Борһанетдин Мәрҗани квартирасында Мәрҗанине искә алу мәҗлесендә катнашкан Г. Ибраһимов, Ф. Агеев һ. б. язучыларның бу мәҗлестә нәрсә сөйләүләре белән кызыксынып, әллә никадәр тикшерү эше алып баралар.



*
* *

Югарыда күренгәнчә, Г. Камал «Азат», «Азат халык» газеталары ябылганнан соң да әдәби тәнкыйть, публицистикада демократик юнәлештә зур көрәш алып бара. Моның өчен ул либераль юнәлештәге «Йолдыз» газетасын файдалана. Социал-демократлар белән тыгыз бәйләнештә булган «Азат халык» газетасыннан соң кинәт либераль юнәлештәге «Йолдыз» газетасына язышу беренче карашка гаҗәбрәк күренүе мөмкин. Бу хәл Г. Камалның замандашларына да сәер тоелган. Габдулла Тукай бу уңайдан «Уклар» журналында «Казанда никах мәҗлесе» дигән фельетон бастырып чыгара. Чыннан да, революцион-демократик позициядә торган Г. Камал «Йолдыз»га ничек күчә соң? Чөнки реакция башлану белән «Азат халык»ны дәвам иттерү өчен объектив мөмкинлекләр калмый. Һәм Г. Камал мөмкин булган матбугат шартларыннан — яшәп килүче «Йолдыз»дан булдыра алганча файдалана, үткен каләме белән татар хезмәт ияләренең хокуклары һәм демократик театр, әдәбият өчен даими көрәш алып бара.

Г. Камал хезмәт сөючән һәм тыйнак журналист иде. Үзе язышкан «Йолдыз»да теләсә нинди каләм иясенең юбилейларына әллә ничә мәкалә, әллә ничә сан багышлаган хәлдә, Казан җәмәгатьчелеге зурлап билгеләгән үзенең «әдәбиятка хезмәт кыла башлавына ун ел тулу мөнәсәбәте илә» «Йолдыз»да шау-шу куптармады. Бу юбилей турында нибары бер-ике информация һәм Г. Тукай белән Г. Сәгъдинең ике мәкаләсе басылып чыкты [1]. Г. Камал үзе исә гади генә бер шигыреннән башка («Дустыма») бу көннәрдә газетада күренмәде. Хәер, эшчәнлек һәм тыйнаклык аның совет чоры иҗатында да төп сыйфатлар булып калды.

**Назим Ханзафаров,**
филология фәннәре кандидаты

# ГАРИЗАЛАР НИ СӨЙЛИ?

Ленинградта Үзәк дәүләт тарих архивындагы документлар арасында Г. Камал кулы белән язылган өч гариза бар. Дөрес, аларның тик берсендә генә әдипнең үз имзасы куелган. Шулай да без калган икесен дә Г. Камал гаризалары дип карый алабыз. Чөнки алары да аның кулы белән язылганнар, аның теләген, үтенечен белдерәләр, аның эшчәнлеге нәтиҗәсе булып торалар.

Г. Камал истәлекләрендә мондый юллар бар: «...1905 ел җитә. Шәһәрнең «азган-тузган» яшьләре театр артындагы урамда, приказчиклар клубында, спектакль куялар. Менә шуннан соң миндә ничә ел томаланып яткан дәрт яңадан кузгала. «Беренче театр»ны язып, үз тормышымны сәхнәгә чыгарып күрсәтәм. Театр куючылар көчәя, ләкин пьесалар юк...» [2]

[1] «Йолдыз», 1910, 605, 613, 630, 700 саннар.
[2] Яза башлавым тарихы. Г. Камал. Әсәрләр, Таткитнәшр, Казан, 2 том, 1951, 267 бит.

Мәгълүм булганча, татар театрының туган көннәре бу. Аның хәл ителмәгән мәсьәләләре, «юк»лары хисапсыз. Шуларның иң мөһимнәреннән берсе — патша цензурасыннан рөхсәт алу. Пьеса китап булып басылган булса да, аны сәхнәдә кую өчен махсус рөхсәт булырга тиеш. Ә ул рөхсәт, төрле сылтаулар белән, бик саран бирелә. Социаль эчтәлекле, сыйнфый юнәлешле үткенрәк пьесаларның язмышы аеруча аянычлы. Менә шул рөхсәтне сорап язылган гаризалар арасында Г. Камал үтенече дә бар. Ул рус телендә, тәрҗемәсе болай:

«Матбугат эшләре буенча Баш Идарәгә
Галиәсгар Галиәкбәр улы
Камалетдинов
үтенече

1890 нчы елда басылган цензура һәм матбугат турындагы уставның 85 нче статьясе нигезендә, «Бәхетсез егет» исемле татар телендәге басма пьесамны ике экземплярда җибәреп, аны театрларда кую өчен Матбугат эшләре буенча Баш Идарәнең рөхсәт бирүен түбәнчелек белән үтенәм.

Казан, 25 сентябрь, 1907 ел.

Китаптагы «Г. Камал» дигән язу — минем псевдонимым.

PS Миңа түбәндәге адрес буенча хәбәр итүегезне түбәнчелек белән үтенәм: Казан, Поперечно-Георгиевская ур., Кудряшев йорты, Галиәсгар Камалетдинов»[1].

Биш айдан соң, 1908 елның 14 январенда, бу әсәрне сәхнәдә куярга рөхсәт бирелә[2]. Бик ашыгып бирелмәсә дә, күп драматургларга зур шатлык китерер иде бу рөхсәт. Берничә еллар буе үтенеп тә җавапсыз калган, яисә «кую өчен уңайсыз», дигән «инсафлы» сүзләргә юлыккан авторлар күп бу чорда. Берәүләр цензура һәм матбугат турындагы четерекле уставны белмәү, сакламау нәтиҗәсендә читкә кагылалар, икенчеләр Герб маркасы өчен түләнмәгән дип җавапсыз калдырылалар. Саный китсәң, күп мондый сәбәпләр. Тәвәккәлләр шулай да җаен тапканнар: Баш Идарәдән рөхсәт көтеп тормый куелган пьесалар да байтак булган бу елларда.




*Алма-Ата шәһәрендә яшь һәвәскәрләр тарафыннан уйналган «Банкрот» спектакле игъланы. (Х. Гобәйдуллин архивыннан.)*

Шул елларда Казанда оештырылып, актив рәвештә культура-агарту эшләре башлап җибәргән «Шәрык клубы» пьесаларга рөхсәт алу мәсьәләсендә үзенең игелекле эшен башкарырга омтыла: драматургларга цензурадан рөхсәт алу тәртипләрен аңлату өстенә, күп кенә авторларның әсәрләрен икешәр нөсхәдә җыеп Матбугат эшләре

---

[1] ЦГИА СССР (Ленинград), 776 фонд, 25 тасвирлама, 916 саклану берәмлеге.
[2] Шунда ук.

буенча Баш Идарәгә җибәрә, клуб исеменнән аларны сәхнәдә куюга оешкан төстә рәсми рөхсәт сорый.

Г. Камал бу чор турында болай дип яза: «Бер заман «Шәрык клубы» ачыла. Мин клубта старшиналарның берсе. Клубны зурайтыр өчен, башында Сәхипҗамал Гыйззәтуллиналар тора торган «Сәйяр» труппасы яллыйбыз. Бер куйган пьесаны ике куйсаң, халык килми. Сәгыйт Рәмиевләр, Ярулла Вәлиевләр, Идрис Богдановлар язган пьесалар гына җитми, халык һаман яңадан-яңа пьесалар сорый. «Уйнаш»ны да язып карыйм, «Дәҗҗал» да языла, башкалары да. Труппа һаман да туймый...»[1]

Менә шушы вакытларда Г. Камал кулы белән түбәндәге үтенеч тә языла. Дөрес, Г. Камалның үз әсәрләренә дә рөхсәт соралганга булса кирәк, аңа клубның рәисе И. Терегулов кул куйган (башка төстәге кара белән).

«Матбугат эшләре буенча Баш Идарәгә
Мөселманнар җәмгыяте
Казан шәһәренең «Шәрык клубы»
үтенече

1890 нчы елда басылган цензура һәм матбугат турындагы уставның 85 нче статьясе нигезендә, төрле язучыларның икешәр экземплярда әсәрләрен җибәреп, «Шәрык клубы» Матбугат эшләре буенча Баш Идарәдән түбәндәге пьесаларны сәхнәдә куярга рөхсәт бирүен түбәнчелек белән үтенә:

1. «Бер сәгатьлек хатын» («Невеста на час»), фарс, 1 пәрдәдә. Д. А. Максфильд әсәре, Г. Сәйфелмелеков тәрҗемәсе.

2. «Кыямәт» («Страшный суд»), комедия, 2 пәрдәдә.

3. «Хатыннар эше» («Бабье дело»), комедия, 2 пәрдәдә. В. Апанаев тәрҗемәсе.

4. «Беренче театр» («Первый театр»), водевиль, 1 пәрдәдә. Г. Камал әсәре.

5. «Бүләк өчен» («Ради подарка»), водевиль, 1 пәрдәдә. Г. Камал әсәре.

6. «Низамлы мәдрәсә» («Реформированное училище»), комедия, 1 пәрдәдә. С. Рәмиев әсәре.

7. «Яшьләр» («Молодежь»), пьеса, 3 пәрдәдә. Ф. Әмирхан әсәре.

8. «Уйнаш» («Разврат»), драма, 3 пәрдәдә. Г. Камал әсәре.

9. «Җиңел хезмәт» («Легкая нажива»), драма, 4 пәрдәдә. Л. Мостафа тәрҗемәсе.

10. «Чун там» («На чем окончится»), комедия, 1 пәрдәдә. К. Бәкер әсәре.

11. «Шәкерт һәм яшьләр» («Ученик и молодежь»), пьеса, 4 пәрдәдә. Г. Терегулов әсәре.

12. «Мөгаллим» («Учитель»), драма, 5 пәрдәдә.

13. «Көнче ир» («Ревнивый муж»), комедия, 3 пәрдәдә. Ф. Б. Ратковский әсәре, Г. Б. тәрҗемәсе.

14. «Зөләйха берлә Фатыйма» («Зулейха и Фатима»), пьеса, 3 пәрдәдә. Идрис Богданов әсәре.

15. «Югалган хатын» («Пропавшая женщина»), комедия, 2 пәрдәдә. И. Богданов әсәре.

16. «Җәмгыять» («Собрание»), комедия, 2 пәрдәдә.

Рәис (имза) И. Терегулов.

Посылкада «Шәрык клубы»ның бер экземпляр уставын җибәрәбез»[2].

«Шәрык клубы»ның бу үтенеченә нинди җавап булганлыгы билгеле түгел. Ул әсәрләргә шуннан соң да кабат-кабат рөхсәт сорала.

«Шәрык клубы» үрнәгендә Петербургка башка шәһәрләрдән дә посылкалар, үтенечләр җибәрелгән. Аларның күбесендә Г. Камал әсәрләре телгә алына. Мәсәлән, 1911—1912 нче елларда Троицк шәһәрендәге «Троицкое общество поощрения Асценического и музыкального искусства» дигән җәмгыять идарәсе (рәисләре — Аитов һәм Рахманкулов, секретаре — Еникеев) бер мәртәбә 27 пьесага һәм 21 шигырь китабына (шигырьләрен сәхнәдән уку өчен), икенче мәртәбә 52 пьеса һәм шигырь китапларына рөхсәт сорый. Алар арасында Г. Коләхметовның «Яшь гомер», Г. Камалның «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Уйнаш», «Бәхетсез егет», Ф. Әмирхан-

[1] Яза башлавым тарихы. Г. Камал. Әсәрләр. Таттосиздат. Казан, 1951, 2 том, 267 бит.
[2] ЦГИА СССР (Ленинград), 776 фонд, 25 тасвирлама, 991 саклану берәмлеге, 3 бит.

ның «Яшьләр», С. Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин», «Низамлы мәдрәсә» һ. б. пьесалары бар. Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, Н. Думави, З. Бәшири, С. Сүнчәләй шигырь китаплары биредә үзәк урынны алып торалар[1].

Г. Камал пьесалары шәкертләрнең үзешчән театр түгәрәкләре репертуарларына да бик теләп кертелгән. Бу уңайдан 1913 елның 1 февралендә цензурага җибәрелгән документ игътибарга лаек. Астраханьның 13 нче зур мәчете каршындагы рус классы Зур Исад мөселман мәхәллә мәктәбе рәисе Гомәр Сәйфетдинович Кугушев үзенең үтенечендә болай дип яза: «Минем тарафтан югарыда телгә алынган мәктәптә укучы малайларыбызның һәм кызларыбызның дәресләрдән тыш вакытларда уйнаулары һәм күңел ачулары өчен кирәк булган дүрт китапны җибәрәм. Югарыда аңлатылганча, С.-Петербург драма цензурасы бүлегенең безнең укучы малайларга һәм кызларга җибәрелгән китаплар буенча уеннар уйнарга рөхсәт итүен түбәнчелек белән үтенәм»[2].

Сүз «Аулакта көрешү», «Безнең шәһәрнең серләре» пьесалары турында бара. Җавапта Г. Камал әсәрен куярга рөхсәт бирелми[3].

Чиләбе музыка-драма җәмгыятенең мөселман бүлегеннән килгән үтенечләрдә дә Г. Камал әсәрләре еш кабатлана. Бу бүлек рәисе Гариф Борнаев (аның иптәшләре Фаттах Маннафович Латыйпов, Х. Җамалетдинов, Ф. Сәйфетдинов, Х. Еникеев, Ш. Самиль, М. Мөхәммәтшин, А. Хәмзинов, Фаретдинов һ. б.) 1913 елның 19 февралендә язган үтенечтә «Бәхетсез егет», «Беренче театр», «Безнең шәһәрнең серләре», «Бүләк өчен» пьесалары бар, Ф. Әмирханның «Яшьләр», Г. Коләхметовның «Яшь гомер», М. Фәйзинең «Яшьләр алдатмыйлар» әсәрләре дә кертелгән[4]. Г. Борнаевның 1914 ел 7 декабрь үтенечендә боларга «Дәҗҗал», «Уйнаш», «Банкрот»та өстәлә[5].

Г. Борнаев үтенечләренә 1913 елның 24 июнендә драма цензурасы биргән җавапта (№ 8286) «Яшьләр алдатмыйлар», «Безнең шәһәрнең серләре» кире кагыла — «куярга уңайсыз» дип әйтелә[6].

Ленинград архивында Г. Камалның үз кулы белән язылган өченче үтенече бар. Монысы башкаларыннан үзенең серлелеге белән аерылып тора. Полиция, цензура игътибарыннан читләшү өчен булса кирәк, бу үтенеч Г. Кариевнең туган авылыннан бер кеше исеменнән язылган.

**«Матбугат эшләре буенча Баш Идарәгә С.-Петербургта**
**үтенеч**

**Мөселман театр сәнгате сөючеләр соравы буенча, Сез галиҗәнабләргә үтенеч белән мөрәҗәгать итәбез: 1913 елның 28 октябрендә, дүшәмбе көнне, Гоголь урамында, № 20, Заславский залында Г. Камалның «Уйнаш» яки «Измена супруга» исемле драмасын куярга безгә рәсми рөхсәт бирергә мөмкин дип таба алмассызмы!**

**Казан губернасы, Чистай өязе, Иске Әлмәт волосте, Мураса авылы крестьяны Мирзаһит Камалов»**[7].

Тексттагы пьеса исеме (гарәп хәрефләре), Г. Камалның башка кульъязмаларындагыча, калын итеп, ясап-ясап язылган. Үтенеч һәм бер экземпляр пьеса 1913 елның 25 октябрендә Баш Идарәгә кергән. Җавап турында мәгълүмат юк.

Архив материаллары белән якыннан танышу, Г. Камал иҗатын һәм тормышын тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итү белән бергә, татар театры һәм драматургиясе тарихының кайбер мәсьәләләре турында уйлануларга да этәрә. Мәсәлән, Октябрь революциясенә кадәрге татар театры репертуарының һәм драматургиясенең идея югарылыгы, сыйнфый-социаль йөзе турында сүз йөрткәндә чынлыкта сәхнәгә менгән әсәрләргә генә таяну, драматургларның һәм режиссерларның чын теләк-үтенечләрен тиешенчә исәпкә алмау әле һаман да сизелә. Патша цензурасына килгән сәхнә әсәрләре белән театрлар репертуарын чагыштырсак, аерма шактый зур — беренчесе идея, проблематика һәм сыйнфый, социаль үткенлек ягыннан караганда

[1] Шунда ук, 1004 саклану берәмлеге, 29 бит.
[2] ЦГИА СССР (Ленинград), 776 фонд, 25 тасвирлама, 1058 саклану берәмлеге, 1 бит.
[3] Шунда ук, 3 бит.
[4] ЦГИА СССР (Ленинград), 776 фонд, 25 тасвирлама, 1058 саклану берәмлеге, 4 бит.
[5] Шунда ук, 1116 саклану берәмлеге, 15 бит.
[6] Шунда ук, 1058 саклану берәмлеге, 12 бит.
[7] ЦГИА СССР (Ленинград), 776 фонд, 25 тасвирлама, 1058 саклану берәмлеге, 23 бит.

шактый өстен торуын күрербез. Биредә драматургларның цензура таләпләренә күпмедер яраклашырга мәҗбүр булуларын да истән чыгармаска кирәк.

Мәсәлән, театр тарихы китабында «Сәйяр» труппасының 1914—1915 еллы сезон репертуары турында сүз барганда, җитдирәк әсәрләр телгә алынганнан соң, болай диелә: «Шулай ук, «Гыйшык бәласе», «Имчеләр корбаны», «Кызлар шулай кызык итәләр», «Безнең заман», «Табылдык», «Кечкенә сугыш», «Качкыннар», «Кыз сорау», «Денщик Гали», «Каенана өйдә булса...», «Көнче ир», «Хат болгатты» кебек җиңелчә пьесалар да куела. Бу сезонда күп кенә яңа әсәрләр күренсә дә, зур эз калдырырлык спектакльләр аз була. Куелган проблемалары һәм аларның чишелеше ягыннан Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» исемле драмасы аерылып тора»[1].

Проблемалы әсәрләр дигәннән. Проблеманы авторлар да, театр да яратмый түгел. Әйтик, 1910 елның 23 мартында театр һәвәскәрләренең (Г. Ильясов, М. А. Төхфәтуллин, Х. Төхфәтуллиннарның) Семипалатинск губернаторына язган үтенечләрендә 14 әсәр арасында Г. Камалның «Беренче театр», «Бүләк өчен» комедияләре белән бергә, Г. Колахметовның «Яшь гомер» драмасын да куярга рөхсәт сорала[2]. Губернаторга Казанда бу әсәрләр куела дип тә аңлатыла. Әмма аннан җавап алынмый. Губернатор исә Баш Идарәдән киңәш сорый. Цензор В. Д. Смирновның мондый әсәрләргә мөнәсәбәте ачык. Ул 1909 елда ук «Яшь гомер» турында үз сүзен әйткән инде: «Бу — эшче пролетариатка, аның, ниндидер митингларга йөреп, анда ораторланучы, аннары участок һәм төрмәләрдә төрле сроклар тутыручы, шуның өчен зарланучы, әмма үзләренең ниндидер хак эшләре җиңеп чыгачагына, гадел, намуслы уй-теләкләренең тормышка ашачагына ышанучы чынлыктагы һәм хыялдагы җитәкчеләренә (коноводам) дифирамбтан башка нәрсә түгел.

Мондый социаль күренешләрнең татарлар арасында булу дәрәслеген арттыру өчен булса кирәк, пьесага рус пролетарий-эшкечеләре дә кертелгән. Күренеп тора, автор уенча, монысы «бөек рус язучысы Максим Горькийга» иярү дип аңланырга тиеш. Шул турыда китап тышлыгында тантаналы рәвештә билдерү дә ясалган.

Бу драма сәхнәдә һичнничек тә куела алмаслыгын нигезләү өчен тагын да дәлил китереп торуның кирәге булырмы. Пьесада пролетарийның, гади әйтсәк — йолкышларның, мөлкәтле класска каршы берниндн сәбәпсез дошманлыгы уятыла. Әлегә әшәке провокаторларның социалистик тенденцияләренә катнашлыклары аз булган татар халкына шундый фикерләр үткәрелә. Гаҗәп, бу басма әсәр дөньяга чыкканда ук урындагы цензура игътибарына очрап, күренгәч үк кулланыштан алынмаган»[3].

Проблемалы әсәрләр менә шундый «кайгыртучан» цензор бәяләве аша үтәргә тиеш булганнар. Ә «җиңелчә»ләренә юл ачык. Күп билдекле цензор, мәсәлән, Мольер әсәре нигезендә Т. Кассап тарафыннан язылган «Пенти Хәмит» тәрҗемәсе «Саран» (төрекчәдән Г. Камал тәрҗемәсе) комедиясен бәяләгәндә: «...Мондый диалог рәвешендәге чепуханы сәхнәдә куярга каршылык юк», — дип, йомшак әсәрләргә дигән мөһерен бик юмарт басып куя[4]. Кызганычка каршы, репертуарның озак еллар буе шушы иләк аша үтүе нәтиҗәсендә ул чорда җиңелчә әсәрләр шактый үрчеп калганнар.

Тарих архивы документлары «Г. Камал тәрҗемәләренең язмышлары турында да ачык сөйли. 1916 елда Г. Кариев тарафыннан язылган үтенечтә, мәсәлән, Г. Камал тәрҗемә иткән «Ревизор» (Н. Гоголь), «Ирексездән табиб» (Мольер), «Бер сәгатьлек адвокат» (русчадан) әсәрләрен куярга рөхсәт сорала[5]. Әмма патша цензурасының 1916 ел 16 сентябрь җавабында «Ревизор», «Мещаннар» (Г. Кәрам тәрҗемәсе) кебек классик әсәрләрне сәхнәләштерү рөхсәт ителми. Театр осталарының күп көч сарыф итүе, зур тырышлыгы белән генә мондый әсәрләрнең кайберләре татар сәхнәсенә менә.

Беренче карашка кыска гына язылган гади үтенечләр булып күренсәләр дә, Г. Камал гаризалары театр һәм драматургиябез тарихына караган җитди мәсьәләләрне ачыклауда зур әһәмияткә ия документлар булып торалар. Эзли китсәң, илебез архивларында мондый кыйммәтле язмалар байтак бит әле.

[1] Татар совет театры (очерклар). Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1975, 30—31 битләр.
[2] ЦГИА СССР (Ленинград), 776 фонд, 25 тасвирлама, 976 саклану берәмлеге.
[3] ЦГИА СССР (Ленинград), 776 фонд, 26 тасвирлама, 85 саклану берәмлеге.
[4] Шунда ук, 776 фонд, 26 тасвирлама, 85 саклану берәмлеге, 53 бит.
[5] Шунда ук, 776 фонд, 25 тасвирлама, 1207 саклану берәмлеге, 3 бит.

Риза Ишморат

# ТАЛАНТЫ АЛДЫНДА БАШ ИЕП...

Бик еш искә алам мин аны. Тукай дисәң дә, янәшәсенә Галиәсгар абзый килеп баса. Габдулла Кариев дисәң дә — ул. Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин һәм татар әдәбияты, драматургиясе, театр сәнгатенең һинди генә күренекле эшлеклесен күз алдына бастырсаң да, янәшәләрендә аларның һәркайсы белән якыннан аралашып яшәгән, көрәшкән, иҗат иткән Галиәсгар Камал тора.

Аның белән шәхсән танышлыгым Казанга килеп берничә ел үткәч кенә башланды. 1927 елның беренче айлары иде. Мин инде бу вакытта Татар дәүләт академия театрында эшли башлап, үземнең ике сатирик комедиямне һәм Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» исемле комедиясен сәхнәләштергән идем. Димәк, үзем дә театр дөньясына борын төртеп килә торган бер яшь иҗатчымын. Көннәрнең берендә, минем пьесаларга һәм сәхнәгә куйган спектакльләремә рецензияләр язган журналист Мөхәммәт Парсин белән бергәләп, «Кызыл Татарстан» редакциясенә килеп кердек. Ул чакта редакция хәзерге Ленин урамы, 21 номерлы йортта иде. Икенче катта яхшы ук зур гына бүлмә. Анда дүрт-биш кеше — редакциянең әдәби хезмәткәрләре. Шулар арасында, бер як кырыйдарак урнашкан өстәл артында, арыган, йончыган кыяфәттәрәк, беренче карашка кырык биш-иллеләр тирәсендәрәк булыр, бер журналист эшләп утыра. Алдындагы кульъязманы игътибар белән укый, төзәтә. Башка өстәлләр артында утыручылар да шулай. Эш кешесен эштән аеру, бигрәк тә ашыгыч йомышың булмаганда, бик уңайсыз. Минем моңа кыюлыгым җитми. Шулай да юлдашым Мөхәммәт Парсин кыюрак булып чыкты. Әлеге абзый белән кул биреп исәнләште дә, миңа карап:

— Менә таныш бул, татар драматургларының агасы да, атасы да — атаклы Галиәсгар Камал абзаң шушы булыр инде,— дип ярып салды.

Мин алгарак атлап баш идем, кул биреп күрештем дә шикелле. Ул арада Парсин Галиәсгар абзыйга минем кемлегемне әйтте. Мактаган булып, йөземне әй, кызарта, әй, кызарта... Имештер, үсеп килә торган өметле яшь драматург, режиссер мин. Новатор. Гадел Кутуй, Әсгать Мәҗитләр белән бер булып, иске реалистик театрны җимереп, яңа театр тудырабыз дип йөрүче актив сулфчыларның берсе — Риза Ишморатов.

— Ә-ә... укыдым, укыдым синең мәкаләләрне. Шул мөгез чыгаручыларның берсемени инде бу егет?— дип, Галиәсгар Камал миңа тагын бер кат күз кырые белән генә карап куйды.

Галиәсгар абзыйның «мөгез чыгаручы егет» дигән сүзе һәм шулай күз кырые белән генә сөзеп каравы реалистик театрга тел тидергәнем өчен шелтәләве сыман тоелды миңа. Бу минутларда башымнан төрле уйлар кичте.

Ләкин нәкъ шушы минутларда тагын бер могҗизалы хәл булып алды. Саубуллашып китә башлагач, Галиәсгар абзый салмак кына торып аягүрә басты да, миңа карап:

— Эшләреңдә уңыш телим, Ишморат энем, мөгез чыгарсаң чыгар, ул һәрбер яшь кешегә хас нәрсә, тик бердәнбер киңәшем шул: реаль тормыштан, реалистик сәнгатьтән аерылма. Реалистик сәнгать, театр бер яңалыкка да каршы түгел. Бер яңа

мөгезгә дә дигәнем. Киресенчә, безнең бүгенге яңалык, социализм өчен булган тырышлык, реализмны таләп итә. Халыкка бары да ачык, аңлаешлы булырга тиеш,— диде.

Сүзләрендә акыл, җитдилек, ә йөзе ачык, көләч, күзләре елмая... Мыегы да юк иде, ахры, ә шулай да ул хәзер минем хыялымда күптәннән бирле йөргән олы талант иясе, атаклы Галиәсгар Камал иде.

Без Парсин белән редактор кабинетына уздык. Галиәсгар абзый үз өстәле янында утырып калды. Башыма тагын кызык кына уй килеп узды: шундый зур талант, атаклы әдип-драматург, ә үзе гади генә эш эшләп, әдәби хезмәткәр вазифасын үтәп, редакциядә утыра. Ни өчен? Хәер, әнә бит ул нәрсә ди: реаль тормыш, халык, реалистик сәнгать...

Ә газета әдипне реаль тормыш белән, халык белән бәйләгән иң нык җепләрнең берсе түгелмени?

Шушы танышудан соң Галиәсгар абзый белән еш кына очрашып, исәнлек-саулык сорашып уза торган булдык. Истәлекле очрашуларның берсе 1928 елда хәзерге Качалов исемендәге зур драма театрында булды. Бу бинада Татар академия театры да эшли иде.

Тәнәфес вакыты. Фойеда Галиәсгар абзый миңа аркасын куебрак баскан бер кеше белән җанлы гына әңгәмә алып бара. Мин, инде ерактан кайткан студент, Галиәсгар абзый белән, әлбәттә, күрешми уза алмадым. Ул миңа ачык чырай белән карады, кулымны кысып күреште һәм, янында торган мәһабәт гәүдәле, кара мыеклы дустына тәкъдим итеп:

— Таныш бул, Сәгыйт, бу безнең, өметле генә яшь драматургыбыз һәм режиссерыбыз, театр техникумын тәмамлап бер ел театрда эшләгәч, без аны Ленинградка, югары белем алырга җибәрдек. Институтка. Атаклы театр эшлеклеләре һәм галимнәреннән сабак алырга.

Галиәсгар абзыйның минем турымда әйткән сүзләрен тыңлап бетерер-бетермәс, аның янындагы кешенең йөзенә күземне төшердем. Я хода! Бу — Сәгыйт абый Сүнчәләй бит! Минем укытучым. Сәгыйт абый үзе дә кычкырып көлеп алды һәм мине кочты.

— Бу уңган, чибәр егетне мин үзем, дөресрәге, Шәриф абый белән икәүләп, менә мондый гына бала чагыннан (ул кулы белән идәннән әз генә калкурак араны күрсәтте), колакларыннан тарта-тарта, ал сабакларын да, арт сабакларын да укыта-укыта, акыл бирә-бирә үстердек. Ә, Риза? Шулай түгелме әллә?

— Әйе, дөрес, нәкъ шулай, Сәгыйт абый,— дидем.— Минем әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәтем бар икән, иң башлап моның өчен мин Шәриф абый белән сиңа бурычлы.

Шуннан соң өчебез өчен дә уртак булган мәсьәләләр турында сүз барды. Бик кыска гына итеп булса да мин аларга Ленинград театрлары һәм андагы спектакльләр турында сөйләдем. Галиәсгар абзыйны иң кызыксындырганы ул елларда атаклы режиссер-педагог Александр Александрович Брянцев тарафыннан төзелеп, киң җәмәгатьчелек тарафыннан күтәреп алынган яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) булды.

— Балалар өчен махсус театр, яшь тамашачылар театры безгә дә кирәк, бик кирәк. Яшьләрне тәрбия итүдә аның роле зур булачак,— диде ул.

Галиәсгар абзый белән 1933 елның беренче айларында булган очрашу хәтергә аеруча нык сеңеп калган. Бу вакытта мин Татар дәүләт академия театрында художество эшләре җитәкчесе идем. Репертуар планына Г. Камалның «Банкрот» исемле комедиясе дә кертелгән. Пьесаны сәхнәләштерү эше Кәрим абый Тинчуринга тапшырылды.

«Банкрот» — Галиәсгар абзыйның иң оста язылган комедияләренең берсе. Ул инде моңа кадәр дә күп мәртәбәләр сәхнәгә куелып, киң катлау тамашачыларның мәхәббәтен яулап алган әсәр.

Пьесаның һәр куелышында тамашачыга нинди дә булса яңа сүз әйтергә, әсәргә салынган фикерне тагын да тирәнәйтә төшеп, тамашачыга аны яңа ягыннан ачарга кирәк. Максат зур, изге, ә вакыт әз. Атна-ун көн эчендә Кәрим абый безгә әсәрне ничек куярга уйлавы турында яхшы ук җентекләп эшләнгән режиссер планын да китереп тапшырды. Без аны режиссерлар коллегиясендә тикшереп яхшы дип таптык. Тик



*Г. Камал әсәрләрен сәхнәдә даими уйнап килгән «Сәйяр» труппасы артистлары (уңнан сулга): Габдулла Кариев, С. Гыйззәтуллина-Волжская, Әхмәт Кулалаев, В. Мортазин-Иманский. (Х. Гобәйдуллин архивыннан.)*

бер мәсьәлә безне, дөресрәге, минем үземне, яхшы ук нык борчый иде. Әсәрне тагын да кызыклырак, тамашачыга үтемлерәк итү ниятеннән чыгып, Кәрим абый текстка берникадәр өстәмәләр, кыскартулар, үзгәрешләр керткән. Алар турында ул коллегия утырышында артык тәфсилләп сөйләп тормады. Ләкин утырыштан соң, икәүдән-икәү генә калгач, нинди үзгәрешләр кертәчәге турында миңа бик җентекләп аңлатты да нәтиҗә ясап әйтте:

— Башка авторның әсәре булса, бу турыда сөйләшеп тору да кирәк булмас иде, мин тезәтеп чыкканча һич сүзсез барыр иде ул. Ләкин бит «Банкрот» — Галиәсгар абзыйныкы. Төрле сәхнәләрдә уйналып зур сынау үткән мәшһүр комедия. Шулай булгач, безнең бу үзгәртүләрне...

— Минем дип сөйлә, Кәрим абый.

— Юк инде, театр әсәрне сәхнәләштереп, тамашачы алдына спектакль итеп чыгара икән, ул минеке генә түгел, безнең спектакль була. Моның өчен, автор каршында да, җәмәгатьчелек каршында да, барыбыз да җаваплы.

Моның шулай икәнен аңлый идем, билгеле. Казанның үзендә үк яшәгән авторның, бигрәк тә Галиәсгар Камал кебек драматургның, әсәрен үзгәртү, үзенең рөхсәтеннән башка сызу, өстәү... Юк, бу тупаслык, әдәпсезлек булыр иде.

Кәрим абый белән бу мәсьәләдә дә без тиз аңлаштык һәм Галиәсгар абзыйны театрга чакырып сөйләшергә дигән фикергә килдек. Икенче көнне Галиәсгар Камал театрда, безнең яныбызда иде инде. Билгеле, без аны театрның нигезен салучыларның берсе һәм иң күренеклесе итеп хөрмәтләп каршы алдык, ул үзе дә безнең белән бик җылы гына күреште. Чыраена, инде бераз эчкәрәк тә баткан күзләренә ягымлы яктылык чыгарып, миңа карап куйды да:

— Ал-а-ай, Ишморат туган, мена бит син нинди бәхетле, өлгер кеше булып чыктың. Безнең барыбыз өчен мөкатдәс булган урын — Татар дәүләт академия театрында зур җаваплы эш башкарасың. Театрга нигез салучыларның берсе Кәрим абыең Тинчурин белән бергәләп бит әле, иңгә-иң куеп. Кәрим генәме, бу театрда татар сәхнәсенең бөтен ветераннары: Зәйни Солтан, Мохтар Мутин, Шакир Шамильский, Хәлил Әбҗәлил... Ә артистларыгыз кемнәр бит! Болгарская, Ильская, Таждарова, Арапова... һәр кайсы үзе бер тарих. Кадерен бел, Риза туган, кадерен бел бу ганиматинен...

— Белә, белә, хәзер инде безнең Ишморат техникум чорындагы кебек футурист та, сулф та түгел,— дип хуплап куйды Кәрим абый, хөрмәтле кунагыбыз сүзенә кушылып.— Кутуй да хәзер бит инде элеккеге Кутуй түгел,— дип тә өстәде.

Галиәсгар абзыйга мин «Банкрот» комедиясен сәхнәгә куярга җыенуыбыз, бу җаваплы эшкә режиссер итеп Кәрим абый Тинчуринны билгеләвебез һәм инде аның бу спектакльне бүген ничегрәк сәхнәдә яңартырга теләве, кайсы рольне нинди артист башкарачагын, кыскасы, режиссерның спектакль планы хакында кыска гына итеп сөйләп бирдем. Галиәсгар абзый игътибар белән тыңлап утырды да:

— Бик хуп, барсы да урынында. Рольләр, минемчә дә, бик дөрес бүленгән. Декорация дә эшләнер, кием-салым да табылыр. Кәрим инде ул оста режиссер, шулай булгач, бары да урынында булыр дип ышанам. Монда инде минем белән сөйләшер урын калмаган,— дип, сүзен тәмамлады, мине нигә чакырып борчыгансыздыр дигәндәй, күзләренә сорау билгесе чыгарып, Кәрим абый белән миңа карап куйды. Без бу карашны аңладык, билгеле. Шуннан туры гына әйттем аңа:

— Сезне чакыруыбызның сәбәбе шул, Галиәсгар абзый, «Банкрот»ны бүген сәхнәләштергәндә, әсәрнең эчтәлеген тагын да бераз тулыландыру, характерларның бәрелешен тагын да бераз кискенләштерү максаты белән Кәрим абый Тинчурин әсәрнең кайбер урыннарына әз-мәз генә төзәтмәләр кертмәкче була. Кайбер образларның сүзләрен кыскарта, кайберләренә, киресенчә, яңа сүзләр өсти, кайбер образларның характерларын шундый-шундыйрак итеп үзгәртү кирәк дип таба. Шулай эшләгәндә спектакль мәгънә ягыннан тулырак, тамашачыга карау өчен кызыклырак булыр,— ди.

— Алай-й,— дип куйды Галиәсгар абзый.— Кариевка яраган «Банкрот» Кәримгә ярамый, тамашачыга яраган Ишморатка ярамый икән болай булгач.

Аның иреннәрендә бик әз генә иронияле елмаю чагылды. Үпкәләде дәү абзабыз, дип уйладым эчемнән генә.

— Юк, Галиәсгар абзый, Кариевка яраган, тамашачыга да яраган комедия безгә дә бик ярый,— диде Кәрим абый, өлкән авторыбызны мөмкин кадәр ышандырырга тырышып.— Шуңа күрә без аны театрыбызның Баку, Ашхабад, Ташкент шәһәрләренә гастрольгә баруы алдыннан әзерлибез дә. Репертуарыбызда югары сыйфатлы әсәрләр булдырасыбыз килә. Спектакльне үткәндәге куелышларына караганда яхшырак, кызыклырак, мөкәммәлрәк итеп чыгару безнең ният. Әгәр безнең бик җиңелчә генә булган төзәтмәләр белән килешмисең икән, без аны нәкъ үзең язганча, бер сүз дә үзгәртми куячакбыз. Безнең фикер белән килешәсең икән, аларны үз кулың белән язып китерәсең. Син автор. Тәҗрибәле, сыналган, дан алган автор. Безнең синә әмер итәргә хакыбыз юк.

— Яле, нинди төзәтмәләр икән ул? — диде Галиәсгар абзый коры гына.

Нәкъ шул сүзне көткән Кәрим абый, кайсын пьесаның читенә, кайсын аерым кәгазьгә язган, кайберләрен башында гына саклаган фикерләрен берәм-берәм тезеп, җентекләп сөйләп чыкты. Сөйләде генә түгел, кайберләрен хәтта ымлап та, уйнап та күрсәтте. Текстта артык күп булмаса да, шактый кызыклы һәм әһәмиятле өстәмәләр иде бу. Шунысы гаҗәп, Галиәсгар абзый ул укыган, күрсәткән төзәтмәләрнең күбесенә һич каршы килмәде. «Монысы ярый, монысына да кул куям, ә монысы минә батмый, бу инде, Кәрим, синең үз мәзәгең, «Банкрот» рухына ят, минемчә...» Шулай диди, ул режиссер төзәтмәләренең барын да тыңлап та, күзе белән сөзгәләп тә чыкты. Яхшы ук озак вакыт алды бу хезмәт, ләкин автор да, режиссер да ашыкмады. Ниһаять, Галиәсгар абзый сүзне түгәрәкләп куйды:

— Боларның күбесе бит инде авторның катнашыннан башка, режиссер үзе эшли ала торган төзәтмәләр. Әсәрнең төзелешенә дә, образларның асыл сыйфатларына да, иң мөһименә, пьесада әйтергә теләгән фикергә дә зыян китермиләр. Аерым сүзләр һәм хәрәкәткә бәйләнгән яңалыкларның барына да диярлек кул куям. Театрда чыгарыла торган спектакльгә сез хуҗа. Ә менә әсәрне бастырып, китап итеп дөньяга чыгарганда, мин хуҗа. Ул төзәтмәләрне китапта калдырырмынмы-юкмы, анысы инде минем эш. Анда карармын. Бүген сезгә миннән фатиха, тулысынча ризалык.

— Бәлки, өйгә алып кайтып, үзең тагын бер кат карап чыгарсың,— диде Кәрим абый, инде сүз тәмам хәл кылынып беткәнгә исәпләп, өстәл яныннан диванга барып утырган Галиәсгар абзыйга карап.

Мин җиңел сулыш алып куйдым. Атаклы драматургыбызның хәтерен калдырудан бик курыккан идем. Бүгенге очрашуыбызның шулай җиңел һәм без көткән нәтиҗә белән тәмамлануына нык шатландым. Күреп торам, Кәрим абый Тинчурин да бик канәгать: йөзендә — сизелер-сизелмәс кенә елмаю, күзләрендә — ялкын. Үз эшеннән канәгать булган чакларда һәр вакыт диярлек шундыйрак кыяфәттә була ул.

Галиәсгар абзыйны икебез дә урамга кадәр озата чыктык.

«Банкрот» спектакле яңа куелышта да зур популярлык казанды, тамашачыларга да, җәмәгатьчелеккә дә, шулай ук авторның үзенә дә бик ошады. Казанда гына түгел, аны Баку, Ашхабад һәм Ташкент тамашачылары да бик яратып карадылар. Театрыбызның олы осталары Галиәсгар Камал һәм Кәрим Тинчурин исеме белән бәйләнгән бу спектакль театрның үсеш юлында бер якты эз булып калды.

Моннан соң инде ярты гасырга якын дип әйтерлек вакыт узды. Бу чор эчендә безнең тормышыбызда зур үзгәрешләр булды.

Галиәсгар Камал ныклы нигезен салган драматургиябез һәм театрыбыз өлкәсендә дә казанышларыбыз зур. Хәзер инде культурабызның иң мөкатдәс урыны саналган Татар дәүләт академия театры, бик хаклы рәвештә һәм зур горурлык белән, Галиәсгар Камал исемен йөртә. Ул яши һәм яшәячәк!

Без, Галиәсгар Камал белән аралашып яшәгән өлкән буын әдипләре, атаклы драматургыбызны, Тукай белән бергәләп «Яшен», «Ялт-йолт» журналларын чыгарган, үзен ачы телле сатирик шагыйрь дә, карикатурачы рәссам да, һәвәскәр артист та итеп таныткан бу киң кырлы талантны, бик самими, бик гадел булган кешелекле кешене, бөтен йөрәге белән социалистик Ватаныбызга бирелгән кыю гражданинны сагынып искә алабыз.


**Рәфика Камалова,**
медицина фәннәре кандидаты

## ӘТИЕМНЕ МИН НИЧЕК ХӘТЕРЛИМ

Әтидән калганда миңа җиде яшь иде. Әти турындагы истәлекләрем дә — әнә шул бала чак хатирәләре генә. Әти мине еш кына үзе белән ияртеп йөри торган булган. Әти белән базарга чыгып, шунда адашканымны хәтерлим. Кеше аяклары арасында озак буталып йөреп бик нык курыккан идем. Ул чагында миңа базар очсыз-кырыйсыз тоелган иде. Әти мине эзләп тапкач, туктый алмый бик озак елаган идем. Берничә мәртәбә әтинең үзе белән Сөембикә манарасына алып менгәнен, еш кына ниндидер художниклар янына алып барганын хәтерлим. Бер барганда минем уенчык агач кувшинны кызыл төскә буятып, икенче бер барганда аңа рәсем төшертеп кайткан идек. Үзе белән урманга алып бара иде. Җиләк, гөмбә ничек җыярга икәнен өйрәтә иде. Кайбер чакта үзе күргән җиләк яки гөмбәне сиздерми генә таягы белән төртеп китәдер иде. Уенчык алганда, магазинга бергә барып, миңа сайларга куша торган иде. Бервакытны шулай дачада торганда Юдино магазинына барып бик матур, нәкъ чын кебек итеп эшләнгән зур уенчык сыер сатып алдык. Поезд вагоннары астыннан чыгып өйгә кайтканда, шул сыерның мөгезе сынды.

Әти кайбер вакытта без уйнаган уенга да кушылып китә иде. Беркөнне шулай без иптәш кызым Нявар белән өйдә, йөгереп, качышлы уйныйбыз, ә әти өстәл артында язып утыра. Качарга миңа чират җитте. Әти, язуыннан бүленеп, мине шкаф башына менгезеп утыртты. Мин шунда качтым. Няварга мине шактый вакыт эзләргә туры килде.

Бервакытны әни камыр ашы пешергәндә, мин бик соранып йөри торгач, минем курчакларым өчен дә бик кечкенә-кечкенә генә пироглар пешердек. Мин әти белән



*«Банкрот» спектакленең макеты. II пәрдә күренеше. Художнигы РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәэмүн Сүтюшев.*



өнине кунакка чакырдым. Мич кырына уенчык өстәл, урындыклар тезеп, өстәлгә пирогларны куйдык. Әти белән әни килеп өстәлнең як-ягына идәнгә утырдылар. Әни пирогны юри-юри генә капкан була да кире куя, ә әти чын-чынлап ашый башлады. Ә мин әти бөтен пирогларны ашап бетерә инде дип куркып елап җибәрдем. Шул чагында әтинең: «Менә монысы һич тә ярамый инде. Ашатасың килмәсә, кешене кунакка чакырмыйлар», дигәне хәтердә калган.

## Кәрим Әмири

# ӘДИП ТОРМЫШЫННАН БЕРНИЧӘ СӘХИФӘ

Тышта суык, җир туңган...

Иренеп-иренеп кенә беренче карлар төшкәләп тора. Мин, ашыгып-ашыгып, каядыр йомыш белән бара идем. Өстенә камалы тун, башына камчат бүрек кигән Галиәсгар абзый Тукай урамы буйлап миңа каршы килә. Култык астына газеталар, озынча тар кәгазьләр кыстырган иде. Мин барып җитмәс борын, үзеннән яшьрәк, кыяфәтеннән үк сәүдәгәр икәнлеге күренеп торган бер Печән базары татары, аның артыннан килеп: «Галиәсгар ага»,— дип кычкырды.

Әкрен генә атлап килгән Галиәсгар абзый, туктап, артына таба борылды да: «Акмый әле»,— дип куйды.

Мин алар янына килеп туктаганда, ике арада шундый сүз бара иде:

— Нәрсә акмый?

— Галиәсгар ага дисең ич. Галиәсгар ничек аксын инде?

— Картаюны белмисең, ахры, һаман да шаян син...

— Ник карт аюны белмәскә, карт аю урманда була ул.

— Һәй, куйсана, әле мин сиңа ул турыда әйтмим бит! Синең әзрәк денең бармы соң, алладан оялмыйсыңмы?

— Нигә, алла өй сатамыни?

— Әстәгъфирулла тәүбә, большевикларда эшли башлагач, бөтенләй юлдан чыккан икәнсең.

— Син үзең юлдан чыккан.

— Ничек инде юлдан чыккан?

— Юлдан килмисең ич, тротуардан атлыйсың.

— Агай-энеңең алтын-көмеш яшергәннәрен язмасаң, большевиклар акча бирми торганнардыр шул.

— Ә, сиңа да барып төртелдемени, күпме яшергән идең соң?

Бу сүздән соң теге кеше дәшмәде. Кулын селтәде дә юлына китеп барды.

Ул иртә белән редакциядә дә, типографиядә дә эшли иде. Шуның белән бергә драма әсәрләре өстендә дә утыра, вакыт таба, үзенең шигырьләрен әдәбият кичәләренә дә барып сөйли иде.

Ул, нинди генә әйбер булмасын, бик пөхтә яза, төзәтергә урын калдырмый. Язган нәрсәсен эшләп бетергәч, укып чыгу гадәте дә юк иде.

— Ничек шулай бик чиста, хаталар җибәрми яза аласың? — дигәч, Галиәсгар абзый:

— Миңа язудан төзәтүе авыррак. Мин аңарга гадәтләнмәгән. Шуңа күрә берьюлы эшен бетереп барырга тырышам,— ди торган иде.

Копияләрен алдырып бармаганга күрә, аның кулъязмалары кеше кулында кала, яисә югалып та бетә иде. Бер-бер инсценировка яисә шигырь язса, аны куярга һәм сөйләргә алып китәләр дә, кире кайтарып бирмиләр. Әдәбият кичәләрендә агымдагы көнгә бәйләнгән вакыйгаларны сәхнә артында артистларга язып бирү яисә шул язганын үзе чыгып сөйләү аның өчен һәр вакыт гадәти бер хәл иде.

Шунысы гаҗәп, ул һич ару-талуны белми кебек иде. Хәтта аның көне буе редакциядә эшләгән чагында дүрт пәрдәлек зур-зур драма әсәрләрен бер кичтә тәрҗемә иткән вакытлары да булгалады. Мәсәлән, 1922 елны Казанда артистларның үз җаваплылыгында труппа оешып, җәйге сезон ачылды. Шул труппаның җитәкчеләгеннән М. Мутин редакциягә килеп:

— Галиәсгар абзый, бик ашыгыч бер эш бар. Синнән башка кеше эшли алмый инде аны. Бик тиз генә шуны тәрҗемә итеп бирсәңче,— дип үтенде.

Бу әсәр Гординның «Сатана» дигән дүрт пәрдәлек сәхнә әсәре иде.

Галиәсгар абзый:

— Әмма теңкәмә тиде шул ашыгыч эшләрегез, нигә соң электәнрәк уйламадыгыз? Утырып иркенләп эшләүгә ни җитә! Башка эшем булмаса, әйтмәс тә идем. Менә бүген бик озын мәкалә тәрҗемә итәсем бар,— диде.

Сөйләшеп аңлашканнан соң, Галиәсгар абзыйга бирелгән мәкалә икенче кешегә тапшырылды, ә «Сатана»ны тәрҗемә итәргә Галиәсгар абзый үзе алынды. Икенче көнне иртә белән ул «Сатана»ны «Иблис» исеме белән тәрҗемә итеп алып килгән иде.

Драма әсәрләрен тәрҗемә итү хезмәте бу сезонда шактый ук күп булды. Өч айлык җәйге сезонда ул дүрт исемдә зур күләмле «Иблис», «Хәзрәти Хәмзә», «Оҗмах кошы» һәм тагын бер әсәр тәрҗемә итеп бирде.

Галиәсгар абзый революциянең беренче көннәреннән үк Совет хөкүмәте хезмәтендә чын күңеленнән бирелеп эшләде. Нинди генә буталчык вакытларда да ул татар буржуазиясе газеталарына, милләтчеләр тирәсенә якын бармады.

Эшче, крестьян, солдат депутатлары советының воззваниеләре, гражданнар сугышы чорындагы 5 нче армия штабының воззвание һәм приказларының тәрҗемәләре — барысы да Галиәсгар абзыйның хезмәтләре иде.

«Корылтай»чы Баттал турында берничә кат сөйләве әле булса исемдә.

Вакыйга болай була: 1918 елны Казанга чехословаклар керәләр. Бу чорда татар милләтчеләре һәм татар буржуаларының иң котырган чагы була. Казанга чехлар керү белән, татар контрларының органы булып «Алтай» исемендәге газета чыга башлый. Моның редакторы мәгълүм эмигрант Бари Баттал дигән кеше була. Ул берничә кат Галиәсгар абзыйны шул «Алтай» газетасында эшләргә чакыра. Ә Галиәсгар абзый бармый. Бу вакытта Галиәсгар абзыйның килере бөтенләй киселгән чак була.

Редакциядән көн саен чакыртып кеше җибәрәләр, Галиәсгар абзый шулардан качып калуын болай дип сөйли торган иде:

— Таңнан торып Бакалтайга китәм дә, кояш баеганда гына кайтам. Тиз генә ашап-эчеп, түбән өйдә тора торган кәләвәче Нуриларга төшеп йоклыйм. Тегеләрнең кешеләре мине эзләп килгән саен: «Өйдә юк!» дип кенә җибәрәләр. Шулай да бер көнне урамда Батталга юлыктым. Ул, мине күрү белән, каршыма кинәт чыгып басып: «Син ничек иректә? Әле кулга алмадылармыни сине?» — дип котымны алды. Аңардан ничек кирәк алай котылдым да, шул ук көнне авылга качып киттем, чехлар куылганчы Казанга кайтмадым.

Казаннан чехлар киткәч, Галиәсгар абзый, кайтып, янәдән «Эш» редакциясенә хезмәткә керә һәм «Ишангали», «Әүлия һәм компаниясе» имзалары белән шул газетада шигырьләрен бастыра башлый.

## Шәриф Еникеев

# ЯГЫМЛЫ ТАВЫШЫ ӘЛЕ ДӘ ЯҢГЫРЫЙ КЕБЕК...

Бу 1930 елның көзе иде. Минем Казандагы сукырлар мәктәбен тәмамлап, Татрабфакка укырга кергән чакларым. Тулай торагыбыз Татар академия театрына якын булганга, мин һәр яңа спектакль куелган саен театрга йөрергә гадәтләндем.

Театр сәхнәсендә куелган пьесаларны, анда уйнаучы чын сәнгать осталарын сокланып, бөтен дөньяны онытып, тәмам мөкиббән китеп тыңлый идем.

Торакка кайтып, салкын бүлмәдә, ярты чиләк сыешлы кара калай чәйнектән алюмин кружкага җылымса су агызып, кара ипи сыныгы белән тамак ялгагач, караватка ятып: «Менә үзебездә — сукырлар җәмгыятендә — үзешчәннәр драма түгәрәген оештырсаң иде»,— дип хыяллана идем. Үземнең хыялларымны, уй-фикерләремне Татарстан сукырлар җәмгыятенең шул замандагы рәисе Кирам абзый Сәйфуллинга да ирештердем. Кирам абзый Сәйфуллин — кызыл партизан, гражданнар сугышында ике күзен һәм сул кулын югалтып кайткан, бик тәвәккәл, принципиаль, уңнан кеше иде. Мине сабыр гына тыңлаганнан соң: «Ярый, Шәриф, мин бу турыда Галиәсгар ага белән сөйләшермен, ул бит бездә — наркомсобеста культура эшләрен алып бара»,— дип тынычландырды. Ләкин мин аның сүзләренә ышанмадым. Шундый олы, атаклы драматург Галиәсгар Камал без — сукырлар янына килеп, драмтүгәрәккә җитәкчелек итсен, имеш!..

Ләкин эш нәкъ менә киресенчә булып чыкты...

Галиәсгар ага Камалны мин 1931 елның январенда сукырлар җәмгыяте бүлмәсендә очраттым.

Кирам абый исә:

— Менә, Галиәсгар ага, шушы инде мин сезгә әйткән студент егет. Ул безнең драмтүгәрәкнең старостасы, таныш булыгыз,— дип, мине аның алдына китереп бастырды.

Без кул биреп күрештек. Г. Камалның йөзен, буй-сынын, кигән киемен күрмәгәнлектән, кыяфәте хакында хөкем йөртә алмыйм. Әмма аның йомшак, калын көр тавышы, ягымлы, якты аһәң белән әйтелгән көлке сүзләре миндә бу — гап-гади, бик сөйкемле кешедер дигән тәэсир калдырды.

Без иртәгесен драмтүгәрәк членнарын җыеп кызыл почмакта очрашырга булдык. Кызыл почмагыбыз К. Маркс урамы, уникенче йортның икенче катында, бер бәләкәй генә, караңгырак бүлмә иде. Кирам Сәйфуллин Галиәсгар Камалдан безнең драмтүгәрәк белән танышуын, әгәр мөмкин булса, үзенең кайбер киңәшләрен бирүен үтенгән иде.

Галиәсгар Камал, олы башын кече итеп, бер дә авырсынмыйча дигәндәй, сөйләшенгән вакытка безнең шул кысан кызыл почмагыбызга килеп керде. Кирам абзый сәламәт кулындагы таягын идәнгә шапылдатып бәрә-бәрә:

— Менә, иптәшләр! Галиәсгар ага Камал үзе сезнең каршыгызда. Сез аңа үзегезнең «артистлык» осталыкларыгызны күрсәтегез. Иң мөһиме, сез аның сүзләрен игътибар белән тыңлагыз да хәтерегездә калдырыгыз, чөнки ул, искечә итеп әйткәндә, театрның алласы. Шуңа күрә аның әйткән һәр сүзе безгә бик кадерле, — диде.

Галиәсгар Камал без утырышкан озын өстәлнең башына килеп утырды һәм бик гади генә итеп безнең һәркайсыбыз белән аерым-аерым таныша башлады.

— Менә сез, туташ, кем буласыз? Ни эштә? — диде ул, арабыздагы бер кызга эндәшеп.

— Мин, абый, Татрабфакта укыйм. Исемем Әминә, фамилиям Әхмәтҗанова, — дип, оялчан гына җавап бирде шадра кыз.

— Ә сезне кем диим, егет? — дип эндәште Галиәсгар ага, Әминә белән янәшә утырган Рәшит Байбиковка карап.

— Мин щетка цехында эшлим, абый, дөньядагы барлык чүп-чарны, шакшылыкны себереп түгәргә телим, шулай ук буржуй калдык-постыкларын себереп ташласыннар иде мин ясаган щеткалар, — дип, кыю гына сүзгә кереште Рәшит, кулындагы артыш таягын боргалап.

— Мин Мәхмүт Харисов булам, — дип сүз алды икенче бер егетебез. — Кичке рабфакта укыйм, көндезләрен матрац цехында матрац ясыйм, ләкин берсе икенчесенә комачауламый. Мин бит дөнья яктысын азрак күрәм, шул миңа бик нык ярдәм итә.

— Мин, абый, ударник, — дип, әрсезләнеп Галиәсгар аганың алдына ук килеп басты уналты яшьләрендәге үсмер.

— Тукта әле, энем, синең исемең, фамилияң бардыр лабаса, — дип көлеп куйды Галиәсгар ага.

— Биредә минем исememне дә, фамилиямне дә белмиләр. Мөбәрәкша Зәйнуллин кайда икән, дип сорасалар, бездә андый кеше юк шикелле, диярләр. Мин эш хакы алу кәгазенә дә «Ударник» дип кенә кул куям, — диде шаян үсмер. — Ягез, Галиәсгар абый, миңа бирәр руль бирерсезме икән?

Үз җавабында Галиәсгар ага шаяртып:

— Сиңа руль тоттырмасак та, син башкара алган рольне табарбыз, — дип малайны тынычландырды.

Шул рәвешчә түгәрәк членнарының хәл-әхвәлләре, тормыш шартлары белән танышканнан соң, ул тәгаен бер фикергә — безгә ярдәм итү ниятенә килде булса кирәк.

Галиәсгар ага безнең драмтүгәрәкнең эше белән чын-чыннан кызыксынды һәм, ихлас күңел биреп, түгәрәктә катнашучыларга үзенең киңәшләре белән ярдәм итә башлады. Алай гына да түгел, тиздән ул драмтүгәрәгебезнең җитәкчесе, режиссеры булып китте.

Галиәсгар ага безгә җиңелрәк пьесалар сайлап ала һәм аны кычкырып укыта торган иде.

Беренче пьесаны уңышлы гына уйнаганнан соң без Галиәсгар Камалның үз әсәрен — «Беренче театр»ны сәхнәгә куйдык.

Тора-бара Галиәсгар ага сукырлар тормышы белән якыннан торып кызыксына башлады, аларның эчке кичерешләрен нечкәлек белән өйрәнде. Щетка мастерское һәм караңгы матрац цехына барып, берничә көн рәттән, ачы тузан, дуңгыз щетина-

сы, ат кылының яман исенә игътибар итмичә, сәгатьләр буе сукырларның ничек эшләүләрен күзәтеп утырды. Аларның гадәтләрен, бер-берсенә булган мөгамәләләрен тәҗрибәле карашыннан уздырды.

Шуннан соң ул безгә «Күзсез мастерлар» дигән әсәрен укырга алып килде. Үзебезнең тормыштан алынганга күрә, әсәр безгә бик ошады, әлбәттә!

Бу әсәрне без бик теләп репертуарыбызга алдык. Теге яисә бу пьесаны куяр алдыннан Галиәсгар ага безгә үз-үзеңне сәхнәдә ничек тотарга, йөзең белән тамашачыларга карап сөйләргә кирәклеген әйтеп, куллары белән күрсәтеп бирә торган иде.

— Сез, дусларым, — ди иде ул, — шуны аңлагыз һәм исегездә тотыгыз: сәхнәдә уйнаучының һәрбер хәрәкәте, кыланышы, бөтен кичерешләре дистәләрчә, йөзләрчә тамашачының күз карашы, игътибары каршында була. «Күзсезләр сәхнәдә» дигән сүз күзлеләрдә зур кызыксыну уята, шулай булгач, без, барлык көчебезне туплап, чын артистларча уйнарга тиеш. Югыйсә безгә аю кәмитен карарга килгән кебек булып чыгуы мөмкин. Аннан соң сез, кадерлеләрем, үзегезне тамашачы итеп тә күз алдына китерә белегез. Үткән атнада Сәүдә йорты клубында әле концерт барган вакытта үзешчән түгәрәкнең ике члены залда үбешеп утырдылар. Барлык тамашачыларның йөзендә көлү, елмаю билгесе чыкты. Бу, әлбәттә, килешми, яхшы түгел...

Без дәррәү кубып:

— Кемнәр иде?! Яшермичә әйтегез, Галиәсгар ага, — диештек.

— Ярар, анысы калып торсын. Алар үзләре белә. Аларның гаебе юк, чөнки күзсез кешегә һәр вакыт караңгы була, күрәсең...

— Ә сәхнәдә үбешәләр бит, ул гаепкә саналмыймыни? — дип кузгалды Рәшит Байбиков.

— Әһә! Каракның бүреге яна. Зәйнәп, ник син авызыңны яптың? — диештек без.

— Дөрес, алар яулыкка капланып үбештеләр, ләкин күз барын да күрә шул. Африка сахраларында страус дигән кош яши, ул мескен үзенең дошманнарыннан башын ком астына тыгып яшеренә, ә ат хәтле гәүдәсе тышта кала. Бу да шуның шикелле инде. Әйе, дусларым, менә мин сезгә карап торам да, тагы бер гаҗәпләнеп куям. Сез дөнья йөзен күрүдән мәхрүм кешеләр, шулай булуга карамастан, дөнья көтәсез, яратышасыз... матур гына гаилә корып җибәрәсез. Мин моңа, әлбәттә, бик шатмын, — диде җитәкчебез.

Без шәһәр клубларында һәм культура сарайларында бер пәрдәле, ике пәрдәле пьесалар, инсценировкалар куя идек. Кичәнең икенче бүлегендә һәрвакыт концерт була. Татар халык җырларын Рабига Ишбулатова бик оста башкара, аның моңлы җырлары барлык тамашачылар тарафыннан җылы каршы алына иде.

Шулай итеп, Галиәсгар Камал һич иренмичә, вакыты белән исәпләшмичә, һаман безнең янга килеп йөрде. Без аңа күнектек, ул тәмам үз кешебез булып китте. Бу дуслык 1933 елның язына кадәр дәвам итте.

Беренче бишьеллык чорында бар нәрсә дә чамалы иде. Шундый мохтаҗлык елларында Галиәсгар Камалның зарланганын, уфтанганын мин ишетмәдем дә, сизмәдем дә. Өч ел ярым җитәкчелек итү чорында, ай-һай, алдымы икән Г. Камал безнең җәмгыятьтән тәңкә ярым акча...

К. Сәйфуллин аңа:

— Галиәсгар ага, сезгә анда бераз премия язылган иде, кереп алыгыз, без жалунье түли алмыйбыз, акчабыз юк, — дигәч: «Юк, Кирам! Миңа сукырлардан сукыр бер тиен дә кирәкми», дигән сүзләре бүгенгедәй хәтеремдә.

Галиәсгар ага Камалның ягымлы, йомшак, мәһабәт тавышы әле дә булса минем колагымда яңгырый кебек... Менә хәзер ул килеп эндәшсә, мин аны йөзләрчә тавышлар арасыннан аерып алыр идем шикелле...

Илдар Юзеев

# ОЗЫН ГОМЕРЛЕ ШАГЫЙРЬ

Тукай, Такташлардан соң поэзиядә үз биеклегеңне яулап алу җиңел түгел. Муса Җәлил һәм Фатих Кәрим, ил язмышы, халык язмышы хәл ителгәндә каләм белән дә, корал белән дә Ватан сугышында катнашып, батырларча һәлак булып, шагыйрьнең яңа тибын — солдат, көрәшче тибын тудырдылар. Икесе ике язмыш. Катлаулы да, фаҗигале дә, бәхетле дә язмыш.

Сугыш алды еллары, рәхимсез сугыш икесен дә түзә алмаслык хәлләрдә калдырып сыный. Әмма ике шагыйрьнең дә ил — халык алдында вөҗданы саф кала. Алар татар шигъриятен солдат поэзиясе, батырлык поэзиясе дигән биеклеккә күтәрделәр. Югары биеклек!.. Ул безнең илебездә генә түгел, дөнья халыкларында да күренә. Фатих Кәрим биеклеген Франциядән торып ук күргән Луи Арагон болай дип яза: «...аның Казан музеенда изге реликвия булып саклана торган шинеле генә түгел, кулъязмаларының соңгы битләренә кадәр пулялар белән тишкәләнеп беткән».

Җәлилләрдән, Кәримнәрдән соң поэзиядә үз биеклегеңне яулау да җиңел түгел шул... Чын мәгънәсендә шагыйрь булу өчен талантлы шигырьләр язу гына җитми, кирәк булганда Ватан өчен кызганмый җаныңны палач балтасы астына куярлык, дошман пулясыннан курыкмыйча, яуда алгы сафта барырлык, үзең яулаган биеклекне бирмичә соңгы сулышкача көрәшү кодрәтенә ия булу да кирәк икән.

һади Такташ тагын ун ел яшәсә, һичшиксез, Җәлилләр, Кәримнәр сафында булыр иде. Фатих Кәрим, чыннан да, Такташны үз араларында тоя:

**Такташ өчен бүген без бер тапкыр**
**Залп белән атыйк дошманга.**

Шагыйрьләр поэзиядә төрлечә ачылалар. Фатих Кәримнең таланты авыр ачыла. Ул озак еллар буе поэзиянең чын асылын төшенми. Шул елларда шигъриятькә шактый зыян китергән декларациядән, формализмнан котыла алмый интегә. Дөрес, шагыйрь сугышка кадәр үк инде әйбәт шигырьләре, поэмалары белән танылa. Әмма бик күпчелек язмалары газета-журнал архивларыннан узмый. Шул елларда ук инде аның лирикага омтылышы сизелә. «Көтәм сине», «Кемгә сөйлим серләремне» шигырьләрен халык әле һаман җырлый. Тик шулай да яшь шагыйрьнең лирикасы тулы көч белән ачылып китәргә нидер комачаулый.

Фатих Кәрим лирик шагыйрь буларак бөтен җаны белән Ватан сугышында ачыла. Сугышның башыннан ахырына кадәр алгы сафта... Шигырьләр окопта буш минутларда блокнотны прикладка салып языла. Тар окопта киң сулышлы, күңелләрне тетрәтерлек, нәфис үрелгән, халыкчан гади җырлар туа. Солдат-шагыйрьнең мәхәббәте дә, нәфрәте дә ташып чыга. Гаҗәп бер факт: 1941—45 нче елларда Фатих Кә-

рим 5 поэма, ике повесть, бер пьеса, 120 шигырь язган! Сокланырлык! Гыйбрәт алырлык! Кайчакларда, үзара очрашканда, «язарга вакыт юк әле» дип әйтүләр искә төшеп, Фатих Кәримнәрдән оятасың.

Фатих Кәримнең сугыш чоры шигырьләре солдатның сөйгән кызына, хатынына, балаларына, әнисенә язган хаты кебек гади. Фронтовикка хас булганча, кыска. Бары тик кысан окопта гына, сугыш шартында гына шундый кыска формалы, афоризм дәрәҗәсендәге шигырьнең тууы мөмкин:

**Үзең турында уйлама,**
**Илең турында уйла,—**
**Илең турында уйласаң,**
**Гомерең озын була.**

Рәхимсез сугыш чынбарлыгы шагыйрьне кырыс реализмга китерә. Шигырьләрдә— автомат тотып кара төндә разведкага баручы, дошман йөрәгенә төбәп атучы солдатның табигый уй-хисләре. Элек кош сайраган аккаенга фашист снайперы менгән, гашыйклар очрашкан яшь нарат төбенә фронтовик дус күмелә...

Шигырьләрдә — сугыш чынбарлыгының катлаулы фәлсәфәсе дә. Сандугачлар сайравын, гашыйклар мәхәббәтен язган кул автоматка тотынырга һәм фашистны үтерергә тиеш. Шагыйрьчә, фашистны юк итү — чын гуманистлык.

«Еллар миңа йомшак күңел бирде», дип җырлаган шагыйрь, Ватан сугышы солдаты буларак:

**Сугыш сугыш инде, рәхимсезлек**
**Ия булып йөри күңелгә,**
**Шпал итеп тезеп**
**фашист гәүдәләрен**
**Юл салабыз бөек җиңүгә,**

— дип тә язарга мәҗбүр.

Фатих Кәрим сугыш чорында иҗатының иң югары ноктасына — халыкчанлыкка, зур гражданлык фикерләрен халыкка үтемле формада шигъри камиллеккә җиткереп әйтә белү югарылыгына күтәрелә. 1944 елны әнисенә язган хатында ул: «Мин үземдә тагын да ныграк үскән иҗат көченә нык ышанам. Әле сокланырлык әйберләр язармын мин»,— дип белдерә. Бу юлларны укыгач, гражданин-солдат-шагыйрьнең әдәбиятыбызны югары баскычка күтәргән мирасы белән горурлану да, шул ук вакытта үкенеч тойгысы да күңелне билəп ала...

**Син борчылма, күңел, яз килсен,**
**Кыр казлары кайтыр күлләргә,**
**Без кайтырбыз туган илләргә,**
**Башлар гына исән-сау булсын,**

— дип язган шагыйрь бөек җиңү көннәренә кадәр яши алмый. 1945 елның 19 февралендә хәрби задание үтәгәндә батырларча һәлак була. Әгәр сугыштан исән-сау кайткан булса, иҗатының биек ноктасына менгән шагыйрь әдәбиятыбызны никадәр яңа әсәрләр белән баеткан булыр иде! Сугышта күргәннәре, кичергәннәре берничә кеше гомеренә тиң бит аның. Аның 70 яшьлек яшьтәшләре әле дә әдәбиятның алгы сафында атлыйлар ич.

Фатих Кәримнең һәлакәте никадәрле үкенечле булса да, аның ялкынлы иҗатының буыннар күңелендә елдан-ел яңара баруын күрү бу хисне җиңә. Иң якын дустына серләреңне сөйләгәндә дә, яшь наратка сөялеп сөйгәнеңне көткәндә дә, ярсып кыңгыраулы гармун уйнаганда да, тирән сагыну минутларында да Фатих Кәрим шигырьләрен искә төшерәсең. Утыз алты яшендә һәлак булган җырчы безнең арабызда мәңге шулай яшь булып яшәр, батырлыгы, шигъри матурлыгы артыннан шагыйрьләрнең яңадан-яңа буыннарын ияртер.

Фатих Кәримнең һәлак булуы символик мәгънәгә ия. ...Кече лейтенант Фатих Кәримов фашистларны биеклектән бәреп төшерергә дигән задание ала. Һәм үз көче белән үз взводыннан берничә тапкыр артык булган дошман ул биеклектән чиге-

нергә мәҗбүр була. Фашистлар биш тапкыр һөҗүм итәләр, әмма биеклек дошман түгел, җил дә үтә алмаслык солдатлар кулына күчкән. Тигезсез сугышта командир-шагыйрь, биеклекне бирмичә, югарыда һәлак була.

Әйе, дошманнар һәр вакыт шагыйрь яулап алган ул биеклекне — кешелеклелек, вөҗдан, хакыйкать, матурлык биеклеген — мушкада тоттылар. Шагыйрьләрнең йөрәкләренә төбәп аттылар, әмма барыбер бу бирелмәс югарылыкны яулап ала алмадылар.

Бу биеклекне кешелек дошманнары әле һаман да мушкада тоталар. Әмма яулый алмый, алмас һәм алмаячак! Чөнки халык яңа геройларын тудыра тора. Алмашка яңа чор шагыйрьләре килә. Ф. Кәримнең бернинди дошман пулясы да ала алмаган шинельле җырлары да һаман биеклектә, һаман да сафта тора.

## Габдрахман Минский

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ЯШЬЛЕГЕ

**Яшьлек —**
**Дәртнең ташыган чоры...**

**Ф. Кәрим.**

Җиргә ап-ак карлар яуган кышкы иртәдә тудылар алар — Ленин гасыры булып тарихка кергән, XX йөз календаре битен башлап ачкан 1901 нче елның 1 нче гыйнварында — Һади Такташ; 1909 нчы елның 9 нчы гыйнварында — Фатих Кәрим.

Арада сигез ел вакыт — бер бала чак гомере. Бар нәрсә дә бала чактан башлана — табигать тә, шигърият тә.

Фатих Кәрим турында истәлекне Такташсыз язып булмый... Моның әдәбият өчен әһәмияте бар. Атаклы шагыйрь белән яшь шагыйрь дуслыгының сафлыгы, гүзәллеге, остазның үз шәкертенә мәхәббәте һәм ихлас таләпчәнлеге бар.

Фатих Кәримнең иң яраткан, халыкча әйтсәк, үлеп яраткан шагыйре-остазы Һади Такташ булды. Бу, әлбәттә, аның яраткан шагыйрьләре бүтән булмаган дигән сүз түгел һәм була да алмый. Ул бөек Тукайны өйрәнеп үсә. Тукай Фатихның бала чагыннан ук гаиләләренә килеп кергән һәм бергә-бергә яратып укылган шагыйрь. Үзенең бер шигырендә ул Тукайны «...Халык моңнарының бакчасында тибрәп үскән гөл»гә тиңли...

Фатих Кәримнең мондый шигъри юллары бар:

**Һәр шагыйрьнең бер алласы була,**
**Мин дә шагыйрь, табынам берәүгә:**
**Табына торган аллам Байрон минем,**
**Һәм Лермонтов минем пәйгамбәр.**

Бу юлларны аңлавы кыен түгел. Аннары бу юллар, Сибгат Хәким язганча, «...кайбер шагыйрьләрчә кыланып, аларга охшарга тырышып кына әйтелгән юллар түгел». Бик урынлы һәм дөрес сүзләр, чөнки бу юлларның мәгънәви җирлеге бар...

Романтизм киңлекләре яшьлек дәртен ташыткан бер чорда Такташның:

**Мин ярапдым серле моңнарым белән бар дөньяны**
**Еглатырга, әйе, миндә көчле Байроннар каны,**

— дип язуы Фатихка бик көчле тәэсир ясый — аңарда дөнья поэзиясе җәүһәрләре

белән танышу теләге уята. Ул Байрон, Лермонтов, Блок, Маяковский шигырьләрен укырга, алардан өйрәнергә керешә.

Моннан егерме ел элек, безгә — бер төркем язучы һәм сәнгать осталарына — Такташның 60 еллыгы уңае белән туган авылы Сыркыдыда уздырылган бәйрәмдә катнашырга туры килде.

Район үзәгеннән җилле-буранлы дала аркылы Сыркыдыга таба сузылган юлдан, кышкы зәңгәр төндә, автобусыбыз кар ера-ера узганда, Такташ поэзиясенең табигать дөньясы һәм бу шигъри дөньяның байлыгын күрәсең: салкын кыш бизәкләрен, чана юлларын томалаган кар эскертләрен, Алсу керфегенә кунган кар бөртекләрен, Ибәй картка ачу итеп, күрәгән карын туздырып искән җил, ялгыз ай, тымызык куллрендәге «ком-корсакларны», иркәләнеп йөргән каз бәбкәләрен, әтәч хатыны Биби тавыкларны, җәй җитәсен белми урам чатында елап утырган песи малае, Тамбов урманнарындагы усак яфраклары шавы, каен кызына гыйшык тоткан усак егетен, зурлар кебек, кулны артка куеп таптап йөргән болыннарны күңелең күге аша күреп хәйран каласың...

**Мин сагындым!**
**Яз күңелемне**
**Алып кайтты туган Димемә;**
**Ярларына басып карадым бер,**
**Кулларымны салып билемә.**

Бу — Фатих Кәрим. Шагыйрь Дим буена бала чагын сагынып кайта. Озакка түгел, кунакка, ә киткән чагында, саубуллашу өчен, соңгы кат Дим буеннан уза. Шагыйрь күңелендә аерылышу сагышы...

**Дим калды бер ялгызы,**
**Тик ай йөри аның төбендә,**

— дип яза ул үзенең бер лирик шигырендә. Такташ иҗатындагы ялгыз ай Фатих Кәримне дә Дим ялгызлыгын көчәйтеп чагылдырган поэтик образ буларак илһамландыра.

Күптән инде, бик күптән, моннан илле еллар элек, безгә — Г. Кутуй белән — тугандаш башкорт халкының үзебездәй яшь әдипләре, шагыйрьләре белән очрашырга, хөрмәтле Мәҗит ага Гафурида кунак булырга, көймәдә мандолина чиертеп, гүзәл Дим буйларын, тугайларын тамаша кылу бәхетенә ирешергә туры килгән иде. Бүген исә, бу истәлекне язып утырганда, ерак еллар артында калган шул очрашулар искә төште...

Дус шагыйрь — Дим егете Фатих Кәримнең шигырьләр китабын ачам. Менә 45 ел элек язылган шигъри «Истәлек»:

**Мин әле дә**
**Сакаллы карт түгел,**
**Тик еракта калды бала чак.**
**Кызык бер көн**
**Бала чагымның**
**Истәлеге булып калачак.**

**Дим буенда,**
**Куе куаклыктан**
**Бозау эзләп йөри идем мин,**
**Арган кояш ял итәргә керә...**
**Тавыш-тынсыз ага иде Дим.**

Кечкенә Фатих бозау эзли. Кинәт сәер бер кош очып килүен күреп, ул дөньясын оныта — куак астына поса...

Кайткан чакта
Иптәшләрем
Миңа каршы чабып килделәр.
— Кайда йөрдең, Фатих,
Ярапланны
Күрә алмый калдың,— диделәр.
Бу истәлек өчен октябрятлар
Мыскыл итәр мине...
Итсеннәр,
Ләкин алар безнең бала чакның
Ничек булганлыгын белсеннәр...

Фатих Кәрим әдәбиятка яшьлеге иртәсендә килде. Бу күп нәрсә турында сөйли. Иртә бөреләнгән иҗат бакчасы җимешле була: Пушкин, Тукай, Такташ, Моцарт, Сәйдәш, Җәлил...

Шунысы характерлы, бу мәшһүрләрнең биографияләрендә шактый гына уртаклыклар бар. Бер яктан — Чеховча әйтсәк — бала чаксыз үзган бала чак, икенче яктан, хәвефле көннәрнең шатлыгын-кайгысын бергә кичереп чыныккан бала чак...

«Татар совет язучылары» дип исемләнгән биографик китапта Фатих Кәрим турында болай диелә: «Ф. Кәримгә әдәбият белән бик яшьләй кызыксынырга семьяда бөтен шартлар була: аның әтисе шигырьләр яза, апасы Мәрьям дә шигырь язу белән мавыга. Абыйсы Габдулла революция һәм аннан соңгы елларда «Ярлы Кәрим» имзасы астында матбугатта үзенең шигырьләрен чыгара. Фатих Кәримнең әнисе халык авыз иҗатын яхшы белә һәм әкиятләрне оста итеп сөйли торган була... Семьяда бигрәк тә Габдулла Тукайны яратып укыйлар».

Бу хакта 1944 елда язып калдырган соңгы биографиясендә Ф. Кәрим үзе дә искә ала: «Егет чагыннан ук сукыр булган әтиемнең үзе өчен язган шигырьләрен безгә укыштыргалаганын ишетү, апам Мәрьямнең үз дәфтәренә Дим буе табигатен тасвирлап язган күп кенә шигырьләрен башкалардан яшереп миңа гына укуы, революция еллары башлангач, абыем Ярлы Кәримнең матбугатта чыгып барган шигырьләрен уку — болар минем әдәбият өлкәсенә табан юнәлеш ясавыма төп һәм башлангыч этәргеч булдылар»[1].

Истәлекләр, биографик белешмәләр, документлардан мәгълүм булганча, яшүсмер Фатих, Габдулла абыйсы тырышлыгы аркасында, Бәләбәй педагогия техникумының хәзерлек группасын тәмамлый. Аннары аны абыйсы шул елларның әдәбият мәккәсе булган Казанга алдыра, чөнки яшь Фатих әле Бәләбәйдә чагында ук (1922 ел) шигырьләр яза башлаган була.

Фатих Казанга килә. Әмма Габдулла абыйсы — шагыйрь Ярлы Кәрим, сугыш яраларыннан калган авыруы көчәю сәбәпле, Казаннан Башкортстанга, Дим буйларына, табигать кочагына кайтып китәргә мәҗбүр була. Китәр алдыннан шагыйрь Ярлы Кәрим Фатихны Казанның Н. К. Крупская исемендәге яшүсмерләр йортында тәрбиягә биреп калдыра...

Фатих миңа бу йортта үзен ничек комсомолга алулары, җыр төзү техникумына керү өчен хәзерләүләре һәм дымланган күзләре белән Габдулла абыйсын сагынуы турында сөйләгәне бар. Өфедә булган көннәребездә Өфе шифаханәсендә авырып яткан шагыйрь Ярлы Кәрим янында булып, энесе Фатихның шагыйрь булырак җитлегеп килүен сөйләп куандырган идек... Безнең белән башкорт шагыйре Сәйфи Кудаш, Сәгыйт Агиш һәм Төхфәт Ченәкәй дә бар иде...

---

[1] Фатих Кәрим. Әсәрләр. I том, Татарстан китап нәшрияты, 1954 ел, 8 бит.

Сүз җае килеп чыккан икән, бүген онытыла төшкән коммунист, кызыл гвардия политругы, Петроградны Юденич бандаларыннан саклау көрәшендә авыр яраланып, 35 яшендә үлеп киткән шагыйрь Ярлы Кәрим турында аз гына булса да тукталып, исемен яд итеп китү кирәктер...

Без — Бөек Октябрь таңында уянган егерменче елларның яшь йөрәкләре — яңа тормышта беренче адымнарыбызны Пушкинның «Алтын әтәч»е, Тукайның «Шүрәле»се, Такташ, Бурнаш, Кәрим Әмири, Шамун Фидаи, Әхмәт Япанчы, Ярлы Кәримнәрнең революцион пафостагы шигырьләре тәэсирендә атлый алдык. Ә инде үсә, камилләшә төшкәч, туган телебез хәзинәсенә бөек рус теле байлыгы да кушылгач, бу исемнәр сафына Маяковский, Блок, Демьян Бедный, Безыменский кебек танылган шагыйрьләр килеп кушылды.

Кояш нурлары җылысында гел югарыга, яктыга үрләп күтәрелгән яшь үсентеләрдәй, олы әдипләрнең җылы карашларын, остазлык мәхәббәтләрен җаныбыз-тәнебез белән сизеп, тоеп үскән Нур Баян, Фатих Кәрим, Демьян Фәтхи, Әсгать Айдар, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Әхмәт Исхак, Абдулла Алиш һәм башкалар, һәм башкалар... Инде бу плеядадан Фатих Кәрим беркадәр аерылып торган икән һәм шуның белән бөек шагыйрь һади Такташның яраткан шәкертләреннән берсе һәм беренчесе булган икән, моны яшь Фатихның тормышта да, иҗатында да көләч оптимистлыгы, тыйнаклыгы, аеруча күзгә бәрелеп торган пөхтә киязлеге белән дә аңлатырга кирәктер... Әйе, Сибгат Хәким әйткәнчә, ул «бераз негрга тартым» иде. «Тырпаеп торган кара чәч, керпе чәч...» Әнә шундый керпе чәчне яткырып кара син. Чәчләребезне яткыру, ялтырату өчен көзге каршында тырыша-тырыша ыспайлануыбыз, нинди күлмәк киярге, кайсы галстугыбызны бәйләргә киңәшә-киңәшә киенүебез, өс-башыбызга «магнолия» исле маен сөртеп, ашыга-ашыга Татар театрына Такташның «Күмелгән кораллар»ын карарга баруыбыз бүген дә исемдә. Ашыкмыйча ярамый, анда безне үзебез өчен иң изге, иң якын, иң кадерле Кадрия белән Сәлимә көтә...

Соңыннан, күп еллар үтеп, күп сулар аккач, шагыйрь кулындагы каләме янына мылтык алып, солдат булып Ватан сугышына киткәч, сугышның уты-ялкыны эченнән, үзенең Кадриясенә «Син еракта» шигырен язар:

**...Син еракта миннән ерагын,**
**Ераклыкка карамый,**
**Яраласа мине дошман,**
**Ул сине дә ялпый.**

**Ялгызмыйк без, ерак түгел**
**Сугышта безнең ара,**
**Мәхәббәтем минем белән**
**Атакаларга бара...**

**Ә шулай да... син еракта,**
**Мин тик хатыңны күрәм,**
**Хатка язган сүзләреңне**
**Күзләрең итеп үбәм.**

Ә бүген исә солдат-шагыйрь Фатих дустым да, без сөйгән кызлар да — бары да еракта...

Фатих Кәрим комсомол шагыйре булып туды, үсте, күтәрелде. Шагыйрьнең ялкынлы йөрәге Ленин комсомолының данлы эшләреннән илһамланып, дулкынланып һәм, хаклы рәвештә, горурланып:

**Комсомолия,**
**Синең әгъзаң бит мин,**
**Сиңа гына**
**Беркеткәнмен бөтен күңелне:**

Шулай булгач,
һәммәгезгә игълан итәм:
Мин дә бүген
Кызыл орденлы,

— дип язды.

Шунысы игътибарга лаеклы. Ленин комсомолы сафында торып иҗат итү бөтен күңелен комсомолга беркеткән Фатих Кәримдә совет кешеләре өчен иң кадерле, кыйммәтле сыйфат — интернациональ дуслык хисләре тәрбияләде. Германия комсомолы исеменнән язылган «Ялкынлы хат» шигыре шуның характерлы бер мисалы.

Төрмә тәрәзәсе,
Башым куям,
Җил сагынган —
чәчем туздыра,
Төрмә салкын,
Тик шулай да
Мин янамын,
нәрсә кыздыра!
Мин хәзергә тимер читлектә,
Ник саклыйлар минем көчемне!
Янар таулар кебек
айкаламын
Алыр өчен соңгы көчемне.

Соңыннан, шактый еллар узып, аяз планета күгендә кара золым болытлары күренгән көннәрдә, солдат-шагыйрь җирдәге тынычлык, яшьлек өчен, Германия комсомолын тимер читлектән — фашизм тырнагыннан азат итү өчен, кулына мылтык алып, изге Ватан сугышы уты эченә керер. Рейхстаг түбәсенә Советлар байрагы — җиңүчеләр байрагын кадарга санаулы көннәр калганда, үлем белән йөзгә-йөз килеп, сугыш кырында ятып калыр...

*
*   *

1928 елның августы азакларында «Яшь язучылар түгәрәге»нең чираттагы утырышы Кызыл Армия сафына китүче берничә яшь язучыны озату кичәсе төсендә уздырылды. Армия сафына китүчеләр исемлегендә мин дә бар идем. Зал тулы яшьләр — югары уку йортлары һәм техникум студентлары. Егетләр, кызлар. Өс-баш ала-кола, әмма пөхтә, йөзләрендә шатлык балкый. Күрешүләр, танышулар. Яңа күтәрелеп килгән татар совет әдәбиятына, аның каләм ияләренә игътибар чиксез зур. Кызыксыну үзәгендә, әлбәттә, олы әдипләр — остазлар, алар безнең түгәрәк утырышларына бик теләп килә, теләп катнаша иделәр...

Кичәдә каләмдәш дусларның нинди шигырьләр укуы хәтердә калмаса да, Фатих Кәрим укыган шигырь бүгенгедәй хәтеремдә. Бу Фатихның миңа багышлаган «Гармун» исемле шигыре иде.

Әлеге кичәдән соң, Фатих белән бергәләп, олы дустыбыз — остазыбыз Такташка кереп чыгарга булдык. Атаклы шагыйрь безне ачык йөз белән шатланып каршы алды. Такташ гаҗәп матур итеп, юмарт итеп шатлана белә, мондый чагында аның шатлыгы бөтен йөзенә җәелеп, зәңгәр күзләрендә ут балкый иде.

Сүзләр әле генә Казанны шаулатып-гөрләтеп узган бер зур вакыйга — Алексей Максимович Горькийның Казанда кунак булып китүе турында барды башта. Аннан Такташны тыңладык. Аның әдәбиятка кагылышлы фикерләрен, аерым шагыйрьләр иҗаты турындагы гаять кызыклы билгеләмәләрен ишеттек. Соңгы вакытларда үзенә карата субъектив тәнкыйтьнең «модалашып» баруы һәм шул эшкә кайберәүләрнең аңлы рәвештә алынуларына да көенеп алдык.

Бу очрашудан соң күп тә узмый, «Яңалиф» журналының 1929 ел 7 нче санында «Берәү» имзасы астында Такташ иҗатына караган ямьсез мәкалә басыла. Фатих Кәрим «Совет әдәбияты» журналының 1935 елдагы 2 нче санында, теге «Берәү» чыгышының тиешле каршылык очратмыйча кала бирүе өчен көенеп, «совет шагыйренә, совет поэзиясенә кул салдырырга ирек бирмәскә кирәк», дип язып чыга.

Атаклы шагыйрь Фатих Кәримне аеруча якын итте. Мондый иҗади якынлык, дуслык шул көннәрдә бергә төшкән истәлекле фото артындагы язулардан аеруча калку күренә. Менә ул язу:

«Такташ абый! Син: «Мине сүгәләр», — дип, бервакыт зарланган идең. Ләкин алар сирәк теллләрдән чыккан сүзләр...

Без синнән өйрәнәбез, син безнең өчен кыйммәтле. Синең белән якын мөгамәләдә булуымны үземнең бурычым итеп саныйм.

Ф. Кәрим, Казан, 12 сентябрь, 1928 ел.»

*

* *

Без, 22 не тутырып, армия сафларына киттек. Фатих калды. Әле аңар 19 яшь кенә иде...

Батыр комдив Якуп Чанышев командалыгындагы укчы дивизиянең кызыл армеецлары булып хезмәт итү еллары, без яшь язучылар өчен үзебезнең дә, иҗатыбызның да чыныгу һәм үсү еллары булды...

Әдәбият һәм сәнгать Кызыл Армия тормышыннан илһамланып язылган әсәрләр — повесть, хикәяләр, пьесалар, шигырьләр, җырлар белән баеды. Яшь композитор Салих Сәйдәшев тә, бу иҗади күтәрелештә катнашып, «Совет Армиясе маршы»н яза. Еллар үтә торды. Тынычлык чоры тудырган идея коралы арсеналына Ватан сугышы солдатлары Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Нур Баян, Хәйретдин Мөҗәй, Фатих Кәрим, Әсгать Айдар, Гали Хуҗи, Шәрәф Мөдәррис, Демьян Фәтхи, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Салих Баттал, Әхмәт Исхак, Әхмәт Ерикәй Зәки Нуриларның сугыш утында, партизан учаклары ялкынында туган җырлары, шигырьләре, поэмалары кушылды...

Әйе, әле язылмаган истәлекләр, Фатих Кәрим васыять итеп калдырганча:

**Сөйләр сүзләр бик күп алар,**
**Иренмичә сөйләсәң;**
**Озын сүзнең кыскасы шул,**
**Күп яшәргә теләсәң:**
**Үлем турында уйлама,**
**Илең турында уйла,**
**Илең турында уйласаң,**
**Гомерең озын була.**

Бүген, җиргә ап-ак карлар яуган шушы январь көннәрендә, без, ике шагыйрьнең — Такташ һәм Ф. Кәримнең — яшьлекләре белән очрашабыз. Алар поэтик үлемсезлеккә яшьләй кереп калдылар. Ил турында уйлап, киләчәккә карап, бишьеллыклар аша коммунизм кырын күреп, шуңа дан җырлап иҗат итте алар...

## Фатих Кәрим

•

Сөйләр сүзләр бик күп алар,
Иренмичә сөйләсәң;
Озын сүзнең кыскасы шул,
Күп яшәргә теләсәң:

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

1942

### Ватаным өчен

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен;
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.

Кала дөнья, кала бар матурлык,
Ал чәчәкләр кала болында;
Чәчәкләргә төренеп эзем кала,
Җырым кала үткән юлымда.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе;
Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

1942

## Минем җырым

Идел ярындагы ак каенның
Яфраклары шаулый җилләрдә;
Назлы аккош җырлый тугайдагы
Төнбоеклы тонык күлләрдә.

Ак каенның җиләс күләгәсе.
Күләгәдә, иркәм, мин дә син;
Аерылганда әйтер сүзләремне
Күзләремә карап сизәсең.

Ак каенга сөялгән ике рәсмем
Елмаялар ике күзеңдә;
Шулай калса алар, сагынганда
Карар идең мине көзгедән.

Аерылабыз, иркәм, мин китәмен
Ватан сугышлары кырына;
Тик онытма, син онытма мине,
Кушып җырла моңлы җырыңа.

Кил, бер үбим, алсу иренеңә
Куныл калсын яшьлек ялкыным;
Мине сагынып искә алган чакта
Истәлегем булып балкыр ул.

Кил, тартынма, сыен кочагыма,
Юк, урынсыз хәзер оялу;
Син бит минем яшьлек хисләремнең
Чәчәкләргә төргән хыялы.

Хыял, татлы хыял,
Ул, яшьлекнең
Киләчәккә җәйгән канаты;
Ул — тормышны бөтен авырлыгы,
Матурлыгы белән ярату.

Кояш баеганчы калыккан ай
Нурсыз, төссез булган шикелле,
Боек, сүлпән, омтылышсыз була
Хыялсыз көн иткән һәр кеше.

●

Назлы аккош җырлый тугайдагы
Төнбоеклы тонык күлләрдә;
Идел ярындагы ак каенның
Яфраклары шаулый җилләрдә.

Ак каенның яшел яфраклары,
Бу дөньяда мәңге тормассыз,
Көз җитүгә сез дә коелырсыз,
Минем белән, әйдә, җырлагыз!

Мәхәббәтне мактап җырлыйк бергә,
Ярдәм итсен безгә кичке җил,

Һәм тирбәтеп агып китсен алга
Дулкынланып аккан киң Идел.

Мәхәббәтнең күле булсын иде,
Һәм коенсаң иде бу күлдә...
Юк, булмасын, булган тиклесе дә
Диңгез булып шаулый күңелдә.

1942

## Исә җил

**1**

Исә җил, тирбәлә тирәк.
Ул тирбәлә, ә йөрәк?
Йөрәгем яна минем.
Яна көндез, яна кичен,
Синең өчен, Туган илем,
Синең язмышың өчен.

**2**

Исә җил, тирбәлә камыш.
Ул тирбәлә, ә сагыш?
Ник бу чаклы сагынам?
Сагынсам да, ничек барыйм?
Карыйм мин Урал ягына,
Офыклар аша карыйм.

**3**

Исә җил, тирбәлә нарат,
Ул тирбәлә, ә Хәят?
Хәятым нишли икән,
Патронны мин аткан санда
Ул ясап өлгерә микән,
Өлгерә микән анда?

**4**

Исә җил, тирбәлә тирәк,
Ул тирбәлә, ә йөрәк?
Йөрәгем яна минем,
Яна көндез, яна кичен,
Синең өчен, Туган илем,
Синең язмышың өчен.

1942

## Сагындым

Идел буйларына тагын
Әйләнеп кайтсам иде,
Ал чәчәкләр арасында
Бер җырлап ятсам иде.

Җир җиләге белән мине
Иркәм сыйласа иде,
Элеккечә бер иркәләп,
Башым сыйпаса иде.

1943

# БУРНАШ БЕЛӘН ЯҢА ОЧРАШУ

Татар совет әдәбиятының күренекле вәкилләре, аның нигез салучылары турында сүз алып барганда, без һәр вакыт зур ихтирам һәм тирән соклану белән Фәтхи Бурнаш исемен дә телгә алабыз. Күренекле шагыйрь һәм драматург, ялкынлы публицист, принципиаль тәнкыйтьче, танылган тәрҗемәче һәм актив җәмәгать эшлеклесе буларак, ул татар әдәбияты тарихында онытылмаслык эз калдырды. Фәтхи Бурнашның киң колачлы әдип, күп кырлы талант иясе булуы хакында аның бай иҗат мирасы бик ачык сөйли. Ул—20 дән артык сәхнә әсәре, 5 либретто, 30 поэма, 200 гә якын шигырь һәм ярты мең чамасы публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләре авторы. Шушылар янына аның тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләрен дә (А. С. Пушкинның «Евгений Онегин», И. С. Тургеневның «Аталар һәм балалар», А. М. Горькийның «Ана» романнары һ. б.) өстәсәк, картина тагын да тулылана төшәр.

Ф. Бурнаш иҗаты белән бүгенге укучылар шактый яхшы таныш. 1959 елда Татарстан китап нәшриятында басылган ике томлы «Сайланма әсәрләре»енә, шуннан соң дөнья күргән «Яшь йөрәкләр» исемле пьесалар җыентыгына аның поэзия һәм драматургия өлкәсендәге иң әйбәт әсәрләре туплап бирелде. Соңгы елларда әдип турында монография (А. Әхмәдуллин. «Фәтхи Бурнаш», Казан, 1967) һәм газета-журналларда байтак мәкаләләр басылды. Шунысы куанычлы: Ф. Бурнаш иҗатын өйрәнү, аның әдәби мирасын барлап матбугатта чыгару һаман дәвам итә. Күптән түгел бу мирас укучылар алдында үзенең тагын бер яңа ягы белән ачылды: язучының әдәбият һәм сәнгать турындагы мәкаләләре һәм рецензияләре аерым җыентык булып дөнья күрделәр [1].

Җыентыкка 1921 елдан 1939 елга кадәрге вакыт аралыгында язылган 26 мәкалә тупланган. Алар Ф. Бурнашның 20—30 еллар дәвамында яшь татар совет әдәбиятын үстерүгә, аны социалистик реализмның олы юлына чыгаруга әдәбият белгече буларак керткән өлешен күз алдына китереп бастыралар.

Илебездәге башка милли әдәбиятлар кебек үк, татар әдәбияты да совет чорына социалистик реализмның әзер кануннары белән коралланган хәлдә килеп кермәде. Яңа иҗат методы озакка сузылган көрәш һәм эзләнүләр нәтиҗәсендә туды һәм ныгыды. Бу процесста аеруча кискен идея-эстетик бәхәсләр мирас һәм традицияләр мәсьәләсе тирәсендә барды. Бу принципиаль бәхәстә үзенең әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән Фәтхи Бурнаш та актив катнашты. Элекке демократик культура мирасын яңа коммунистик культура төзүдә файдалану кирәклеге турында В. И. Ленин һәм партия өйрәтүләренә таянып, Ф. Бурнаш пролеткультчыларга, аларның иске мирасны тулысы белән себереп түгәргә маташуларына каршы килешмәүчән көрәш алып барды. Бу бигрәк тә аның Тукай иҗатына мөнәсәбәтендә ачык күренә. «Тукай милләтче», «Тукай буржуа шагыйре» дип расларга тырышучыларга отпор биреп, 1922 елда ук ул «Тукай шигырьләрендә иҗтимагый моңнар» дигән мәкалә язып бастырды. Бурнаш Тукайның буржуа шагыйре булмау гына түгел, бәлки, киресенчә, үзенең каләме белән изүче сыйныфларга кар-

[1] Фәтхи Бурнаш. Әдәбият һәм сәнгать турында (мәкаләләр, рецензияләр). Төзүчеләре Азат Әхмәдуллин, Назим Ханзафаров. Татарстан китап нәшрияты, 1978.

шы аяусыз көрәшкән булуын кире каккысыз дәлилләр белән раслады. Тагын бер елдан соң язылган «Тукай турында тәнкыйтьчеләр» исемле мәкаләсендә исә Тукайның халыкчанлыгы мәсьәләсен аеруча калку итеп куйды. «Тукай,— дип яза Ф. Бурнаш,— чын мәгънәсе белән халык, гаммә шагыйре булып... үзенең бөтен тарихын, тормышын гаммә белән нык бәйләгән, аның шатлыгы белән шатланып, аның хәсрәтләре белән генә янган, бөтен иҗатын гаммәнең үз карашы, үз хыяллары, үз типлары, үз темалары белән тоташтырган, буржуа шагыйрьләренең «мин-минлек» музаларын җимереп, гаммә күгендә гөмбәз булып утырган халык шагыйре иде.

Пролетариат тәнкыйтьчеләре дә менә шул ноктадан чыгып кына аның иҗатын мәңгегә гаммәнең үз малы, үз милке итеп кабул итәргә һәм аның канат читен дә буржуа кулына бирмәскә тиешләр».

Классик мираска мөнәсәбәтендә Ф. Бурнашның эзлекле, нык караштa торуын башка мисаллар белән дә раслап була. Җөмләдән берсе — «юлаучы» язучыларга мөнәсәбәт. 20 нче елларда «юлаучылар»-га, ягъни иҗат эшчәнлекләре революциягә кадәр үк башланган язучыларга тамырдан хата карашлар яшәп килде. Моның тарафдарлары «юлаучылар»ның иҗаты һәм язу методлары инде искерде, яңа әдәбиятны бары тик яшьләр генә тудырырга тиеш дип чыктылар. Атап әйткәндә, бу таләп К. Нәҗминең 1926 елда басылган аерым мәкаләләрендә катгый төстә куелды. Җыентыктагы «Кирегә киртә сикермәскә кирәк» дигән мәкалә әнә шуларга җавап төсендә язылган. Фәтхи Бурнаш әлеге карашның партия сәясәтенә турь килмәвен аңлата, «без, иске язучыларның партия-совет платформасында мәдәният төзешергә сафыбызга килүчеләрне «долой!» дия алмыйбыз. Аларда партия-совет җәмәгатьчелеген алга җибәрү өчен хезмәт итәрлек никадәр мәдәни, иҗади көч булса, без алардан файдаланабыз, без аларга юл куябыз», дип күрсәтә.

Фәтхи Бурнашның полемика-бәхәс төсендә язылган мәкаләләрендә («Матур әдәбият тирәсендә», «Бу турыда нык җитәкчелек кирәк» һ. б.) яңа социалистик әдәбият нинди булырга, кемгә хезмәт итәргә тиеш дигән мөһим сорауларга җавап эзләнә. Бурнаш басым ясап күрсәткәнчә, әдәбият «социализм төзелешенең большевикларча темплары белән бер эздән барырга, хезмәт иясенең социализм планын үтәү өчен көрәшләрен, каһарманлыкларын үзендә гәүдәләндерергә тиеш». Ләкин, әдип, вульгар социологларча, бөтен игътибарны әсәрнең коры идея ягына гына юнәлтүдән ерак тора. Алай гына да түгел, ул моңа каршы ныклы көрәш алып бара. Форма һәм эчтәлек мәсьәләсендә партия өйрәтмәләренең асылын дөрес аңлап, Ф. Бурнаш татар әдәбиятында да урын алган төрле формалистик агымнарны кат-кат тәнкыйть итә. Шул ук К. Нәҗминең «партия җитәкчелеге измнар, формалар мәсьәләсенә кагылмый, партия җитәкчелегенең авырлык үзәге әдәбияттагы идеологиягә салынган» дигән хата карашын кире кагып, партия җитәкчелегенең әдәбиятны «футуризм, имажинизм кебек, массаның фикерен тәрбияләүне читкә ыргытучы, тышкы оригинальлеккә, формализмга бирелүче» агымнарның басып китүеннән саклау өчен дә кирәклеген әйтеп чыга. Матур әдәбият «эшче-крестьян массасының зәвыгын, рухын даими тәрбия эченә алырлык чын иҗади һәм сәнгатьчә төс алырга тиешле», ди Бурнаш. Җае чыккан саен ул әдәби осталыкка Г. Тукай, Ф. Әмирхан кебек классик язучылардан өйрәнергә чакыра.

Шул рәвешчә, Ф. Бурнашның теоретик планда язылган күп кенә мәкаләләре татар совет әдәбиятын үстерүгә, аңарда партиялелек һәм халыкчанлыкның тирәнәюенә сизелерлек тәэсир ясыйлар. Тәнкыйтьче буларак, Бурнаш аерым язучыларның иҗатларына, яңа әсәрләргә, спектакльләргә багышлачган мәкаләләр белән дә матбугатта даими чыгыш ясап бара. «Муса Җәлил шигырьләре» дигән рецензиясе аның яшь каләмнәрне үстерүдә никадәр таләпчәнлек, кайгыртучанлык, сизгерлек күрсәтүе турында бик ачык сөйли. Әхмәт Фәйзинең «Качкын» либреттосына язылган рецензиясе исә яшьләрне әдәби осталыкка өйрәтүнең матур бер үрнәге булып тора.

Җыентыкны укыганда Ф. Бурнашның культурабызның күп төрле өлкәләре белән якыннан кызыксынган булуы, үзе яза торган теманың асылына яхшы төшенеп эш итүе сокландыра. Менә ул композитор Солтан Габәши оештырган хор концерты турында тирән тәэсирләнеп рецензия белән чыга, хор эшчәнлеген җыр-музыка өлкәсендә «теоретик, гыйльми, мәгълүм техника кануннары нигезендә иҗат итүгә» күчү юлында алга таба бер адым дип бәяли. Яки Мәскәүдә үткәрелгән казакъ сәнгате декадасы уңае белән «Кыз Җефәк» һәм «Җалбыр» исемле музыкаль спектакльләр-

гә төпле анализ биреп, «формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик булган казакъ совет сәнгатенең балкып, чәчәк атуына» сөнә. Бөек рус шагыйре М. Ю. Лермонтовның 125 еллык юбилее алдыннан «аның шигырьләрен, поэмаларын, пьесаларын һәм прозаик әсәрләрен тәрҗемә итеп халкыбызга җиткерү, Лермонтов иҗаты өстендә эшләп, язучыларыбызның иҗат көчләрен үстерү» бурычын күтәрә. Төп иҗат эшчәнлеген драматургия өлкәсенә багышлаган Ф. Бурнаш үз вакытында, Татар дәүләт академия театры директоры буларак, театрны үстерү, аның репертуарын яхшырту, артистларның башкару осталыгын күтәрү юнәлешендә актив эшчәнлек күрсәтә. Җыентыкта әдипнең шушы мәсьәләләргә караган мәкалә һәм рецензияләре дә шактый.

Революциянең беренче айларыннан ук большевистик матбугат фронтында җиң сызганып эшкә керешкән, «Кызыл Армия», «Кызыл Татарстан», «Чаян», «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») кебек газета-журналларга редакторлык иткән Ф. Бурнаш вакытлы матбугат турында да күп язган. Матур әдәбиятны үстерү турында сүз алып барганда ул еш кына һәм бик хаклы рәвештә матбугат һәм нәшрият эшен яхшырту бурычларын да куя («Матбугат, әдәбият тирәсендә», «Матбугат һәм әдәбият» h. б.).

Рецензияләнә торган җыентык А. Әхмәдуллинның кереш мәкаләсе белән ачыла. Мәкалә авторы Ф. Бурнашның әдәбият һәм сәнгать тәнкыйте өлкәсендәге эшчәнлегенә җентекле анализ ясый, бу эшчәнлекнең төп әһәмиятле якларын ачыклый, бер үк вакытта Ф. Бурнашның аерым хаталарын да искәртә. Кыскасы, кереш мәкалә җыентыкның эчтәлеген тагын да тулырак аңлау өчен ышанычлы ачкыч ролен үти. Китап ахырында бирелгән «Искәрмә һәм аңлатмалар» бүлеге дә шушы максатка хезмәт итә.

Йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: Фатхи Бурнашның бу җыентыгын чыгарып, Татарстан китап нәшрияты һәм төзүчеләр бик кирәкле эш башкарганнар. Беренчедән, бу китап үзенең төп положениеләре белән әле бүгенге әдәби процесс өчен дә зур әһәмияткә ия. Икенчедән, ул әдәбият, театр, матбугат тарихыбызны һәм, әлбәттә, Фатхи Бурнаш иҗатын өйрәнү өчен кыйммәтле чыганак булачак.

Билгеле, җыентыкны тагын да баерак һәм тулырак итеп төзергә мөмкин булыр иде. Биредә әле әдипнең бай кульязма архивы аз файдаланылган (бары бер текст— «Качкын» либреттосына рецензия алынган). Шулай ук рус телендә басылган мәкаләләреннән берсен дә җыентыкта күрмибез. Безнеңчә, «Красная Татария»дәге Мөхәммәт Гали, Фатих Әмирхан, Габдулла Кариев турындагы материаллар игътибарга лаеклы.

Ф. Бурнаш Тукай турында күп язган автор. Аның «Тукайны сагыну» («Көн» газетасы, 1919, 17 апрель), «Тукайның тормышы, шәхесе» («Татарстан», 1923, 15 апрель), «Тукай турында тәнкыйтьчеләр» («Безнең юл», 1923, 8—9 саннар) кебек мәкаләләре әлегә бу җыентыктан читтә калганнар.

Соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты классик язучыларның күп томлы сайланма әсәрләрен бастырып чыгару юлында күркәм эш алып бара. Якын киләчәктә Фатхи Бурнашның да шундый басмасын хәзерләп, аның бер томын язучының әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтләренә багышлау бик урынлы булыр иде.

**ХУҖИ МӘХМҮТОВ,**
**филология фәннәре кандидаты**

# БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧ

Совет властеның беренче елларыннан алып, безнең көннәргәчә матбугат һәм полиграфиябезнең үсеш юлларын һәрьяклап яктырткан бу китапта [1] язучыларыбыз һәм журналистларыбызның хезмәтләренә дә лаеклы урын бирелгән. Хәер, матбугат һәм полиграфия өлкәсендә генә түгел, мәдәниятнең кайсы гына тармагына күз салмыйк, әдипләр катнашмаган, алай гына да түгел, алар башлап йөрмәгән тармак бар микән? Әйтик, театр сәнгатен үстерү, шул җөмләдән үзешчән сәнгатьне булдыру һәм аның эчендә кайнап актив эшләүдә Галиәсгар

[1] В. Гафуров, З. Мифтахов. Развитие полиграфии и печати в Татарии. КГУ нәшрияты, 1977 ел, 267 бит.

Камал, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Фәтхи Бурнаш, Риза Ишморат, Әнәс Камал кебек драматургларыбыз тәпкә җигелеп хезмәт иттеләр. Алар, сәхнә әсәрләре язу белән бергә, кайсы артист, кайсы режиссер, кайсы театрның әдәби бүлек мөдире яки директорлары булып та эшләделәр. Күп кенә әдипләребез, мәсәлән, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Фатих Сәйфи-Казанлы, Әхмәт Фәйзи, Садри Җәләл, Гази Кашшаф, Хатип Госман кебекләр халык мәгарифенең иң актив педагоглары һәм югары уку йортларының укытучылары булдылар. Казанда беренче радио тапшыруларын Шамил Усманов һәм журналист Исмәгыйль Усмановлар оештырып җибәрде. Соңрак бу эшне Хәсән Туфан, Гариф Гобәй, Әхмәт Ерикәй һәм башкалар дәвам иттерде. Драматург Мирхәйдәр Фәйзинең үлмәс «Галиябану»ын һәм башка кайбер әсәрләрен авыл китапханәсендә эшли-эшли иҗат итүе мәгълүм. Завод-фабрикаларыбызның яңа гына ачылган кызыл почмакларында һәм беренче колхозларыбызның клубларында да язучыларыбыз эшләвен беләбез. Мәдәният учакларын гөрләтеп кабызуда йөрәк ялкыннарын кызганмаган бик күпләр башта әдәбиятны яратучылар гына булып, тора-бара үзләре дә журналист яки язучы булып киттеләр.

Мәдәниятебезнең барлык тармакларын үстерүне полиграфия һәм матбугаттан аерым күз алдына китерү мөмкин дә түгел. Әнә шушы хакыйкатьне яхшы төшенгән әдипләребез Совет властеның беренче елларыннан ук матбугат һәм полиграфиябезне үстерүдә бөек Ленин тарафыннан куелган кичектергесез бурычларны аңлап эш иттеләр.

Әлеге китапның беренче битләрен ачу белән үк укучы Фатих Әмирхан, Галимҗан Нигъмәти, Һади Такташ һәм башка күренекле әдипләребез, журналистларыбыз белән очраша. Әле моңа хәтле китапларын укып кына белгән бүгенге укучы, бигрәк тә яшьләр, әдипләребезнең фидакарь хезмәтләре белән якыннан таныша ала. Аларны редактор, корректор, газета-журнал хезмәткәре буларак типография цехларында очратабыз икән, бу күренеш укучыны бер дә гаҗәпкә калдырмас. Чөнки без әдипләребезнең полиграфчылар белән көндәлек элемтәдә булуларын яхшы беләбез. Бу чын мәгънәсендә иҗади дуслык иде.

Иҗади дуслык дигәннән, әнә шул дуслыкны ачык раслаган характерлы бер мисалга тукталыйк. Мәгълүм ки, егерменче еллар ахырларында Һади Такташ үзенең мәшһүр «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасын иҗат итте. Әсәрнең төп геройлары — Зөбәйдә һәм наборщик егет. Сүз уңаенда гына булса да шуны искәртеп китәргә кирәк, Такташка хәтле һәм әле безнең көннәрдә дә татар әдәбиятында шактый кыен, мәшәкатьле, әмма мактаулы бу хезмәт— наборщик хезмәтен иске алучы булмады кебек. Үз вакытында «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре Такташка типографиядә бик еш булырга туры килә. Шулай бер көнне шагыйрь корректор булып эшләүче, үзенә якын таныш булган чибәр кызның боегып утыруын күреп ала. Кызыксына торгач, ул аның бер наборщиктан йөкле булып калуын белә, ә наборщик исә сөйгән кызына кырын карый башлаган, туачак баласын да танырга теләми. Чын мәхәббәтне чәлпәрәмә китергән бу коточкыч хәл шагыйрьне тәмам тетрәтә һәм бер әсәр язу хисен уята. Аны ул «Мәхәббәт тәүбәсе» дип исемли. Баштарак кыз белән егенең бик тә яратышып йөргәннәрен белеп, ул поэманың беренче юлларын:

**Җырлыйм Зөбәйдәнең наборщикка**
**Булган көчле гыйшкы турында...**

— дип башлый. Һәм наборщикка тирән нәфрәтен белдереп, болай дип дәвам итә:

**Кайда син, әй ата булыр кеше,**
**Шулмы инде синең сөюең!**
**Шулмы инде синең Зөбәйдәгә:**
**комсомолкам, бәгърем! диюең.**

Күрәсең, шагыйрь абыеның нәфрәт белән язган бу чәнечкеле юллары наборщикка тәэсир итми кала алмый һәм ул шунда ук типографиядән чыгып, больницага Зөбәйдәсе яткан палатага ашыга..

Әдипләребезнең типографиядә эш арасында, кичләрен һәм төннәрен калып корректорлар бүлмәсендә иҗат эше белән шөгыльләнүләре турында тагын да мисаллар китерергә мөмкин булыр иде. Ләкин бу күзәтүдә безнең күбрәк полиграфия һәм матбугатның үсеш юлларын ачыклауга тукталасыбыз бар.

Мәгълүм ки, революциягә хәтле үк Казанда һәм өяз шәһәрләрендә хосусый вак типографияләр байтак булган. Әмма хал-

кыбызның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек полиграфия базасы Октябрьдән соң гына барлыкка килә. Башта эрерәк типографияләр, ә егерменче еллардан алып уннарча вак типографияләр национализацияләнә. Бу процесс байтак елларга сузылып, Казанда полиграфия техникасы белән коралланган зур ике типография — «Татполиграф» һәм Камил Якуб исемендәге типография оештырыла. Ниһаять, татар халкы бөек Ленин һәм марксизм классиклары китапларын, татар язучыларының әсәрләрен үз туган телендә күпләп укуга ирешә.

1924 елның көзендә партиянең Татарстан өлкә комитеты каршында марксизм-ленинизм классиклары әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп чыгару буенча Галимҗан Ибраһимов җитәкчелегендә махсус комиссия төзелә. Бу комиссия составында Исхак Рәхмәтуллин һәм журналист Латыйф Гомәровлар да эшлиләр.

Безнең типографияләр һәм нәшриятларыбызда халыклар дуслыгын чагылдырган бер матур традиция яшәп килә. Бу турыда китапта күп санлы мәгълүматлар бирелгән. Мондый күркәм традиция безнең көннәрдә тагын да көчәеп, башлыча, өч тармакта дәвам итә. Беренчедән, Казанда басыла торган китапларның зур өлеше бөтен республика һәм өлкәләргә озатыла. Икенчедән, полиграфия комбинаты менә инде күп еллардан бирле төрекмән, казакъ, каракалпак һәм башка кайбер халыклар телендәге әдәбиятны бастырып чыгару белән дә шөгыльләнә. Өченчедән, «Татполиграф»ның хәреф кою цехы байтак еллар буена күп кенә милли типографияләрне хәреф кассалары белән тәэмин итеп килә. Бу турыда китапта шактый кызыклы материаллар тупланган.

Егерменче еллар урталарында китап продукциясе чыгару күзгә күренеп үсә башлый. 1923 елда нибары 59 исемдә китап басылып, аның гомуми тиражы 400 мең чамасы булса, 1929 елда инде 1 миллион 200 меңнән артык тираж белән 270 исемдә китап чыгарыла. 1925 ел башында Казанда татар һәм рус телләрендә 7 журнал, шул исәптән «Безнең юл», «Октябрь яшьләре», «Мәгариф», ә бераз соңрак «Чаян», «Азат хатын», «Авыл яшьләре» журналлары дөнья күрә башлый. 20 нче еллар ахырында Татарстанда кантоннар бетерелеп, 43 район төзелә, һәм аларның барысында да диярлек типографияләр булдырыла, район газеталары чыга башлый. Район типографияләрен җиһазландыру, аларның полиграфия базаларын ныгытуда «Татполиграф» коллективы зур булышлык күрсәтә. Полиграфия өлкәсендә әзерлекле кадрлар да ярдәмгә килә. Шул ук елларда күп кенә журналистлар, язучылар районнарга редакторлар һәм әдәби хезмәткәрләр булып даими эшкә китәләр.

Газета-журналларның һәм китапларның тиражлары сизелерлек арткан саен, басма әдәбиятны киң катлау укучыга җиткерү шулай ук язучы һәм журналистның актив катнашы белән алып барыла. Шул уңайдан 1929 елның җәендә зур бер группа күренекле татар язучылары, журналистлар һәм танылган сәнгать осталарының Астрахань, Махачкала, Баку, Тбилиси, Ялта, Харьков һ. б. күп кенә шәһәрләрдә булып кайтулары зур роль уйнады. Ике ай буена дәвам иткән бу сәяхәттә алар язучылар оешмаларында, нәшрият һәм типографияләрдә, китап сәүдәсе коллективлары белән эшлекле очрашулар үткәрделәр. Киң катлау укучылар белән дә һәр шәһәрдә әдәби кичәләр үткәрелеп, татар әдәбиятының һәм сәнгатенең үсеш юллары, бүгенгесе һәм киләчәге белән таныштырылды.

50 нче еллар урталарында исә, союз күләмендә бердәнбер буларак, Казанда өлкәара китап базасы ачылу татар әдәбиятының үсү юлын тагын да ачыграк чагылдырды. Әнә шул еллардан башлап автономияле республикалар, Идел буе һәм Урал өлкәләрендә генә түгел, союздаш республикаларның күп кенә китап кибетләрендә татар әдәбияты бүлекләре булдырылды.

Китап пропагандалауда язучыларыбызның мактауга лаеклы хезмәтләрен күрсәтеп үтү урынлы булыр. Без берничә мисалга гына тукталабыз. Уфада һәм Ташкентта үткәрелгән союзкүләм китап күргәзмәләре һәм китап ярминкәләрендә язучы Әмирхан Еники катнашты. Язучы киң катлау укучылар һәм китап сөючеләр белән кабат-кабат очрашып, аларны әдәбиятыбызның үсеш юллары, Татарстан китап нәшриятының тематик планнары белән таныштырды, китап магазиннарында, китапханәләрдә булды. Нәтиҗәдә, бу шәһәрләрнең китап сәүдәсе оешмалары татар китапларына заказлар бирә башладылар. Шушындый ук нәтиҗәле очрашулар Алма-Атада һәм Казакъстанның башка шәһәрләрендә дә еш үткәрелеп, анда

язучы Ибраһим Сәләхов, Нури Арсланов һәм композитор Латыйф Хәмиди катнашты. Шуны да әстәп әйтергә кирәк, композитор бүген дә Алма-Атаның китап кибетләрендә еш булып, татар китапларын кайтарту эше белән даими шөгыльләнеп килә. Белоруссиядә һәм Кыргызстанда Зәки Нури, Астраханьда Габдрахман Минский белән журналист Солтан Таһиров, Чиләбедә Атилла Расих, Свердловскида Самат Шакир белән Зиннәт Вәли һ. б. язучылар, журналистлар булып, китап магазиннарында татар әдәбияты бүлекләре ачуда булыштылар.

Шундый эшлекле чаралар һәм халкыбызның культура ихтыяҗлары елдан-ел үсә баруы нәшрият һәм полиграфия коллективлары алдына мактаулы бурычлар куя. Һәм, әйтергә кирәк, бу бурычларны үтәү юлында хәзер дә күп кенә чаралар тормышка ашырыла. Күзәтелә торган китаптан берничә генә мисал китерик. 1971—1976 нчы елларда Татарстан китап нәшрияты 1980 исемдә китап һәм брошюралар бастырып, аларның гомуми тиражы 36 млн. данәдән артып китә. Нәшрият һәм полиграфия коллективлары В. И. Ленинның 45 томлык әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп бастырып чыгаруны тәгәлләде. Бөек юлбашчыбызның биографиясе «В. И. Ленин һәм Татарстан» дигән хезмәтләр зур тиражларда шулай ук татар телендә басылып таралды. Язучыларыбыздан Риза Ишморат, Сибгат Хәким, Мостафа Ногман, Гали Хуҗи һәм башкаларның Ленин темасына багышлап язылган әсәрләре кабат-кабат басылып дөнья күрде. Бөтенсоюз төзелеше булган КамАЗ турында нәшрият 75 исемдә төрле китап һәм брошюралар бастырып, аларны союз укучысына тәкъдим итте.

Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты, Мәскәү, Ленинград матбагаларыннан кала, илебезнең иң эре китап фабрикасына әверелде. Аның барлык цехлары полиграфия техникасының соңгы яңалыклары белән җиһазландырылып, алар белән идарә итүче уннарча, йөзләрчә хәзерлекле полиграфия кадрлары үсеп чыкты. Шулардан коммунистик хезмәт бригадасы (мастеры И. Кыямова), Хезмәт Кызыл Байрак ордены кавалеры технорук М. Вәлиуллин, КПССның XXV съезды исемендәге китап басу бригадасы ударниклары Г. Гарипов, Т. Җаббарова, Р. Йосыпов, Ленин орденлы фальсовщица С. Фәйзуллина, алдынгы линотипистка А. Ферафонтова һәм башка бик күпләрнең исемен горурлык белән искә алырга мөмкин.

Китапта республикабызның матбугат һәм полиграфия базасының үсеш юлларын чагылдырган рәсми материаллар, мисаллар, диаграммалар бирелгән. Аның битләре сирәк кулларда сакланып калган тарихи рәсемнәр белән бизәлгән. Мәсәлән, бертуган Кәримовлар типографиясендә эшләгән бер группа наборщиклар, полиграфчыларның язучылар һәм журналистлар белән төшкән рәсеме, 1928 елда матбугат работниклары съезды делегатлары, Татарстан матбугаты һәм полиграфиясе ветераннары, полиграфия комбинатының бүгенге алдынгыларының фоторәсемнәре бирелгән.

Бу күзәтүдә без күбрәк республикабыз матбугаты һәм полиграфиясен үстерүдә язучылар һәм журналистларның тынгысыз эшчәнлегенә игътибар юнәлттек. Әйе, безнең күпләгән әдипләребез, зур иҗат эшчәнлекләре белән мәшгуль булган хәлдә, матбугатыбызны һәм полиграфиябезне үстерү һәм китапны киң масса укучыга җиткерүдә мактауга лаеклы эш башкарып киләләр.

Әлеге күзәтүдә без кульязмада әзерләнеп тә, китапка керми калган кайбер мисаллардан да файдаландык. Китапны татар телендә бастырып чыгарганда һәм русчасының да алдагы басмасында бу өстәмәләр, шулай ук әлеге китап чыкканнан соң барлыкка килгән яңалыклар да өстәлсә яхшы булыр иде.

Соңгы ярты гасыр эчендә әле полиграфиябез һәм матбугат үсеше юлларын киң яктырткан китап юк иде. Бу — беренче карлыгач. Китап журналистлар, әдипләр һәм полиграфчылар өчен генә түгел, киң катлау укучыны да кызыксындырыр дип уйларга кирәк. Совет матбугаты бәйрәме көннәренә бер бүләк булыр бу китап.

**ГАРИФ МИҢНУЛ.**

# ЮЛ ДӘВАМ ИТӘ

*Тәнкыйтьче Роберт Бикмөхәммәтовка 50 яшь*



Аның республикабыз пионерлары һәм комсомолы матбугатында беренче мәкалә һәм рецензияләре басыла башлавына инде өч дистә еллар узып киткән. Әдәби түгәрәккә йөрүче яшьләр иҗатына, яшь буынның тормышка аяк басуы темасын яктыртучы әсәрләргә багышланган кечерәк күләмле ул язмалар әдәбият мәйданына дәртле яшь каләм иясе, кайнар рухлы тәнкыйтьче килүен хәбәр итәләр иде. Бу шулай булып чыкты да. Совет чынбарлыгы тудырган шартларда илебезнең иң мәртәбәле уку йортларында белем туплавы, Казан һәм Мәскәү матбугатында даими язышып, әдәби җыелышларда, конференцияләрдә катнашып, илебезнең әдәбият корифейларыннан туктаусыз өйрәнүе аңа санаулы еллар эчендә үткен һәм җитез каләмле тәнкыйтьче, киң эрудицияле әдәбият белгече булып үсеп җитәргә мөмкинлек бирде. Бүген исә без Роберт Бикмөхәммәтовны,— милли әдәбият вәкиле булып калган хәлендә,— бөтен союз күләмендәге әдәби процессны әйдәп баручы әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр арасында күрәбез.

Милли әдәбиятлардан интернациональ киңлеккә,— Р. Бикмөхәммәтовның иҗат юлын бер сүз белән әнә шул рәвешчә билгеләргә була. Чыннан да, аның эшчәнлегендә өч тел (татар, рус, башкорт телләре) стихиясе бергә кушыла. Зур иҗат потенциалына, гражданлылык темпераментына ия булган әдип Татарстан, Башкортстан республикалары әдәби җәмәгатьчелеге тормышында да, союз күләмендәге әдәби хәрәкәттә дә актив катнашырга өлгерә.

Татар һәм башкорт телләре моң-аһәңнәрен ул, күрәсең, әле Башкортстан АССРның Татарстан белән чиктәш районы Илештә үткәргән бала чак елларында, революция һәм гражданнар сугышы ветераны гаиләсендә үскән, ә аннары Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган чорларда күңеленә сеңдерә килгән. Сәләтле яшь тәнкыйтьчене биредә тиз күреп алалар һәм 1952 елда, университет курсын тәмамлауга ук, Татарстан Язучылар союзы рекомендациясе белән Мәскәүгә, А. М. Горький исемендәге әдәбият институты аспирантурасына укырга җибәрәләр. 1956 елдан алып ул А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтында, алтмышынчы еллар башында «Дружба народов» журналының баш редактор урынбасары булып эшли. Хәзерге көндә исә Мәскәү дәүләт университетының совет әдәбияты тарихы кафедрасында СССР халыклары әдәбиятлары секторын җитәкли.

Р. Бикмөхәммәтов әдәбият дөньясында заман рухын үткен тоючы тәнкыйтьче һәм киң теоретик гомумиләштерүләр ясарга сәләтле әдәбият галиме буларак танылды. Илленче еллар башыннан алып «Комсомолец Татарии», «Советская Татария», ә аннары «Комсомольская правда», «Литературная газета», «Дружба народов», «Вопросы литературы», «Литературное обозрение», «Казан утлары» һәм башка газета-журнал битләрендә, СССР халыклары әдәбиятлары үсеше проблемаларына багышланган төрле җыентыкларда тәнкыйтьченең күләмле мәкаләләре һәм саллы рецензияләре бер-бер артлы дөньяга чыга тора. Әдип бу мәкаләләрендә Г. Тукай һ. Такташ, М. Гафури калдырган олы мирасның бүгенге әдәби тормышыбызда тоткан урыны хакында уйлана, Ш. Бабич, Ә. Фәйзи, Х. Туфан, Г. Бәширов, С. Хәким, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов һ. б. язучы һәм шагыйрьләребезнең әсәрләрен анализлый, ул әсәрләрнең поэтик, стилистик һәм жанр үзенчәлекләрен тикшерә.

Тәнкыйтьче татар әдәбияты классигы Г. Ибраһимов, патриот шагыйрь Муса Җәлил иҗаты хакындагы монографик хезмәтләре белән бу олы әдипләрнең мирасын өйрәнүгә зур өлеш кертте. Аның 1957 һәм 1962 елларда Мәскәүдә басылып чыккан «Муса Җәлил. Биографик һәм тәнкыйть очеркы», «Муса Җәлил. Иҗат очеркы» исемле китаплары совет әдәбият белемендә күренекле урын тота.

Татар шагыйрьләренә багышланган аерым хезмәтләре тәнкыйтьченең милли поэзиядә традицияләрнең тоткан роле, татар шигъриятендә гасырлар буенча килгән традицион образлар, стиль чаралары тарихын тикшерүгә алып килә. Әдипнең бу тикшеренүләре 1960 елда Казанда «Поэзиябезнең сулмас чәчәкләре» исеме астында аерым басмада да чыкты.

Р. Бикмөхәммәтовның барлык бу хезмәтләре татар әдәбияты туплаган мәгънәви, эстетик кыйммәтләрне бөтен союз укучысына җиткерү, совет әдәбиятының уртак хәзинәсенә әверелдерүгә булыша. Ул үзенең фәнни-әдәби эшчәнлек колачын әлекле төстә киңәйтә килә. Тәнкыйтьче Ә. Фәйзинең «Тукай» романын совет тарихи романы калыбына салып тикшерә, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы хакында язганда социаль-политик роман үзенчәлекләрен дә гомумиләштерә, татар совет прозасында революция темасының ничек үзләштерелүен өйрәнә.

1960 еллар башыннан «Дружба народов» журналы битләрендә Р. Бикмөхәммәтовның илебез халыклары әдәбиятларының үзара йогынтысы, эчке бәйләнешләре, алар үсешендәге уртак тенденцияләргә багышланган фәнни мәкаләләре басыла башлый. Тәнкыйтьчене әдәбиятта миллилек һәм интернациональлек нисбәте уйландыра. Ул 1965 елда «Вопросы литературы» журналы оештырган дискуссиягә катнашып, илебезнең төрле әдәбиятлары, төрле язучылар иҗатының үзенчәлекле якларын өйрәнү аларның үсеш закончалыкларын билгеләүгә китерергә тиеш дип чыга.

Р. Бикмөхәммәтов рус әдәбияты белән илебезнең башка халыклары әдәбиятлары арасындагы үзара тыгыз бәйләнеш мәсьәләләрен җентекле өйрәнә, рус язучылары Л. Леонов, Ю. Бондарев, Ф. Абрамов, белорус язучысы В. Быков иҗатын Ч. Айтматов, А. Мохтар, К. Кулиев, Р. Гамзатов, Д. Кугультинов әсәрләре белән янәшә куеп карый, аларны чукча прозаигы Ю. Рытхеу, нивх В. Санги иҗатлары белән очраштыра, шул ук яссылыкта татар әдипләре Х. Туфан, С. Хәким, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, башкорт каләм осталары М. Кәрим, Ф. Исәнгуловларның иҗат дөньяларын күздән кичерә.

Төрле милләт язучылары әсәрләрен әнә шул рәвешчә янәшә куеп тикшерү тәнкыйтьчегә теге яки бу каләм иясенең алга таба үсеш перспективасын, милли әдәбиятларның киләчәк офыкларын гомумсоюз масштабыннан чыгып билгеләргә мөмкинлек бирә.

Илленче еллар ахыры, алтмышынчы еллар башларыннан алып Р. Бикмөхәммәтов үзәк журналлар битләрендә барган әдәби-тәнкыйть дискуссияләрендә, региональ һәм бөтен союз конференцияләрендә, Мәскәү, Прага, Лейпциг шәһәрләрендә үткән халыкара симпозиум һәм конгрессларда даими катнашып килә, үзенең чыгышларында әдәбиятларны өйрәнүдә чагыштырма-тарихи методология принципларын куллану, әдәбиятларның эчке бәйләнеш закончалыкларын билгеләү кебек җитди теоретик мәсьәләләрне күтәрә.

Р. Бикмөхәммәтов соңгы ун ел эчендә «Вопросы литературы» журналында бастырган күп кенә мәкаләләрендә күп милләтле совет әдәбиятын илебез һәм бөтендөнья әдәбияты тарихында зарури этап тәшкил итүче яңа тип әдәби бердәмлек итеп карый. Бу концепцияне ул Идел буе регионы әдәбиятларының тарихи үсеше һәм хәзерге чорына, Себер, Төньяк Кавказ һәм башка регионнар әдәбиятларына багышланган хезмәтләрендә тирәнәйтә килә. Әдәби-эстетик регионнарның генезисын ачу, бөтен союз әдәбияты үсешендә аларның тоткан урынын билгеләү совет әдәбиятының эчке бөтенлеген, структурасын һәм киләчәктәге үсеш перспективаларын тирәнтен аңлауга ярдәм итә. Р. Бикмөхәммәтовның «Яңа үсеш этабында» («Вопросы литературы», 1971 ел, 9 сан), «Дөнья әдәбияты биеклегенә куеп», (1975 ел, 6 сан), «Үткәне һәм бүгенгесе. Бөтендөнья әдәби процессында совет әдәби бердәмлеге һәм регионнары» (1977 ел, 3 сан) дигән һәм башка мәкаләләре нәкъ әнә шул максатларга хезмәт итәләр һәм совет әдәбият белемен яңа теоретик фикерләр, күзәтүләр белән баеталар. Аның кайбер хезмәтләре немец, инглиз, поляк телләренә тәрҗемәләрдә дә басылып чыккан.

Әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеген Р. Бикмөхәммәтов фәнни-оештыру һәм әдәби-иҗтимагый эшләре белән бергә алып бара. Ул Татарстан, Башкортстан республикалары әдәби җәмәгатьчелеге, РСФСР һәм СССР Язучылар союзлары белән даими бәйләнеш тота, төрле әдәби конференцияләр, киңәшмәләр, фикер алышуларны оештыруда катнашып килә. Аның бу эшчәнлеге СССР, РСФСР һәм күп кенә автономияле республикалар язучылары союзлары тарафыннан рәхмәт язулары белән билгеләп үтелгән.

Әдәби тәнкыйтьче, әдәбият галиме, прозаик (ул, йөздән артыграк мәкалә һәм әдәбият белеме буенча җиде монографиясе өстенә, Мәскәүдә проза әсәрләре китабын да дөньяга чыгарды. Кара: «Дорога остается», Мәскәү, 1969 ел) Роберт Гата улы Бикмөхәммәтовка — 50 яшь. Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редколлегиясе аны илле еллык юбилее һәм иҗат эшчәнлегенә утыз ел тулу уңае белән кайнар котлый, әдипкә киләчәктә дә яңадан-яңа иҗат уңышлары тели.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДӘБИЯТ ГАЛИМНӘРЕНЕҢ БӨТЕНСОЮЗ ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

18—20 октябрьда Казан шәһәрендә СССР Фәннәр академиясе А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, СССР һәм Татарстан Язучылар союзы, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты тарафыннан оештырылган һәм совет Көнчыгышы әдәбиятларында социалистик реализм эстетикасы һәм поэтикасы актуаль проблемаларына багышланган бөтенсоюз фәнни конференциясе булып үтте.

Конференция эшендә катнашу өчен республикабыз башкаласына Мәскәүдән һәм Ленинградтан, Әзербайҗан, Казагыстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан союздаш республикаларыннан, Башкортстан, Дагстан, Калмык, Мари, Чуваш, Удмурт һәм башка автономияле республикалардан күренекле әдәбият галимнәре, язучылар килде.

18 октябрьда узган пленар утырышны кереш сүз белән А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтының совет әдәбияты бүлеге мөдире СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Г. И. Ломидзе ачты.

Конференциядә катнашучыларны КПСС-ның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән тәбрикләү сүзе белән Татарстан Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов чыкты.

Пленар утырышта филология фәннәре докторлары А. Н. Иезуитов (Ленинград), З. С. Кедрина (Мәскәү), Казагыстан ССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты З. А. Әхмәтов, филология фәннәре докторлары М. Х. Хәсәнов, И. Г. Нигъмәтуллина совет әдәбияты үсешенең хәзерге этабында социалистик реализм методологиясе һәм теориясе проблемаларын, совет Көнчыгышы әдәбиятларының үсеш тенденцияләрен билгеләүдә социалистик реализмның куәтле тәэсир көчен, тугандаш әдәбиятлар арасындагы аерылгысыз бердәмлек, уртак сыйфатлар тамырлануы мәсьәләләрен үзәккә алып тикшергән доклады белән чыктылар.

Утырышта шулай ук язучылар Юрий Суровцев (Мәскәү) һәм Әбдеҗәмил Нурпеисов (Алма-Ата) чыгыш ясадылар.

Икенче көнне фәнни конференция утырышлары аерым секцияләргә бүленеп дәвам иттерелде. Беренче секция утырышы Үзбәкстан ССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты И. А. Солтанов, филология фәннәре докторлары З. С. Кедрина, М. Ш. Шукуров (Дүшәмбе), филология фәннәре кандидаты А. Г. Әхмәдуллин (Казан) җитәкчелегендә барды. Докладлар «Кеше концепциясе һәм әдәбиятларның идея-художество ягыннан яңарышы» темасы тирәсенә тупланды. Икенче секция утырышына Казагыстан Фәннәр академиясе член-корреспонденты З. А. Әхмәтов, филология фәннәре докторлары М. К. Кошчанов (Ташкент), А. А. Гаджиев (Баку), Н. Г. Юзиев (Казан), филология фәннәре кандидаты А. Г. Яхин (Казан) җитәкчелек итте. Бирелдәге докладларда тугандаш әдәбиятлардагы стиль һәм жанр төрлелеге мәсьәләләре үзәккә куелды. Һәр ике секция утырышында Алма-Ата, Ташкент, Дүшәмбе, Баку, Ашхабад, Уфа, Чабаксар, Махачкала, Улан-Удэ, Ижевск, Казан, Алабуга һәм башка шәһәрләрдән килгән әдәбият галимнәренең утызлап доклады тыңланды.

Кичен Татарстан Язучылар союзында конференция җитәкчеләреннән берсе, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев белән очрашу булды. Ул СССР Язучылар союзының бүгенге эшчәнлеге, илебез халыклары әдәбиятларының үзара тыгыз бәйләнешы һәм үсеш юллары турында сөйләде.

20 октябрьдагы пленар утырышта филология фәннәре докторлары Л. И. Залесская (Мәскәү), А. А. Гаджиев (Баку) һәм Л. П. Каюмов (Ташкент) докладлары тыңланды. Шулай ук язучылардан Антонина Коптяева (Мәскәү), Пиримкул Кадыйров (Ташкент) һәм Гариф Ахунов (Казан) чыгыш ясады.

Соңыннан Казагыстан ССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты З. А. Әхмәтов, филология фәннәре докторлары З. С. Кедрина һәм И. Г. Нигъмәтуллина секция утырышлары нәтиҗәләренә йомгак ясадылар.

Конференция җитәкчеләре СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Г. И. Ломидзе һәм СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев йомгаклау сүзе белән чыктылар. Алар бу конференция эшенә югары бәя бирделәр, аның совет әдәбият белеменә зур фәнни өлеш кертүен әйттеләр.

Конференция эшендә КПСС өлкә комитеты бүлек мөдирләре М. М. Мусин һәм Ә. С. Миндубаев катнашты.

## ПАРТИЯ ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА ОЧРАШУ

19 октябрьда партиябезнең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре иптәш Ф. Ә. Табеев бетенсоюз фәнни конференциясе җитәкчеләрен — СССР Фәннәр академиясе А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтының совет әдәбияты бүлеге мөдире СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Г. И. Ломидзе һәм СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцевны кабул итте.

Әңгәмәдә шулай ук ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов һәм КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

Татарстан Язучылар союзы идарәсе сентябрь аенда «Казан утлары» журналының 1978 елгы 1—6 саннары хакында сөйләшү уздырды. Сөйләшүдә язучылар, китап нәшрияты һәм газета-журнал редакцияләре хезмәткәрләре, әдәбият сөючеләр катнашты. Беренче ярты еллыкта журналда тәкъдим ителгән публицистик әсәрләр һәм очерклар хакында язучы Җәмит Рәхимов, шигъри әсәрләр турында шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов, әдәби тәнкыйть материаллары хакында әдәбият белгече Флера Ганиева докладлары тыңланды. Докладчылар «Казан утлары» битләрендәге күп кенә әдәби, публицистик, шигъри әсәрләр, тәнкыйть мәкаләләре һәм башка материалларның заман таләпләренә җавап бирүен, киң катлау укучылар массасы тарафыннан кызыксынып кабул ителүен билгеләп үттеләр, кайбер әсәрләр һәм әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышланган мәкалә һәм очеркларның аерым кимчелекләрен күрсәттеләр. Фикер алышуда шагыйрә С. Сөләйманова, журналның баш редакторы урынбасары Ә. Баянов, әдәби тәнкыйть бүлеге мөдире Р. Мөхәммәдиев һ. б. катнашы.

Утырышны Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов йомгаклады.

## ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНЫҢ ОТЧЕТ-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЫ

5 октябрьда Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булып узды. КПССның XXV съезды карарларын тормышка ашыруга әдәби иҗат көчләрен туплау эшендә партия оешмасының еллык эшчәнлеге нәтиҗәләре хакында партбюро секретаре Туфан Миңнуллин отчет доклады белән чыкты. Язучылардан Г. Паушкин, И. Юзеев, Г. Минский, республикабыз пионерларының «Ялкын» журналы редакторы Р. Хафизова, тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев, прозаик В. Нуруллин, шагыйрь Р. Миңнуллин һәм башкалар фикер алышуда катнашып, партия оешмасы һәм партбюроның идея-политик һәм оештыру эшендәге уңышларын билгеләп үттеләр, язучыларның җәмәгать эшчәнлегендә активлыгын тагын да ныграк җанландыру мөмкинлекләрен күрсәттеләр. Җыелышта шулай ук иҗат яшьләре белән эшләү, балалар әдәбиятын үстерү мәсьәләләренә дә җитди игътибар бирелде.

Коммунистлар партия бюросының яңа составын сайладылар. Партбюро составына Г. Ахунов, В. Ихсанова, Т. Миңнуллин, З. Нури, М. Скороходов, С. Хәким, И. Юзеев иптәшләр керде. Партбюро утырышында партоешма секретаре итеп Туфан Миңнуллин сайланды.

Партия җыелышында КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Татарстан Язучылар союзы поэзия секциясенең чираттагы утырышы танылган шагыйрь, тәрҗемәче һәм популяр җырлар авторы Нури Арсланов иҗатына багышланып үткәрелде. Шагыйрь утырышка килгән иптәшләренә үзенең иҗаты турында сөйләде, классик поэзия үрнәкләрен тәрҗемә итү тәҗрибәсе белән уртаклашты, бүгенге яшь шагыйрьләр иҗатына тукталды, сорауларга җаваплар бирде.

*
* *

Шушы ук секциянең икенче бер утырышында «Идел» әдәби альманахының соңгы саннарында басылган шигъри әсәрләр тикшерелде. Яшь каләм ияләренең шигъри әсәрләре хакында Ә. Рәшитов доклады тыңланды. Шагыйрьләрдән Ш. Маннур, Ә. Баянов, М. Шабаев, Р. Гатауллин, Р. Миңнуллин, М. Галиев, тәнкыйтьчеләр М. Вәлиев һәм Р. Кукушкин яшьләр альманахында урнаштырылып килгән әсәрләрнең идея-художество эшләнеше ягыннан саннан-санга яхшыра, тема колачының киңәя баруын билгеләделәр, киңәш һәм тәкъдимнәрен әйттеләр.

*
* *

Язучылар союзы балалар әдәбияты секциясенең чираттагы утырышы Шәүкәт Галиевнең балалар өчен язылган шигъри әсәрләрен тикшерүгә багышланды. Бу хакта доклад сөйләгән Р. Кукушкин, фикер алышуда катнашкан И. Юзеев, А. Тимергалин, М. Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, Р. Миңнуллин, Н. Мадьяров, Н. Гайсин һәм башкалар Шәүкәт Галиевнең нәниләр өчен иҗат иткән шигырь циклларын шагыйрьнең балалар әдәбиятын үстерүгә керткән зур өлеше дип бәяләделәр. Бу сөйләшү балалар поэзиясенең бүгенге бурычлары турында күп кенә җитди уртак фикерләргә китерде.

## РЕСПУБЛИКА ИҖАТ ЯШЬЛӘРЕ СЕМИНАРЫ

4 октябрь көнне Казанның Яшьләр үзәгенә республиканың бик күп төбәклә-

реннән килгән биш йөзгә якын яшь каләм ияләре, яшь рәссамнар, артист һәм музыкантлар, кинематографчылар һәм архитекторлар җыелган иде. Өч көн буе бирсдә ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Культура министрлыгы, язучылар, рәссамнарның иҗат союзлары, Бөтенсоюз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге, СССР Архитекторлар союзы Татарстан бүлеге тарафыннан оештырылган иҗат яшьләре республика семинары эшләде. Республикабыз иҗат яшьләренең һәр ел рәттән инде менә алтынчы тапкыр шушы рәвешчә зур мәйдан ясап очрашуы, иҗат мәсьәләләре турында җитди сөйләшүе иде ул.

Семинар иҗат яшьләренең гомуми җыелышы белән башланып китте. Аны ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. Р. Газизуллин ачты. Көн тәртибендә «ВЛКСМның 60 еллыгы һәм ВЛКСМның XVIII съездында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Л. И. Брежнев речь, ВЛКСМның XVIII съезды карарлары яктылыгында Татарстанның әдәби иҗат һәм сәнгать яшьләре бурычлары» каралды. Бу хакта ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Ш. Р. Агеев доклады тыңланды. Аннары иҗат союзлары һәм оешмаларының яшь вәкилләре сүз алды. Яшь тәнкыйтьче Мансур Вәлиев, яшь прозаик Әхәт Гаффаров, музыка белгече Маргарита Фәйзуллаева һ. б. үз яшьтәшләрен бүгенгенең иң актуаль проблемаларын гәүдәләндерү, замандашларыбызның күпкырлы образларын сурәтләүдә иҗади кыюлыкка өндәделәр.

Семинарда Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясенең 1978 елгы лауреатлары игълан ителде. Алар — шагыйрь Фәнис Яруллин, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары Николай Дунаев һәм Равил Шәрәфиев, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе солисты Зиннур Нурмөхәммәтов, В. В. Куйбышев исемендәге Казан химия заводының «Саз» вокаль ансамбле (художество житәкчесе Рифкать Гомәров). Лауреатларга дипломнар һәм значклар тапшырылды.

Семинар эшендә КПСС өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

5 һәм 6 октябрьдә иҗат яшьләре унынчы бишьеллыкта Татарстан экономикасы үсеше, идеологик көрәш һәм культура, халыкара хәл, нәфис иҗатның психологик нигезләре дигән темаларга лекцияләр тыңладылар. Махсус утырышта яшь язучы һәм шагыйрьләр, рәссам һәм композиторлар, кинематографчыларның бишенче республика семинарыннан соң иҗат иткән иң яхшы әсәрләре турында фикер алышу үткәрелде. Аерым секцияләрдә «Татарстанның яшь язучылары әсәрләрендә хезмәт кешесе образы», «Җәмгыять һәм шәхес», «Культура өлкәсендә идея көрәше һәм яшь буын» дигән темаларга дәресләр үтте.

## ЯШЬ РӘССАМНАР КҮРГӘЗМӘСЕ

Иҗат яшьләренең алтынчы республика семинары барган көннәрдә ТАССР сынлы сәнгать музеенда яшь рәссамнарыбыз иҗатына багышланган махсус күргәзмә ачылды. Күргәзмәгә килгән күп санлы тамашачылар яшь рәссамнарның республикабызда барган бөек төзелешләр, хезмәт батырларын, замандашларыбызның күркәм образларын, шәһәр һәм авыл җирләрендә кайнап торган тормыш дәртен сурәтләгән, табигать һәм кеше гармониясен җырлаган дистәләрчә сынлы сәнгать, акварель, графика, скульптура әсәрләрен күздән кичерделәр. Анда бигрәк тә В. Аршинов, Ш. Шәйдуллин Ф. Якупов, Ф. Хәсьянова эшләре бай эчтәлекле тирән образлылык хасиятләре белән игътибарны җәлеп итте. Күргәзмә яшь рәссамнарның сәнгатьле фикерләү ягыннан да, профессиональ осталык ягыннан да шактый зур үсешкә ирешкәнлекләрен раслый.

*
* *

Мәскәүнең «Советская энциклопедия» нәшриятында «Музыкальная энциклопедия» нең IV томы басылып чыкты. Анда Татарстанның халык артисты композитор Салих Сәйдәшев, РСФСР һәм ТАССРның халык артисткасы, җырчы һәм композитор Мәрьям Рахманкулова хакында белешмә бирелгән.

*
* *

Мәскәүнең «Искусство» нәшрияты С. М. Червоннаяның «Живопись автономных республик РСФСР (1917—1977)» дигән китабын дөньяга чыгарды.

Автор Бөек Октябрьдан соңгы алты дистә ел эчендә РСФСР автономияле республикалары сынлы сәнгате ирешкән казанышларны барлый, милли сәнгать мәктәпләренең үзара бәйләнешләрен күздән кичерә. Хезмәттә Татарстан рәсем сәнгатенә зур урын бирелә.

*
* *

Шул ук «Искусство» нәшриятында С. М. Червоннаяның «Искусство Советского Татарстана. Живопись, Скульптура, Графика» дигән китабы басылды.

Китапта художникларыбыз әсәрләреннән иллюстрацияләр, сәнгать тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар хроникасы Татарстанда эшләүче художникларның исемнәр күрсәткече урнаштырылган.

## ӘДИПЛӘР УКУЧЫЛАР АЛДЫНДА

Комсомолның алтмыш еллыгы алдыннан язучы һәм шагыйрьләребезнең беренчә группасы, музыкантлар һәм җырчылар белән берлектә, республика шәһәр һәм авылларында әдәби-музыкаль очрашулар үткәрделәр. Казанның 42 нче номерлы техник училищесында узган шундый очрашуларның берсендә шагыйрь Илдар

Юзеев, прозаиклар Гариф Ахунов' Мөсәгыйть Хәбибуллин, Вакыйф Нуруллин, Михаил Скороходов, драматург Туфан Миңнуллин катнашты. Училище укучыларына алар Татарстанда әдәбият һәм сәнгать тормышы, әдипләребезнең бүгенге яшьләргә багышланган әсәрләре турында сөйләделәр, әдәбият яңалыклары белән таныштырдылар.

## ТАНТАНАЛЫ КИЧӘ

28 сентябрь кичендә А. Алиш исемендәге Казан Пионерлар сараена шәһәребез җәмәгатьчелеге вәкилләре, язучының каләмдәшләре, әдәбият галимнәре, укучы яшьләр һәм пионерлар җыелды. Монда герой-шагыйрь М. Җәлилнең иң якын көрәштәшләреннән берсе, күренекле балалар язучысы Абдулла Алишның тууына 70 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Кичәне Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты. Батыр якташыбызның тормышы, көрәш һәм иҗат юлы хакында язучы Ләбибә Ихсанова доклад сөйләде. Кичәдә җәлилчеләрнең берсе, Үзбәкстанда яшәүче Фәрит Солтанбеков фашизм тоткынлыгында М. Җәлил, А. Алишлар алып барган яшертен көрәш көннәре турында истәлекләре белән уртаклашты.

•

## БӨТЕНСОЮЗ КИТАП КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

Ленин комсомолының 60 еллыгына багышланган «Бөтенсоюз китап күргәзмәсе» октябрь аенда Чаллы шәһәренең «Энергетик» культура сараенда үтте. Анда илебез нәшриятлары бастырып чыгарган политик, фәнни-экономик, матур әдәбият китапларыннан барысы мең алты йөз басма куелган иде Күргәзмә эшендә Мәскәү әдипләре Д. Терещенко, А. Хорт, Н. Путяева, В. Жигарев, Казаннан Г. Паушкин, Н. Беляев, Ә. Рәшитов катнашты. Алар КамАЗда, культура сарайларында, мәктәпләрдә эшчеләр, инженерлар, укучы яшьләр белән очраштылар, илебезнең китап басу эшендәге казанышлары, нәшриятлар эшчәнлеге, әдәбият яңалыклары хакында сөйләделәр.

## ТЕЛЕСПЕКТАКЛЬ —БӨТЕНСОЮЗ ФЕСТИВАЛЕ ЛАУРЕАТЫ

Кемерево шәһәрендә телевизион спектакльләрнең бөтенсоюз фестивале булып үтте. Ул СССР Конституциясенең бер еллыгына багышланган иде. Фестивальгә илебезнең уналты телестудиясе үзләрендә әзерләнгән спектакльләрне алып килде. Казан телевидение студиясе анда Ә. Баяновның «Тау ягы» повесте буенча эшләнгән «Йолдызлар житә һәркемгә» исемле спектакль белән катнашты һәм иң зур бүләкне яулады, казанлыларга махсус диплом бирелде.

Фестивальнең «Иң яхшы режиссерлык эше өчен» дигән призы телеспектакльнең режиссеры Әхтәм Зариповка бирелде. Спектакльдә төп рольне башкаручыларның берсе — Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисткасы Фирдәвес Хәйруллина «Хатын-кызлар ролен иң оста башкаручыга» дигән призга лаек булды.

## ХЕЗМӘТКӘ—ХӨРМӘТ

Совет драматургиясе өлкәсендәге хезмәтләре өчен драматург **Туфан Абдулла улы Миңнуллинга** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1978 ел, 23 октябрь Указы нигезендә, **Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде

*
* *

Республика хезмәт ияләренә культура хезмәте күрсәтүдәге уңышлары өчен Минзәлә дәүләт драма театры коллективы Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының **Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

*
* *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан дәүләт педагогия институтының җыр һәм аны укыту методикасы кафедрасы мөдире **Җәләл Гаяз улы Садриҗиһановка**, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1978 ел, 18 октябрь Указы нигезендә, **РСФСРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.



*Галиәсгар Камал сатирик журнал «Яшен» редакциясендә.*

М. РӘХИМОВ рәсеме.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Менә Сез «Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» журналының Яңа елда чыккан беренче санын алдыгыз.

Журналның икенче санында Сезне ниләр көтә!

Бу сан Әдип Маликовның «Медальләр» дигән шигырьләр циклы белән ачыла. Шигырьләр Совет Армиясе сугышчыларына багышланган. М. Горький премиясе лауреаты Сибгат Хәкимнең «Йөгерә чәчәкләр офыкка» дигән шигырьләр циклы авторның тормыш фәлсәфәсен сөйли.

Икенче санда Әхсән Баяновның «Аязучан болытлы һава» дигән повестен һәм Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» исемле тарихи романын укырсыз. Роман берничә санга бүлеп басылачак.

Самал Шакирның «Утлы еллар әле дә хәтердә» дигән очеркы партиянең Әгерҗе район комитетының беренче секретаре Нургали Сафин эшчәнлеге турында, Кояш Тимбикованың «Казан кызлары» дигән очеркы олимпия чемпионнары — рапирачы кызлар хакында сөйләр.

Сәнгать бүлеге Шамил Монасыйповның «Татар скрипка сәнгате» дигән мәкаләсен тәкъдим итә.

Бу санда «Бүгенге поэзия турында сөйләшү»гә «Шагыйрь — заман баласы» дигән мәкалә белән Саҗидә Сөләйманова һәм «Шагыйрьләргә заман текәлгән» дигән мәкалә белән Рашат Низамиев катнаша.

Әдәби тел мәсьәләләренә карата Г. Кудашев, Л. Яфаров, Ә. Булатов, Й. Гәрәй мәкаләләре басыла. Яңа китапларга рецензияләр, укучылар сүзе, нәниләр өчен шигырьләр һ. б. материаллар белән танышырсыз.

Журнал ахырына әдәбият һәм сәнгать яңалыклары бирелә.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ